ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.2008





*Гаяз Исхакый*
*(1878-1954)*

**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2008*

# 2

**(1024)**

ТМ
татмедиа

*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте химаясендә чыгарыла*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
✆: **Факс**—(843) 541-38-77.
💻: **E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

Бөтендөнья татар конгрессы IV корылтае материаллары. .......... 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Фәнис ЯРУЛЛИН. Төрле еллар—төрле җырлар. *Шигырьләр.* .......... 15
Равил ВӘЛИ. Канатлы татар. *Роман.* .......... 23
Шәүкәт ГАЛИЕВ. Халкым, син моңнан яралган... *Шигырьләр.* .......... 67
Марат КӘБИРОВ. Елмаю. *Хикәя.* .......... 71
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Ил-көн каршында. *Шигырьләр.* .......... 81
Фәнзәлия МӘСНӘВИЕВА. Ачы алма. *Хикәя.* .......... 85

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ШИГЪРИЯТЕННӘН**

Кырымтатар шагыйрьләре шигырьләре. Бәкер ЧАБАН-ЗАДӘ,Чәләби ҖИҺАН, Әмди ГӘРӘЙБӘЙ, Әшраф ШӘМИ-ЗАДӘ, Сәйтүмәр ӘМИН, Шәүкый БИКТҮРӘ, Леман СӨЛӘЙМАН .......... 90

**ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ**

Флүн МУСИН. Милләт сагында. .......... 95

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Локман ЗАКИР. Казан шәһәренең исемен ни өчен үзгәртмәгәннәр? Мәхәббәт, коммунизм һәм тәмәке. .......... 105
Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ. Тормыш мизгелләре. .......... 109
Ф. ЯРУЛЛИН турында замандашлары. .......... 124

**ФАТИХ ХӨСНИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Рифат СВЕРИГИН. Фатих Хөсни феномены. .......... 128

**ГАКЫЙЛЬ СӘГЫЙРОВКА 70 ЯШЬ**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Рух баеклеге. .......... 135

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Илшат ВӘЛИУЛЛА. Илче. .......... 142

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Гомернең бер елы. *Көндәлек сәхифәләреннән.* .......... 147

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .......... 158
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. .......... 171

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Радик ФӘИЗОВ. Забастовка. Юлбашчы башы. Тере... Ленинны күрдек! .......... 163

**ШАҺИНУР МОСТАФИНГА 60 ЯШЬ**

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Күңелендә күпме җылылык бар... .......... 182

«Казан утлары» архивыннан. .......... 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .......... 187

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*


Материалы IV съезда Всемирного конгресса татар.
«Проза и поэзия»: роман Р. ВАЛИ «Крылатый татарин» (начало);
рассказы М. КАБИРОВА «Улыбка», Ф. МАСНАВИЕВОЙ «Кислое яблоко»;
стихи Ф. ЯРУЛЛИНА, Ш. ГАЛИЕВА, И. ГИЛЯЗОВА.
«Поэзия братских народов»: стихи поэтов крымских татар Б. ЧАБАН-ЗАДЫ, Ч. ДЖИГАНА, А. ГАРАЙБАЯ, А. ШАМИ-ЗАДЫ, С. АМИНА, Ш. БИКТУРЫ, Л. СУЛЕЙМАНА.
«К 130-летию Г. Исхаки»: статья Ф. МУСИНА «На благо нации».
«Публицистика»: статья М. АХМЕТЗЯНОВА «Фрагменты жизни»;
статьи Л. ЗАКИРА.
«К 100-летию Ф. Хусни»: статья Р. СВЕРИГИНА «Феномен Фатиха Хусни».
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение); Ф. ГАРИПОВА «История наших деревень» (продолжение).
«Книжное обозрение»: статья И. ВАЛИУЛЛЫ «Странник».
А. ГИЛЯЗОВ. Странички из дневника.
«Рассказы из жизни» Р. ФАИЗОВА.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Белый парус»: Р. ЮСУПОВА. «Приключения Тэтчера» (продолжение).
В номере отмечаются 75-летие Х. Махмутова, 70-летие Г. Сагирова, 60-летие Ш. Мустафина.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Казанская мечеть «Кулшариф»; ученая Ханиса АЛИШИНА.


## IN THIS ISSUE:


IV congress materials of World congress of Tatars.
«Prose and poetry»: novel by R. VALI «Winged Tatar» (beginning);
stories by M. KABIROV «Smile», F. MASNAVIEVA «Sour apple»;
verses by F. YARULLIN, Sh. GALIEV, I. GILYAZOV.
«Poetry of fraternal people»: verses by Crimean Tatars poets B. CHABAN-ZADY, Ch. GIGAN, A. GARAYBAYA, A. SHAMI-ZADY, S. AMIN, Sh. BIKTURA, L. SULEYMAN.
«To 130th anniversary of Iskhaki»: article by F. MUSIN «For nation blessing».
«Publicism»: article by M. Ahmetzyanov «Fragments of life»; articles by L. ZAKIR.
«To 100th anniversary of F. Husni»: article by R. SVERIGIN «Fatih Husni phenomenon».
«Science»: A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation» (continuation);
F.GARIPOVA «History of our villages» (continuation).
«Book review»: article by I. VALIULLA «Wanderer». A. GILYAZOV. Pages from diary.
«Stories from life». R. FAIZOV. Pages from «Tatar encyclopedia».
«White sail»: R. YUSUPOVA. «Thatcher's adventure» (continuation).
In number are celebrated 75th anniversary of H. Mahmutov, 70th anniversary of G. Sagirov, 60th anniversary of S.Mustafin.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life. On our covers: Kazan mosque «Kulsharif»; scientist Hanisa ALISHINA.


*The magazine edits monthly*


*** Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.**
*** Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
*** Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.**



Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.01.2008 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т–59 Тираж 5121.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2008 ел.

# БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ

2007 елның 12-15 декабрендә Казанда Бөтендөнья татар конгрессының IV корылтае булып узды. Аның эшендә катнашкан 765 делегат һәм кунакларның 175е Татарстан шәһәрләре һәм районнарыннан, 414е—РФнең 60 төбәгеннән, 174е 32 чит илдән килгән иде. Корылтай эшендә, беренче тапкыр буларак, Әфганстан, Израиль, Словакия, Көньяк Африка Республикасыннан һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән вәкилләр катнашты.

Олуг кунаклар арасында РФ төбәкләр үсеше министры урынбасары Камил Исхаков, Россиянең Үзбәкстандагы илчесе Фәрит Мөхәммәтшин, Россиянең Кыргызстандагы илчесе Валентин Власов, РФ Тышкы эшләре министрлыгының Милләттәшләр белән эшләү департаменты директоры, чит илләге милләттәшләр белән эшләү буенча хөкүмәт комиссиясенең җаваплы сәркатибе Александр Чепурин, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Владимир Зорин, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе, Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил Гайнетдин, АКШның Висконсин университеты профессоры Юлай Шамил угылы, Мәскәүнең татар милли-мәдәни мохтәрияте рәисе Рәсим Акчурин, Төркиядән профессор Надир Дәүләт, филология фәннәре докторы, Садри Максудиның оныгы Гонул Пултар, Финляндиядән Окан Дахер һ.б. бар иде.

Корылтай үз эшен М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында ачып җибәрде. Пленар утырышны ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин алып барды. Ул форумны ачканда, корылтайның Бөтендөнья татар конгрессы оешуына 15 ел тулу көннәренә туры килүен искәртеп үтте. Шушы вакыт эчендә Бөтендөнья татар конгрессы Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез арасындагы бәйләнешләрне шактый ныгытуга ирешкән, ТРның дәрәҗәсен халыкара аренада күтәрергә ярдәм иткән.

Зал Президент Минтимер Шәймиев чыгышын алкышлар белән каршылады. Илбашы Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының уңышлы эшчәнлек нәтиҗәсендә абруй казануын, сайланган юлның дөрес булуын әйтте.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров үз чыгышында ике корылтай арасындагы иң зур казанышларның берсе итеп татарның яшь, тынгысыз, фидакяр, тырыш яшьләрен бергә туплый алуны күрсәтте.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты каршында махсус комиссияләр булдырылган. Аларның эшенә иҗат һәм фән белән шөгыльләнүче күренекле шәхесләр җәлеп ителгән. Шулай ук башкарма комитет каршында этномониторинг үзәге эшли башлаган.

Хисап докладында Р.Закиров татар телен үстерү, милли мәгариф

мәсьәләләренә дә кин тукталды. Ул Самара, Мәскәү, Ульяновскида милли мәгариф өлкәсендә уңышлы эшләүләрен билгеләп үтеп, мәгарифтә хәл ителәсе мәсьәләләрнең гаять күп булуын әйтте. Чиләбе, Оренбург, Екатеринбург, Төмән, Пенза кебек татарлар күпләп яши торган шәһәрләрдә ана телебездә укыту мәсьәләсе әлегә кадәр хәл ителмәгән. Чыгышта күтәрелгән мөһим мәсьәләләрнең тагын берсе—Россия төбәкләрендәге татар авылларының хәле. Бу эштә әле генә гамәлгә куелган Бөтенроссия зур татар авыллары ассоциациясенә өмет баглана.

Россия Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары В.Зорин Татарстанда ирешелгән уңышларының төрле халыкларның үзара аңлашып һәм бер-берсен хөрмәт итеп яшәүләренә дә бәйле булуын искәртеп үтте. «Халыклар кулга-кул тотышып, үзара ихтирам белән яшәгән Татарстанның тәҗрибәсе бик әһәмиятле»,—диде ул.

Доклад буенча фикер алышуларда катнашкан милләттәшләребез, аерым алганда, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Р.Гайнетдин, язучы Ф.Бәйрәмова, ТР Дәүләт Советы депутаты, драматург Т.Миннуллин, Мәскәүдән Р.Акчурин, Дәүләт Думасы депутаты, федераль милли-мәдәни Советы рәисе И.Гыйльметдинов һ.б. бердәм булырга, киңәшеп эш итәргә кирәклеген әйтте.

Президент М.Шәймиев пленар утырыш ахырында кайбер татар җәмгыятьләре активистларына «Фидакарь хезмәт өчен» медале, Рәхмәт хатлары һ.б. бүләкләр тапшырды.

Аннары корылтай үз эшен «Татар халкының рухи байлыгын саклауда фән, мәгариф һәм мәдәниятнең роле», «Милли яңарышта хәзерге эшмәкәрләрнең роле һәм татар химаячелеге традицияләре», «Заманча дөньяда татар яшьләре» дигән секцияләрдә дәвам итте. Аларда Татарстанның РФ төбәкләре белән сәүдә-икътисади хезмәттәшлеген үстерүгә, мәдәният, мәгарифкә кагылышлы мәсьәләләр тикшерелде.

Фән, мәгариф һәм мәдәният секциясендә корылтай делегатлары аеруча күп иде. Ул утырыш Татарстан Фәннәр академиясенең зур залында узды. Анда Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З.Вәлиева, Татарстан ФА президенты Ә.Мәзһәров, мәгариф һәм фән министры Н.Вәлиев, Литвадан килгән вәкил—З.Кәримова, Германиядән—В.Вәгыйзова һ.б. чыгыш ясады.

Пленар утырышның «Корстон»да узган йомгаклау өлешен Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин корылтай адресына юлланган телеграммаларны укудан башлап җибәрде. Форум делегатларына һәм кунакларга РФ Президенты В.Путин котлавы җиткерелде. Ульяновск өлкәсе губернаторы С.Морозов Ульяновск шәһәрендә Кол Галигә һәйкәл куелачагын хәбәр иткән иде. Ватандашларның халыкара берлегеннән, Россия әрмәннәр берлеге һәм Халыкара әрмән конгрессыннан телеграммалар килде. Сәламләү телеграммалары РФ тышкы эшләр министры С.Лавров, Мәскәү шәһәре мэры Ю.Лужков һ.б.дан алынды.

Бөтендөнья татар конгрессының IV корылтае делегатлары хәл ителәсе милли мәсьәләләр турында РФ Президенты В.Путинга мөрәҗәгать, башкорт халкына мөрәҗәгать һәм корылтайның резолюциясен кабул итте. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе итеп кабат Р.Закиров сайланды. Пленар утырыш бер төркем делегатларга Татарстан дәүләт бүләкләрен тапшыру белән тәмамланды.

Соңыннан «Корстон» комплексында Президент М.Шәймиевнең корылтай делегатларын һәм кунакларны кабул итү мәҗлесе оештырылды. Аннары соңгы ике көндә делегатлар һәм кунаклар Казанның истәлекле урыннарын карады, Г.Камал театрында «Телсез күке» спектаклен тамаша кылдылар, республика районнарына сәяхәт иттеләр.

Минтимер
Шәймиев,
*Татарстан Президенты*

# БЕЗ—КҮП, БЕЗ—БЕРДӘМ!

(БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ
IV КОРЫЛТАЕНДА ЯСАЛГАН ЧЫГЫШЫ)

Хөрмәтле делегатлар! Газиз милләттәшләр!

15 ел элек дөнья татарларының I съездын уздыру турында Указга кул куйганда, дөресен әйтим, милләтебезнең хәрәкәте шундый зур колач алса иде, дип чын күңелемнән теләгән идем. Чираттагы съездга дөньяга сибелгән татарның меңнән артык вәкиле җыелган икән, димәк, беренче адымнардан ук юлыбыз дөрес сайланган. Хәзер инде Бөтендөнья татар конгрессын халкыбыз тарихында иң уңышлы проектларның берсе дип бәяләргә мөмкин. Бу чынбарлыкта шулай. Иң куанычлысы—без бүген бер гаилә кебек: кая карама—таныш йөзләр күрәсең. Безнең барыбызны да тарихи Ватаныбыз Татарстанда, аның мәркәзе—меңьеллык Казанда җыелуыбыз белән чын күңелдән котлыйм.

Әгәр дә без элеккеге елларда, нигездә, татар телен һәм мәдәниятен саклау турында сүз алып барсак, бүген инде XXI гасыр шартларында халкыбызның үзаңы үсү таләпләренә җавап бирерлек сәясәт алып бару турында планнар корабыз.

Бөтендөнья татар конгрессы, аның башкарма комитеты үзләренең уңышлы эшчәнлеге нәтиҗәсендә тиешле абруй казанды. Бүген алар белән Россия Федерациясе субъектлары да, чит илләр дә санлашырга мәҗбүр. Әлбәттә, моңа Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсешендәге күтәрелеш тә, дөньяның төрле почмакларында татарларның мәдәни үзәкләрен торгызу да зур йогынты ясады. Татарстан татар халкына таянган шикелле, милләтебез дә республикабызга өмет баглый. Асылда, бу безнең ныклы һәм иң ышанычлы нигез ташыбыз.

Безнең тарихыбыз искиткеч бай, мондый тарих белән теләсә нинди милләт горурланыр иде. Һәм без горурланабыз да. Бу галәмдә татарлар һәрвакыт иҗтиһат итү вазыйфасын үтәп килгән. Үзегез беләсез, заманында күп кенә китапларда һәм хәтта кайбер дәреслекләрдә дә татарларны, татар-монголларны җимерүчеләр дип яздылар. Соңгы елларда еш кына бу мәсьәләгә кагылышлы фәнни хезмәтләр, яна карашлар барлыкка килә. Алар арасында Лев Гумилев дәвамчылары булган урыс галимнәренең хезмәтләре игътибарга лаек. Вакытлар узу белән карашлар үзгәрә. Россия дәреслекләре дә әкренләп яңадан языла. Без бу юнәлештәге эшебезне алга таба да дәвам итәргә тиешбез. Тарихның бәхәссез дәлилләре безнең якта. Иртәме-соңмы, татарлар турында тарихи дөреслек җиңеп чыгачак. Моңа бернинди шигебез юк.

Әйтик, Чыңгызхан да, Батый хан да, беренче чиратта, дәүләтчелекне үзгәртеп коручылар булган. Әлбәттә, урта гасырларда һәрвакыт һәм һәркайда сугыш барган, әмма безнең ата-бабаларыбыз бер халыкны да туган теленнән, мәдәниятеннән, диненнән мәхрүм итмәгән, алар һәрбер халыкка үз икътисадларын үстерергә тулы мөмкинлек биргән. Алтын Урда булмаса, Россия дәүләтчелеге дә, бәлкем, алай тиз барлыкка килмәс иде, Евразия дә бөтенләй башкача оешыр иде. Көнбатышны Көнчыгыш белән бәйләү татарларның тарихи миссиясенә әйләнгән. Бу вазыйфа бүгенгәчә актуаль булып кала. Алтын Урда төрле халыклар тормышына бөтен Европа һәм Азия үзләштергән хәрби сәнгатьне генә түгел, финанс, салым системаларын, элемтә ысулларын да керткән.

Совет заманында кайбер татарлар урыс, үзбәк, казакъ булып язылды. Мин моны гаепләү күзлегеннән әйтмим. Киресенчә, без, бернигә карамастан, һәрвакыт җаныбыз, тәнебез белән татар булдык һәм татар булып калачакбыз. Язмышларыбыз төрле-төрле безнең. Шул сәбәпле кемдер татарча сөйләшә белми, кемдер керәшен, кемдер мөселман... Беләсез, Польша-Литва татарлары да бар, алар да бик үзенчәлекле. Әмма без—бердәм халык, чөнки без милли рухыбызны саклап калдык. Иң мөһиме шул. Бу—безнең рухи байлыгыбыз.

Безгә, болгарлар яки татарлар, мөселманнар яки тәңречеләр дигән шикле сүз куертуларны туктатырга вакыт. Болгарлар һәм татарлар XIII гасырда сугышкан, әмма аларның тамырлары уртак булган. Болгарлар—көнбатыш һуннар, ә татарлар—көнчыгыш һуннар. Асылда, алар бер культура кешеләре һәм уртак телдә сөйләшкән.

Россия Федерациясендә халык исәбен алу вакытында татарларны бүлгәләргә теләүчеләр дә аз булмады. Әмма барып чыкмады. Без моңа юл куймадык. Бу алга таба да Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенең мөһим юнәлеше булып калырга тиеш.

Туганнар! Кем кайда гына яшәмәсен, бу мәсьәләнең уңай чишелеше турыдан-туры безнең һәрберебезнең үз милләтен яратуыннан гына тора. Тиздән, киләсе елларның берсендә халык исәбен алуның чираттагысы уздырылачак. Шуңа күрә бу фикерне ассызыклап әйтүне мөһим дип саныйм.

Безнең халык төрле илләрдә яши һәм бар җирдә дә тотрыклылыкка омтыла, дустанә мөнәсәбәтләр кора белә. Кайбер татарлар Польша-Литва чикләрен саклаган, кайберәүләр Россиядә генә түгел, Төркиядә һәм башка чит илләрдә сәясәтне, тел үсешен, икътисадны үзгәртеп корган.

Безнең ата-бабаларыбызның тормышы җиңел булмаган, әмма алар лаеклы яшәгән. Бүген исә тормышыбызны югарырак дәрәҗәгә күтәрү һичшиксез зарур, тарихны истән чыгармаска кирәк, аннан башка киләчәк була алмый. Татарстан Фәннәр академиясе бу юнәлештә эшләп килә. Шул ук вакытта республикадан читтә яшәгән татарлар турында күбрәк язарга кирәк, дип уйлыйм. Себер, Польша татарлары яки Кытайда яшәүче татарлар турында китаплар бар. Әмма татарлар күп җирләрдә һәм еш кына таралып яшиләр. Сан ягыннан күпме булуларына карамастан, алар барысы да безгә кадерле. Барысы турында да язарга кирәк, мөмкинлекләр дә, авторлар да табарга кирәк. Бу эшкә эшкуарлар да үз өлешләрен кертергә тиеш, дип саныйм, чөнки бу безнең уртак бурычыбыз.

2007 елда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары арасында вәкаләтләр бүлешү турында яңа Шартнамә гамәлгә керде. Бу уңайдан республиканың сәяси тормышында яңа чор башланды. 1994 елның 15 февралендә кабул ителгән Шартнамә үзенең тарихи ролен үтәде. Ул республикадагы икътисади реформаларга, милекнең, эчке сәясәтнең һәм тышкы элемтәләрнең мөстәкыйльлегенә нигез салды. Аның күп кенә кагыйдәләре Татарстанның закон актларына әйләнде һәм илдә федератив мөнәсәбәтләрне үстерүгә аерым өлеш кертте. Нәтиҗәдә, халкыбызның, республиканың дәрәҗәсе тагын да күтәрелде.

Быел федераль закон көченә кергән Шартнамә яңа мөмкинлекләр ача. Ул Татарстан Конституциясен дәүләтчелегебез нигезләренең берсе итеп танып, республиканың гамәлдәге статусын беркетеп куйды. Бу исә республиканың статусы, Татарстанның Төп Законының 1 нче маддәсе буенча, референдум үткәрү нәтиҗәсендә генә үзгәртелә ала, дигән сүз. Шартнамәнең мөһим пунктларыннан берсе—тел мәсьәләләрен җайга салу, атап әйткәндә, ул Татарстан Президенты вазыйфасына дәгъва итүче кандидат республикадагы ике дәүләт телен дә белергә тиеш дигән таләпне раслады. Шартнамәдә республиканың халыкара элемтәләре дәрәҗәсе, милләттәшләр белән эшләү зарурлыгы, Татарстан паспортының үзенчәлекләре беркетелгән, икътисад, мәдәният һәм башка өлкәләрдә төп юнәлешләр билгеләнгән. Әйткәнемчә, бу Шартнамә федераль закон белән расланды, шуңа күрә Россиядә, республикада бөтен дәүләт органнары, шул исәптән суд органнары да аның белән исәпләшергә бурычлы.

Пользуясь случаем, хотел бы особо отметить и поблагодарить Президента Российской Федерации Владимира Владимировича Путина за понимание и

поддержку в принятии федеральной Программы социально-экономического развития Республики Татарстан на 2001—2006 годы, которая стала основой нынешнего успешного развития республики, за личное руководство государственной комиссией по подготовке и проведению юбилейных торжеств 1000-летия города Казани, а также за политическую волю в утверждении Федеральным Собранием нового Договора о разграничении полномочий между органами государственной власти Республики Татарстан и Российской Федерации.

Важным событием текущего года стало проведение съезда народов Татарстана, который принял решение о создании Ассамблеи народов республики. Думаю, что исполком конгресса татар будет тесно сотрудничать с этой важной структурой.

В последние годы наблюдается ощутимый рост самосознания русского и других народов страны. Этот сложный процесс часто проходит болезненно, вызывая иногда и открытые националистические стычки. Наша с вами задача—сделать всё возможное, чтобы даже самые сложные противоречия разрешались мирным путем.

Национальное образование у татар имеет глубокие традиции и играет важную роль в формировании их национальной идентичности. Поэтому с тревогой было встречено татарской общественностью и органами государственной власти ряда субъектов решение федеральных парламентариев об изъятии национально-регионального компонента из системы образовательных стандартов. Государственным Советом Республики Татарстан и мною направлено обращение Президенту страны о недопустимости такого подхода. Надеюсь, что новый состав Госдумы вернется к рассмотрению данного закона. Надо четко представлять себе, что народы Российской Федерации рассматривают наличие национального образования как важное завоевание демократии, от чего они просто так не откажутся.

Безнең Конституциядә, яна Шартнамәдәге кебек үк, милләттәшләргә ярдәм итәргә мөмкинлек бирүче маддә бар. Республика органнары һәм Татарстанның җәмәгать оешмалары бу юнәлештә Россия Федерациясенең Тышкы эшләр министрлыгы белән бергә эш итә һәм һәрвакыт уртак тел таба.

Татарларның дөнья буйлап бик күп мәдәни үзәкләре барлыкка килде. Әмма Казан шәһәре барыбер милләтебез символы гына түгел, бөтен татарның башкаласы булып кала. Бөек Тукай язганча:

*Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;*
*И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!*
*Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;*
*Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.*

Башкалабыз Казанның Россиядә күренекле шәһәрләрнең берсенә әверелүе очраклы хәл түгел. Ә кайбер газеталар аны хәтта Көнчыгыш башкала дип тә атый. Казаннан рәсми делегацияләр һәм туристлар өзелми. Казан Кремле, инде белгәнегезчә, ЮНЕСКОның тарихи мирас исемлегенә кертелде.

Гомумән, Татарстан тормышында—икътисадта да, сәясәттә дә, авыл хуҗалыгында да, мәдәнияттә дә житди уңай үзгәрешләр күзгә ташлана. Республиканың ил төбәкләре арасында абруе тагын да күтәрелде, халыкара элемтәләребез ныгый. Бүген Татарстан зур төзелеш мәйданын хәтерләтә. Хәер, республиканы торак төзелеше генә түгел, нефть химиясе, химия, машина төзелеше кебек тармаклар үсеше дә нык үзгәртә. Табигый ки, нефть чыгару мөһим тармак булып кала бирә, ләкин республиканың киләчәге югары технологияләргә, фәнгә һәм мәгарифкә бәйле. «Беләге юан берне егар, белеме булган меңне егар», ди безнең халык мәкале. Бирелә дә халык акылына таянырга кирәк. Күптән түгел Казанда татар галимнәренең I халыкара форумы узды. Бөтен дөньядан җыелган татар галимнәре үзара фикер алышты, тәҗрибә уртаклашты. Форсаттан файдаланып, Төркия белән бергәләп Анталиядә телескоп куйган һәм яңа галактика ачкан галимнәргә, аеруча Казан дәүләт университеты галимнәренә рәхмәт әйтәсем килә. Мондый казанышлары булган илләр бик күп түгел.

Бөтендөнья татар конгрессының Татар авыллары ассоциациясе оештыру башлангычын да хупларга кирәк, дип саныйм. Мәдәниятебез гасырлар буе авылда үскән һәм авылда сакланган. Авыл—ул икмәк үстерә торган туфрак кына түгел. Әхлагыбыз, туган телебез авыл жирендә шытып чыккан. Милләтнең тамырлары—авылда. Күренекле татар сәясәтчеләре, эшкуарлары, мәдәният эшлеклеләре дә күбесенчә авылдан чыккан шәхесләр. Авылның кадерен белергә кирәк. Туган авыл, туган туфрак—татарда үзе бер тирән фәлсәфә.

Татарстан Республикасы халыкара мөнәсәбәтләрен ныгытып килә. Бу—милләтебезне дөньяга танытуның бик отышлы юлы, дип исәплим. Безгә күп кенә чит дәүләтләрнең башлыклары килә башлады. Быел рәсми визит белән Кытай Халык Республикасы Рәисе Ху Цзиньтао килеп китте. Республикада Кытай ижат коллективларының чыгышлары узды, Конфуций үзәге ачылды, һәм күп кенә килешүләргә кул куелды. Чехия Республикасы Президенты Вацлав Клаус та Казанга сәяхәтеннән канәгать калды.

Ислам Конференциясе Оешмасының форумы белән бәйләнешләр ныгыды. Россия Федерациясенең Тышкы эшләр министрлыгы каршында оештырылган «Россия—Ислам дөньясы» төркеме белән хезмәттәшлек тә яңа баскычка күтәрелде. Менә Татарстан делегациясенең Төркия, Согыд Гарәбстаны, Катар, Иордания кебек илләргә баруы да йогынты ясады. Сөйләшкән-килешкән эшләрне гамәлгә ашыру өчен Ислам Конференциясе Оешмасының Яшьләр форумын, Ислам Фәннәр академиясенең утырышын Казанда уздырдык. Ислам банкы белән хезмәттәшлеккә нигез салынды. Тиздән Россия-Гарәп эшлекле советы һәм Ислам Конференциясе Оешмасы, Ислам банкы, Россия Тышкы эшләр министрлыгы ярдәмендә Халыкара инвестиция конференциясе дә Казанда үткәреләчәк. Башкалабызда шушы көннәрдә Иранның генераль консуллыгы ачылу да Татарстан һәм Иран эшкуарлары арасында элемтәләрне ныгытачак.

Татарларның Ислам диненә бәйле традицияләре белән кызыксыну көчәя. Бу рухи мирас безнеке генә түгел, ул дөньякүләм мирас та булып санала. Россия Хөкүмәте житәкчеләре уңай бәя биргән Россия Ислам университеты, илдәге һәм чит илләрдәге күпсанлы мәдрәсәләр бу традицияләрне дәвам итәр, дип ышанам.

Татарстан һәм Европа илләре арасындагы элемтәләрнең ныгуы да куанычлы хәл. Мәсәлән, Европаның реконструкция һәм үсеш банкы үзенең еллык жыелышын зурлап Казанда үткәрде.

Без Европа Советында Жирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессында уңышлы катнашып киләбез. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин 2000 елдан башлап Төбәкләр Палатасының Мәдәният һәм мәгариф комитетын житәкли. Бу—республиканың һәм халкыбызның абруе үскәнен дәлилләүче тагын бер мисал.

Соңгы елларда бөтен дөнья буйлап Сабан туйлары үткәрү матур гадәткә әйләнде. Бу татарлар өчен генә түгел, башка күп халыклар өчен уртак бәйрәмгә әверелде. Әмма матур гадәтләр белән беррәттән, яңа башлангычлар да кирәк безгә. Мәсәлән, заманча оештырылган милли үзәкләр, интернет технологияләр, китапханә, медиаханәләр, «Татарстан-Яңа Гасыр» телекомпаниясенең корпунктлары, эшлеклезыялы татар клублары булдыру—болар барысы да милли мәнфәгатьләр өчен хезмәт итәргә тиеш. Әлеге үзәкләр каршында татар мәдәниятенә ярдәм итү фондлары оештыру да яхшы булыр иде.

Казандагы югары уку йортларында читтә яшәүче милләттәшләребезнең балаларын укытуга мөмкинлекләр ачылу мисалында бер фикер әйтәсем килә. Хәзерге вакытта Татарстанда, Алабуга шәһәрендә ирекле икътисади зона эшли башлады, Түбән Кама шәһәрендә бик зур нефтехимия комплексын төзергә керештек. Бу комплексларны төзү һәм анда эшләү өчен безгә бик күп яшь белгечләр, яшь хезмәткәрләр кирәк. Республикада яшьләр өчен махсус торак ипотека системасы булдырылды. Ул хәзергә Россиядә бердәнбер һәм түбәндәгедән гыйбарәт: иң күбе 3 ел эчендә яшьләргә, 27 ел дәвамында түләү шарты белән, елына 7 процентлы кредит нигезендә фатир сатып алу мөмкинлеге бирелә. Шушы 2007 елда гына, әлеге ипотека буенча 10 мең фатир төзелеп, яшьләргә биреләчәк.

Минем уйлавымча, без мондый шартларны читтә яшәүче милләттәшләребезгә дә тәкъдим итә алабыз. Мондый гамәл сезнен күнелләргә хуш килер, дип уйлыйм. Тотыныйк әле без бу эшкә! Яшь белгечләр булып үзебезнен балаларыбыз, балаларнын балалары килеп эшләсә, монда урнашып, ныклап тамыр җәя алырлар иде.

Тагын бер мәсьәлә. Сез беләсез, «Майкрософт» фирмасы татар шрифтларын үз системасына кертте. Хәзер татарлар Интернет аша иркенләп аралаша ала. Татарнын таралып яшәвен исәпкә алсак, бу безнен өчен бик мөһим, житди адым. Хәзер безгә татарлар өчен уртак мәгълүмат кыры булдыру кулкә җинеләйле.

Республикабыз өчен өстенлекле бурыч—«Татарстан—Яна Гасыр» спутник телевидениесен үстерү. Бирелә без хәл итәсе финанс мәсьәләләре дә бар. Бу телеканал гомумтатар каналы, бәлки, аннан да колачлырак канал булсын өчен, яхшыдан-яхшы кадрлар, Россиядә һәм башка илләрдә яна корпунктлар ачу зарур. Аны урыслар да, казакълар да, башка милләт, башка ил кешеләре дә карый бит. Дөрес, бу мәсьәләләрнен барысын да бер көндә хәл итү мөмкин түгел, әмма шуны онытмаска кирәк: бу—безнен милләт алдындагы изге бурычыбыз. Берничә ел элек мондый телеканал тормышка ашмас хыял кебек иде, ә бүгенге көндә ул инде эшләп килә, анын эшчәнлеген кинәйтергә кирәк.

Туган телне саклап калу мәсьәләсе дә элеккечә көн үзәгендә. Без Тукайнын «Туган тел» шигырен яхшы беләбез. Ул хәзер татарнын гимны булып санала. Татар телен саклап калуда республиканын, мәктәпләрнен, галимнәрнен роле зур, әлбәттә. Әмма минем ассызыклап әйтәсем килә—ана телен өйрәтү ин элек гаиләдә башланырга тиеш, дип саныйм. Бөтен проблемаларны дәүләт җилкәсенә күчереп калдыру дөрес булмас иде. Әйтик, «Туган тел»не бишектә үк ишеткән баланын татар булып үсүенә ышаныч зуррак. Татарстанда без болай карар иттек: балалар ким дигәндә өч тел—татарча, урысча, инглизчә белергә тиеш. Бу безнен яшьләргә хәзерге заман шартларында зур мөмкинлекләр ача.

Хөрмәтле делегатлар! Мөхтәрәм кунаклар!

Биш елга бер шушылай зур җыен җыеп, бер фикердә булып, милләтебез алдындагы бурычларны билгеләп барлау, хәл итү әмәлләрен эзләү киләчәгебезгә ышанычны арттыра. Иншалла, эшебезнен күркәм нәтиҗәләрен дә күрәбез. Алга таба да милләт абруен саклап, башка халыкларга үрнәк булып яшәргә кирәк безгә. Тормыш ваклыкларыннан өстен булыйк, бер-беребездән гаеп эзләмик. Замана бездән бердәмлек таләп итә. Бердәм булганда, без булдырабыз. Күптән түгел узган Дәүләт Думасына сайлаулар да моны ачык күрсәтте. Март аенда буласы Россия Президентын сайлау да һичшиксез оешкан төстә узачак.

Кадерле милләттәшләр!

Тиздән Корбан гаетен бәйрәм итәрбез. Яна ел да якынлашып килә. Барыгызны да шушы бәйрәмнәр белән чын күнелдән котлыйм, һәммәгезгә исәнлек-саулык, иминлек, муллык, бәхет теләп калам. Уйларыбыз изге, гамәлләребез игелекле булсын.

## *Очрашу мизгелләре*












## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ IV КОРЫЛТАЕНЫҢ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ПРЕЗИДЕНТЫ В.В.ПУТИНГА МӨРӘҖӘГАТЕ

Без, Бөтендөнья татар конгрессының IV съездында катнашучылар, Сезгә күпмилләтле дәүләтнең башлыгы һәм Россия Федерациясе Конституциясенең гаранты булуыгызны истә тотып, милли мөнәсәбәтләргә кагылган җитди мәсьәләләргә игътибар итүегезне сорап мөрәҗәгать итәбез. Безне Россия Федерациясенең эчке сәясәтендә төрле милли төркемнәрнең мәнфәгатьләрен игътибарсыз калдыру тенденциясе нык борчый. Сезнең «Культура» («Мәдәният») дәүләт каналында Россия халыклары тормышын яктырткан даими мәдәни тапшырулар булдыру хакындагы Бөтендөнья татар конгрессының III корылтаеннан соң бирелгән фәрманыгыз бүгенге көнгә кадәр үтәлмәде.

Татар халкының милли мәгариф системасын җимерүгә юнәлдерелгән гамәлләр дә бездә зур борчу тудыра. Тарихтан күренгәнчә, төрле чорларда милли мәнфәгатьләргә игътибар итмәү сәясәте халыклар арасында бары читләшүгә һәм шикләнүләргә китерә, җәмгыятьтә киеренкелекне арттыра, һәм бу беркайчан да Россия дәүләтчелеген ныгытуга хезмәт итмәде.

Өстәвенә, Россия Федерациясе Дәүләт Думасы тарафыннан «Мәгариф турындагы» Федераль кануннан мәктәпләрдә туган телне һәм Россия халыкларының тарихын өйрәнергә мөмкинлек биргән региональ компонент та төшереп калдырылды. Мәгариф өлкәсендә барган «оптимизация»ләү һәм аларны норматив финанслау программалары да борчылырга мәҗбүр итә, чөнки болар Россия Федерациясендәге милли мәктәпнең нигезләрен какшата. Бүген күп кенә төбәкләрдә милли мәктәпләргә мәгариф структуралары тарафыннан үги балага күрсәтелгән мөнәсәбәт яшәп килә. Ә бит халыклар арасындагы үзара татулыкны саклап калу, ныгыту өчен Россия этносларын, аларның телен һәм мәдәниятен үстерергә, туган телдә белем бирүче милли мәктәпләргә уңай шартлар тудырырга кирәк.

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ IV КОРЫЛТАЕНЫҢ ТАТАР ХАЛКЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле милләттәшләр!

2007 елның 12-15 декабрендә Казанда Бөтендөнья татар конгрессының чираттагы IV съезды узды.

Мәгълүм ки, татар халкы, зур тарихи үсеш юлы үтеп, киләчәккә олы өметләр баглап, XXI гасырга аяк басты. Безнең ата-бабаларыбыз үз телләрен, милли мәктәпне, халыкның мәдәниятен, динен саклап кала алганнар. Алар безгә, дәвамчыларына, татар халкының милли мәдәниятен үстерергә һәм күп гасырлар элек нигез салынган дәүләтчелек традицияләребезне саклауны васыять итеп калдырганнар. Бүген дә безнең халкыбыз Россия Федерациясенең демократик институтларын, чын федератив мөнәсәбәтләрен саклау һәм үстерү, гражданлык җәмгыяте институтын булдыруны яклап чыга.

Бөтендөнья татарларының Татарстанны үзләренең тарихи ватаннары, рухи һәм мәдәни мәркәзе буларак кабул итүе табигый күренеш. Без аның уңышларына сөенәбез, омтылышлары белән яшибез. Татар дөньясын һәм Татарстанны бүген берберсеннән аерым күз алдына да китереп булмый. Без Татарстанның казанышлары белән дә, татар милләтенең даның дөньяга тараткан мәшһүр ватандашларыбыз уңышлары белән дә горурланабыз. Унбиш ел элек төзелгән Бөтендөнья татар конгрессы алеге алгарышта әһәмиятле роль уйный, халкыбызны берләштерү эшенә зур өлеш кертә. Дөнья татарлары өчен Конгресс оештыручы, берләштерүче үзәк булуын һәм үзенең кирәклеген раслый алды.

Бөтендөнья татар конгрессының IV съезды иң җитди мәсьәләләрне билгеләде,

бигрәк тә милли мәгарифкә һәм яшьләрне рухи-әхлакый тәрбияләүгә игътибарны юнәлтте. Әлеге мәсьәләләрнең бөтен тирәнлеген аңламый торып, аларны чишү мөмкин түгел. Бу безнең уртак эшебез. Милли яңарыш бездән җаваплылык, ныклык, үҗәтлек һәм бердәмлек сорый торган бөек эш. Бары тик шулай булганда гына без милли мәдәниятләрне юкка чыгаручы глобальләшү шаукымнарына каршы тора алачакбыз. Безнең туган телебез, тарихи хәтеребез, татар халкының мәдәни мирасы кешелек дөньясының күп гасырлар дәвамында тупланган рухи байлыгының аерылгысыз өлеше булып тора. Бу безгә тарихи тәрәккыят юлында ныклы адымнар белән алга барырга көч бирә. Бергә һәм бердәм булганда, без максатларыбызга, һичшиксез, ирешербез!

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ IV КОРЫЛТАЕНЫҢ ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ХАЛКЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ

Газиз туганнар!

Дөньяда башкорт белән татардан да якынрак халык юк. Безне охшаш телләр, уртак мәдәни һәм рухи кыйммәтләр, ислам дине, борынгы бабаларыбызның йолалары, гореф-гадәтләре берләштерә. Күп гасырлар дәвамында без шатлыкларны да, кайгыларны да бүлештек, ярдәмләшеп, ут күршеләр булып яшәдек. «Башкортлар һәм татарлар—Идел һәм Урал кинлекләрен иңләп очкан көчле һәм горур бер кошның ике канаты»,—дип юкка гына әйтмиләр. Милләтләребезнең бөек вәкилләре—Салават Юлаев, Габдулла Тукай, Мифтахетдин Акмулла, Мәҗит Гафури, Ризаэтдин Фәхретдин—безгә туганлык һәм дуслыкны васыять итеп калдырганнар.

Ләкин соңгы 10-15 елда, кайбер кешеләр тырышлыгы белән, халыкларыбыз арасындагы җылы мөнәсәбәтләргә бер-беренә ышанмау һәм читләшү кебек ямьсез күренешләр үтеп керде. Нәтиҗәдә, Башкортстан һәм Татарстан бәйләнышлары, сәнгатькарләр, галимнәр, язучылар, артистлар, иҗтимагый оешмаларыбызның аралары суына башлады. Шул ук вакытта, башкорт һәм татар милләтеннән булган гади кешеләрнең үзара дустанә мөнәсәбәтләре сакланып килә, туйлар гөрли, гаиләләр төзелә, балалар үсә, мондый гаилә корулар хәтта катнаш никахлар дип тә саналмый.

Татар-башкорт мөнәсәбәтләренең бүгенге халәте Бөтендөнья татар конгрессының IV корылтае делегатларында зур борчылу тудыра. Аерым шәхесләрнең, үз халкының мәнфәгатьләрен яклаучы булып кыланган төркемнәрнең амбицияләре безнең халыкларыбызга зыян сала. Моны аңлап, без, кирәкмәгән үпкәләүләрне онытып, бер-беребезгә гаеп ташлауларны туктатырга чакырабыз. Әйдәгез, киләчәгебез һәм туганлык хакына, халыкларыбыз тарихындагы бу тапланган битне ябып, яңасын ачыйк.

Без, беренче чиратта, башкорт һәм татар халыкларының зыялыларына, сәясәтчеләренә мөрәҗәгать итәбез. Чөнки ике тугандаш халыкның, республикаларыбызның язмышы шуларның акыллы, киләчәкне уйлап кылган гамәлләренә бәйле. Бүген, мәдәниятләрнең үзенчәлекләрен юкка чыгару, глобальләшү шартларында, башкортларга да, татарларга да ассимиляция куркынычы янаган чорда, дөньяда яшәп калуыбыз шик астында булганда, үзара мөнәсәбәтләр ачыклау белән шөгыльләнер чак түгел. Әйдәгез, демократия, федерализм, гражданлык җәмгыятен, халыклар ирекен кулга-кул тотынып бергә яклыйк, безгә янаган афәтләргә бердәм каршы торыйк! Бер-беребезгә таянып кына без милли яңарыш мәсьәләләрен хәл итә алабыз!

Яшәсен башкорт һәм татар халыклары дуслыгы!



## Фәнис Яруллин

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ
ФӘНИС ЯРУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАР—ТӨРЛЕ ҖЫРЛАР

* * *

**Әгәр йөрәгең таш булса,**
**Хисләрем булыр тамчы.**
**Тамармын да тамармын мин,**
**Таш тишелеп чыкканчы.**

**Әгәр йөрәгең боз булса,**
**Ут булырмын, тор белеп.**
**Янармын да янармын мин,**
**Бозың беткәнче эреп.**

**Йөрәгең кыя тау булса,**
**Ургырмын чишмә булып.**
**Агармын да агармын мин,**
**Тау төшкәнче убылып.**

*1962*

* * *

**Идәндәге һәр валчыкны**
**Җыеп алсам, көлмәгез;**
**Ипине хөрмәт итәм мин—**
**Саран да бу, димәгез.**

**Юлдан шөреп иелеп алсам,**
**Ни таптың дип килмәгез;**
**Хезмәтне хөрмәт итәм мин—**
**Юләр дә бу, димәгез.**

**Куш куллап тотсам бәхетне,**
**Калдырыгыз, тимәгез;**
**Бәхетне кыен табам мин—**
**Комсыз да бу, димәгез.**

*1965*

* * *

Беренче кат кайгыны мин шунда белдем,
Ул чак миңа ни барысы биш яшь иде,
Әтиебез яу кырында һәлак булды,
Кайгы ул көн ташып торган күз-яшь иде.

Шатлыкны мин беренче кат шунда белдем:
Яңа гына сугыш беткән айлар иде,
Әниебез мич тутырып ипи салды,
Бәхет ул көн түп-түгәрәк, кайнар иде.

Ә аннан соң шатлыклар да, кайгылар да
Күрмәдем дип әйтмимен мин сезгә һич тә.
Ләкин хәтер соңгыларын тиз онытты,
Тик болары бүгенгедәй һаман истә.

*1966*

## Төшендә дә күрде ана

Төшендә күрде дә ана
Сузганын ап-ак киндер,
Торып җыештырды өен:
Килергә тиеш кемдер,
Килергә тиеш кемдер.

Төшендә күрде дә ана
Болытлар өермәсен,
Чәчәкләрен чыгып япты:
Бозлар суга күрмәсен,
Җилләр ега күрмәсен.

Төшендә колын күрде дә
Су буе болынында:
Торып күлмәк текте ана
Туачак оныгына,
Булачак буынына.

*1967*

## Каз кычкыра

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Җил каерган канатын;
Һаваларга оча алмый,
Талпына да кала тын.

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Тавышы ерак китә;
Очкан кошлар өстән генә
Хәлләрен сорап китә.

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Күккә сузган муенын.
Ак болытлар арасыннан
Эзли бугай үз юлын.

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра,
Кырга сыймый тавышы;
Кемнәр килеп уртаклашыр
Кыр казының язмышын?

*1968*

* * *

Дуслар белән күрешкәндә,
Егыла-егыла көлешкәндә,
Шатлыкларны бүлешкәндә,
Әгәр кинәт күңелем тулса,
Күзләремдә яшьләр булса,—
Тиргәмәгез,
Кичерегез!

Алда таулар очраганда,
Янда терәк булмаганда,
Эшләрем дә уңмаганда,
Әгәр кинәт җебеп төшсәм,
Чылансалар күзләр яшьтән,—
Бер тиргәгез,
Кичермәгез!

*1969*

## Ким булыр шикелле

Тормасам кояштан иртәрәк,
Чык белән юмасам битемне,
Матур чак йокланып үтәр дә,
Бәхетем ким булыр шикелле.

Эшемдә юл ярып бармасам,
Куймасам эшкә бар көчемне,
Иң кызык ачышлар бетәр дә,
Бәхетем ким булыр шикелле.

Уңыштан зиһенне чуалтып,
Тик әрәм итсәм дә бер көнне,
Кешелек табынына куясы
Өлешем ким булыр шикелле.

*1970*

* * *

Әллә күктә яшен гөлт итте,
Әллә кызлар кашын сикертте:
Өлгермәдем һични аңларга,
Ялкын капты зәңгәр таңнарга.

Әллә көзләр артык тиз җитте,
Әллә яшьлек артык тиз үтте:
Утын күрдем—җылысын сизмәдем,
Болынын күрдем—гөлен өзмәдем.

*1972*

## Күңел күзем

Маңгай күзем күрмәгәнне
Күрә күңел күзем.
Шуңар кылган эшем өчен
Һич кызармый йөзем.

Бар минем илем каршында
Шагыйрь дигән атым.
Шул атыңа тугры бул, ди
Күңел күзем—халкым.

*1979*

## Чын мәхәббәт бармы?

Чын мәхәббәт юк ул, дисәм әгәр,
Үпкәләрләр бик бәхетле парлар.
Ә бәхетле парлар күпмелеген
Әйтә ала бары җәйге таңнар.

Чын мәхәббәт юк ул, дисәм әгәр,
Бик күпләрнең хәтере калыр кебек.
Әмени соң кайнар күз яшьләрен
Яшәүчеләр тик мендәргә түгеп.

Чын мәхәббәт кенә елата бит
Һәм яралый безнең җаныбызны;
Җан яралы булгач, без соң аны
Чын мәхәббәт диеп саныйбызмы?

Чын мәхәббәт юк ул, дисәм әгәр,
Нәрсә әйтер миңа сөйгән ярым:
Ул бит мине ничә еллар буе
Кулларында йөртә, түкми зарын.

Чын мәхәббәт юк ул, дими, дуслар,
Дәва гына эзлик ярабызга,
Замананың Таһир-Зөһрәләре
Арабызда яши, арабызда.

*1983*

* * *

Язмыш, язмыш, күп сорамыйм
Синнән бер дә:
Яманлыкны онытмаслык
Хәтер бирмә.
Йөрәгемне май басарлык
Байлык бирмә,
Һичкем өчен сызланмаслык
Саулык бирмә.
Кешелегемне кумәрлек
Шөһрәт бирмә.
Сөюне таптап изәрлек
Кодрәт бирмә.
Усаллыктан сукраерлык
Күңел бирмә.
Кешеләрне туйдырырлык
Гомер бирмә.

*1986*

## Мин генә күренәм тирбәлеп

Язмышым салынган савытны
Утыртып баш түбәң өстенә
Атлыйсың таңнардан таңнарга
Сыкранмый-зарланмый һич кенә.

Кичәсең ничәмә карурман,
Уең юк кирегә борылырга.
Егылсаң тәгәри савытың,
Ярамый иелергә, егылырга.

Төшәсең диңгездән диңгезгә
Курыкмый йотар дип тирәнлек.
Ярсулы дулкыннар өстендә
Мин генә күренәм тирбәлеп.

*1987*

## Бүген кемнәр

Бер ак каурый алып кайттым
Су буеннан чирәмнән.
Каурый калган, ә соң кошын
Язмыш кая җибәргән,
Туган-үскән җирләрдән?

Кулларымда ап-ак каурый,
Әйтерсең ак кулъяулык.
Ярым киткән, истәлеккә
Калган бары шул яулык—
Бер ярага ябарлык.

Ак каурыйның ап-ак төсе
Сакланырмы озакка?
Бүген кемнәр каурый тотып
Аккошларын озата,
Кайтмас җиргә, еракка?

*1988*

## Халык бар

Горурлыгы олы булса,
Күңелендә җыры булса,
Җырлап атлар юлы булса—
Димәк, әле халык исән!

Тураерга биле булса,
Күтәрергә иңе булса,
Авызында теле булса—
Димәк, әле халык исән!

*1990*

## Мәңгелек тартыш

Һәр күңелдә иблис тә бар фәрештә дә,
Бара алар арасында мәңге тартыш.
Иблис белән фәрештәнең тартышында
Газапланып язылa шулай безнең язмыш.

Була көннәр: күңелне гел иблис били,
Ул тантана итә анда, җырлый, бии.
Мәҗлес ясый: эчә, тарта, сүгенә, көлә,
Яхшылыкка берни дә урын бирми.

Ә кай көнне фәрештәбез өстен була,
Эчкә шәфкать һәм мәрхәмәт кереп тула.
Кулларыбыз гел игелек эшләп тора,
Андый көндә иблис телен тешләп тора.

Тартышмыйча яши алмый алар һич тә,
Бу икәүгә тар ахры күңел—җиһан.
Күңелнең бер почмагында посып кына
Кем җиңәр дип карап тора безнең Иман.

*1992*

* * *

Дөнья—камыт,
Туу белән киясең дә—
Булмый кабат салып.

Тормыш—тәртә,
Күпме генә чәбәләнмә—
Арасына кертә.

Язмыш—арба,
Гел шуны тартып йөрисең,
Кая гына барма.

*1994*

* * *

Сафлыкка шундый нык сусалган,
Зиһеннәр, акыллар чуалган.
Әчимче күзеңнең нурларын,
Яктырсын беразга уйларым.

Шатлыкка шундый нык сусалган,
Үткәннәр рәшәгә уралган.
Әчимче туйганчы шатлыгың,
Йөземә күчмәсме аклыгың.

Сөюгә шундый нык сусалган,
Йөрәккә карурман моң салган.
Таратчы шул моңнар томанын,
Яктырсын мәхәббәт урманым.

Бәхеткә шундый нык сусалган,
Юллары ялкынга уралган.
Табалмыйм, табалмыйм, табалмыйм,
Юлларның очлары югалган.

*1997*

## Ярлыка

Мал өчен, дан өчен түгелә кан,
Җир җитми—күңелләр тарлыкка.
Нәфсенә кол булган бәндәңне
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Күпләрнең өмете өзелгән,
Ышанмый хакыйкать барлыкка.
Адашкан, саташкан җаннарны
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Кешеләр үзенә кул сала,
Түзмичә изелү-хурлыкка.
Сабыры төкәнгән мескенне
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Юләрләр хакимлек иткәндә
Инсаннар әйләнә сарыкка.
Сарыкка әйләнгән инсанны
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Сугышлар. Суешлар. Кырышлар.
Халыклар ачулы халыкка.
Гөнаһка баткан бу дөньяны
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

*1999*

* * *

Вәгъдә—иман.
Шулай булган
Халык иманлы чакта.
Хәзер инде калган алар
Икесе ике якта.

Бу ике дус арасына
Биек тау чыккан калкып.
Кавыша алмый сүз һәм гамәл
Гүя әкияти Сак-Сок.

*2000*

## Бир бишне

Иртүк торып шигырь язып куйдым,
Көнем булыр әле уңышлы.
Изге эшкә фатихасын биреп,
Фәрештәләр миңа булышты.

Кәгаземә кояш төшеп торды,
Каләмемдә нурлар биеде.
Тәрәзәмне җилләр киереп ачып
Иркенәйтте минем өемне.

Эчтән генә бер көй көйли-көйли
Кереп киттем шигъри диңгезгә.
Ак җилкәнле ак корабым бирдем
Йөрәге саф, күңеле керсезгә.

Акчарлаклар булып күккә мендем,
Балык булып чумдым тирәнгә.
Рәхмәт әйттем күккә, җиргә, суга—
Язарыма куәт биргәнгә.

Әй, Шигърият! Нинди кодрәтле син,
Берни дә юк синә тиңләрлек.
Синсез каян көчләр алыр идем
Җиде катлы күккә менәрлек?

Йөрәгемдә син яшәгән чакта
Мин сәламәт, мин хөр, мин көчле.
Яшик әле мәңге бергә-бергә,
Шигъриятем, әйдә, бир бишне.

*2001*

## Яңа гына

Яңа гына әле, яңа гына,
Килгән идең минем яннарыма;
Мин белмәгән гаҗәп сихри төсләр
Килеп керде минем таңнарыма.

Яңа гына әле, яңа гына,
Язмыш суккан иде яңагыма.
Канлы яшьләремне сөртә-сөртә
Йөгердем мин бары алга гына.

Төшә-төшә тирән упкыннарга,
Бирешмичә тау-тау дулкыннарга—
Таяндым да синең иңнәреңә
Йөгердем мин якты көннәремә.

Кара көннәр артка чигенделәр,
Керфекләргә нурлар эленделәр.
Барыр юлларыма йолдыз явып
Энҗе-мәрҗән булып сибелделәр.

Яңа гына әле, яңа гына,
Тормыш суккан иде яңагыма.
Тотындым да олы Мәхәббәт һәм
Шигърияттнең серле таягына—

Очып киттем кошлар юлы буйлап,
Озак бардым, туктап ялга гына.
Ни арада гомер үтеп киткән,
Башланган иде бит яңа гына.
Яңа гына!

*2007*



Равил
Вәли

# КАНАТЛЫ ТАТАР

РОМАН

*Рудольф Нуриев дөньядагы иң
атаклы вә борынгы бабасы
Чыңгыз ханга охшаган: ул килә
һәм... шунда ук яулап та ала!
Дөрес, йөзләгән шәһәр-
кирманнәрне түгел, ә меңләгән,
миллионлаган тамашачылар
йөрәген!*

Джон Мартин,
Америка балет сәнгатенен
күренекле белгече

## Беренче кисәк

### 1

Бию сәхнәсе хәтле зур өстәлдә, йөрәкләрне шомга салып, кызыл тугралы телефон чылтырады.

Сирәк янгырый торган әлеге телефон телгә килгәч, Киров театрының баш балетмейстеры Константин Сергеев, гадәттә, каушап-югалып кала торган иде. Бу юлы да шулай булды. Кызыл тугралы телефоннан рәхмәт әйтеп маташмаслар—Ленинград каласының гына түгел, бөтен илнең балет сәнгатендәге йөзек кашы саналган мәртәбәле театр чыгышларына ниндидер дәгъвалары бардыр, мөгаен.

Артык дулкынланудан тирләп-юешләнеп киткән учы белән кысып, Константин Михайлович телефон трубкасын колагына якын ук китерде:

—Алло! Сергеев тыңлый...

—КПСС Үзәк Комитетыннан борчыйлар иде әле сезне...

Ата каз ысылдавын хәтерләткән әлеге шомлы сүзләрне ишеткәч, коты ботына төшеп, Сергеев бераз телсез калып торды:

—Үзәк Комитет?..

—Әйе... Дөресрәге, аның махсус комиссиясеннән.

Шомлы «комиссия» сүзен ишеткәч, Сергеевның уч төпләренә генә түгел,

---

Равил ВӘЛИ (1942)—*язучы; «Җөй», «Олуг хан ярлыгы» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

хәтта сөяк кебек шома маңгаена да салкын тир тамчылары бәреп чыкты:

—Гафу итегез... Ә ул нинди комиссия?—диде Сергеев, юеш маңгаен дүрткә бөкләнгән чиста кульяулыгы белән сөртә-сөртә.

—Киров театрының тиздән чит илләрдәге гастрольләре башланасын беләсездер бит инде?

—Әлбәттә, әлбәттә...—диде Сергеев, ниһаять, бераз тынычлана төшеп.— Хәзерге вакытта менә шул гастрольләргә әзерлек мәшәкатьләре белән яшәгән көннәребез!

—Менә нәрсә, иптәш Сергеев!—диде комиссия әгъзасы, рәсми тонга күчеп.—Әнә шул гастрольләрдә катнашачак йөз дә егерме кешегезнең тулы исемлеге иртәгә иртүк безнең кулда булырга тиеш!

—Аңлашылды. Тырышырбыз!—диде Сергеев, телефон трубкасын куярга ашыкмыйча гына.

Үзәк Комитет дигәндә—аяк идәндә!

Әле һаман җыерчык кунарга өлгермәгән төз муенындагы ак бөрчекле кызыл галстугын бераз бушата төште дә, Сергеев теге ашыгыч исемлек мәшәкатьләренә кереп чумды. Дөрес, ул исемлек дигәннәре күптән әзер дә кебек иде инде. Чөнки чит илләргә гастрольләр белән чыгарга теләүче артистларга һичкайчан кытлык булмады һәм булмаячак та! Бердән, дәрәҗәсе ни тора?! Икенчедән, кайда чыгыш ясасаң, шул ил акчасы белән түләнә торган берничә айлык командировка хакы! Монысы еллар буе җан асрарлык кына акчага эшләп күнеккән совет артистлары өчен күпкә мөһимрәк тә әле.

Ә инде булачак ике айлык гастрольләрнең сәяси-идеологик ягына килгәндә...

Театр җитәкчелеген партиянең шәһәр комитетына чакыртып та монарчы гел колакларына тукый килделәр:

—Онытмагыз: Ленинградның атаклы Киров театрын чит ил гастрольләренә җибәрү совет системасы өстенлекләрен бар җиһанга тагын бер кат раслап күрсәтү өчен эшләнә. Шуңа күрә, чикләр аша атлап чыккач йөзгә кызыллык китермәсеннәр өчен, Париж—Лондон гастрольләрендә катнашучыларның һәркайсы җиз иләк аша үткәрелергә тиеш!..

Әйе, болары шулаен шулай. Һәм театрның баш хореографы Сергеев күңеле бу яктан тыныч диярлек: совет артистлары, сирәк була торган шундый дәрәҗәле һәм төшемле сәфәрләрдән киләчәктә дә колак какмау хакына, һәммәсен дә эшләячәк!

Тик менә театрның яңа балкый башлаган яшь йолдызы Рудольф Нуриев белән нишләргә? Һичкемгә баш бирергә теләмәгән үҗәт холыклы, ләкин балет сәнгатендәге күп нәрсәләргә инде хәзер үк үз карашы, үз фикере булган искиткеч талантлы һәм тырыш бу биючене Париж—Лондоннарга җибәрү мәсьәләсендә ялгышлык кылып, алай-болай үз башларына хәсрәт алмасылармы?

Сергеевны Нуриевка каршы өстергән, баш балетмейстерның фәкать үзе һәм хатыны Наталья Дудинская гына белергә тиешле шәхси сәбәпләр дә бар иде. Алар—Киров театры сәхнәсендә күпме еллар балкыган иң якты йолдызлар. Икесенең дә озын-озак мактаулы хезмәтләре «СССРның халык аристы» дигән олы дәрәҗәләр белән тамгаланган.

Ләкин биюченең сәхнәдәге гомере, искән җилләр кебек, бик тиз генә үтә дә китә икән! Илле яшьләр чамасындагы ирле-хатынлы бу ике артистның да бию кояшы инде батуга таба бара иде. Ләкин әле кулда власть, аякларда исә азмы-күпме егәр барында бииселәр бик тә, бик тә килә иде. Аеруча бөтен дөньяны шаулатачак чит ил сәхнәләрендә. Аларның моңдый биюләре, бәлки, соңгы тапкырдыр?

Менә шуңа күрә Рудольф Нуриев кебек яңа кабынган яшь йолдызлар яктылыгыннан көнләшепләр үләрлек иде. Бу көнләшү газапларын читкә-чатка бик чыгармаска тырышып, Константин Михайлович эчтән генә сыза,

эчтән генә яна-көя иде.

Хәер, кирәк чакларда ул авыр холыклы Нуриевны үз көндәшләренә каршы бик оста файдалана да белде. Ә бу көндәшләреннән иң талантлысы һәм яше, димәк, Сергеевнын киләчәк карьерасы өчен иң куркынычлысы, һичшиксез, Юрий Григорович дигән хореограф иде. Менә шул хореограф, чуар холыклы дип саналган Рудольф Нуриевнын киләчәктә күп биючеләр борынына чиртәчәк нинди якты йолдыз булачагын күреп вә тоеп, тотты да көннәрдән бер көнне аны тиздән азәрбайҗан композиторы Ариф Меликовнын төрек шагыйре Назыйм Хикмәт әсәре буенча куелырга тиешле «Мәхәббәт турында легенда» исемле яна спектакленә Фәрхад дигән төп рольне башкаручы итеп билгеләде. Ә бу вакытта Константин Сергеев бөек рус композиторы Петр Чайковскийнын шулай ук төп рольдә Рудольф Нуриев биегән «Аккош күле» балетын сәхнәгә әзерләү белән мәшгуль иде.

Берьюлы ике спектакльдәге ике төп рольне башкаруга әзерләнүнең ничек тыгызга туры киләчәген белсә дә, көнчыгыш темасына бәйле һәм мөселман халыкларына хас моң-биюләр белән беренче мәртәбә очрашканлыктан, Рудольф Нуриев Юрий Григорович тәкъдимен бик теләп кабул итте. Карт төлке Сергеевка исә шул гына кирәк иде дә! Ул тотты да «Аккош күле»нең репетицияләр вакытын «Мәхәббәт турында легенда»ныкыннан соң ук башланып китә торган итеп билгеләде. Арада бер бинадан икенчесенә күчеп өлгерерлек тә буш вакыт юк.

Һәм моның тискәре нәтиҗәләре озак көттермәде.

Беркөнне шулай «Мәхәббәт турында легенда» өчен билгеләнгән вакыт чыгуга, сәгатенә карый-карый, Рудольф Нуриев «Аккош күле» репетициясенә китәргә җыена башлады. Ләкин аның бу теләгенә үз сүзендә шулай ук нык торучан яшь хореограф Юрий Григорович аркылы төште:

—Сез кая җыендыгыз, Нуриев? Без бит бүгенге репетицияне ясап бетермәдек әле?

—Сез бетермәсәгез бетермәссез—ә минем вакыт чыкты!—диде Нуриев, кырт кисеп һәм ишеккә таба бара башлады.

—Тукта диләр, Нуриев!

Ләкин Рудольф тукталмады. Балет киемнәре салынган сумкалы иңбашын сүзсез генә сикертеп куйды да юлын дәвам итте.

—Кабатлап әйтүем... Әгәр хәзер кире борылмасагыз, бу репетицияләр залына бүтән килеп йөрмәсәгез дә була!

—Минем «Аккош күле» репетициясенә дә барып өлгерәсем бар—аңлыйсызмы шуны?

—Анысында минем эшем юк!

—Алайса, хушыгыз!—диде Нуриев һәм ишекне галәмәт каты ябып чыгып та китте.

Шулай итеп, Юрий Григорович белән әйбәт кенә башланып киткән иҗади хезмәттәшлек, икенче бер хореографның таяк тыгуы аркасында, кинәт кенә өзелде дә куйды. Акылдан бигрәк кызу канлы хискә бирелеп ясалган бу адымы өчен соңыннан Рудольфка бик нык үкенергә туры килде. Чөнки ул Фәрхадның чиста-саф сөюе турындагы бу әсәрне һәм әлеге сөюне озата барган көнчыгыш музыкасын чын күңеленнән яратып өлгергән иде. Нәкъ менә Рудольфтай татар биючесе өчен куелырга тиешле балетта очынып биюләр, ни үкенеч, ана насыйп булмады шул...

Ә менә бүгенге һәм киләчәк көндәше Григоровичның Нуриев кебек үтә талантлы яшь биючедән колак кагуы өчен сөенүдән баш балетмейстер нишләргә дә белмәде. Шулай да бер казанга үзе белән Нуриевны да сыйдырып булмастыр, шәт. Ул әле яшь. Быел Париж белән Лондонга бармый калганнан гына укасы коелмас! Җитмәсә, күпләр күзенә кылчык булып кадалган эреле-ваклы гөнаһлары да әкәмәт күп! Нәкъ тимер авызлыгын читкә төкереп, йөгән-тышауларын өзә-өзә чапкан ярсу толпар диярсең! Ә бит Париж-

Лондоннарга барган очракта, авызлыклы йөгәнен дулап өзгән бу кыргый татарның тагын әллә ниләр тождыруы бар! Аллам сакласын!

Сергеев, моңарчы булган барлык икеләнүләрен бер читкә этәреп, Үзәк Комитет комиссиясенә тапшырыласы исемлектән Нуриев фамилиясен эзләп тапты һәм, ниһаять, аны әллә кайдан чекрәеп торырлык кызыл кара белән бер селтәнүдә сызып ташлады.

## 2

Ләкин Сергеевның кара ниятләре кыска гомерле булып чыкты.

Аның юлына совет балеты сәнгатенең Франциядәге «тулы хокуклы илче»се, танылган сәхнә эшкуары Жорж Сориа аркылы төште. Киров театрының тиздән Парижда башланып китәчәк гастрольләрендә бу иҗат коллективының иң-иң якты һәм яшь йолдызы Рудольф Нуриев катнашмаячагын каяндыр, үзе генә белгән кешеләреннән ишетеп алган да, күпме чикләр, күпме киртәләр аша үтә-үтә, СССР мәдәният министры Екатерина Фурцеваның кабул итү бүлмәсенә турыдан-туры килеп тә кергән!

Илнең иң зур, иң кодрәтле җитәкчеләре арасында хатын-кыз затыннан бердәнбер министр булса да, бөтен совет империясе мәдәниятен гайрәтле кулда дер селкетеп тоткан бу идарәче хатынга Жорж Сорианың үзе дә, башкарган эш-гамәлләре дә яхшы таныш иде. Шуңа күрә сәнгать өлкәсендәге булдыклы эшкуарны ул әллә кайдан балкып торган якты йөз белән каршы алды:

—О—о!.. Безнең кадерле һәм хөрмәтле импрессариобыз! Нинди җилләр ташлады үзегезне?.. Йә, ничек анда Франциядә? Безнең Киров театры гастрольләренә әзерлекләр ничегрәк бара, месье Сориа?

—Әйбәт кенә бара иде дә... Һич көтмәгәндә туктап калды бит әле, мадам Фурцева!—диде Жорж Сориа, төшенке тавыш белән.

—Ә ни өчен туктап калды? Моның сәбәпләре нидә, месье Сориа?

—Эш бит менә нәрсәдә, мадам Фурцева! Минем ишетүемчә, Ленинградның атаклы балет труппасы Парижга Рудольф Нуриев кебек яшь йолдызларны түгел, ә инде пенсия яшенә җиткән яки җитеп килүче биючеләрен алып килергә җыена икән. Француз тамашачылары, билгеле инде, картайган андый йолдызларны карарга һич тә атлыгып тормый...

Екатерина Алексеевна, мәсьәләгә төгәллек кертергә теләп, сорап куйды:

—Кемнәр инде ул картайган йолдызлар?

Жорж Сориа, музыкантларныкы төсле озын-нечкә бармакларын бөгә-бөгә, саный башлады:

—Илле яшьлек юбилеен инде узган елны ук уздырган Константин Сергеев—менә булдымы бер, аның шундый ук юбилейны киләсе елда үткәрәчәк сөекле хатыны Наталья Дудинская—менә булдымы ике, яше буенча алардан әллә ни калышмаган Алла... Гафу итегез, фамилиясе тел очымда гына тора...

—Ә—ә... Алла Шелестмы?

—Менә-менә... Ә бит француз тамашачылары Советлар Союзының картаеп барган халык артистларын түгел, ә беренче чиратта Рудольф Нуриев кебек яшь йолдызлар биюен күреп ләззәтләнү өчен киләчәк!

Француз эшкуары сүзләрен Екатерина Фурцева да хупларга мәҗбүр булды:

—Дөрес, бик дөрес, месье Сориа!

Һәм, ил кәнәфиенең иң түрендә утыручы турылыклы көрәштәше Никита Хрущев алып барган халыкара сәясәтне кайгыртып, авыр сулый-сулый өстәп куйды:

—Чынлап та... Париж тамашачылары агылып килмәгәч, совет сәнгатенең чит илләрдәге дәрәҗәсе турында нинди сүз булырга мөмкин? Ә без капма-каршы ике системалы җәмгыятьләр арасында килешмәүчән көрәш-ярыш,

совет престижы турында сүз алып барган булабыз.

—Дөрес, мадам Фурцева! Ләкин бит бу ашыгыч мәсьәләнен әле икенче ягы да бар.

—Тынлыйм...

—Театрнын художество житәкчесе булуыннан файдаланып, күпчелек спектакльләрдәге төп рольләрне месье Сергеев бары тик үзе генә биергә карар иткән.

—Төгәлрәк әйткәндә?

—Рәхим итегез: «Жизель»дәге Альберт, «Йокыга талган гүзәл» дәге Зәнгәр кош, «Баядерка»дагы Солор, «Дон Кихот»тагы Базиль, «Тарас Бульба»дагы Андрей партиясен...

—Менә ниче-е-ек?..

—Ә бит Парижлагы гастрольләр башланырга бик аз вакыт калып бара. Һәм бу рольләрне тиз арада үзләштерүне бары тик Рудольф Нуриев кына булдырачак!

—Тел төбегезне анлыйм: Нуриев та Нуриев...

—Нуриев булмыйча сон? Ул бит гастрольчеләр исемлегенә бөтенләй кертелмәгән дә, мадам Фурцева!

—Кертелмәгән?!. Менә монысы минем үземә дә анлашылып житми, месье Сориа!

—Кертелмәгән шул менә, кертелмәгән...

Ярыйсы тулы гәүдәле министр, биек аркалы кәнәфиеннән жинел генә торып, Жорж Сорианы ишек катына хәтле озатып куйды:

—Борчылмагыз, месье Сориа! Әле эш узмаган—барысын да тиз арада жайларбыз. Рәхмәт кереп анлатуыгызга! Тик моннан шуны белеп китегез—Киров театрынын сез теләгән яшь биючесе Рудольф Нуриев Париж гастроленә, һичшиксез, барачак!

Жорж Сориа бөтеркә чәчле башын түбәнчелек белән аска иде:

—Чын күнелдән рәхмәт, мадам Фурцева! Бәлки әле Нуриевнын утлы-давыллы биюен карарга үзегез дә Парижга килеп чыга алырсыз?

—Бәлки... Хушыгыз, месье Сориа!

Бераздан исә Киров театрынын баш балетмейстеры бүлмәсендә тагын кызыл тугралы телефон чылтырады:

—Әйе, Сергеев тынлый,—диде Константин Михайлович...

—Фурцева...

Кылыч чынлавын хәтерләткән корыч тавышны ишеткәч, Сергеевнын хәтта күз аллары карангыланып китте:

—Исәнмесез, иптәш Фур...

Аны ярты юлда бүлдерделәр:

—Сез ни оятыгыз белән әле анда яшьләргә юл бирмәскә маташасыз, иптәш Сергеев?

Ачуы килгән чакларында министр Фурцеваның имәндәй ирләрне дә дер калтырата алуын яхшы белә иде Сергеев. Иелгән башны кылыч кисмәс дигәндәй, мондый вакытларда ана каршы дәшмәскә кирәк. Бары шул гына. Бераздан ул тынычланачак...

—Йә, нигә дәшмисез әле анда?

Ниһаять, Сергеев та телен бераз әйләндерә алырлык хәлгә килде:

—Кемгә юл бирмибез икән, иптәш Фурцева?

—Чит ил гастрольләренә баручылар исемлегендә нигә Нуриев юк?

—Ә—ә... Менә кемне күздә тотасыз икән! Тик ни бит... Нуриев, бик талантлы булса да, ышанычсызрак егет күренә бит...

—Дәлилләр?

—Үзен бүтәннәрдән өстен куярга ярата...

Корыч тавышлы министр аны бу урында кырт кисте:

—Өстен булгач—ник өстен куймасын! Чит илләр сәхнәләрендә совет

системасының өстенлеген тагын бер кат раслап күрсәтү өчен, безгә иҗат кояшлары батып барган биючеләр түгел, ә нәкъ әнә шундый Нуриевтай яшь йолдызлар кирәк тә!

Чит ил сәхнәләрендә тиздән булачак чыгышлары белән хушлашуга тиң әлеге сүзләрне ишеткәч, Сергеевның тәмам тез буыннары калтырый башлады:

—Ни бит, иптәш Фурцева! Сүзне тынламый бит...

Ниһаять, корыч тавышлы министрның һичнинди карышуларга юл калдырмый торган хәлиткеч сүзләре ишетелде:

—Менә нәрсә, Сергеев! Хәзер үк Нуриев фамилиясен өстәп куегыз да, теге исемлекне кабат бастырып, кичекмәстән монда җибәрегез!

—Ә без аны җибәрдек бит инде.

—Кая?

—Партиянең шәһәр комитетына... Субординацияне саклап...

Фурцеваның болай да кырыс тавышында кинәт кискен ризасызлык төсмерләре чагылып китте:

—Субординация саклап торыр вакыт калмаган инде хәзер! Рудольф Нуриев кичекмәстән гастроль репетицияләрен башлап җибәрсен!

—Аңлашылды, иптәш Фурцева!

Ләкин министрның Сергеев өчен иң авыр, иң мәрхәмәтсез сүзләре бетмәгән иде әле:

—Икенчесе: Париж—Лондон гастрольләрендә шәхсән сез үзегез биергә тиешле рольләрнең һәммәсен Рудольф Нуриев башкарыр. Яшьләргә чын-чынлап юл бирергә вакыт җиткәндер, ниһаять!

Кикриге бик тиз шиңгән Сергеевның калтыранулы тавышы бу юлы бик мескенләнеп чыкты:

—Ә без соң, иптәш министр?.. Чит ил гастрольләренә Сергеев белән аның хатыны бөтенләй бармыйлар булып чыгамы, алайса?

—Барырсыз... Ләкин биючеләр түгел, ә аларның остаз-киңәшчеләре булып! Хушыгыз!..

Сергеев, кызыл тугралы телефон трубкасын куйгач, әле бик озак исенә-хушына килә алмыйча торды. Ничә дистә еллар гөрләтеп биегән сәхнә белән хушлашуларны ул һич тә болай булыр дип күз алдына китермәгән иде. Вакытында китә белмәсәң, менә ничек бер селтәнүдә тиешле урынына утыртып куя алалар икән шул!

Гарьлегенә түзә алмагач, Сергеев тотты да үз теләге белән эштән китү турында гариза язды. Ләкин йөрәк барыбер тынычланмады. Китеп кая барасың? Алтмышны ваклый башлаган биючегә кемгә кирәге бар? Юк, тот та гаризаңны ертып ат! Чебеннең дулап кайчан тәрәзәне ватканы бар? Әле болай хет театр дилбегәләренең берсе синең кулыңда калачак. Алдың-артыңны карап йөри белмәсәң, әле анысын да Юрий Григорович дигән яшь көндәшең тартып алырга күп сорамас...

Ә иң кирәкле чакта, үз юлына аркылы төшкәнә өчен, ярсу канлы теге азиат кыргыеннан, ягъни мәсәлән, Рудольф Нуриевтан тиешле үчен ала беләчәк әле ул! Дөрестән дә, борын асты кибеп өлгермәгән ул малай-шалай кем дә, СССРның халык артисты Константин Сергеев кем?!

### 3

Ленинград-Париж рейсы белән алар очып китәргә тиешле май иртәсе, инде яз азаклары җитүгә карамастан, шактый салкын иде әле. Йөрәкләрдәниндидер шом уятып, күктә бертуктаусыз кургашындай кара болытлар йөзә. Әнә шул күккә очып менеп китәсе һәм авыр болытлар һич агылып туймаган бу сулы-утраулы төбәктән тизрәк кояшлы көнбатыш тарафларына барып чыгасы килә башлый. Анда көннәр аязрактыр, анда көннәр җылырактыр кебек бит, шайтан алгыры!

Киров театры артистларын озата килүчеләр арасында Рудольфның Уфадан инде Ленинградка күчеп яши башлаган өлкән апасы Роза белән хореография училищесыннан яраткан остазы Александр Пушкин һәм аның сөекле хатыны Ксения Юргенсон да бар иде. Сөңге очлары кебек тезелешкән тимер рәшәткәле киртә артына басып, кулларын болгый-болгый, алар кара галстуклы ак күлмәге өстеннән калын-җылы свитер һәм су үткәрми торган чытырдавык плащын киеп җибәргән, тынлаусыз көлсу-көрәнсу чәчләренең бер көлтәсе уң чигәсенә ишелеп төшкән Рудольф артыннан байтак озак карап тордылар. Очкыч ишегеннән кереп китәр алыннан, җәлт кенә борылып, Рудольф та аларга күз төшереп алды. Ни гаҗәп, аны озата килүчеләр таянган ул очлы рәшәткәләр бу минутларда аркылы-торкылы беркетелгән шыксыз төрмә тәрәзәләренә охшап калган иде.

Парижның Ле Бурже аэропортында совет биючеләрен галәмәт озын һәм кин-иркен эчле зәңгәр автобус каршы алды. Гастрольгә килгән йөздән артык артист авыр чемоданнары-ниләре белән кереп тулгач, бәбкәләрен канатлары астына сыендырган ана каз кебек, ул хәтта бераз җиргә чүгеп куйгандай булды. Аннары, як-якка чайкала-чайкала, акрын гына Республика мәйданындагы «Модерн» кунакханәсенә таба кузгалып китте.

Гастрольгә китәр алдыннан тиешле оешмаларның усал агайлары аларның колакларына кат-кат тукып кисәткәннәр иде инде:

—Карагыз аны: Париж урамнарында ялгыз аерылып калмыйча, берничә кешелек төркем булып кына йөри күрегез! Юкса, балагә таруыгыз бар. Провокация дисезме... Монда андый очраклар бик еш булып тора. Иң әйбәте—үзегезгә беркетелгән зәңгәр автобустан бер карыш та читкә китмәү. Ул сезне ашарга да, бию-репетицияләргә дә йөртеп, чын-чынлап көпчәкле йортыгызга әверелер...

Рудольфның ачуын иң нык китергәне исә нәкъ менә шушы автобуста вәгъдә ителгән күмәк тормыш иде. Аларны кечкенәдән күмәк сафларда атлап йөрергә өйрәттеләр. Аннары кызыл галстуклы пионерлар һәм комсомолларның тыгыз сафларына кысып тәрбияләделәр. Сафта исә берниндә туктап калу яки читкә атлау да була алмый, чөнки арттан килүче шунда ук үкчәнә китереп бәрәчәк!

Инде гомерләрендә беренче мәртәбә чит илләр туфрагына аяк басарга җай чыккач та, иркенләп сулыш алырга ирек бирмиләр совет кешесенә. Автобусның үзенә дип билгеләнгән йомшак кәнәфиенә килеп утыргач, иң беренче эш итеп, Рудольф ябык пәрдәләрне як—якка шудырып—ачып җибәрде. Аннары, ике баштагы төймәләренә басып, өске пыялаларны шудырып төшерде. Тынчу автобус эченә азмы-күпме яктылык һәм урам һавасы кереп тулды. Ләкин гомер буе куркытылып көн күргән бүтән юлчылар, ниндәндер шүрләп-шикләнеп, үз тәрәзәләрен, үз күнел пәрдәләрен ачарга ашыкмадылар.

Чит ил гастрольләренә, ышанычлырак булсын өчен, өйләнеп өлгермәгән буйдакларны, гомумән, монарчы чыгармыйлар иде. Көнбатышта совет сәнгатенең дәрәҗәсен тагын да күпайтып күрсәтү хакына бу юлы яшь һәм якты йолдыз Рудольф Нуриев өчен генә кырыс кагыйдәдән чыгарма ясалды. Инде хәзер ана кемне бүлмәдәш итәргә? Әлбәттә, кызлар кебек нәзберек холыклы Юрий Соловьевны! Бу мәсьәләне, үзе генә белгән яшерен максатларны күздә тотып, театр директорының кадрлар буенча урынбасары һәм Дәүләт Иминлеге Комитетының әлеге иҗат коллективындагы рәсми булмаган вәкиле капитан Владимир Стрижевский хәл кылды. Чөнки Соловьевның биюче хатыны , гастрольләр алдыннан кинәт авырып китеп, Ленинградта калган иде. Аннары, биючелек сәләте зур булса да, холкы буенча Соловьев артык юаш һәм күндәм—ни кушсаң, шуны үтәргә мөмкин!

Кунакханә бүлмәләренә азмы-күпме урнашып бетүгә, вакытны әрәм үткәрмәс өчен, совет артистлары Наполеон заказы буенча төзетелгән атаклы Пале Гарнье театры бинасында беренче репетицияне ясарга киттеләр. Париж

Операсының балет төркеме дә шушы ук бинада урнашкан булып чыкты. Шунлыктан, күнегүләрдән бушауга, корбанын эзәрлекләгән мәченекедәй яшертен-сыгылмалы адымнары белән шыпырт-шыпырт басып, Рудольф француз биючеләре янына килеп тә житте:

—Тау Мөхәммәткә килмәсә, Мөхәммәт үзе тауга барыр ди. Гафу итегез... Сезнең белән танышырга күптәннән һәм бик теләсәм дә, безнең житәкчеләр моны өнәп бетерми,—дип сөйләп китте ул рус, инглиз һәм француз сүзләре үзара катыштырылган уртак телдә көчкә-көчкә сукалап.—Тик бу, минемчә, һич кенә дә дөрес түгел! Ничек инде ике ил биючеләре үзара аралашмаска тиеш икән? Без бит-уртак һөнәр ияләре! Без бит-биючеләр!!!

Өч кешелек төркемнән берсе алгарак чыгып, күрешер өчен кулын сузды:

—Әйдә соң, алайса, танышыйк! Мин Пьер Лакотт буламын.

—Рудольф...—диде Нуриев, нишләптер, үз фамилиясен әйтеп тормыйча гына.

—Ә-ә...Нуриевмы?! Беләбез, беләбез!..—диде Пьер Лакотт һәм өскә күтәрелгән баш бармагын шартлатып куйды.—Мерси, месье Нуриев!

—Ә сез мине каян беләсез?

—Чөнки биюегезне күреп сокланганым бар.

—Кайда?

—Венада... Яшьләрнең халыкара фестивалендә... Чайковскийның «Йокыга талган гүзәл» балетыннан Зәңгәр кош биюе... Па-де-де... Фантастика!

—Менә ниче-ек!.. Рәхмәт, Пьер... Пьер...—дип бераз төртелеп торды да, үзе дә сизмәстән, Рудольф шаярту катыш әйтеп куйды.—Ә-ә, Пьер Безухов!

Ләкин бу фамилия дә Пьер Лакоттка таныш булып чыкты:

—О-о, Толстой!.. «Сугыш һәм тынычлык»!..

Кечкенәдән китап укырга бик һәвәс булганлыктан, Рудольф Нуриевның да бу дөньяда һич белмәгән нәрсәсе юк иде. Шуңа күрә Пьер «Безухов» һәм аның иптәшләре белән уртак телне ул бик тиз тапты.

Ләкин әйбәт кенә башланып киткән бу танышлыкны ничек дәвам итәргә? Ә бәлки Киров театры житәкчеләреннән мондый рөхсәтне француз биючеләренең үзләреннән соратып карарга кирәктер?

Пьер Лакотт аксак-туксак тел төбен шунда ук аңлады. Һәм бу теләкне тизрәк гастроль башлыгы Сергеевка житкерергә ашыкты. Ләкин, хәерчегә жил каршы дигәндәй, Константин Михайловичның инглизчәсе ипи—тозлык кына булып чыкты. Аңа хатыны Наталья Дудинская ярдәмгә килде:

—Ерак юлдан килә-килә биючеләребез бик арыды. Аларга кичекмәстән ял итеп алырга кирәк.

Рудольф, өскә сикергән аякларын һавада бер-берсенә бәреп, шунда ук житез пируэт ясап алды:

—Ә мин менә һич кенә дә арымадым.

Дудинская шунда ук аның авызын ябарга ашыкты:

—Сез әле артык яшь. Бөтен кешене дә үзегез белән тиңләргә ярамый, Нуриев!

Гастроль башлыгы Сергеев та, дилбегәне үз кулына алып, хатынының сүзләрен жөпләп куйды:

—О, юк! Болай да йөгән кияргә яратмаган Нуриев берүзе Париж урамнарына чыгып китсен, имеш!

Пьер Лакотт, янәшәдә басып торган иптәшләренә озын куллары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә, аңа каршы төшеп тә карады:

—Без бит дүртәү булачакбыз, месье Сергеев.

—Кемнәр инде ул дүртәү?

—Мин, ягъни Пьер Лакотт, Клара Мотт, Клод Бесси һәм, ниһаять, месье Нуриев. Үзегез дә беләсез: дүртебез дә—биючеләр. Ягъни балет хакында сөйләшәсе уртак сүзләребез күп булачак безнең.

Сүз балет мәсьәләсенә килеп ялгангач, Сергеев та икеләнә калды:

—Шулай булса гына инде... Тик озакка түгел!

—Әлбәттә, месье Сергеев, әлбәттә... Мерси!

Сүзнең ни турында барганын ишетеп, гастроль башлыгы янына шунда ук аның урынбасары Владимир Стрижевский килеп житте. Колакны колакка куеп пышылдаша-пышылдаша, алар тиз генә ни турындадыр кинәшеп алдылар. Ниһаять, бер фикергә килеп, Сергеев уртак теләкләрен әйтеп салды:

—Нуриевка иптәшкә аның бүлмәдәше Соловьев та барыр.

Француз биючеләре моңа каршы түгел икәнлекләрен белдерергә ашыктылар:

—Рәхим итсен!

Үзләрен һичшиксез озатып йөриячәк КГБ шымчыларына артык мәшәкать тудырмас өчен, башта әлләни ерак китеп тормадылар. Клод Бесси дигән биюче кыз шушы тирәдә генә яши икән. Якын-тирә урамнарны бераз урап әйләнделәр дә, тар тыкрыктан кырт борылып, сөйләшү-танышуларны чәй өстәле янында дәвам итү өчен, шулар йортына кереп киттеләр.

Кинәт эз югалткан шымчы күләгәләр исә каушап-югалып калды. Алар, тегеләй дә болай тыз-быз чабышып, «качкын» биючеләрне эзләргә керештеләр.

Ә кунакчыл Клод Бесси өендәге чәй өстәле янында дусларча сөйләшү әйбәт кенә дәвам итте. Дөрес, болай да аз сөйләшә торган һәм оялчан Юрий Соловьев авызына гел су капкандай утырды. Ләкин барлык төймәләре каптырылган сары кәчтүменен эчке кесәсенә баш шымчы Стрижевский тарафыннан салып җибәрелгән шырпы тартмасы хәтле генә нәни магнитофонының тиешле төймәсенә, үз вакыты житкәч, ул тиз генә басып куярга онытмады, әлбәттә.

Ә Рудольф, тел белгән—ил ачар дигәндәй, Соловьев белән икесе өчен дә сөйләде. Дөрес, чит илләргә гастрольләр белән чыккан совет артистларының икесеннән берсенең КГБ шымчысы булуын ул яхшы чамалый иде. Шуңа күрә, сакланганны Ходай саклар дип, сәяси темаларга бик кермәскә тырышты. Ә теләгән очракта бу хакта сөйләшер сүзләр дә байтак җыелган иде. Әйтик, Кубада килеп чыккан хәрби кризис, «салкын сугыш»ның кайнарлана баруы, Франция башлыгы генерал Шарль де Голльнең АКШ президенты Джон Кеннедины Париждагы Елисей сараенда кабул итәргә җыенуы... Ләкин сүз барышы бу тарафларга якынлаша башлауга ук, Рудольф дилбегәне гел балет темасына борып җибәрә килде.

Һәм бик дөрес эшләгән булып чыкты!

Чәй өстәле янындагы эчкерсез һәм тансык сөйләшүгә бирелеп, кичке уннар житүен дә сизми калганнар иде. Димәк, рөхсәт ителгән «комендант сәгате» чыгып, совет артислары тукталган «Модерн» кунакханәсенә кичекмәстән кайтып китәр вакыт житкән! Пьер Лакотт, үз автомобиленә утыртып, Рудольф белән Юрийны тиз генә әлеге кунакханә ишеге төбенә хәтле илтеп куйды.

Кичке урамнан зур тизлектә чапкан машина тормозларын шыгырдата-шыгырдата килеп туктауга, кул сәгатенә карый-карый, Юрий Соловьев кунакханә эченә атылды. Ашыгып-кабаланып икенче кат баскычларыннан менеп килгәндә, аны ачудан симез йөзе тәмам бүртенеп чыккан алыптай гәүдәле Стрижевский каршы алды һәм, җилтерәтеп дигәндәй, үз бүлмәсенә алып кереп китте.

Ә Рудольф, һаман сөйләшер сүзләре бетмәгән әңгәмәдәшеннән тиз генә аерылып китәсе килмичә, Пьер Лакотт машинасы янында байтак басып торды әле. Менә француз дусты, саубуллашыр вакыт житүне белдереп, аңа шоколадлы конфет тартмасын сузды.

—Рәхмәт...—диде Рудольф, ачык тартмадан нибары бер конфетны алып.

—Ал, Руди, тагын ал!—диде Пьер Лакотт, һаман кыстый биреп.

—Юк, Пьер!—диде Рудольф, конфет тартмасын автомобильнең ян тәрәзәсеннән кире сузып.—Әгәр рөхсәт итсән, мин бу конфетларның көн саен берсен генә ашап торыр идем.

Рудольфның самими хәйләгә корылган бу гамәле француз биючеләре белән бүгенгедәй очрашуларны киләчәктә дә дәвам итәргә теләвен белдерә иде. Пьер Лакотт, моңа ризалыгын биреп, Наполеон Бонапартныкына охшаш текә ияген сүзсез генә кагып куйды.

## 4

Киров театрының баш балетмейстеры булу өстенә Париж һәм Лондон гастрольләре өчен җаваплы төп җитәкче итеп тә билгеләнгәч, Сергеевның шиңгән кикригенә тагын кызыл төс керә башлады. Үзе һәм сөекле хатыны Наталья Дудинскаяның олыгаю сәбәпле сәхнәдән читләштерелү ачуын, ак эт бәласе—кара эткә дигәндәй, ул иң әүвәл балет сәнгатенең бүгенге көндәге иң якты йолдызы Рудольф Нуриевка юнәлтте. Дилбегәнең әлегә үз кулында булуыннан файдаланып, тотты да гастрольне ачу спектакльләрендә катнашучылар исемлегеннән Рудольфны төшереп калдырды. Тыңлаусыз һәм алама холыклы башы яшь! Гастрольнең беренче көннәреннән үк, француз тамашачыларының иң көчле алкышлары аңа гына тәтемәсен әле! Өлгерер дан-шөһрәт диңгезендә коенып!

Ә горурлыгына көч килгән Рудольф, гастроль башлыгының чираттагы бу этлегенә үч итеп, Париж сәхнәсендәге беренче спектакльләргә бөтенләй барып та тормады.

Бер атнага сузылачак әлеге «тәрәзә»дән файдаланып, тотты да Париж—башкала белән җентекләп танышырга чыгып китте. Хәзер аның Клара Сент дигән кечкенә генә, ләкин бөтерчектәй гаҗәеп тере гәүдәле, каштан төсендәге чәч көлтәләре нәфис инбашларына шарлавыктай агып төшкән үтә дә чая һәм чибәр яңа танышы бар! Аның белән дә шул ук Пьер дусты таныштырды.

Клара Сент та кечкенәдән сәнгатькә, аеруча аның балет төренә үлепләр гашыйк булып үскәнлектән, ике яшь йөрәк арасындагы дуслык күпере бик тиз сузылды. Дөрес, күзгә-башка әле бик яшь күренсә дә, әтисе—Аргентина рәссамы, әнисе исә Чили кызы булган бу чибәркәйнең инде ярәшелгән егете дә бар икән. Әлеге егет Франциянең бүгенге мәдәният министры, язучы Андре Мальро улы Винсент булып чыкты. Әлегә бу егет чит ил сәяхәтләрендә дөнья гизә икән.

Рудольфның исә моңа карап кына бер дә көнчелек хисләре кузгалмады. Булсын, биш яшендә үк әти-әнисе белән Парижга күченеп яши башлаган шундый чибәркәйнең инде күптән ярәшелгән ышанычлы егете дә булсын! Ул бит министр хәтле министрның кайнар канлы булачак киленен үзенә каратырга җыенмый. Дус-дошманның, аеруча КГБ шымчылары игътибарын үзенә җәлеп итмәү җәһәтеннән, Клара Сентның әнә шундый ярәшелгән һәм үтә дәрәҗәле килен булуы әйбәтрәктер дә әле!

Ләкин гыйшык утында әле беренче мәртәбә генә чын-чынлап яна башлаган яшь йөрәккә фәрман бирү бөтенләй мөмкин түгел—аның үз кануннары була икән шул! Рудольф кебек үк кайнар канлы, рәсем һәм балет сәнгатен кечкенәдән үлепләр яраткан Клара Сент та СССРның ерак Урал тауларыннан килгән татар егетенә тәүге күрүендә үк муеннан гашыйк булды. Ул иң элек аның берәүнекенә дә охшамаган утлы-өермәле биюләрен яратты. Әйе, сәхнәдә—тилергән һәм канатлы өермә! Ә менә шушы тилергән биюче тормышта оялчан гына гап-гади бер егет булып чыкты.

Хәер, гади генәме?

Клара Сент иң элек Рудольфның биюе белән генә түгел, киенү рәвеше буенча да бүтәннәрдән нык аерылып торуына игътибар итте. Чөнки бу вакытта киң таралган модага ияреп, егетләрнең күбесе матросларныкына охшаш киң балаклы чалбарлар кисә, Рудольфныкы урта буйлы гәүдәсенә артык сыланган, артык тар булуы белән әллә кайдан күзгә ташланып тора иде. Ә башында—көрәнсу чәчләре өстеннән кыеклатып чәпәгән кара төстәге француз береткасы.

Кайчан сатып алып өлгергән диген?! Димәк, яшәү һәм киенү рәвеше белән дә Рудольф үз замандашлары, үз ватандашларына охшамаска тырыша.

Клара Сент тагын Рудольфның өске калын-сусыл иреннәренә дә игътибар итте. Тумыштан «куян» иренле мондый кешеләр, гадәттә, сакаурак була. Ләкин Рудольфның сөйләмендә бернинди кимчелек тә юк! Димәк, үзе әйтүенчә, балачакта аны ниндидер эт-мазар тешләгән. Тик ин гаҗәбе шунда: әлеге җөй Рудольфның кыю карашлы йөзен һич бозмый, киресенчә, матур киемдәге затлы төймә кебек, ана өстәмә бизәк, өстәмә нур сирпеп тора иде.

Рудольф та Клара Сентның үзенә артык озак текәлгән карашына игътибар итми калмады:

—Ә-ә... Сабый чакта әтинен ау эте тешләгән мине... Шуннан калган эз ул...

—Менә ниче-ек...

Әтиләргә бәйле сүз бераздан Рудольфның нәсел-нәсәбенә барып ялганды:

—Руди, әйт әле—синен әниен кем булган?

—Татарстанның Әлки районындагы Төгәлбай авылында туып үскән гади бер татар кызы.

—Һөнәре?

—Уфа дигән каланын бер заводында буш шешәләргә сөт—кефир тутырып торган.

—Андый сәер һөнәр дә буламы?

—Була икән шул менә...

—Ә ни өчен Уфада?

—Чөнки булачак әтием шул якларда туып-үскән.

Әниләр мәсьәләсе ачыкланып житкәч тә Клара Сент сораулар бирүен туктатмады:

—Руди дим, Руди! Ә әтиен кем булган?

—Кызыл комиссар...—диде Рудольф, теләр-теләмәс кенә.

—Ә-ә... Полиция комиссарымы?

—Юк... Хәрбие.

—Ә «кызыл» сүзе ни аңлата?

—Революциянен капма-каршы көчләрен бездә әнә шулай ике төскә аерып йөрткәннәр. Кызыллар һәм аклар...

—Кызылы аңлашыла. Ә аклары?

—Алары кызыл коммунистларның кан дошманнары булып чыга инде...

Ярый, болары да ачыклана төште. Ә инде сүз барышы Рудольфның борынгы бабаларына килеп төртелгәч, четерекле сорауларга җавап табу шактый кыенлашты. Ләкин һаман да шул кечкенәдән китаплар күп укып үскәнлектән, Рудольф ерак тарих сәхнәләрендә дә үзен бик иркен хис итә булып чыкты.

—Борынгы бабаларым ни белән шөгыльләнгәнме?..—дип кайтарып сорады ул һәм, бераз уйланып торгач, сүзен дәвам итте:—Жир эшкәртеп, иген иккәннәр... Ватаннарын дошманнан саклаганнар.... Бүтән ил-дәүләтләрне дер калтыратып, кайчакларда үзләре дә яу чапканнар...

—Татарлармы?.. Менә-менә... Ә ни өчен аларны барлык тарихчылар да диярлек начар-куркыныч итеп сурәтли?

—Белмәгәнгә күрә!—дип, черки куган кешедәй, бер кулын кискен генә селтәп куйды Рудольф.—Чиркәү тарихчыларының чираттагы уйдырмасы ул, беләсең килсә.

—Ә ни өчен, алайса, татарлар бүген дә бик күп төбәкләргә сибелеп яшиләр?

—Юк, алар сибелмәгән! Аларның бүген дә борынгы үз җирләрендә гомер кичереп яткан көннәре. Тик көчәеп киткән күршеләре татарларның җирләрен бер-бер артлы басып алганнар. Менә шуңа күрә алар төрле төбәкләрдә утрау-утрау бүленеп калган...

Кичәге һәм бүгенге тарих сәхифәләрендә казыну Клара Сентны да

ялыктыра төште булса кирәк, тиздән ул сүз сөрешен бөтенләй икенче тарафка борып җибәрде:

—Ә хәзер, кадерле Руди, рус ресторанына кереп, тамакларны бераз ялгап чыгарбыз.

Рудольф, ялгыш ишетмәдемме дигәндәй, гаҗәпләнеп сорап куйды:

—Парижда рус рестораны??

—Шулай, Руди, шулай... Менә хәзер үзең күрерсең.

—Мин риза. Әйдә, күрик, алайса.

«Доминика» исемле әлеге ресторан якында гына—атаклы Монпарнас янәшәсендә урнашкан булып чыкты. Анда пешерелгән милли ризыклардан авыз итәргә, нигездә, урыс эмигрантлары йөри икән. Урыс аракысын чөмерә-чөмерә, еракта, инде бик еракта торып калган кадерле, ләкин бүтән һич кабатланмас гомер юлларын тирән сагыш белән искә төшереп утыру аларның күптән инде иң яраткан шөгыленә әйләнгән.

Балта элеп куярлык тәмәке төтене белән тулган ресторан залына кереп утыргач, канәгатьсезлек белдереп, Рудольф йөзен чытып куйды. Чөнки сасы тәмәке дигәннәрен аның кечкенәдән авызына алып караганы да булмады.

Ризык төрләре язылган исемлекне укыштырган арада Рудольф күз карашының бер чите белән генә күреп алды: алар янәшәсендәге өстәлгә киң кырыйлы кара эшләпә һәм шундый ук төстәге плащ кигән ике кеше кереп утырды. Гадәттә, Париж урамнарыннан ялан тәнгә ябышкан мунча себеркесе яфрагы кебек гел үзенә ияреп йөргән шәхси шымчыларын Рудольф күптән танырга өйрәнеп өлгергән иде инде. Боларның йөзләре нишләптер таныш түгел. Совет илчелегеннән урыс эмигрантлары ресторанына махсус җибәрелгән тагын да тәҗрибәлерәк, тагын да дәрәҗәлерәкләре, күрәсең.

Аклы-каралы карлыгач түшенә охшатып киенгән официантларның берсе, колагына хәтле елмаеп, Нуриевлар өстәле янына килеп туктады. Ул әүвәл, чал чәчле башын ия-ия, Клара Сентны сәламләде. Аннары Рудольфка әллә кайчангы танышы кебек балкып һәм , иң гаҗәпләндергәне, чын татар телендә эндәште:

—О-о, месье Нуриев! Француз гәҗитләреннән укып, без сезнең тиздән Париж сәхнәсендә бии башлыйсыгызны беләә һәм күптән көтә идек инде! Тик, нишләптер, һаман күренмисез.

—Шулай килеп чыга шул әлегә...

Кечкенәдән урыслар арасында үссә дә, Уфадан ерак булмаган Әсән авылындагы әби-бабалары янына сирәк-мирәк кайтып торганга күрәме, Рудольф туган телен бөтенләй үк онытып бетермәгән иде әле. Биюче милләттәшенең күптән сагындырган туган телдә җавап кайтаруын ишеткәч, теге официант бөтенләй балкып китте. Түшендә Антонов дигән урыс фамилияле язу эленеп торса да, ул керәшен татарларыннан булса иде кирәк.

Шулай әйбәт кенә сөйләшеп утырганда Рудольфның тавышы яшь әтәчнеке кебек карлыгып чыга башлады. Төнге Париж урамнарын туктаусыз гизеп йөреп, күрәсең, тамагына салкын тидергән иде ул.

Моны официант агай да сизеп алды:

—О-о, месье Нуриев!.. Хәзер тазартабыз ул чирегезне,—дип сөйләнә-сөйләнә, менә ул буфет шкафыннан конгырт төстәге эчемлек салынган бик затлы шешә алып килде. Бөкесен борып ачып, әлеге эчемлекне торна муеныдай тар-биек чәркәләргә агызды.—Рәхим итегез: үзебезнең перцовка!

Аракының исеме «Русская перцовка» булса да, әлеге исем һәм шешә тышындагы бүтән язулар, ни өчендер, француз телендә башкарылган иде. Моның серен беләсе килеп, Рудольф сорап куйды:

—Месье Антонов, үзебезнең перцовка дигәнне ничек аңларга? Туган илебездә ясалган эчемлекме бу, әллә...

—Юк, юк... Франциянеке, месье Нуриев, Франциянеке!

—Нәрсә, суык тигәннән эчелә торган салкын төбәк аракысын җылы якта

яшәүче французлар да ясый башлаганмы? Гажә-ә-әп!

—Гаҗәп шул, месье Нуриев, бик гаҗәп!

—Монын бер-бер сәбәбе дә юк түгелдер инде, ә?

—Бар, месье Нуриев, бар! Һәм ул тарих бә-әк гыйбрәтле! Теләсәгез, хәзер үк сөйләп тә бирермен... Тик башта, танышу билгесе итеп, берне күтәреп куйсагыз иде. Ә үземме? Юк, мина ярамый. Чөнки эштәмен. Аннары мина, шөкер, салкын да тимәгән бит...

Француз перцовкасы, дөрестән дә, бөтен кагыйдәләрен җиренә җиткереп ясалган иде, ахрысы. Бер мәртәбә йотып куюга, ул тамак төбен ачы борыч кебек көйдереп алды.

Кинәт йөзе чытылган Рудольф исә бераздан соклануын белдереп куйды:

—Вәт французлар, ичмаса!.. Ничек шулай оста ясый белгәннәр диген, ә!

Анын сүзләренә официант Антонов кушылды:

—Башына төшкәч башмакчы буласын икән ул!

Рудольф исә һични анламады:

—Башмакнын монда ни катнашы бар икән сон?

—Бар икән шул менә!—диде Антонов.—Ярый, сөйләп бирим, булмаса. Мен сигез йөз дә уникенче елнын көзендә, мәгълүм ки, Наполеон Бонапарт гаскәре Мәскәүне басып ала. Башта эшләр шәп бара боларнын: башкалада азык-төлек күп, көннәр әлегә җылы тора... Ләкин тиздән мәрхәмәтсез салкыннар, Мәскәүдә исә коточкыч янгыннар башлана. Французлар тәртәне азык-төлеккә бай һәм җылырак табигатьле көньякка борып карый. Ләкин, иманнарын укытып, аларны тагын таныш Смоленск юлына борылырга мәҗбүр итәләр. Менә шунда башлана да инде французларга тәмуг газаплары: ашарга—такы-токы, өстә—юка шинель, җитмәсә, бөтен тәннәрне калтыратып, өшеткеч җил-буран уйный.

Ә урыс гаскәренә нәрсә! Һәйбәт туклану, җылы киенүләре өстенә, аларнын алтын ука-чуклы генерал-офицерлары гына түгел, гади солдатларына хәтле тәндәге «таракан»нарны күз ачып йомганчы куып чыгарган ниндидер конгырт сыеклык эчә. Шуна салкын тидереп кырылмыйлар да!

Тырышып эзләнә торгач, чигенгән юл читендәге шәһәр-авылларнын подвалларыннан французлар да сихерле эчемлекне көннәрдән беркөнне табып алалар. Ипи куасы төсендәге шул аракыны эчә башлагач, китә французларнын эшләре хутка! Дөрес, әҗәл даруына әйләнгән ул эчемлек беренче чиратта генерал һәм маршал ише югары дәрәҗәле командирларга гына эләгә.

Ә инде безнен татар һәм башкорт солдатлары да шактый күп хезмәт иткән урыс гаскәре мен сигез йөз дә ундүртенче елда Парижны яулап алгач, бирелдәге Елисей кырында махсус ресторан ачыла. Анда урыс хәрбиләре өчен Рәсәйнен үзеннән күпләп китертелгән атаклы «перцовка»лар сатыла башлый. Аларны парижлылар да бик теләп ала. Шулай итеп, салкын тиюгә каршы уйлап чыгарылган «Себер аракысы» французлар өстәленә дә бик җинел генә менеп кунаклый. Бүгенге көндә ул Париждагы урыс ресторанында ин күп һәм яратып эчелә торган аракылардан санала. Менә шул...

Рудольф милләттәш агае сөйләгәннәрне соныннан җөпләп куйды:

—Да-а!.. Ярыйсы кызык һәм гыйбрәтле тарих икән шул бу, месье Антонов!

—Менә әйттем бит...

Алар тагын, тагын сөйләштеләр.

Рудольфнын үзләренә таныш түгел ниндидер «чит-ят» телдә сөйләшеп торуына кара киемле теге шымчылар да игътибар иттеләр. Җитмәсә, кайда диген—урыс эмигрантлары ресторанында бит әле! Алар ялт та йолт карана башлагач, бөтен ашауның тәме бетте. Шунлыктан, тиешле акчаларын түләп, Рудольф белән Клара Сент биредән тиз генә чыгып тайдылар.

Кичке Париж урамнарыннан култыклашып, ашыкмыйча гына кайтышлый, юл унаеннан әле кайбер кибетләргә дә сугылдылар. Рудольф тәти уенчыклар тезеп куелган киштәләр янына әйди башлагач, Клара Сент кинәт шикләнә

калды: аны бит өйләнмәгән егет дигәннәр иде—әллә курчак белән уйнарлык бала-чагалары ук бар микәнни соң?!

Юк, Рудольф алай бер дә курчак дигәннәренә үрелмәде. Аның бөтен гамендә уенчык рельслардан келтер-келтер тәгәрәгән электр поезды иде! Хәтта кызыл, сары, яшел күзләрен челт-челт ачып һәм йомып торган семафорына хәтле бар! Рудольфның кайчандыр поездда туган тимер юл баласы икәнлеген, гастрольгә барган һәр җирдән диярлек аның паровоз-поездлар апкайтуын, инде мондый сувенирлардан тулы бер депо төзеп җибәрергә мөмкин икәнлеген белгәч, Клара Сент та яңа танышы, яңа дустының сәер гадәтенә гаҗәпләнеп бетә алмады.

Парижның рәсем-картиналар һәм музыкаль әсәрләр сатыла торган кибетенә килеп кергәч тә алар шактый озак тоткарландылар. Рудольфны пейзажчы рәссамнәр һәм Бах, Шопен, Лист, Бетховен кебек композиторларның әсәрләре аеруча кызыксындырды. Әйе, болары аңлашыла иде.

Ә менә Рудольфның хатын-кызлар күбрәк керә торган чүпрәк-чапрак кибетенә ыргылуын Клара Сент башта һичничек аңлый алмады. Егетне СССР кибетләрендә әлегә сатылмый торган «лайкр» исемле яшел тукыма аеруча кызыксындырды. Клара Сент өчен шулай ук бик сәер тоелган бу гамәлен исә Рудольф «Мәхәббәт турында легенда» балетындагы Фәрхад ролен башкару өчен тегеләчәк киемнәре белән бәйләп аңлатты.

СССРдан чит ил гастрольләренә килгән артист халкы, гадәттә, үзенә, туганнары һәм дус-ишләренә чүпрәк-чапрак сатып алудан бушый алмый. Дөрес, Рудольф та дефицит әйбер җыя. Ләкин үзе өчен түгел, ә ярты юлда бүленеп калган, киләчәктә һичшиксез башкарыласы Фәрхад роле өчен җыя!

Әйе, Клара Сентның болай да гашыйк күңелен сөендереп, Рудольфның чын биючеләргә, зур биючеләргә генә хас мондый асыл сыйфатлары торган саен күбрәк ачыла бара иде.

## 5

Моңарчы җибәрелгән эреле-ваклы гөнаһлары өстенә, Рудольф Нуриев һәм «Чили шпионкасы»сының бүген урыс эмигрантлары рестораныңда булуы, анда ниндидер шикле официантлар белән кеше аңламый торган чит-ят телдә сүз куертуы хакында шомлы хәбәр сәгате-минутында ук Киров театры җитәкчелегенә килеп ирешкән иде инде. Тыелган мондый гамәлләр өчен аларның да башларыннан сыйпамаслар, мөгаен.

Гастроль башлыгы Константин Сергеев аеруча борчуга төште. Юк, каһәр төшкере теге Нуриевны дүрт-биш көн элек үк Париж сәхнәсенә чыгармыйча, ул артыгын да бөгеп җибәргән түгелме соң? Имеш, кайчандыр үзе биегән рольләрне аның тагын да әйбәтрәк итеп башкаруыннан көнләшә. Имеш, гастрольнең беренче көннәреннән үк Париж тамашачылары алкышларына аның гына күбрәк лаек булуыннан курка... Ә менә хәзер тиешле җавабыңны ничек бирерсең? Ә бит сораячаклар аңардан, һичшиксез, сораячаклар:

—Нигә әле Нуриев дигән биючегез көне-төне чит ил рестораннарында типтереп йөри? Нигә аны сәхнәдә биетмисез? Нигә француз тамашачысы ничә көн инде Нуриевның биюен таләп итеп кычкыра? Нәрсә бу, нинди саботаж?!—диячәкләр.

Ә Сергеевның акланыр сәбәбе бармы? Дөресен генә әйткәндә, юк андый җавап! Әйе, үзсүзле Нуриевны акылга утыртмак булып, ул үзе тишек көймәгә кереп бара түгелме соң?!

Ә бит эшләр Дәүләт Иминлеге Комитетына барып җитсә, анда күп сөйләшеп тормаслар. Театрның баш балетмейстеры дигән дәрәҗәле исемеңнән генә түгел, газиз ирегеңнән дә бик тиз колак кактырулары бар. Шуңа күрә тизрәк Нуриевка карата кылган хилаф гамәлеңне, Сергеев, төзәт! Әле соң түгел! Югыйсә, үзеңне төзәтәчәкләр!

Рудольф Нуриевнын бүген кич «Баядерка» балетында Солор партиясен башкарырга тиешлеген Сергеев спектакль башланырга нибары бер сәгать кала кереп әйтте. Әле дә ярый, алдан сизенгән кебек, ул Парижлагы дусларына янына чыгып китмәгән иде.

Шушы берничә көндә генә дә үзенә каршы әллә нихәтле киртәләр куеп өлгергән Сергеевка ачуы бик яман иде Рудольфнын. Ләкин ул, ниһаять, зур сәхнәдә бүген башкарылачак биюе хакына, үзенен ярсу холкын тыеп калмакчы иде.

Тик барыбер чәнечкеле укларын юнәлтми кала алмады:

—О-о, сәхнәгә чыгарга әле тагын бер сәгать бар! Нигә аны шулай иртә әйтергә булдыгыз?!

Рудольфнын төрттерүен Сергеев башта анламаганга сабышып маташты:

—Өлгерәсез... Сезгә әле балетнын өченче актында гына чыгасы.

—Ә буянасы-бизәнәсе?—диде Рудольф, усал шаярту чәнечкеләрен һаман тирәнгәрәк батырып.

—Син нәрсә?..—диде шактый каушый төшкән Сергеев, ничек «сез»дән «син»гә күчүен дә сизми калып.—Зәнгәрләр генә ул бизәнә дә сылана дигәндәй...

Һәм кыек атып, туры тидерелгән үтергеч җавап:

—Зәнгәрләрдән ишетәбез, Константин Пи-ха-лыч!

Сергеевнын кайчандыр Киров театрындагы зәнгәрләр исемлегендә йөртелүен Рудольф монарчы да ишеткәләгән иде инде. Анын сүзләре баш хореографнын бик авырткан җиренә килеп тиде, ахрысы. Тән-фигыле генә түгел, җан төзелеше дә үтә нечкә кузәнәкләрдән яратылган Сергеевнын нәфис йөзе, житәрлек кан килми башлаудан, кинәт балет чүәгедәй ап-ак төскә керде.

Бераздан ул үзен кулга алды һәм, әҗәткә каршы йомыш дигәндәй, Рудольфнын әтисе исеменә төрттереп куйды:

—Ну и Хамиты-ыч!.. Ну и Ха-а-ам!..

—Гамәленә күрә җавабы...

Ләкин Сергеевнын әйтәсе сүзе бетмәгән икән әле:

—Безнен яшьлектә кылынган гөнаһлар, буласы булган—буявы сенгән дигәндәй, инде үткән дә киткән... Ә менә синен ул зәнгәрләр исемлегенә килеп эләгәсе көннәрен алда әле. Кара аны—сак бул! Инде беренче сигналлар килә башлады...

—Куркытмагыз ла...

—Мин куркытмыйм. Уеннан уймак чыга күрмәсен дим...

Бүтән чакларда сәхнәгә чыгар алдыннан, үз бүлмәсенә бикләнеп, Рудольф уйларына чумып алырга ярата иде. Дөресрәге, башкарасы биюләренен һәр мизгелен тагын бер мәртәбә күнел күзе аша үткәрә. Шул ук Сергеев аркасында, бүген монысына өлгерә алмады—хәерлегә була күрсен!

Ләкин Рудольф мона артык борчылмады. Чөнки Парижга китәр алдыннан анын яраткан остазы житәкчелегендә ясалган бер айлык күнегүләре әрәмгә китмәгән—гастрольләр исемлегенә кертелгән теләсә кайсы балеттагы төп рольне монарчы күрелмәгән ин югары дәрәҗәдә биерлек булып, бөтен тән буыннарына яна көч, яна омтылыш кереп тулган иде. Сәхнәгә атылып килеп чык та, тамашачыларны һуштан яздырып, менә хәзер үк бии башла! Ул мона әзер, күптән әзер иде.

Санаулы минутлар тиз үтә икән...

Менә «Баядерка» балетынын беренче акты башланыр мизгелләр дә килеп житте.

Тик чү, ни бу?!

Пәрдә ачылып бетәргә дә өлгермәде, «Ну-ри-ев!» та «Ну-ри-ев!» дип бертуктаусыз кычкырып, түземсез тамашачылар Рудольфнын, ниһаять, Париж сәхнәсенә чыгып күренүен таләп итә башладылар. Югыйсә, ничәнче көн

инде алар Ленинградның нәкъ менә шушы яшь биючесе чыгышын күреп ләззәтләнү өчен киләләр. Ә ул юк та юк! Ягъни француз тамашачыларына балта урынына шөшле тоттырып алдыйлар түгелме?

Бүген тамашачылар аеруча күп килгән иде. Залда гына түгел, рәт араларында да энә төртерлек буш урын юк! Рудольф Нуриевнын бүгенге «Баядерка» балетында, ниһаять, биергә тиешлеге турындагы хәбәр килеп ирешкән, күрәсең. Нишләтәсең, тамашачы таләбенә буйсынмый кала алмыйсың. Нуриевны бүген тере килеш күрмичә, ул сәхнә алдында тынлаусыз чәчле башын имичә торып, тамаша залы тәки тынычланмады.

Балетның беренче ике акты уңышлы гына тәмамланды. Ләкин көн дә була торган мондый уңыш кына уңыш димени ул?! Менә хәзер, ичмаса, сәхнәгә утлы өермә үзе килеп чыгачак! Берәүләр аны канатлы, икенчеләр хәтта тилергән өермә дип тә атыйлар. Кайсысы дөресрәктер? Ләкин өермә, ни әйтсәң дә, өермә инде!

Кыскасы, Париж хәтле Париж сәхнәсендә ярсу өермәне тизрәк күрәселәре килеп, бөтен кеше, бөтен тамашачы түземлекнең соңгы чигенә җитә-җитә тәмам әсәренгән иде.

Бер үк хәрәкәтләрне кабатлый-кабатлый, диагональ буйлап, менә сәхнәгә егерме дүрт кыз чыгып тезелде. Өрсәң очып китәрлек сыек зәңгәр күлмәкле, нечкә билле ул биючеләрнең бармак очларында бөтерчек кебек бертуктаусыз әйләнеп торулары иртәнге җилдә талгын гына тирбәлгән томанлы иген кырын хәтерләтә иде. Биюче кызлар—зәңгәр күләгәләр. Чөнки әсәрдә сурәтләнгән индус сугышчысы Солор төшендә кайчандыр үзе өзелепләр сөйгән, инде вафат булган баядерка Никияне күрде. Бөтен тән буыннарына әбелхәят суы бөркелгәндәй көч-гайрәт өстәлгән Рудольф—Солорның җәя угыдай ничек очып керүен күргәч, тамашачылар сокланудан телсез калды. Бу очышка, балет биючеләре телендә антраша дип йөртелгән бу гүзәл хәрәкәткә Рудольф Нуриев бар кодрәтен, бар гайрәтен салган иде шул.

Иң әүвәл ул, ике инбашын ике кулы белән кочаклап, өскә орчыктай томырылды. Һәм ике аяк белән дә берьюлы этелеп! Бу хәрәкәтнең бөтен кыенлыгы һәм матурлыгы да нәкъ әнә шунда иде. Әлеге этелү шулкадәр дә көчле килеп чыкты ки, Рудольфның гәүдәсе бермәлгә һавада дирижабль кебек эленеп тора башлады. Тик көчле мускуллы аякларының, бөркет канат каккандай, әледән-әле бер-берсенә бәреп куюлары гына җирнең тарту көчен җингән бу хәрәкәтнең дөрестән дә чын очыш икәнлеген искәртеп тора.

Менә бу антраша дисәң дә антраша! Менә бу, ичмаса, чын биюче! Ә үзе нинди яшь! Аннары Рудольф Нуриевның бүтән бер биючедә булмаган сере—тамашачыга нindидер сихри тәэсир итү көче бар иде. Сәхнәдә ул биергә керешү белән, тамашачы йөрәгенә аның киереп ачылган бәгыреннән күзгә күренмәс нindидер токлар агыла башлый. Һәм әлеге көч спектакль азагынача залны сихерләп тота.

Ә бу көчнең нигезен тәшкил иткән иң төп нәрсә—биюченең тумыштан бирелгән таланты, аның теге яки бу партияне башкарганда чагылган ихласлыгы, үҗәт тырышлыгы. Моның нәкъ менә шулай икәнлеген залдагы һәр тамашачы ачык тоеп утырды.

Күптән, инде бик күптән мондый дәрәҗәдәге бию осталыгын күрмәгән Париж тамашачылары уч төпләре уттай кызганчы, идәнгә аяклары белән тибә-тибә, кул чаптылар. Һәркайсының телендә—Нуриев та Нуриев!

Әлеге тамашачылар арасында Франция хөкүмәтенең сәнгать киңәшчесе Игорь Эйснер, соңгы көннәрдә Рудольфның аерылмас юлдашы Клара Сентка ярәшелгән егет әтисе, илнең мәдәният министры Андре Мальро кебек идарәче шәхесләр утыру бүгенге көчле алкышлар дәрәҗәсен тагын да үстереп җибәрде, билгеле.

Ләкин Рудольфны иң гаҗәпләндергәне гастроль башлыгы Константин Сергеев булды. Спектакль тәмамлануга, сәхнә артына йөгереп диярлек кереп,

Рудольф Нуриевнын кулын ин беренчеләрдән булып ул кысты:

—Котлыйм, Нуриев! Парижлагы гаҗәеп зур уңышын белән ихластан котлыйм!

—Рәхмәт, Константин Михайлович!

Рудольфтан бигрәк үзе өчен бугай, үкенечле тавыш чыгарып, Сергеев өстәп куйды:

—Хәер, мин бу дебютыңның нәкъ менә шулай могҗизалы һәм уңышлы буласын күптән белә идем инде...

«Белгәч соң?.. Париж сәхнәсенә мине ник элегрәк чыгармадың? Ник аяк чалып маташтың?» димәкче иде дә, яшь көндәше уңышларына сөенүнен картаеп барган биючегә ансат булмавын чамалап, ярый әле вакытында телен тешләде. Сәнгать дигән бөек көчнең һәртөрле үпкә-сапкаларны оныттырып торырга сәләтле сихри сихәте бар, күрәсең. Ә бит килгән... баш хореограф, горур башын иеп, яшь көндәшен котларга килгән! Килә алган!! Моның өчен аңа рәхмәттән тыш ни әйтәсең?!

6

Рудольф Нуриевнын Париж сәхнәсендәге кичәге дебюты турында язган «Фигаро», «Ле Монд» һәм башка француз газеталарын күздән кичереп чыккач, канәгатьсезлек белдереп, КГБ капитаны Владимир Стрижевский арпа башагыдай саргылт-йонтәс кашларын җыерып куйды. Кайсына гына карама—Нуриев та Нуриев! «Рус балетының татар фамилияле яна йолдызы», «Париж сәхнәсендә могҗизалы очыш», «Сәхнә космонавты»... Фәлән-фәсмәтән! Тәмам Алланын кашка тәкәсе иткәннәр Рудольф Нуриевны!

Ә ул кашка тәкә кичә нишләгән?! Тоткан да, чит ил сәхнәсендәге беренче зур уңышын билгеләп үтү өчен, француз дуслары белән Елисей кырына—«Тилергән ат» исемле төнге клубтагы шәрә хатын-кызлар чыгышын карарга китеп барган. Әле кайчан гына рус эмигрантлары ресторанында Чили өстерәлчеге белән буталуы җитмәгән, инде хәзер шәрәләр исе борынына керә башлаган, димәк ки?

Тукта, чү! Шәрәләр дигәннән...

Нуриев ишедәй тимер авызлыклы йөгән кияргә яратмаучылар өчен күптән әзерләп куелган теге запас кармакны кулланыр чак җитмәде микән? Чөнки, бию түгәрәгенә йөрүне катгый тыйган этисен кечкенәдән алдап-юлдап үскәнлектән, Рудольф бу өлкәдә бик остарган хәйләкәр төлке булып чыкты. Ул барлык гамәлләрен дә, менә күрегез дигәндәй, КГБ шымчылары күз алдында эшли. Бер караганда, ана һичничек бәйләнеп тә булмый кебек. Кичке спектакльдән соң, зәңгәр автобуска утырып,бүтән биючеләр белән кунакханәгә кайта. Утны сүндереп йокларга яткан була. Һәм берәздән, кунакханә эшчеләре йөри торган арткы ишектән, төнге урамга чыгып шыла.

Ләкин төнге Париж белән сокланып йөргән өчен генә кешене җинаять җаваплылыгына тарттырып булмый. Хөкем итәр өчен саллы дәлилләр кирәк. Ә алар юк! Рудольфның даими юлдашлары саналган Пьер Лакотт белән Гислен Тезмар—Париж операсының ирле-хатынлы биючеләре! Клод Бесси—шулай ук ышанычлы артист. Ә инде Нуриевнын аерылмас юлдашы Клара Сентка карата берниндн шик тә туа алмый. Чөнки ул—Франция мәдәният министры улының ярәшелгән кәләше. Винсент Мальро ерак сәяхәтеннән кайтып төшүгә, алар туйларын үткәрәчәк! Менә бит: хәйләкәр Нуриев КГБның очлы күзләреннән саклану кирталәрен ничек оста корган! Аны ялан кул белән генә эләктерә алмыйсың! Димәк, хәйләгә каршы хәйлә куллану фарыз.

Ә Киров театры директорының сәяси һәм масса эшләре буенча урынбасары булып исәпләнүче КГБ капитаны Владимир Стрижевский күптән әзерләп куйган хәтәр кармак шуннан гыйбарәт иде: балет сәнгатендә «зәңгәрлек»

чире шактый киң таралган. Аеруча—көнбатыш илләрендә. Чөнки анда бу хәтәр чир үз иркенә куелган. Бернинди рәсми тыюлар да бөтенләй юк диярлек. Һәр аулак почмакта—ирек, ирек, ирек!

Дөрес, СССРда шулай ук шактый андыйлар. Ләкин бу оят һәм хәтәр шөгыль бирелә бик яшерен төстә, бик куркып кына кылына. Курыкмассың бар! Баш очында гына үткен кылыч—Җинаять кодексының 120 һәм 121нче маддәләре эленеп торсын да! Аларның икесе буенча да гаепләнүчене җиде елга ирегеннән мәхрүм итү каралган. Һәм бу үткен корал монархы дәүләт иминлеге саклау оешмаларына бик турылыклы һәм нәтиҗәле хезмәт итеп килде.

Әгәр шушы ук кылычны, бераз куркытып алу өчен, Рудольф Нуриевның баш очында да ялтыратып карасаң? Дөрес, әлегә аның ни туган илендә, ни Парижда зәңгәрлек чире белән тотылганы булмады. Ләкин фаш ителгәч, илгә исе чыга башлый. Хәзер исә нәкъ вакыты.

Ә тәртәгә тибеп маташкан яшь алашаны кабат тәртә арасына кертүнең капитан Стрижевский әллә кайчан уйлап куйган юлы үтә гади һәм ышанычлы иде. Алар бит ут холыклы Рудольф Нуриев белән аз сүзле, юеш-күндәм Юрий Соловьевның икесен юкка гына бер бүлмәгә кертмәделәр. Менә хәзер беренчесенең һәр атлаган адымы, һәр сөйләшкән сүзе, һәр сулаган сулышы, минуты-секундында дигәндәй, тиешле кешеләренә җиткерелеп барыла. Кирәксә, алар хәтта Рудольфның фәлән көнне фәлән кибеттән ни нәрсә сатып алганына хәтле белеп торалар.

Ләкин хәзер инде Юрий Соловьевны үз көндәшенә каршы тагын да нәтиҗәлерәк файдаланыр чак килеп җитте. Әнә шул ният белән, табышына якынайган мәчедәй сак-йомшак кына басып, ул яшь биюче бүлмәсенә юнәлде. Рудольф Нуриев, гадәтенчә, кичке биләменнән кайтмаган иде әле. Ә Юрийның яраткан үз шөгыле—караватында ниндидер тарихи китап укып ята.

Ишектә Стрижевский күренүгә, Соловьев ятагыннан ялт кына сикереп торды:

—Рәхим итегез, Владимир Дмитриевич!

—Рәхмәт, Юра!—диде Стрижевский, караватчитендә вак шпаллы рельсләрен өскә күтәреп яткан уенчык поездны кулына алып—Охо-о... Бер көпчәге рельстән каерылып ук чыга башлаган... Димәк, еш уйныйсыз?

—Ыхы... Күбрәк Рудик уйный. Ни дисәң дә, поездда туган тимер юл баласы бит.

—Китче, булмастыр ла!

Соловьев, үзең КГБ офицеры—үзең шуны да белмисең дигәндәй гаҗәпсенеп, капитан Стрижевскийга карап куйды:

—Рудик үзе моны берәүдән дә яшерми.

Һәр нәрсәне бөтен ваклыкларына тикле белергә тиешле капитанның горурлыгына көч килде, ахрысы. Ул шунда ук сүзне икенче якка борып җибәрү ягын карады:

—Соңгы спектакльләрдә француз тамашачыларының кемгә күбрәк кул чабуын үзең дә күрәсеңдер дип беләм.

—Күрәм, билгеле—Рудикка!

—Гастрольнең иң беренче көннәрендә, ул биемәгәндә, алкышларның иң көчлесе сиңа эләгә иде төсле.?

—Мин көнләшмим, Владимир Дмитриевич... Чөнки алкышларның иң көчлесенә ул—нәкъ менә Рудик Нуриев лаек!

—Ай-һай... Лаек микән?

—Ә нигә икеләнергә?

—Биюче буларак, бәлки лаектыр да... Ә менә гражданин, үз иленен патриоты буларак? Гастрольдәге ирекккә чыккач, күпме гасырлар иелгән башын югары күтәрде поганый татарин! Көн саен нинди дә булса мөгез чыгармыйча калмый. Кичә рус эмигрантлары ресторанында буталган. Бүген Ларин

фамилияле тагын бер эмигрант белән танышып алган...

—Анысы кем икән инде?

—Дәүләти булмаган Париж балетын оештырып җибәрүче диме шунда. Хезмәт юлын кенәз Феликс Йосыповка ялланып эшләүдән башлап җибәргән икән.

—Кенәз Йосыпов? Теге атаклы шамакай Распутинны үз куллары белән атып үтергән кенәзме?

Бу урында капитан Стрижевскийга, белем шәрифләренең сайлыгы өчен, шәкерте алдында тагын кызарырга туры килде:

—Менә анысын белмәгән идем...

—Әгәр шул кенәз икән—Казан ханбикәсе Сөембикәнең әтисе Йосыф морзага ерак оның тиешле кеше дә була инде ул.

—Шулдыр, шул кенәздер...—дип җөпләп куйды капитан Стрижевсий, ниһаять.—Кенәз Йосыповта хезмәт итүен белгәч, теге Ларин дигән эмигрантка Рудольф Нуриев менә ни өчен мунча себеркесенең яфрагы кебек ябышты. Атаклы кенәз Йосыпов һәм биюче Нуриев! Ни әйтсән дә, тамырларында бер үк татар каны ага шул!

—Анысы шулайдыр... Тик ни бит, Владимир Дмитриевич...

—Нәрсә?

—Сез бая әйткән Ларин фамилияле кеше рус эмигранты түгел, ә французларның Парижда яшәүче күренекле балет эшлеклесе Раймундо де Ларрен булырга охшаган. Ишетәсезме, Ларин түгел—ә Ларрен!

Капитан Стрижевскийның симез бите, ни өчендер, кинәт чөгендер төсле кызарып чыкты:

—Ларрен?.. Чынлапмы?..Каян беләсең?..

—Ничек инде, Парижга гастроль белән килгән балет биючесе шул Париждагы атаклы балет эшкуарын белмәсен икән? Җитмәсә, Раймундо де Ларрен түгел, ә аның булачак хуҗасы маркиз де Куэвасның кайчандыр Парижда зур кибетләр тоткан кенәз Йосыповта хезмәт итүе хакында без дә Рудольф белән күптән түгел генә укыган идек.

—Парижга килгәчме?

—Әйе.

—Ә ул китапны каян алдыгыз?

—Рудикка яңа танышы Клара Сент бүләк иткән.

Таныш фамилия ишетелгәч, капитан Стрижевский көрәктәй ике кулы белән җирән чәчле чигәләрен кысып тотты:

—Уф-ф!.. Тагын Чили шпионкасы!..

—Алай димәгез... Франция министрының булачак килене ул!

—Беләбе-ез...

Капитан Стрижевскийның исә үз кайгысы кайгы иде. Театрның бүтән житәкчеләренә әйтеп тормыйча гына Нуриевның Париждагы кыланышлары хакында Мәскәүгә җибәреп өлгергән яшерен хәбәрендә ул, нәкъ менә ул мәгълүм француз эшлеклесе де Ларренны, һаман да шул наданлыгы сәбәпле, рус фамилиясе Ларин белән атаган иде. Өстәвенә, маркиз де Куэвасны да шушы ук аләм белән бутаган!Әгәр чорманның бик чамалы икәнлеген Мәскәүдә сизеп алсалар, оятыннан кайларга барырсың?

Бер карасаң, Ларрен ни дә, Ларин ни! Тик юк шул: аерма—җир белән күк арасы! Монда бит ашыгыч һәм үтә яшерен хәбәрдә җибәрелгән тупас хата турында сүз бара! Һаман да шул киребеткән Нуриев аркасында. Юк, артык узына башлаган бу малайны, ниһаять, тиешле урынына утыртыр вакыт җитте кебек. Юкса, ул татыйсы тукмак, тиешле чаралар күрмәгәнен өчен, үзеннең газиз башкаена килеп төшә башлавы да бик ихтимал.

Театр директоры Георгий Коркин белән художество житәкчесе Константин Сергеев берни югалтмаслар. Рудольфның ил йөзен кызартырлык кыланмышлары өчен алар коры кисәтү алырлар да котылырлар. Ә менә син,

капитан Стрижевский, инде исе чыга башлаган майор дигән дәрәҗәле исемнән генә түгел, хезмәт урыныңнан да шәпләп кенә колак кагуың бик ихтимал!

Иң әйбәт саклану чарасы—үзең һөҗүм итү, диләр. Димәк, алга, алга, булачак майор!

Наданлыгы өчен оялу хисләрен җиңеп, капитан Стрижевский сүз дилбегәсен тагын үз кулына алды:

—Ә бүген, Юра, Нуриев чираттагы төнге биләменнән кайтуга, без синең белән кечкенә генә тамаша куеп алырбыз!

—Нинди тамашадыр бит...

—Бурыч бик гади: ничек итеп Нуриевның төлке койрыгын зәңгәр капкынга эләктерергә?

Юрий Соловьев һични аңламады:

—Зәңгәр капкын? Анысы ни тагын, Владимир Дмитриевич?

—Тиздән аңлашылыр... Ә теге төн кошы кайткач, син белән авыртып торудан зарланып алырсың. Аннары массаж ясавын үтенерсең.

Бу урында Соловьев, шымчылык кубызына ничек бии башлавын тоеп, каршылык күрсәтеп маташты:

—Әгәр үтенмәсәм?

—Димәк, әйбәт кенә башланып киткән биючелек карьераңны тәмам бозачаксың! Онытма: бездә каршы әйтүчеләрне яратмыйлар!—диде Стрижевский, кырыс кына итеп. Һәм юатулы тавыш белән өстәде.—Курыкма... Нуриевның сиңа төнге массаж ясый башлавы гына кирәк.

—Шуннан?

—Утырган да шуган—ыштанына кар тулган, диләрме әле?

—Мин шаяртмыйм, Владимир Дмитриевич.

—Мин дә!—диде Стрижевский, җитди төскә кереп.—Шуннан шул: ике шаһит пүнәтәй, тиешле протокол!

Капитан Стрижевский җеп очларын яшереп маташса да күнел күзләре киерелеп ачылган Соловьев һәммәсен дә аңлап алган иде инде:

—Һәм миннән гаризамы?

—Юк, бу юлы кирәкми!—дип тынычландырды аны мәкерле Стрижевский.

—Ә нигә?

—Чөнки бу юлы без, рәсми төс биреп, эшне зурга җибәрергә җыенмыйбыз. Безнең ният—җиде ел төрмә белән кисәтеп, Нуриевны нык кына бер куркытып алу! Бәлки, файдасы тияр!

## 7

Капитан Стрижевский дөрес уйлаган булып чыкты.

Ике пүнәтәйле төнге тамашадан соң, алыштырып куйгандай, Рудольф тәртибен кискен үзгәртте. «Модерн» кунакханәсенә соңлап кайтулар хәзер бетте. Француз танышлары белән Париж рестораннарына йөрү туктатылды. Хәер, мона хәзер вакыты да калмый иде аның. Гастроль спектакльләрендә кич саен биисе. «Баядерка»дан соң «Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», «Дон Кихот» балетлары да зур уңыш белән үтте. Һәркайсында төп партияләрне биегән Рудольф Нуриевның осталыгы бүтәннәрнекеннән бер башка аерылып торды. Париж гәҗитләре аны егерменче елларда бөтен Францияне шаулаткан, тамырларында татар каны да аккан атаклы поляк биючесе Вацлав Нижинскийга тиңләделәр, җирнен тарту көчен җиңгән галәмәт биек сикерүләре өчен, кешелек дөньясының шул көннәрдә ирешкән иң зур казанышын күздә тотып, «сәхнә космонавты» дип атадылар.

Рудольф беренче уңышлардан баш әйләнү чиренә каршы торуның иң үтемле чарасы—тирле хезмәт икәнлеген яхшы аңлый иде. Шуңа күрә ул, тудырылган мөмкинлектән файдаланып, биеде, биеде һәм тагын бер кат биеде!

Әйе, Сергеев аяк чалу сәбәпле гастрольнең беренче көннәре Рудольф өчен бик уңышлы килеп чыкмаса да, тора-бара һәммәсе көйләнде-түгелгән тир, ирешкән осталык һәрвакыт үзенең куанычлы нәтиҗәләрен бирмичә калмый икән шул!

Тик менә бу көннәрдә ышанычлы яңа танышы Клара Сентның газиз башкаена ишелеп төшкән тау хәтле кайгы белән генә нишләргә? Ярәшкән сөеклесе Винсент Мальронның автомобиль һәлакәтендәге фаҗигале үлемен ишеткәч, ул бөтенләй Рудольфтан аерыла алмас хәлгә килде, ана тәмам сыена башлады...

Көтелмәгән бу үлем исә усал агайларның Рудольфка бәйләнү мөмкинлеген дә шактый арттыра төште. Чөнки ике гашыйк йөрәк арасыннан өченче көндәш алып ташланды. Хәзер аларга үзара якынаю өчен һичкем комачаулый алмастыр...

Үзенә ни янавын тоеп, Сент белән мөнәсәбәтләрендә дә Рудольф итәк-җиннәрне җыя төште. Клара исә, ни сөенеч, моны дөрес аңлады. Аралардан салкын язмыш җиле исеп куйган өчен Рудольфка аз гына да үпкәләмәде.

Ләкин капитан Стрижевскийның театр язмышыннан бигрәк үз киләчәген кайгыртып юллаган теге кара хәбәре тиешле эшен үтәргә керешкән иде инде. СССРның Франциядәге илчелегендә КГБ резиденты булып хезмәт итүче имзасы да куелган әлеге шомлы хәбәр иң әүвәл Дәүләт Иминлеге Комитеты башлыгы Александр Шелепин өстәленә менеп ятты. Кайчандыр Сталинның иң ышанычлы шәкертләреннән саналган, берара ил комсомолын җитәкләп танылган бу «тимер Шурик», остазы күптән түгел шәхес культында кискен гаепләнү сәбәпле, соңгы вакытларда бик сак—җиде кат үлчи-үлчи, бер мәртәбә кисеп эш итәргә күнеккән иде. Аеруча элек-электән кызыл йөгән кияргә яратмаган балет артистлары белән үтә четерекле мәсьәләдә «колагы» торган иде аның.

Франциядән алынган яшерен хәбәрне Шелепин башта кат-кат укып чыкты. Анда бу көннәрне бөтен Париж сәхнәләрен гөр китергән совет биючесе Рудольф Хәмит улы Нуриевның коммунизм төзүчегә хас әхлак кагыйдәләренә туры килмәүче хилаф гамәлләре бик җентекләп язылган иде. Таныш фамилия күзенә чалынгач, тигез юлда сөртенгән кешедәй, Шелепин укуыннан кинәт туктап калды.

Нуриев, Нуриев!

Тукта, кайда ишеткән иде соң әле ул телгә бик тә ятышлы бу татар фамилиясен? Ә исеме, никтер, Гитлерныкына охшаган.

Хәтер шүрлегендә казына-казына, Шелепин хәтта авыз эченнән генә таныш исемнәрне кабатлап куйды:

—Рудольф тә Адольф, Адольф та Рудольф...

Әһә-ә-ә! Тәки исенә төште...

... Моннан бер ел чамасы элек—КПСС Үзәк Комитеты Президиумы әгъзасы Николай Булганин дачасында булган иде ул истәлекле очрашу. Әле кайчан гына илнең бу зур түрәсе СССР хөкүмәтен җитәкли иде. Сталин үлгәч, ил дилбегәсе өчен көрәшнең кискенләшүен, бөтен көч-куәтнең бер кулда гына булырга тиешлеген сылтау итеп, КПСС Үзәк Комитетының Беренче секретаре Никита Сергеевич Хрущев Булганин вазифасын да үзләштерде. Ләкин моңа карап кына алар арасыннан кара мәче узмады кебек. Һәрхәлдә, инде шактый картаеп өлгергән Булганин Хрущевка карата үпкә белдермәде. Алар элеккечә үк ышанычлы дуслар булып кала алдылар. Булганин дачасында уздырылган истәлекле очрашу да шушы дуслыкның бер чагылышы иде.

Ни өчен истәлекле? Чөнки табигатьнең Мәскәү янындагы гүзәл бер почмагында ил җитәкчеләре белән бу дәрәҗәле очрашуга мәшһүр композиторлар Дмитрий Шостакович, Арам Хачатурян, виртуоз маэстро Святослав Рихтер кебек сәнгать осталары да чакырылган иде. Менә шул осталар арасында ике яшь биюче—Рудольф Нуриев һәм Ирина Кургапкина

да бар иде. Очрашу программасында язылганча, алар шаян-шук музыкалы «Дон Кихот» балетыннан вариацияләр башкарырга тиеш иделәр. Әлбәттә, халык көйләренә якын торган, шуңа күрә картлар күңеленә аеруча ошардай мондый үтә тере һәм җанлы музыкалы бию тиккә генә сайлап алынмаган—Никита Сергеевичның ташып түгелергә җиткән гәүдәле хатыны Нина Петровна һәм, димәк ки, Хрущев үзе дә үлепләр балет карарга яраталар иде.

Ил башлыгының капитализм белән узышта совет сәнгатенен алгы сафларда барырга тиешлеге турында шактый озакка сузылган нотыгыннан соң, ниһаять, «оҗмах»ка җыелучылар стендлы ату ярышларында көч сынаша башлады. Ярышларның бу төрендә Советлар Союзы Маршалы Климент Ворошиловка тиңнәр табылмады. Ә менә янәшә урмандагы тере кабан дуңгызына атуда Никита Хрущев берәүгә дә маһы бирмәде.

Каршыдагы тирән һәм чиста сулы буадан алтын тәңкәле кәрәкәләрне каптырып шактый арыгач, кетер ак җәймәле, сый-сихәт муллыгыннан сыгылыплар торган озын өстәлләр тирәсенә килеп утырдылар. Совет сәнгатенең алда торган бөек уңышларына ак юл теләп, бер-бер арты шампан бөкеләре атылды. Һәм менә оҗмах җирендә очрашуның күптән көтелгән җырлы-биюле өлеше башланып китте. Бер-бер артлы тезелешеп киткән озын өстәлләргә каршы якта, бөтенләй янәшәдә генә, тигез итеп шомартылган такталардан сәхнә ише әйбер ясалган иде. Ләкин ул «Дон Кихот» балетыннан Рудольф Нуриевның искиткеч биек һәм галәмәт ярсу сикерешле вариацияләре өчен артык кечкенә булып чыкты. Шунлыктан, сәхнәдән очып чыгып китмәс өчен, әлеге балеттан гади адажионы гына башкарырга туры килде.

Ләкин шампан парларыннан инде шактый кызып алган тамашачы түрәләрне шаккатыру, тәмам акылдан яздыру өчен, монысы да бик җитә калды.

Алар сәхнәгә Святослав Рихтер уйнавыннан соң чыктылар. Менә композитор Рахманиновның ул башкарган гүзәл моннары тынып калды.

Һәм, әйтерсең, сәхнәдә утлы өермә купты!

Рудольф Нуриевның югалган сөйгәнен эзләп тар сәхнәнең бер почмагыннан икенчесенә ташлану—бәргәләнүләре шулхәтле көчле-кодрәтле, Людвиг Минкусның дәртле музыкасына шулхәтле туры килеп тора иде ки, тамаша рәтләре буйлап гүя ниндидер сихри ток җибәрелде. Ул ток монарчы төрле якка сибелгән атом кисәкчекләрен бер тарафка юнәлтте. Шул гаҗәеп ток тәэсиренә буйсынып, алдан сөйләшеп куйгандай, тамашачылар бер-бер артлы урыннарыннан торып баса башладылар:

—Браво, Нуриев!

—Браво, Кургапкина...

Ленинградтан бу очрашуга махсус чакыртып китерелгән яшь биючеләр чыгышы тәмамлангач та көчле алкышлар әле озак дәвам итте.

Рудольф Нуриев дигән яшь совет биючесенең уңышлы чыгышы Никита Сергеевичка аеруча көчле тәэсир итте. Шуңа күрә, аның турында күбрәк беләсе килеп, ул Нина Петровна янәшәсендәге СССР мәдәният министры Екатерина Фурцева янына күчеп утырды. Турылыклы көрәштәш, ышанычлы хезмәттәш кенә түгел, күптән инде гаилә дуслары да булып яшәгәнлектән, табигать кочагындагы мондый хозурлыкта Хрущев аңа рәсми тонга күчмичә, гади генә эндәшүне хуп күрде:

—Катя, каян килеп чыкты мондый самородок, ә!

—Башкириядан ул, Никита Сергеевич.

—Милләте кем? Башкортмы?

—Юк, Уфа татары диләр...

—Әтисе, әнисе?

—...

Ниндидер бер татар егете турында шуннан артыгын белмәве сәбәпле, министр хәтле министрның көймәсе ошбу урында комга килеп терәлде. Ләкин

Никита Хрущевның ярсу-дәртле холкы тиз генә тынычлана алмады:

—Менә бу егет биюче дисәң дә биюче!—диде ул, соклануын дәвам итеп.—Менә бу егет көнбатышның мактаулы биючеләренә «кузькин мать»ларын күрсәтәчәк икән әле!

Хрущевның һаман тынычлана алмавын күреп, аның янына тиз генә Рудольфның үзен чакыртып китерделәр. Изүләре милли бизәкләр белән чигүле украин күлмәген кигән Никита Сергеевич башта аны киң күкрәгенә кысып кочаклады, аннары күптән инде ныгып өлгергән җилкәсеннән аталарча кагып куйды:

—Так держать, Нуриев брат!

—Рәхмәт, Никита Сергеевич!

—Әтиең исәнме? Кем?

—Фронтовик майор.

—Бик яхшы. Ә белемең?

—Менә быел яңа гына Ленинград хореография училищесын тәмамладым.

—Нишләп шулай соңлап?

Ил башлыгының бу кыен соравына Рудольф ничек җавап бирергә дә белмәде. Ләкин үзе дә фронт юлларын кичкән, шул юлларда гүәрдиндәй очучы улын югалткан Хрущев икенче бер фронтовик малаеның балет училищесына нишләп соңга калып килү сәбәпләрен бик тиз аңлап алды:

—Йә, ярый... Соң булса да уң булсын...

СССР Дәүләт Иминлеге комитетының рәисе буларак, Александр Шелепин да әлеге тамашаны караган һәм Хрущевның җилкәсе артында гына утырган иде. Шуңа күрә ул Никита Сергеевичның яшь биюче Нуриев хакында һәр әйткән сүзен аермачык ишетеп торды. Менә хәзер шул асыл биючегә кара дегетле мичкә тәгәрәтеп маташалар. Җитмәсә, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, вакыты ничек туры килеп торуын кара әле син!

Куба утравында килеп чыккан СССР—АКШ каршылыгы...

Германияне урталай бүлеп күтәрелгән Берлин дивары...

СССР һәм АКШ җитәкчеләренең тиздән Вена каласында очрашып сөйләшергә җыенуы...

«Доктор Живаго» дигән антисоветчыл романы өчен бирелергә тиешле Нобель бүләген алудан баш тартырга мәҗбүр ителгән Борис Пастернакның көтелмәгән үлем хәлләре...

Хәзер шушы каршылыклар бинасына, тагын бер кирпеч булып, Парижда Рудольф Нуриев кылган кырын гамәлләр кереп ятсынмы?

Партия, аның кодрәтле лидеры Никита Хрущев, үзе һәм хатыны үлепләр балет карарга яраткан кеше буларак, моңа ни әйтер? Юк, ашыгып ашка пешеп куйма, тимер Шурик! КПСС Үзәк Комитетының четерекле моңдый эшләрне караучы махсус комиссиясе бар. Нуриев мәсьәләсендә башта менә шул комиссия үз сүзен кистереп әйтсен!

## 8

КПСС Үзәк Комитетының чит илләргә чыгучы совет кешеләре белән шөгыльләнә торган махсус комиссиясендә «Нуриев эше»н тиз тоттылар. Кичен вакытында кайтмыйча, шикле француз артистлары белән дуслашып алган, аны төнге шәрәләр клубында, хәтта рус эмигрантлары ресторанында күргәли башлаганнар. Рудольф Нуриев шәхсән үзе әнә шул ресторанда бер «акгвардияче шпион» белән кеше аңламый торган мөселман телендә сөйләшеп торган. Парижда танышкан яңа гыйшкына ияреп, аның әнисе фатирына барган. Фәлән-фәсмәтән...

Оят! Хурлык!! Коммунизм төзүченең әхлак кагыйдәләренә туры килмәүче моңдый гамәлләре өчен, яшь биюче Нуриев кичекмәстән туган иленә куып кайтарылырга тиеш! Әлбәттә, урынсыз шау-шу тудырып, советча яшәү

дошманнары кулына яңа дәлилләр тоттырмас өчен, бу эшне шыпырт кына башкарырга кирәк.

Мәскәү хәтле Мәскәүдән мондый эчтәлекле хат-фәрман килеп төшкәч, СССРның Франциядәге илчелегендә ашыгыч киңәшмәгә җыелдылар. Анда Киров театры җитәкчеләре дә чакырылган иде.

Инде нишләргә?

Әйе, чит җирдә тәртәгә тибеп маташкан бер яшь биючене тиешле урынына утыртырга теләүләре белән дәүләт иминлеге сагында торучылар, бәлки, хаклыдыр да. Аларга да, эш күрсәтеп, дан-дәрәҗә йолдызларын күбәйтү яки зурайту кирәктер. Ләкин бит мәсьәләнең Париждагы гастрольләр уңышлы үтүгә бәйле икенче ягы да бар!

Сүз барышы бу турыга җиткәч, мөнбәр артына гастроль башлыгы Константин Сергеев чыгып басты. Парижга килүләренең беренче көннәреннән үк Нуриевка иркенләп бии башларга юл куймавы, шунлыктан үз иркенә җибәрелгән биш-алты көн эчендә аның тарафыннан кылынган кырын эшләрдә үзенең дә гаебе барлыгын, Мәскәү тукмагының бер башы аның башына да төшү ихтималын яхшы аңлый иде ул. Шуңа күрә ярсый-ярсый, очынып-очынып сөйләде:

—Бер тиенлек куян өчен ун тиенлек зыян ясарга маташмыйк инде без... Ярый, Уфадагы әнисе нык чирләгән яки тагын Булганин дачасында биисе бар кебек шома сәбәпләр табып, без Нуриевны туган иленә куып та кайтара алыйк ди. Шуннан ни-нәрсә килеп чыгачак? Француз тамашачыларыннан театр кассасына чиста валюталы табыш керү бермә-бер азаячак. Чөнки аларның күпчелек өлеше Нуриевны, бары тик Нуриевның ничек биегәнен карау өчен йөри!

Бу урында, театр башлыгын хуплап, илчелекнең гастрольләр өчен җаваплы хезмәткәре Михаил Клейменов та юка ияген кагып куйды:

—Дөрес, бик дөрес, Константин Михайлович!

Илчелек тарафыннан да хуплау тапкач, Сергеев исә чыгышын нык ышанулы сүзләр белән тәмамлады:

—Париждагы гастролебез тәмамланырга нибары ун көн калып бара. Аннары Англиягә китеп барачакбыз. Инде шушы ун көндә Нуриевтан баш тартып, француз тамашачыларын ярсытмаска иде. Ә менә аны Лондонга алып бару-бармау мәсьәләсендә ныгытып уйларга кирәктер...

Акыллы тәкъдим иде бу. Һәм Мәскәүгә әнә шундый уртак тәкъдим җибәрелде дә. Ләкин башкалада тиз генә тынычланырга теләмәделәр. Нуриевны тимер читлеккә утыртып җибәрүне таләп итеп, Париждагы совет илчелегенә тагын ике хат-фәрман юлланды. Эшләр болайга киткәч, ниһаять, Нуриевны туган илгә 1961 елның 16 июнендә кайтарып җибәрергә кирәк диелгән ныклы карарга киленде. Һәм бу гамәлне тавыш-тынсыз гына тормышка ашыруның бик хәйләкәр вә мәкерле планы төзелде.

Менә Париж белән хушлашыр чак та килеп җитте.

Иртәгә Лондонга китәсе төнне Рудольфка йокы бөтенләй эләкмәде. Саубуллашу спектаклендәге Солор биюен гадәттәгедән дә күбрәк алкышлар казанып тәмамлагач, соклану һәм рәхмәт хисләреннән чиксез тәэсирләнгән француз тамашачылары белән озын-озак хушлашу минутлары булып алды. Аннары чәчәк бәйләмнәренә күмелгән Клара Сент белән Рудольф Нуриев «Дсих Мадоts» («Ике маймыл») исемле төнге ресторанга кереп утырдылар. Анда байтак сөйләшеп утыргач, урамга чыгып, каршыдагы елга ярына барып бастылар.

Төнге Сена гаҗәеп тыныч һәм гүзәл иде. Алар басып торган бер ярдан икенчесенә, балык тәңкәләре хәтле генә вак һәм көмеш дулкыннарын тирбәлдереп, ай сукмагы сузылган. Кетер-кетер атлап, шул сукмактан култыклашып кереп китәсе һәм аргы яктагы сөю-мәхәббәт тулы бәхет ярына барып чыгасы килә башлый.

Алда аларны нәрсә көтә? Кавышумы, әллә мәңгегә аймыл булумы?

Шулчак Клара Сент төз аякларының бармак очларына басып бераз күтәрелә төште дә, Рудольфның колагына бик кадерле берничә сүз пышылдады:

—Ә син монсуланма, Руди! Без әле Лондонда тагын очрашырбыз. Хәтта иртәгә, юк, бүген үк икән инде...

Рудольф, үз колакларына үзе ышанмыйча, кабатлап сорады:

—Лондонда?.. Бүген үк?

—Әйе, Руди! Минем билет инде кесәдә!

—Нәрсә? Әллә бер үк рейс белән очабызмы?—дип канатланып китте Рудольф.

—Юк, анысына ук ирешеп булмады, Руди! Чөнки шымчыларыгыз юлга аркылы төште.

—Чынлапмы?

—Зарар юк, Руди. Мин Лондонга сездән соңгы икенче рейс белән үк килеп житәчәкмен. Һәм без тагын бергә булырбыз.

—Рәхмәт, дустым! Шулай була күрсен...

Кинәт ярыйсы ук көчле төнге җил исә башлады. Каяндыр көнчыгыш тарафлардан бүрек хәтле генә болытлар күтәрелеп чыктылар да, зурайганнан-зурая барып, Сена елгасы өстеннән агылып үтә башладылар. Бая гына бәхет ярына чакырган көмеш ай сукмагы да, болыт караңгысы астында калып, күздән гаип булды. Төнге Сенадан салкын җил исәргә кереште. Ике гашыйк, җылы эзләп, бер-берләренә елыштылар. Ләкин, ни гаҗәп, аларның тәннәре туңганнан-туңа гына бара иде.

Шулчак Рудольф бу төнге туңу, күнелгә кереп оялаган бу төнге шомның сәбәпләрен бар нечкәлегенә хәтле аңлап алгандай булды. Ресторанда утырганда да, Сена яры буйлап йөргәндә дә аның бит күнел күзләре гел Клара Сентта булса, маңгай күзләре исә һаман әйләнә-тирәдә иде. Һәм, ни гаҗәп, бу төнне аларга электән ябышып-ияреп йөргән теге шымчылар күренмәде. Моны ничек аңларга һәм аңлатырга? Тиздән барыбер Лондонга очасы дип, Рудольфның төнге гөнаһларына кул селтәгәннәрме? Әллә бу сәер халнең төбендә әлегә ул белмәгән мәкерле бер хәвеф ятамы?

Һәрхәлдә, ике гашыйк тиздән Лондон аэропортында очрашырга сүз биреп аерылыштылар. Бу вакытта инде иртәнге дүрт тулып килгәнлектән, юл чыгар алдыннан бераз черем итеп алу өчен, Клара Сент Рудольфны Париждагы Ле Бурже аэропортыннан озату өчен барып тормаска тиеш булды. Моның шулай булуын Рудольф үзе теләде: ярәшелгән ярын югалту хәсрәтеннән болай да ябыгып-сулыгып калган мадмуазельне тагын нигә мәшәкатьләргә—барыбер берничә сәгатьтән Лондон каласында кабат күрешәчәкләр ич!

Ләкин кырыс чынбарлык аларның беркатлы һәм нарасый уй-хыялларын бик тиз чәлпәрәмә китерде!

Рудольф «Модерн» кунакханәсенә кайтып керүгә, өзеп-өзеп бүлмә телефоны чылтырады. Пьер Лакотт икән:

—Руди, юлга ашыгып әзерләнмәсәң дә була. Җинел машинамда аэропортка үзем генә җилдертеп илтеп куярмын!

—Кайгыртуың өчен рәхмәт, Пьер! Юк, коллективтан аерылмыйча, бу юлы зәңгәр автобуста гына барыйм әле.

—Мин берни аңламыйм, Руди!

—Нәрсәне?

—Син бит стройда сарык көтүе кебек атлап йөрүне үзең үк яратмыйм дия идең?

—Күңелем сизә... Бу юлы мине ниндидер хәвеф көтәдер кебек, Пьер!

—Борчылма Руди!.. Ә мин сине озатырга барыбер киләчәкмен!

—Кирәкмәс иде... Рәхмәт инде, алайса...

Киров театры артистлары утырган зәңгәр-озын автобус Ле Бурже аэропортына акрын гына кузгалып китте. Рудольфның сизгер күңеленә кереп

утырган теге шомның беренче билгеләре тиздән үзләрен шактый ачык сиздерә башлады. Ник дигәндә, бүтән гастроль сәфәрләре вакытында артистлар авиабилет дигәннәренең нинди төстә икәнлекләрен дә белми-күрми калалар иде. Чөнки ул билетларның һәммәсе дә театрның оештыру эшләре өчен җаваплы хезмәткәрендә була торган иде. Ә бу юлы?

Театр администраторы Нодар Грузинский тотты да, артистлар фамилиясен кычкырып әйтә-әйтә, һәр авиабилетны аэропортка барышлый ук тиешле ияләренә таратып чыкты:

—Соловьев?

—Мин.

—Рәхим итеп, алыгыз!

—Осипенко?

—Мин...

Әйтерсең, тиешле исемлектән стройдагы солдатларны кичке барлау бара! Һәр совет кешесенең кечкенәдән канына сеңдерелгән күмәкчелек авазларын ишеткәч, Рудольфның тагын җен ачуы чыкты. Ләкин ул, ниндидер яшерен мәкер сизеп, бу юлы үзен кулда тотарга тырышты.

—Нуриев?

—...

Бераздан баягы тавыш тагын кабатланды:

—Нуриев диләр!.. Нәрсә, төне буе сөйгәне белән хушлашып йөреп йокламагач, әллә мәрткә үк китеп барган инде?

—Лондонга барасы килмидер, бәлки...

Юк, Рудольф мәрткә дә китмәгән, аның Лондонга да бик барасы килә иде. Ләкин ул, алдан көтелмәгән бу билет тарату «уен»ыннан ниндидер мәкер көтеп, бик игътибар белән Нодар Грузинский кыланышларын күзәтте. Нишләрләр, Нуриевның әле һаман билет алмавын күреп, тамашаны дәвам итәрләрме? Әллә...

Тиешле билет Нуриев кулына килеп кергәч, канәгатьләнү хисләрен белдереп, Нодар Грузинский хәтта калын мыек очларын сыпырып куйды. Аннары, янәшәсендә басып торган гастроль башлыгы Константин Сергеев белән колактан-колакка кинәшеп алгач, билетлар таратуын дәвам итте:

—Макарова?

—Йоклый...

—Сизова!

—Мин...

Шулчак Рудольфның җәя бавы кебек киерелгән сизгер күнеле барысын да аңлап алды: әһә—ә, имәндә икән чикләвек! Билет өләшкәндә Макаровага йоклап калырга да ярагач, ә Нуриев фамилиясен исә ничә мәртәбә кычкыргач, димәк, әлеге тамаша махсус Рудольф өчен—бүтәннәр белән беррәттән билет биреп, аны тынычландыру өчен эшләнгән булып чыга түгелме соң?!

Тик менә ни өчен тынычландыралар? Менә болары әлегә Рудольф өчен караңгы иде...

**9**

Ленинград артистларын озатырга килүчеләр арасыннан пумаладай җирән чәче әллә каян тырпаеп торган Пьер Лакоттны Рудольф бик җинел эзләп тапты.

—Клара Сент килә алмады инде,—диде Пьер, Рудольфның хәленә кереп.— Кемнедер озатып йөреп, төнлә бик арыган.

—Белә-әм...—дигән булды Рудольф, Пьерның дусларча төрттерүен үпкәләми генә кабул итеп.

Һәм авыр сулап куйды: менә аның Париж дигән калада Пьер Лакотт атлы тагын бер бик ышанычлы дусты аерылып калачак!

Лондонга очучыларның таможня, ягъни тамгалы тикшерү аша узар минутлары да килеп житте.Юлчыларны берәм-берәм уздыра торган бусага төбенә жирафтай озын муенлы тагын теге Нодар Грузинский килеп басты. Һәм Ленинград биючеләренен бая гына һәркайсына таратылган авиабилетларны кабат жыеп ала башлады. Рудольф та үзенекен кире тапшырды. Һәм, театр житәкчелеге тарафыннан кылыначак чираттагы бу этлекнен максатын тәмам анлап бетерәсе килеп, башта Грузинскийга, аннары анын янәшәсендәге гастроль житәкчесе Сергеев белән иминлек сакчысы Стрижевскийга текәлеп карады. Рудольфнын үзләренә төбәлгән карашын тойгач, алар йөзендә мыскыллы елмаю чагылды: әһә-ә, килеп каптыңмы тимер капкынга дөньяның булачак бөек биючесе? Хәзер инде син аннан котыла алмассын. Чөнки зәнгәр койрыгын жиде еллык төрмә дигән калын бозга ябышып каткан!

Менә совет артистларын берәм-берәм очкыч мәйданчыгына таба туплый башладылар. Бу юлы тар ишекле бусага төбенә гастроль башлыгы Константин Сергеев үзе дә килеп баскан иде. Бусаганы атлап чыккан һәр биючегә тагын теге билетларны бирә бардылар. Ә менә Нуриев чираты житкәч, чалбар һәм түш кесәләренә суккалап, хәйләкәр Грузинский аны юри озак эзләп интекте. Әйе, Рудольфка хәзер билетлы уеннын максаты тәмам ачыкланып житте—аны Лондон дигән калага жибәрмәскә карар кылынган иде, тәгаен!

Рудольфнын шиген раслагандай, гастроль башлыгы Сергеев менә аны бусага аша агылган артистлар чиратыннан чакырып чыгарды һәм, жиненнән кысып тотып, читкә әйдәде:

—Ә хәзер игътибар белән мине тынлагыз, Нуриев!—диде ул, рәсми тонга күчеп.

Рудольф та нәкъ шундый ук рәсмилек белән жавап кайтарды:

—Тынлыйм, иптәш Сергеев!

—Сез хәзер безнен белән очмыйсыз, Нуриев!

—Ә ни өчен?—диде йөзе кинәт ап-ак төскә кергән Рудольф, тәмам сабырлыгын жуеп.

—Чөнки менә әле генә Мәскәүдән ашыгыч телеграмма алдык!

—Ерак юлга чыгар алдыннан нинди телеграмма ул тагын?

—Нинди түгел... Никита Сергеевич Хрущевнын үзеннән! Һәм бу исем сезгә яхшы таныштыр дип уйлыйм...

Гастроль башлыгынын эчке киная белән әйтелгән бу сүзләренә, әжәткә каршы йомыш дигәндәй, Рудольф тагын да төрттеребрәк жавап бирде:

—Ә-ә... Булганин дачасы... Андагы очрашуда маэстро Рихтернын пианинода өздереп уйнавы...

«Кичәдә катнашкан илбашы Хрущев һәм атаклы командарм Буденныйнын теттереп биюен яки маршал Ворошиловнын украинча өздереп жырлавын түгел, беренче нәүбәттә маэстро уйнавын телгә ала бит азгын малай актыгы!»—дип уйлап куйды Сергеев һәм сүз уйнатып теш агартуын дәвам итте:

—Рәхмәт, онытмагансыз!

Мондый чакларда Рудольф та сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел:

—Ничек инде онытыйм ди, иптәш Сергеев! Маэстро хәтле маэстро янәшәндә басып торсын да!

Сергеев, юка иреннәрен чәйни-чәйни, Рудольфка сүзсез генә карап торды да, ниһаять, әйтеп куйды:

—Горур була белү начар түгелдер, билгеле... Тик ни бит, Нуриев...

—Ни инде, Константин Михайлович? Ник ул сүзегезне баядан бирле тел очында әвәлисез?

—Әйтергә туры килә, болай булгач... Галижәнап Никита Сергеевич сезнең ашыгыч төстә Мәскәүгә кайтып житүегезне һәм тагын Кремль банкетында биюегезне көтә!

—Теге чакта ошаткан, димәк?

—Шулай килеп чыга...

—Ә Лондонга?

—Безгә, Кремль банкетында биегәч, Мәскәүдән килеп кушылырсыз,— диде гастроль башлыгы, берни булмагандай итеп.

Тик Сергеев бу мизгелдә үзенә томырылып караган Рудольфтан күзләрен яшергән һәм, никтер, бөтенләй читкә карап тора башлаган иде.

Ялган күзләр, ялган сүзләр!

Әйе, хәзер инде шикләнмичә әйтергә дә була—аны көпә-көндез күзгә төтен җибәреп алдыйлар! Һәм моның нәкъ шулай икәнлеге тиздән тәмам ачыкланды.

Менә Париж—Лондон рейсы белән очачак пассажирларны самолетка утырта башладылар. Күпме вакытлар Киров театры сәхнәсендә бергә биегән хезмәттәшләре белән хет адәмчә саубуллашып калыр өчен, Рудольф та ак очкычлы перронга ташланды. Аны шунда ук самолетка утырып өлгермәгән иптәшләре сырып алды:

—Кайгыңны уртаклашабыз, Рудик!

—Чын күңелдән...

—Авыру әниеннең хәле ничек икән анда?

—Уфада озак тоткарлана күрмә инде, дускай!

—Лондонда бергә биисебез барлыкны онытма!

Кайгы?

Авыру әнкәй??

Уфа???

Рудольф һични аңламады: аның иптәшләре ни сөйлиләр? Аптырагач, ул үзе белән күп кенә спектакльләрдә бергә биегән Алла Сизованы нәфис-нечкә беләкләреннән якынрак тартып китерде:

—Мин берни аңламыйм, Аллочка! Кемнең әнкәсе авырган? Кем әйтте?

—Ник... Безгә Сергеев шулай диде, Руденька!

—Нәрсә диде?

—Нуриевның әнкәсе каты чирләп киткән, шуңа ул Лондонга түгел, ә Уфага оча диде.

—Ах, иблис җан!.

Ачуыннан нишләргә белмәгән Рудольф тагын аэропорт залына йөгереп керде һәм гастроль башлыгы Сергеевның якасыннан алды:

—Хрущев чакырткан, имеш... Кремль банкеты, имеш... Нигә инде әниемнең каты авыруын башта ук әйтмәскә?! Миңа әле олуг түрәләрдән газиз әнкәем кадерлерәк лабаса!

Артистлар Лондон очкычына кереп утырган—билетсыз Нуриевтан өркер сәбәпләр калмаган кебек иде инде. Шуңа күрә Сергеев та бу юлы дөресен әйтеп сөйләште:

—Әниеңнең каты авырып китүен нигә башта ук әйтмәдекме?

—Соң?

—Чирләмәгәнгә күрә!

—Ах, имансыз!—диде Рудольф һәм, ачуыннан сулышы буылып, ярты сүздән бүленеп калды.

—Бар, бар, тилергән азиат—кайтып кит тизрәк кыргый Себереңә! Менә анда иманның нинди булуын җиде ел буе бик әйбәтләп күрсәтәчәкләр әле сиңа.

Мондый оятсызлыкны СССРның халык артисты исемен йөрткән остазыннан Рудольф һич көтмәгән иде. Тамаша башланыр алдыннан сүндерелә торган люстра кебек, акрын гына сүнә-сүрелә баруын тәки тыныч кына кичерә алмый, картлач!

Француз биючесе Пьер Лакотт бүген аерылышу минутларында Рудольфка сөяк саплы пәке бүләк иткән иде. Көнче Сергеевка булган ачуын ничек

алырга белмичә, ул әнә шул пәке яткан кесә төбен капшап куйды. Ләкин аның һәр хәрәкәте хәзер ныклы күзәтү астына алынган иде инде. Шул мизгелдә үк Рудольфның чалбар кесәләренә тыгылган кулларына ике яктан ике әзмәвер килеп асылынды. Бу әзмәвер-күләгәләрнең берсе күптән таныш капитан Стрижевский иде. Ана чит илдә тәртәгә типкән, коммунизм хәтле коммунизм идеалларына беренчеләрдән булып каршы чыгарга җөрьәт иткән Нуриевны, кулларына богау салып, кичекмәстән Мәскәүгә алып кайтырга дигән махсус фәрман бирелгән иде. Һәм бу үтә мөһим эш өчен төп җаваплы кеше—әгәр куелган бурычны әйбәт кенә башкарып чыга алса, иртәгесен үк һичшиксез майор, хәтта ки подполковник булачак Стрижевский иде.

Дөрес, Нуриевның кулларына әле тимер богау салынмаган. Чөнки монда СССР түгел, ә Франция җире! Богаулы биюченә алай-болай коммунизм дошманнары күреп алып шау-шу куптарса, нихәл итәрсен?! Мондый дәрәҗәдәге яшерен һәм җаваплы эштә акрын кирәк, ипләп кирәк!

Ә Мәскәү самолеты очып китәргә нибары ике сәгатьләп кенә калып бара. Шушы вакыт эчендә беләкләргә генә түгел, җанга да тырнакларын батырган куркыныч Стрижевскийдан ничек тә котылып өлгерергә кирәк. Югыйсә, эшләрнең узып, туннарның тузып куюы да бик ихтимал.

Рудольф, нишләргә белмичә, беләкләрен бушатмак булып карады.

Юк, бу очракта беләкләрне түгел, башны күбрәк эшләтергә кирәк, башны! Син бит мондый хәлләргә аз юлыкмадың, Рудольф! Һәм монарчы аларның һәркайсыннан исән-сау гына котылу әмәлен таба алдың, шөкер!.. Тукта! Терекөмеш кебек тере гәүдәле Клара Сент... Әтисе—Франциянең билгеле рәссамы һәм эшкуары. Өстәвенә, ил министрының булачак килене дә иде бит әле... Коткарса, менә кем аны коткара алырга мөмкин! Ләкин ул Рудольфның хәзерге хәле хакында һични белми. Дусты артыннан Лондонга очар алдыннан, ул әлегә изрәп йоклый.

Кларага ничек хәбәр итәргә?.. Тукта!.. Лакотт... Аның турылыклы яна дусты Пьер Лакотт!..

Рудольф совет артистларын озатырга килгән француз тамашачылары арасыннан тубал башлы таныш йөзне эзләде. Әнә ул! Пьер Лакотт та әле генә булып алган хәлдән каушап калган һәм, нишләргә, ни кылырга белмичә, аптыраулы күзләре белән Рудольфка томырылып карап тора иде.

Стрижевский кысып тоткан уң кулын Рудольф тагын кымшатмак булып карады. Юк, отыры катырак кына кыса, мәлгунь!

Аптыраган Рудольф, ниһаять, хәйлә кулланып карарга булды:

—Нишләптер, борын очым кычытып китте бит әле, Владимир Дмитриевич.

—Димәк, тиздән каяндыр күчтәнәч алачаксыз.

—Юк, мин шаяртмыйм—дөрестән дә кычыта!

—Алайса, кашыгыз!

—Ничек? Ике кулым да...

Ниһаять, бер кулны бушаттылар. Борын очын тиз генә кашып алгандай итте дә, кипшегеп киткән иреннәренә якын ук китереп, Рудольф француз дустына рәттән өч мәртәбә «һава үбүе» җибәрде. Ниһаять, Пьер Лакотт та күреп-абайлап алды—ни әйтергә тели ана Руди бу гашыйклар теле аша? Әһә-ә!.. Үбү... Сөю-мәхәббәт... Димәк, Клара Сент! Капкынга эләктерелгән Рудиның кыен хәлен әйтеп, менә кемгә тиз генә хәбәр итәргә кирәк!

## 10

Өзеп-өзеп чылтыраган телефон тавышына Клара Сент сискәнеп уянды.

Ак трубканы кулына алганчы ук, күңел кылларының сизгер тибрәнүе аша, ул әлеге чылтырау артында торган ниндидер шомны тоеп өлгерде:

—Алло!

—Бу—мин, Пьер...

—Исәнме...
—Гафу ит, Клара—исәнләшеп торырга да вакыт юк!
—Ни булды, Пьер?
—Рудины кулга алдылар!
—Кайда? Кайчан??
—Ле Бурже аэропортында... Менә әле генә...
—Кемнәр?
—Күп уйлашып торыр вакыт юк, Клара! Ишегалдыгыздагы машинаңа тиз генә чыгып утыр да, күз ачып йомганчы монда килеп җит! Ул сине бик көтә.
—Хәзер, алай булгач...
Кинәт килеп туган киеренкелектән зур итеп ачылган күзләренә салкын су тамчылары бөркеде дә, бөтерчектәй елгыр гәүдәсенә кара кофтасын кия-кия, Клара Сент ишектән чыгып йөгерде. Баскычтан ашыга-ашыга төшкәндә, чынаяк тәлинкәседәй зур пыялалы кара күзлеген киярgә һәм, йодрык кадәрле генә затлы күн сумкасыннан алып, түгәрәк көзгесенә дә күз ташларга өлгерде. Каратут маңгаена сибелгән каштан төсендәге чәчләрен рәтләп торырга да вакыты юк—анысын инде машинасында барганда...
Пьер Лакотт чылтыратып озак та үтмәде, Клара Сент йөрткән җинел автомобиль аэропорт ишеге төбенә чабыш атыдай ыжгыртып килеп тә туктады. Һәр минут, хәтта һәр секунд та исәптә иде! Шуңа күрә, пассажирлар тыз да быз кайнашкан аэропорт залының бер аулаграк почмагында—ике әзмәвер арасында кысылып утырган Рудольфны күреп алуга, Клара шунда ташланды.
Рудольфның сакчылары башта аның юлына аркылы төшмәк булып карадылар:
—Кая?.. Кая шулай мөгезсез сыер кебек ыргыласыз? Артка!.. Рөхсәт юк!
Ләкин биредә әлегә СССР түгел, ә Франция җире иде. Шунлыктан Клара Сент аз гына да куркып тормады:
—Нәрсә... Француз кызына хәзер Франциядән китеп баручы егете белән хушлашырга да ярамый башладымы? Кайчан әле мондый да хурлыклы тәртипнең кергәненә? Бу кыргый канунны кем кертте? Мәскәүме?!
Теге шымчылар беразга каушап-югалып калдылар. Клара Сентның тәбәнәк кенә буйлы гәүдәсенә исә, кечкенә дә—төш кенә дигәндәй, киресенчә, көч—гайрәт кереп тулды:
—Их, сез-з-з!.. Хатын-кызга башта урын бирәләр!—дип капитан Стрижевскийны әүвәл чөгендер төсле кызартып оялтты да, ике дә уйламыйча, менә ул Рудольфның уң ягына кысыла-кысыла кереп утырды. Һәм, сөйгән егетен үбә-үбә хушлашкан гашыйк кыздай, аның колагына кайнар иреннәрен якын ук китереп, француз телендә нидер пышылдый башлады.—Руди, тиздән сине иленә көчләп апкитәчәкләр. Төгәл итеп кенә әйт: син моңа ризамы, әллә юкмы?
Рудольф, кискен ризасызлыгын белдереп, чуалчык чәч көлтәләре ишелеп төшкән маңгаен як-якка селкеп куйды.
—Руди, маңгаеңны бүтән селкемә—аңларлар. Ә менә, минемчә, французча рәхәтләнеп сөйләшә алабыз. Чөнки, күренеп тора, сакчыларың бу телдә һични аңламый.
Әйе, бу мәсьәләдә Клара Сент хаклы иде: капитан Стрижевский һәм аның ярдәмчесе француз телен ипи-тозлык та белмәүче, алай гына да түгел, Мәскәүгә юллаган ашыгыч донесениеләрендә француз эшлеклесе Раймундо де Ларренны Ларин фамилияле рус эмигранты дип бутаган шыр наданннар иде. Шуңа күрә, алар бераз ис-акылларына килеп өлгергәнче, Рудольф белән Клара алдагы хәлиткеч минутларда нишләргә кирәклек хакында җентекле сөйләшеп өлгерә алдылар.
Капитан Стрижевскийдан җитәкләткән хәлдә Мәскәүгә кайтып китү турында бернинди сүз дә була алмый! Бу—җиде еллык төрмәгә ябылып,

биючелек хакындагы яшьлек хыялларыннын котылгысыз тестә жимерелеп төшүе дигән сүз! Димәк, бары бер юл кала—алга һәм бары тик алга! Бөтен өмет синдә, тәмле телен, нурлы йөзенне ничек оста итеп эшкә жигә белүендә, Клара Сент! Һәм, күз генә тия күрмәсен, кечкенәдән ижат вәкилләре арасында әвәрә килеп үскәнгәме, Парижда яшәүче бу аргентиналы Чили кызынын кинәт кенә артистлык сәләте ачылып китмәсенме?!

Капитан Стрижевскийнын болай да шикле күнелендә артык шом тудырмас өчен, менә ул Рудольфнын мангаеннан чупылдатып үпте дә утырган жиреннән сикереп торды:

—Хуш, Руди! Андый-мондый бүтән очрашмасак, бәхил булып тор!

—Сау бул!..

Янәсе, алар бүген башка күрешмәячәк—тыныч булып тор, Стрижевский!

Ә хәйләкәр Сент исә һичкая ашыкмагандай акрын гына атлап килде-килде дә, полицейскийлар бүлмәсе урнашкан икенче катка алып менүче баскыч турысына житеп тегеләр күздән югалгач, бөтенләй йөгерә үк башлады. Көпә-көндез баскычтан йөгереп йөргән бу нинди сәер нәмәстәкәй икән дип хәтта анын артыннан кайберәүләр башларын чайкый-чайкый карап калдылар.

Ниһаять, менә ул—ишегенә латин хәрефләре белән «Аэропорт полициясе» дип язылган бүлмә!

Микрофонлы ниндидер пультлар, телефон аппаратлары белән шыплап тутырылган бүлмәдә, өстәлдәге кәгазьләренә иелеп, ике полицейский утыра иде. Алар ниндәндер тирән дулкынланган каратут йөзле кызны урыннарыннан торып каршы алдылар:

—Рәхим итегез!.. Ни йомыш, мадам?

—Аста—беренче катта... Франциядә сәяси сыену урыны сорап, Ленинград биючесе утыра!—диде Клара Сент, сулышы кабып.

Сирәк очраган бу сүзләрне ишеткәч, полицейскийларнын күзләре мангайларына сикереп менде:

—Сәяси сыену?! Кем ул? Атомчы бөек галимме, әллә...

—Юк... Дөньянын булачак бөек биючесе!

—Ә-ә, булачак бөек... Кем инде ул, әгәр әйтергә яраса?

—Нуриев.

Француз телендәге йомшак авазларны хәтерләтеп, әллә кайдан жырлап торган бу гажәеп музыкаль, гажәеп нурлы фамилияне ишеткәч, полицейскийлар сөйләмендәге баягы ышанып бетмәү чаткылары өреп очыргандай шунда ук юкка чыкты:

—Әле шушы көннәрдә генә сокландыргыч биюләре белән бөтен Парижны шаккатырган Рудольф Нуриевмы?

—Шул үзе.

—О-о, дөрестән дә бөек биюче!—диде баягы полицейский, соклануын дәвам итеп.—Әгәр ул Парижда калса, безнен өчен олы табыш, ә Советлар Союзы өчен коточкыч югалту булачак бу!

Аркылы-торкылы кин каешлар уралган куе яшел киемле, саргылт чәчле, табак битле әлеге полицейский Россия Думасынын кайчандыр Ленин хәтле Ленинны тәнкыйть иткәне өчен төрмәдә черетелгән депутат-социалистынын улы Грегори Алексински иде. Ул—Ле Бурже аэропортында чик күзәтчелегенен башлыгы булып эшләүче тәжрибәле офицер. Шунлыктан сәяси сыенуга бәйле четерекле хәлләрне бөтен нечкәлекләренә кадәр бик тиз анлап алды. Ләкин, тимер авызлыклы кызыл йөгәнен өзеп хөр иреккә ыргылган Рудольф Нуриевны күнеленнән тулысынча якласа да, Алексински әлегә үзенен большевикларга үчле рус эмигранты баласы икәнлеген белдертмәскә булды. Чонки ул—Франциянен чик сагындагы жаваплы кеше. Әгәр моны Париждагы совет шымчылары белеп алсалар, Нуриевны сәяси сыену сорарга менә кемнәр котырткан һәм хәзер дә аны менә кемнәр канат астына алып маташа дип сөрән сугулары бар.

Аннары Грегори Алексински Париж Операсының элеккеге директоры һәм балет биючесе Серж Лифарьның күптәнге танышы иде. Һәм, гомумән, сәнгатьнең балет төрен кечкенәдән үлеп яратканга, аның биюче артистлар арасында бүтән таныш-белешләре дә байтак иде. Ленинград балетының яшь йолдызы Рудольф Нуриев чыгышларын да ул Париж сәхнәсендә кат-кат карады. Аларны ошады гына дию аз, алар Грегори Алексинскиның большевиклар илсез һәм әтисез иткән яралы бәгырендә мәңге җуелмас җылы эз калдырды. Менә шуңа күрә ул бу минутларны совет җәтмәсендә чәбәләнгән яшь һәм искиткеч талантлы биючене коткару өчен бөтенесен дә эшләргә ният кылды.

Дөресен генә әйткәндә, ул үзе каршында энә өстендәгедәй утырган Клара Сент дигән кызның да тиздән министр килене булырга тиешлеге, ләкин ярәшелгән егете юл фаҗигасенә очрау сәбәпле генә туйлары үткәрелми калуын да яхшы белә иде. Ләкин Нуриевка зыян китермәү хакына, әлегә ана да бу турыда һични әйтми торырга булды.

—Менә нәрсә, сеңлем,—диде Грегори Алексински, ниһаять, бүленгән сүзне дәвам итеп.—Безнең хәзер җәтмәдәге Нуриев янына барырга хакыбыз юк. Ничектер, җаен табып, ул үзе безнең янга килергә һәм сәяси сыену сорап мөрәҗәгать итәргә тиеш.

—Ә ничек?—диде Клара Сент, нәфис кулларын чәбәләндереп.—Аны бит ике яктан ике әзмәвер кысып тоткан.

—Ә менә монысын уйлашырга кирәк...

Бер читкәрәк китеп, ике чик сакчысы ни турындадыр тиз генә киңәшеп алдылар. Алар уртак фикерне тиз таптылар. Каракошлы көмеш йөзек кигән урта бармагын изәп, чик күзәтчелеге башлыгы Грегори Алексински Клара Сентны үзе янына чакырып китерде:

—Ярдәмчем белән без икәү астагы кафе-бар ишеге каршында басып торырбыз. Рудольфлар утырган эскәмиядән алты метрлап кына читтәрәк. Ә сез, мадам Сент, хушлашыр алдыннан кофе эчеп алу сылтавы белән, Нуриевны шунда алып килергә тырышыгыз.

—Яхшы.

—Ә хәзер—алга, сеңлем! Бергә сөйләшеп эшләгәннәр икән дип уйламасыннар өчен, без бераздан төшәрбез.

Икенче катның озын-текә баскычларыннан төшеп җиткәндә, бая гына хушлашып киткән егете янына кабат ничек якын киләсен Клара Сент тәмам уйлап җиткергән иде инде. Әйтик, бик мөһим бер әйберен бирергә онытккан булып кыланырга.

Нәкъ ул уйлаганча килеп чыкты да. Клара Сент башта Рудольф кулына Парижның истәлекле урыннары төшерелгән бик матур открыткалар бәйләмен тоттырды. Әйдә, мондый тәти сурәтләр җыйгач, Мәскәвенә кайтып китәргә җыена икән дип тынычлансыннар.

Ә менә Клара Сент алып килгән бияләй кадәрле һәм тиз эри торган тундырма Рудольф беләгенә ябышкан иминлек сакчылары өчен чын мәгънәсендә көтелмәгән әйбер булды. Бердән, аны иясенә тапшырганда Клара сиздермичә генә дустының колагына французча:

—Әнә, күрәсеңме—кафе-бар ишеге төбендә сине ике полицейский көтәчәк!—дип пышылдый алды.

—Күрәм...

Тартылган җәя җебедәй киеренке хәлдәге Рудольф нишләргә кирәклеген шунда ук аңлап алды. Бу очракта коткарса аны балет телендә «зур пируэт» һәм «антраша» вә «кабриоль» дип йөртелгән гаҗәеп көчле, гаҗәеп кодрәтле сикерешләр генә коткара алачак иде!

Менә Рудольф кулындагы тундырма бер читеннән агып-агып ук төшә башлады. Аны ашап та, ялап та бетерү мөмкин түгел иде. Шунлыктан баллы-ябышкак тамчылар капитан Стрижевский һәм аның ярдәмчесе киемнәрен дә буяп өлгерде. Ачуларыннан нишләргә белмәгән сакчылар, Рудольфның

кулларын ничек ычкындыруларын үзләре дә сизмичә, киемнәренә сыланган тундырма тапларын сөртә-сөртә сукранырга керештеләр:

—Егермедә тундырма ашап утырмаса сон!

—Шулай, шулай... Нәкъ детсад баласы диярсен...

Ә Рудольфка шул гына кирәк иде дә!

Менә ул тирән итеп сулыш алды да, жон эрләүче әбиләр кулындагы орчык кебек бер урында бөтерелеп, өскә томырылды! Ә соң чиккәчә киерелеп торайган аяклар исә нәкъ зыр-зыр әйләнгән вертолет канатларын хәтерләтә иде.

Башы аэропорт залынын түшәменә тия язгач, «антраша» алымын кулланып, Рудольф һәр буыны, һәр күзәнәге тынлаучан гәүдәсен горизонталь хәлгә китерде һәм полицейскийлар басып торган кафе-бар турысына дирижабль кебек очып бара башлады. Хәтта шушы очышы вакытында, «кабриоль» алымын кулланып, кыска, ләкин галәмәт көчле аякларын вак-вак кына итеп берберсенә бәргәләп куярга да онытмады. Очар кошларның канат кагуына охшаган бу гаҗәеп гүзәл хәрәкәтләрне, матурлыктан бигрәк, Рудольф очыш ераклыгын озынайту өчен эшләде.

Һәм ул үз дигәненә иреште! Кафе-бар турысына житкәч, гәүдәсен кабат вертикаль пируэт халәтенә китерде дә, аста кулларын жәеп басып торган чик сакчылары кочагына салмак кына килде дә төште.

Аэропортның самолетлар көтү залында ирексездән тамашачыга әйләнгән юлчылар, бу могжизаны күргәч, «аһ!» иттеләр.

Менә сиңа «зур пируэт»!

Менә сиңа «антраша»!

Менә сиңа «кабриоль»ле дирижабль очышы!

СССР дигән кызыл империя нигезеннән убылып төшкән ин тәүге ташларның берсе буларак тарихка кереп калачак әлеге легендар очышы вакытында, тирә-яктагы бөтен юлчылар ишетеп торырлык итеп, ул әле өч мәртәбә кычкырып куярга да өлгерде.

Башта—үзе яшисе килгән чит ил телендә:

—I want freedom!

Аннары—кире әйләнеп кайтудан баш тарткан зур Ватаны телендә:

—Я хочу остаться здесь!

Ин соңыннан—кече Ватаны, ягъни туган телендә:

—Мина ирек кирәк!!

Чөнки монын шулай булуын һәм әлеге сүзләрнең кычкырып вә кимендә ике шаһит алдында әйтелүен Женева конвенциясендә кабул ителгән халыкара канун таләп итә иде.

## 11

Әле генә күрсәтелгән бер пәрдәлек «аэропорт балеты»ннан капитан Стрижевский, ниһаять, аңына килеп өлгерде. Хәзер инде анарда тундырмадан буялган кием түгел, ә күккә очып менеп китеп, өрәктәй юкка да чыккан Нуриев кайгысы иде. Мондый ачык авызлык күрсәтеп, аягыннан эләккән асыл кошны кулдан ычкындырган өчен баштан сыйпамаслар! Хуш, майор, хуш, подполковник погоннары диярргә генә калыр микәнни сон?

Юк, ятып калганчы—атып карарга кирәк! «ТУ» самолеты Мәскәүгә очып китәргә әле тагын ярты сәгатьләп бар. Эзләп тап качкын чикерткәне һәм, богау киертеп, бүтән сикермәслек ит! Их, башта ук шулай эшләгән булсачы! Имеш, Франция жире! Имеш, кеше хокукларын бозып, халыкара гауга килеп чыкмагае! Нидән куркып торырга—Франциядә бит элек-электән коммунистлар өстенлек итә. Бастилия!.. Жанна де Арк!.. Ә коммунистларның рухи Ватаны кем? Советлар Союзы! И Стрижевский, Стрижевский!.. Сынаттын бугай син бу юлы, бик нык сынаттын!

Ачудан кып-кызыл булып бүртенгән, мангае шабыр тиргә баткан

Стрижевский, тамаша карарга җыелган юлчыларны богылдай таза гәүдәсе белән як-якка ерып, алга ташланды. Менә ул Нуриевны йолып алуда катнашкан куе яшел киемле, биек фуражкалы чик сакчыларының берсен аюныкыдай юан куллары белән якасыннан эләктереп алды да:

—Кая куйдыгыз безнең биючене? Ни хакыгыз бар?—дип ысылдый-ысылдый, тарткалый-йолыккалый башлады.

Ләкин Грегори Алексински ярдәмчесе комиссар Жаго Лаш та тазалык өләшкәндә читтә торып калганнардан түгел иде. Тәбәнәк кенә гәүдәле булса да, ул төптән алдырган юан гәүдәле һәм, өстәвенә, француз көрәшенең дә бик күп вә хәйләкәр алымнарын белә иде.

—Табып китерегез Нуриевны! Юкса...—дип тәкерек чәчүен дәвам итте Стрижевский.

—Кайда, кем җирендә басып торуыгызны онытмагыз, месье...

—Өркетмә, комиссар! Сезнең кебек комиссарлар безнең үзебездә дә буа буарлык.

Чик сакчысы Жаго Лашның капитан Стрижевский шатырдатып тарткан якасы ертылып ук чыкты. Эшләр болайга киткәч, юан-йомры гәүдәсе белән Стрижевскийның үшән корсагы астына йомгак кебек тәгәрәп керде дә, комиссар Лаш авыр түшкәне кунадай жилкәсе аша чөеп тә җибәрде! Стрижевский барып төште бер якка, куен кесәсендәге пистолеты—икенче якка. Һәм шуның белән әле кайчан гына кодрәтле иминлек сакчысы шым булды.

Ә могҗизалы сикерүеннән соң әле һаман еш-еш сулыш алган Рудольфны, сәяси сыену сорау турындагы рәсми кәгазьләрне тутыру өчен, икенче каттагы махсус бүлмәгә чакырып алдылар.

—Менә сезгә аерым бүлмә,—диделәр аңа.—Күрәсезме, ике якта аның ике ишеге бар. Ул ишекләрнең берсе полиция бүлмәсенә, икенчесе исә тагын ярты сәгатьтән Мәскәүгә очып китәчәк «ТУ»лайнеры янына алып чыга. Кайсы ишекне сайлыйсыз—монысы сезнең ихтыярда! Ашыкмыйча тагын бер кат һәм соңгы мәртәбә уйланыр өчен, Женева конвенциясенең халыкара кануны буенча, сезгә унбиш минут вакыт бирелә.

Ишек йозагын тышкы яктан бикләп, полицейскийлар чыгып китте. Рудольф исә авыр да, ымсындыргыч та уйлары белән ялгызы гына торып калды.

Әйе, ике төрле язмышка алып чыга торган ике ишек! Аларның берсе, элеккечә,—коллыкка, икенчесе исә хөрлек, азатлыкка карап ачыла. Кайсын сайларга?

Бүлмәдәше Юрий Соловьевка төнге массаж ясаганда «тотылганы» һәм Париждагы бүтән төрле зур вә кечкенә гөнаһлары, ягъни кумәк сафта атлап йөри белмәгәне, дөресрәге, теләмәгәне өчен, аны СССРда җиде еллык токтынлык, сасы төрмә көтә. Әти-әнисе һәм апаларына, рухи хурлыктан тыш, моның әлләни зыяны тимәс тиюен. Ә чит илдә калган очракта? Ул иректә булып, аның гөнаһлары өчен туганнарын төрмәдә интектермәсләрме? Юктыр кебек... Ни дисәң дә, хәзер Сталин заманнары түгел, ә Хрущев җепшеклеге дәвам иткән көннәр бит! Һәрхәлдә, барысы да Рудольфның чит илләрдә үзен ничек тотышыннан, аның бию өлкәсендәге уңышлары һәм җиңүләреннән бәйле булыр кебек.

Үз-үзенә ныклы ант биргәндәй, Рудольф йодрыкларын тагын да кыса төште һәм ныклы адымнар белән полиция бүлмәсенә алып чыга торган ишеккә таба юнәлде. Анда аны чик күзәтчелеге хезмәтенең башлыгы Грегори Алексински кочагын җәеп каршы алды:

—Ирекне сайлый алуыгыз белән чын күңелдән котлыйм, месье Нуриев!

Буш бүлмәдә берьялгызы бикләнеп утырып, Рудольф артык дулкынланган иде. Шуңа күрә ул кыюсыз һәм басынкы тавыш белән генә әйтеп куйды:

—Рәхмәт...

Алексински Рудольфка берничә чиста бланк кәгазе сузды:

—Ә хәзер, сәяси сыену сорауны законлы төскә кертү өчен, менә бу рәсми документларны тутырып бирерсез, месье Нуриев!

Үзенә атап әйтелгән «иптәш» түгел, ә күнеленә күптән якын «месье» сүзен ишеткәч, ничектер, Рудольфка бик сәер һәм рәхәт булып китте. Французча язылган бланк кәгазьләрен тотып, менә ул өстәл янына килеп утырды. Ләкин бая гына шундый җаваплы адымны ясар алдыннан уянган шом анын күнелендә һаман басылып өлгермәгән иде әле. Коммунистик кызыл кыйблага табынулары белән бүтән капиталистик илләрдән бик нык аерылып торулары инде хәтта тарихларга кереп калган хәйләкәр французлар, хәзер генә колакларына житкәнче елмайгандай кыланып, иртәгә аны Париждагы совет илчелеге кулына тапшырырга җыенмыйлармы? Бәлки, чик аша мондый хөр сикерүне Англиягә баргач ясарга кирәк булгандыр? Ләкин ана мондый мөмкинлек биреллеме сон? Лондон дигән янгырлы вә дымлы калага үзе түгел, анын бер кочак балет чүәкләре белән уенчык электр поезды һәм дә китаплары, шулай ук биелми калган балеттагы Фәрхад роле өчен кирәкле яшел тукыма салынган кара чемодан-сумкасы гына китеп барды бит!

Рудольфнын жанында кайнаган шомлы шикләрне раслагандай, төйнәлгән йодрыклы кулларын ярсып селки-селки, полиция участогы бүлмәсенә ак кәстүм-чалбарлы, шома итеп таралган саргылт чәчле дипломат Михаил Клейменов килеп керде. Франциядәге совет илчелегенен мәдәният мәсьәләләре белән шөгыльләнүче бу хезмәткәрен, дөресрәге, погонсыз шымчысын Нуриев элек тә күргәләгән иде.

—Советлар Союзы гражданы Нуриев кайда? Нигә аны безнен рөхсәтсез алып киттегез?—дип тамагы ярылганчы акыра башлады ул, керә-керешкә.

Ләкин сабыр-тигез тавышлы Алексински аны бик тиз тиешле урынына утыртты:

—Тынычрак булырга кинәш итәм: бердән, монда Мәскәү дә, совет илчелеге дә түгел; икенчедән, Нуриевны без алып китмәдек—ул безгә үз теләге, үз аяклары белән очып килде.

—Очып? Ничек инде... Кош түгел бит ул очарга?.. Хәзер без анын үзеннән сорыйк, алайса,—диде дә, июнь эссесендә ак күлмәк якаларын артык кысып торган кызыл бөрчекле галстугынын бала йодрыгы тикле зур төенен аска шудырып бушаткач, ул бераз иркен сулыш алып торды. Аннары симез муены һәм тар мангаендагы тир тамчыларын кульяулыгы белән сөртеп алгач, сүзен дәвам итте:—Мин әле генә ишеткәннәр чынмы, дөресме, Нуриев?

—Дөрес.

—Нәрсә... Әллә син Советлар Союзы дигән бөек Ватаныбызга бөтенләй кайтмаска булдынмы?

—Нәкъ шулай, месье Клейменов!

Француз булмаганнарнын күбесен кытыклый торган әлеге дә баягы «месье» сүзен ишеткәч, совет илчелеге хезмәткәре тәмам ярсып чыкты:

—Месье, имеш... Ах, ашаган табагына төкергән поганый татарчонок! Ах, эт баласы! Әле син шулаймы?—диде ул һәм Рудольфнын болай да уттай кызган янак төбенә бар көченә китереп сукты.—Мә, алайса, теләгәненне ал, симергән кол!

Нишләтәсен, кол булгач—түзми хәлен юк!

Совет илчелеге хезмәткәренен үз янагыннан ут чыгарып җавап бирми калу горур жанына никадәрле генә кыен булмасын, киләчәге хакына эшне зурга җибәрмәс өчен, Рудольф бу юлы ярсу хисләрен йөгәнли алды. Анын каруы, большевикларга карата талканы күптәннән коры булган полиция комиссары Грегори Алексински эшне тиз тотты:

—Инде күрдегез, ишеттегезме Нуриевнын сәяси сыену сораганын? Менә анын өстәлендә—тиешле документ бланклары. Хәзер ул аларны тутырачак.

Ә сезнең белән, месье Клейменов, хәзергә сөйләшер сүз бетте. Кем әйтмешли, алдыгызга карагыз да—атыгызны куалагыз!

Рудольф Нуриевның чик аша бу хөр сикерүе өчен тиздән үзенә шәп кенә тукмак эләгәчәген яхшы аңлаган Михаил Клейменов, ишекне бөтен көче белән шапылдатып ябып, ниһаять, чыгып китте:

—Ә бу башсызлыгы өчен Нуриевның үзенә дә, аны канат астына алып маташкан акгвардияче эмигрантлар һәм кайбер бүтәннәргә дә шәп кенә эләгәчәк әле!

Менә син ә—Грегори Алексинскиның катлаулы үткәне хакында берни белмиләр дип йөр син аларны! Күрмәсләр, сизмәсләр—шуның өчен дә азу ярган совет чекистлары бит инде алар.

Ле Бурже аэропортында ярты сәгать элек кенә булып алган гаҗәеп һәм гыйбрәтле хәлләр турында ул арада сизгер журналистлар да белеп өлгерде. Үз укучыларына мондый да кызыклы, мондый да мавыктыргыч хәбәрне сәгате-минутында җиткерергә ашкынган каләм әһелләре качкын биюче бүлмәсен тоз сипкәндәй сырып ала башладылар. Аларның бер-бер артлы агылган сорауларыннан котылыр әмәл калмагач, Рудольфка иркенләп тиешле документларын тутыру мөмкинлеген бирү өчен, Клара Сент дилбегәне үз кулына алырга һәм кыска гына матбугат конференциясе уздырырга мәҗбүр булды.

Качкын биюченең легендар сикерүле гамәленә бәйле сораулар гаять күп һәм төрле яклатып бирелде:

—Рудольф Нуриевның сез кеме буласыз: чираттагы гашыйкасымы, әллә инде ярәшелгән кәләшеме?

—Берсе дә түгел, без аның белән чын дуслар гына әлегә.

—Ә киләчәктә?

—Анысын инде киләчәк үзе күрсәтер.

—Ә министр улы Винсент? Бер ай элек кенә һәлак булган ярыңны шулай тиз оныту мөмкинме?

—Минем аны онытканым юк.

—Ә Рудольф?

—Ул миннән моны таләп итми.

Аргентина һәм Чили гашыйкларының кайнар канынннан яралып, чегән арбасыннан төшеп калган бу кара чутыр кызның авырткан җиреннән тиз генә эләктереп булмауны аңлагач, очлы күзле, сизгер колаклы каләм әһелләре Рудольф Нуриевка бәйләнешле сорауларга күчтеләр. Соңгы елларда бөтен җиһанны, хәтта Америка хәтле Американы Кубадагы ракеталары белән дер калтыратып тора башлаган совет империясе идеалларын, халыклар дуслыгы, кеше ирегe дигән ялган кыйммәтләрен фаш итеп берьялгызы каршы күтәрелгән һәм ахыр чиктә җиңеп чыккан бу легендар татар егете турында инде байтак нәрсәләрне белеп өлгергән иде алар. Хәтта бөтен кирәк-яраклары салынган юл сумкасының хезмәттәшләре белән Лондонга китеп баруын да!

—Нуриевнын Лондонга китеп барган юл сумкасында ниләр булды икән—шуны әйтә алмассызмы?

—Балет чүәкләре.

—Монысы аңлашыла. Тагын?

—«Мәхәббәт турында легенда» балетындагы Фәрхад роле өчен тегелергә тиешле затлы тукыма.

—Бу балет гастроль репертуарында юк иде бит. Ул тукыма нигә кирәк булды икән?

—Ленинградка әйләнеп кайткач, Киров театры сәхнәсендә ул бу рольне һичшиксез биисенә өметләнеп яшәде.

—Туктагыз: бу—бик мөһим! Димәк, Рудольф Нуриев Франциядә калачагын Ленинградтан ук планлаштырып килмәгән булып чыга?

—Әйе, чемодан-сумкада Лондонга китеп барган яшел тукыма—моның бик саллы һәм ышандыргыч дәлиле!

—Үз акчасына сатып ала-ала, тиздән башкарасы роле өчен кием-салым җыймаса... Фәрхад образын Рудольф Нуриев нигә шулай яратты икән?

—Үзе дә татар һәм «Мәхәббәт турында легенда» музыкасы көнчыгыш мотивларына бик бай булгангадыр.

—Ленинградтан киткәндә үк Франциядә калырга уйламагач, ул бу артык җитди һәм җаваплы адымны нигә ясады икән?

—Чөнки аны мәҗбүр иттеләр.

—Ничек итеп?

—Хрущевның үзеннән, имештер, Мәскәү Кремлендә бию өчен ялган чакырту җибәрттереп.

—Моның ялганлыгын ничек дәлилли аласыз?

—Гастроль башлыгы Сергеев Лондонга китеп баручы театр артистларына,имештер, Нуриевның әнисе каты авырган—ул шуна күрә башта Уфага кайтып килә дигән хәбәр тараткан.

—Мәкерле алдашулар нигә кирәк булды икән?

—Рудольфны Мәскәүдәге Лефортово төрмәсенә ябып куймакчы булдылар.

—Нинди гөнаһлары өчен?

—Бүлмәдәш биючесенә төнге массаж ясавы өчен.

—Төгәлрәк аңлатып китсәгез икән.

—Төнге массаж дигән бу провокацияне махсус оештырдылар.

—Кемнәр?

—Театр җитәкчеләре һәм совет илчелегенә кереп оялаган чекистлар.

—Нигә?

—Рудольфның койрыгын ялган җинаять эшенә бәйләп куеп, аны даими куркыту, аңа басым ясау өчен.

—Тагын?

—Рудольфның иң төп гаебе шунда: ул—дөньяның булачак һәм, һичшиксез, бөек биючесе! Әнә шуңа Советлар Союзында аннан көнләшәләр, әнә шуңа юл бирмиләр. Өстәвенә, татар да булгач...

—Аның татарлыгы ни дәрәҗәдә? Ана телендә сөйләшәме?

—Татарчаны яхшы аңлый, начар сөйләшә.

—Нигә икән?

—Чөнки хәрби хезмәттәге әтисенә ияреп, кечкенәдән бер рус шәһәреннән икенчесенә күчеп йөргән, күбрәк руслар белән аралашып үскән.

—Ә әнисе ни караган?

—Яшәү шартлары бик кыен—ачлык-ялангачлык булганлыктан, фронтка киткән иреннән дүрт сабыен кочып калган ана кеше бу мәсьәләгә шулай ук тиешле игътибар бирә алмаган.

—Аңлашыла...

Клара Сентка сокланмыйча мөмкин түгел иде. Рудольф Нуриевның шәхси сәркәтибе диярсең! Хәйләкәр һәм усал телле каләм әһелләренең турыдан ярып биргән сорауларына ничек чатнатып кына җавап биреп тора! Нибары ике—өч атна эчендә алар ничек шулай бер-берләренең эчке һәм тышкы серләрен белеп өлгерә алганнар? Бу хәл үзе генә дә алар арасында урнашкан чын дуслык хакында ышандырып сөйли иде.

Качкын биюче турындагы төпле һәм үтә кызыклы мәгълүматларын бик теләп уртаклашкан Клара Сентка, ниһаять, бүгенге очрашуның соңгы сораулары бирелде:

—Чемоданы Лондонга китеп барган Нуриев бер кат күлмәк—ыштаннан һәм бер тиен акчасыз калган диләр. Ул ничек яшәр икән?

—Юкка борчыласыз. Беренче көннәрдә француз дуслары булышыр.

—Ә киләчәктә?

—Биегән кеше бай була диләр. Дөньяның иң бөек биючесе булачак Рудольф Нуриевның бар җиһанда иң бай кешегә дә әверелер көннәре алда әле. Менә күрерсез!

—Шулаен-шулай да ул... Әгәр менә хәзер без—шушы гаҗәеп мөһим сөйләшүдә катнашкан халыкара журналистлар да Нуриевка ярдәм йөзеннән бераз акча җыеп бирә алсак?

Клара Сент бу тәкъдимгә теше-тырнагы белән каршы төште:

—Яхшы ниятегез өчен рәхмәт, билгеле. Ләкин юк-юк! Нинди ярдәм ди ул! Минем мәгълүм эшкуар кызы икәнлекне яхшы беләсездер дип уйлыйм. Шуңа күрә Рудига беренче дәрәҗәдә кирәкле кием-салымнар һәм балет чүәкләре сатып алуда һичнинди кыенлык тумас дип уйлыйм.

Ләкин юмарт күңелле каләм ияләре монарчы күрелмәгән матбугат конференциясе үткәреп көн героена әйләнгән Клара Сентның ай-ваена карап тормадылар. Һәр гәҗитнең баштагы битендә бирелә торган кыска хәбәрне укып чыгарлык вакыт узды микән, юк микән, кулдан-кулга тапшырылып, бер кочак акча җыелып та өлгерде.

Кылынган изгелекне кабул итмичә ярамый иде.

Француз франклары, немец маркалары гына түгел, арада йөз, хәтта мең долларлы АКШ акчалары да булган валюта өемен тигез рәтләргә бүлә-бүлә җыйды да, башындагы чәчбугыч бавын салып, Клара Сент аларны бергә бәйләп куйды. Һәм, көтелмәгән бүләкне тиешле иясенә тапшыру өчен, Нуриев бланклар тутырып утырган бүлмә ишеген шакыды.

Ишекне Рудольф үзе ачты:

—Ә-ә, Клара!..Әйдә-әйдә... Бик вакытлы кайттың! Теге бланкларны әле яңа тутырып бетердем...—диде ул, кош тоткандай балкып.—Ә-ә, гафу ит—күрмичә дә торам икән. Нәрсә бу?

—Акча...

—Нинди акча?!

—Менә, Руди, пресс-конференциядә катнашкан халыкара журналистлар, акча җыеп, ярдәм йөзеннән сиңа тапшырырга куштылар.

—Пресс-конференция? Акча?!

Зур-симез төргәкне Клара Сент Рудольфка сузды:

—Мә, ачып кара башта. Аннары барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирермен.

Рудольф авыр чакта ярдәмгә килә белүче адәм балаларының изгелеге салынган кадерле төргәкне чишеп җибәрде. Бөтен өстәл өстен тутырган Франция франкларын, Германия маркаларын, АКШ долларларын күргәч, шытырдап торган шул акчаларны кочаклый-кочаклый, ул кинәт үкси-үкси елап җибәрде. Соңгы көннәр, соңгы сәгатьләрдә күргән—кичергәннәрдән нечкәргән күңел, язгы Сена елгасы кебек, ярларыннан ташып чыгарга гына тора иде шул!

Шытырдавык кәгазьләр өстенә, тып та тып килеп, татлы күз яшьләре тамды. Төрле тәнле, төрле телле, төрле иман-кыйблалы адәм балаларының нибары бер изгелеге тамдырган илаһи тамчылар иде болар!

## 12

Рудольф ишек кыңгыравы тавышына сискәнеп уянды.

Күзгә төртсәң күренмәслек мондый кара төн уртасында кем, нинди адәм йөрер икән? Әллә Франциядәге совет илчелегенә бу көннәрдә күпләп оялаган чекистлармы? Имештер, туган иленә хыянәт иткән Рудольф Нуриевны алай-болай Мәскәүгә урлап китәргә килмәгәнме алар?!

Париждагы Ле Бурже аэропортында бер көн элек кенә булып алган хәлләр исенә төште дә, Рудольф күңеленә чын-чынлап шом йөгерде. Кичә кич аны яшерен фатирга озатканда француз полицейскийлары да:

—Карагыз аны, месье Нуриев! Кемнәр генә, кайчан гына килеп шакымасыннар, тиешле вакыты җитми торып, фатирыгыз ишеген һичкемгә ачасы булмагыз!—дип колагына кат-кат кисәткәннәр иде.

Рудольф та түземсезләнеп сорап куйган иде:

—Ә ул вакыт кайчанрак җитәр икән соң?

—Бер атналап узгач... Вакыйгалар агышына карап...

—О-о, котәселәр озак икән әле! Ә телефон?

—Үзегез дә шалтыратмагыз, бүтәннәргә дә җавап бирмәгез!

—Ә бөтенләй өзеп куйсак?

—Алай да ярамый. Чөнки, шул телефон хәлләренә карап, совет чекистлары сезнең өйдә булу яки булмавыгызны белеп торачак. Иң яхшысы—телефон трубкасын алмау...

Рудольф, тынлаусыз чәчләрен артка таба сыпыра-сыпыра, аптыраулы кыяфәт белән үз-үзенә әйтеп куйды:

—Да-а, кыз да утызда...

—Яшерен фатир тәрәзәсенә калын пәрдә эленгән. Аны бер читеннән күтәреп, алай-болай каршыдагы бакчага күз ташлый күрмәгез, месье Нуриев!

—Ә нигә?—диде һәртөрле тыюларны кечкенәдән җаны-тәне белән сөймәгән Рудольф.

—Чөнки ул бакчага караган караңгы тәрәзә совет чекистлары тарафыннан бик көчле күзәтү астында тотылачак.

—Димәк, ничә көн ялгыз...—диде Рудольф, үз язмышыннан канәгатьсезлек белдереп.—Димәк, иректә төрмә?

—Түзәргә туры киләчәк, месье Нуриев!.. Киләчәк көннәрегезнең ирекләге хакына...

Күңел түренә кереп оялаган шомны арттырып, ишек кыңгыравы тагын, тагын чыңлады.

Юк, төнге ишек кыңгыравы тавышыннан гына шыр җибәрә торган кеше түгел иде анысы Рудольф. Ләкин белә торып совет чекистлары куйган тар муенлы шешә авызына барып керергә дә ярамый иде.

Ә ишек кыңгыравы һаман чыңлады да чыңлады. Инде нишләргә!

Курыкканга куш күренер дигәндәй, тукта, чү! Бу бит калын-тыгыз чыңлы ишек кыңгыравы түгел, ә суярга алып барган дуңгыз баласыныкыдай нечкәәче тавыш белән ишек төбендәге телефон аппараты чыелдый икән бит, ләбаса!

Моны аңлагач, Рудольф:

—Уф-ф!..—дип хәтта җиңел сулап куйды.

Ә каһәр телефон һаман чыелдавын белде.

Ятагыннан тиз генә сикереп торды да, күптән күнегелгән гадәте буенча, Рудольф кызыл телефон трубкасына үрелмәк булды. Ләкин бармаклары килеп орынуга, аның бөтен кулы, бөтен тәне пешеп киткәндәй тоелды.

Аптырагач, тавышы басылсын өчен, ул аны як-яктан берничә мендәр белән каплап куярга мәҗбүр булды. Телефонның эчпошыргыч чырылдавы тиздән ишетелми башлады башлавын. Тик күңел, җан тынычлыгы гына һаман кайтмады.

Алла—ничәдер көнлек ялгызлык!

Тукта!.. Һәр михнәтнең бер рәхәте булмый калмас дигәндәй, ул бит хәзер ашыкмый-кабаланмый гына хәтерли, үткән көннәрен искә төшерә ала икән әле! Менә боларын инде, шөкер, беркем дә тыя алмый.

Иң беренче булып, әлбәттә инде, Ленинградтагы атаклы Киров театры сәхнәсенә тәүге кат аяк баскан көннәре искә килеп төште...

...Рудольф эшкә алынуга, кышкы сезон тәмамланып, Ленинградның Киров театры артистларын чираттагы ялга тараттылар. Кара диңгез буендагы ял йортына бушлай юллама кесәдә иде инде. Рудольфка аны укуын бик уңышлы тәмамлаган өчен бирделәр.

Инде хәзер Кара диңгезнең ак сыртлы дулкыннары кочагында бераз иркәләнеп, ял итеп кайтырга да була. Оят түгел! Син моңа Питер каласында кара тиренне агызып ирештең, Рудольф!

Әйе, болары шулаен шулай. Тик Уфадагы әти-әнисе, өч газиз апасы ничек яшәп ята икән анда? Юк, башта аларның хәлен белеп килми торып, тәртәне Кара диңгез якларына борырга һич кенә дә ярамый иде. Тыныч күңел белән

китмәгәч, ял була димени ул! Рудольфның чит җирләргә гастрольләр белән баргач алып кайткалаган менә дигән күчтәнәчләре дә бар иде: әнисенә—чәшке тиресеннән тегелгән затлы тун, буш вакытларында ауга чыгарга яраткан әтисенә—ике көпшәле мылтык, апаларына—затлы өс-баш, бизәнү кирәк-яраклары. Аларның һәммәсе дә остазы Пушкин фатирында саклана иде. Шуларны тиз генә барып алды да, чәй дә эчеп тормыйча, чыкты-китте Рудольф тимер юл вокзалына.

Әйе, әйе! Вакыты никадәрле генә тар-ашыгыч булмасын, Рудольф ерак араларга гел поездда утырып йөрергә ярата иде. Көпчәкләре тимер рельслардан келтер-келтер тәгәрәгән вагоннарда гаҗәеп авыр, ләкин ифрат кадерле балачак һәм яшүсмер елларынны искә төшерә-төшерә кайтулар искиткеч рәхәт бит ул! Аннары Рудольф бит—поездда барганда туган тимер юл баласы да әле!..

Уфа каласы аны урак өсте көннәрендә генә була торган эссе кочагына кысып каршы алды. Питер тарафларында ул белем эстәп йөргән өч ел эчендә биредәге хәлләр бөтенләй үзгәрешсез калган диярлек. Әти-әниләре белән өч апасы Зенцов урамындагы ике бүлмәле фатирда кысыла-кысыла көн күреп яталар. Уртанчы апасы Лилия үзе кебек үк телсез-чукрак ире Фәнилне йортка керткәч, тар тишеккә—тана башы дигәндәй, мондагы хәлләр бөтенләй түзеп булмаслыкка әйләнгән. Кайсыдыр шаяны хәтта коридор стенасына «Хәрәкәт кагыйдәләрен сакла һәм үтә!» дигән язу да элеп куйган. Болар бит барысы да әтиләре Хәмит фронтовик-майор һәм хәзер үзе эшли торган заводның торак бүлү комиссиясендә әгъза була торып әле! Юк, үзе һәм ишле гаиләсе өчен бөтенләй көрәшә белмәгән «намуслы коммунист» иде аларның әтисе. Һәм шулай булып калган да!

Ә үзе Рудольф алып кайткан ике көпшәле ау мылтыгына сабыйларча сөенде бит әнә!

—Рәхмәт, улым!—диде ул, сөенеч яшьләрен сөртә-сөртә.—Рәхмәт һәм, зинһар өчен, мине гафу ит!

—Ә ни өчен, әти?

—Яшүсмер елларында биючелеккә илткән юлларында бик күп киртәләр куйганым өчен.

—Кирәкмәс, әти... Буласы булган—буявы сеңгән дигәндәй...

—Сеңеп бетмәгән шул әле, улым, сеңеп бетмәгә-ә-ән...

—Нигә, әти?

Отставкадагы майор Хәмит Нуриевның бер сәер гадәте бар иде. Тормышның үзенә һәм ишле гаиләсенә кагылышлы байтак мәсьәләләрдә бик тыйнак булып кала белсә дә, ике сызык эчендәге зур йолдызлы өлкән офицер погоннарын күптән салса да, сугыш кырындагы батырлыклары өчен бирелгән хәрби орден-медальләреннән ул бик озак аерылырга теләмәде. Менә бүген дә Питер һәм Мәскәү сәхнәләрендә баш әйләнгеч уңышлар казанган бердәнбер улы кайту хөрмәтенә әнә шул бүләкләре тагылган яңа кәстүмен киеп җибәргән иде.

Алтмыш яшенә якынлашкан солдат, хәрби бүләкләрен чылтыратып, Рудольфка якынрак килеп утырды:

—Эш бит менә нәрсәдә, улым... Синең Мәскәү хәтле Мәскәү сәхнәсендә ничек биюеңне, завод клубына барып, бер киножурналдан әниең белән без дә карый алдык. Бик мактадылар үзеңне. Хәтта илнең генә түгел, бөтен дөньяның булачак мәшһүр биючесе дип тә бәяләделәр үзеңне.

—Ә нәрсә... Моңа сөенергә генә кирәк, әти!

—Сөендек, улым, бик сөендек!

—Соң?..

—Синең уңышларың күбәйгән саен, минем гөнаһларым да гел арта гына барадыр кебек... Бүтәннәрен инде әйткән дә юк... Уфаның яшь биючеләре Ленинградтагы кабул итү имтиханнарына инде күптән китеп беткәннәр—без быел соңга калганбыз дип алдашуым аркасында, син бит яшьтәшләреңнән

күпме соңга калып укый башладың. Хәтерлисеңме, улым?

—Хәтерлим, әлбәттә!

—Хәзер аңлыйм: мин бит синең кечкенәдән, бик бәләкәйдән талпынган хыялларыңны менә шушы кулларым белән буып ташлый язганмын, улы-ы-ым!

—Үз-үзеңне юкка бетермә, әтием! Аның карауы, мин кырыс тормыш куйган теләсә теләсә нинди киртәләрне сикереп үтәрлек булып, бәләкәйдән чыныгып үскәнмен. Менә... Үз максатыма барыбер ирешеп киләм бит, шөкер.

—Шулай дисеңме?.. Соңлап булса да аңына килгән әтиеңне аңлый белүең өчен рәхмәт сиңа, улым. Һәм, зинһар, мине кичерә күр!

Әтисенең инде каз тәпие сурәтләре кунган күз төпләреннән көмеш тамчылар тәгәрәп чыга башлавын күргәч, үз итеп-якын итеп, Рудольф аны гомерендә беренче тапкыр бугай киң кочагына кысты:

—Кичерәм... Сиңа да зур рәхмәт, әти.

—Ә миңа ни өчен, улым?

—Үз ялгышыңны, соңлап булса да, таный алуың өчен!

—И улым, улы-ы-ым минем...

Күптән көтелгән бу хәлләрне бер читтән шыпырт кына күзәтеп торган әнисе Фәридәнең дә җанында бәхет чаткылары канат какты. Ул, урамда һәм хәтта тыгын өй эчендә кыздырган август эссесенә карамыйча, улы Рудольф бүләк иткән затлы туннны бер салды да, тагын киде. Аннары, ишек төбендәге озын көзге каршына басып, баш түбәсеннән урталай икегә бүлеп таралган, инде күптән чал йөгергән чәч көлтәләренә, җыерчыклы түгәрәк киң маңгаена, табак битле йөз-кыяфәтенә озак кына карап торды.

Әйе, килешә, бик килешә иде ана улы Ленинградтан алып кайткан затлы тун!

Шулчак зур көзге каршында көязләнеп маташкан кадерле әниләре янәшәсенә газиз балалары килеп басты.

—Мондыйлар да затлы тунны әниеңнең әле беренче киюе. Рәхмәтләр яусын инде, улым-күз нурым! Аяк-кулларың сызлаусыз була күрсен!—диде әнисе Фәридә, кош тоткандай балкып. Һәм ире Хәмиткә күз ташлый-ташлый, өстәп куйды:—Кем уйлаган бит ә, кемнәр генә уйлаган...

—И-и... Бигрәкләр дә килешә инде үзеңә!—диде өлкән кызы Роза, әнисе өчен сөенеп бетә алмыйча.

Кече кызы Резидә дә шундый ук сөенү хисләрен белдерде. Ә менә уртанчы кызы Лилия, телсез булганлыктан, кулларын нарасый балалар кебек чәбәк-чәбәк китереп кенә куйды.

Тун шатлыгына бәйләнешле иң мөһим, иң куанычлы сүзләрне исә Рудольф үзе әйтте:

—Инде шушы туныңны киеп, быел кышын әти белән Ленинградка барырга һәм Киров театры сәхнәсендә улыгыз биюен карарга насыйп булсын, әнием!

—Барырбыз, улым, барырбыз... Рәхмәт үз итеп чакыруына!

Ата кеше ата кеше шул! Шундый да ерак һәм шөһрәтле сәфәрнең барып чыгасына ышанып бетмичә, ул кинәт сорап куйды:

—Ә без анда кайда йокларбыз соң, улым? Син үзең дә әлегә тулай торакта гына яшәп ятасың түгелме?

—И-и, әтисе!.. Бер кечкә—кер мичкә дигәндәй...

—Алай түгел, Фәридә! Без инде вокзалларда куныл йөри торган яшьтә түгел!..

Рудольфның алдан кычкырып, тумаган тайга атланып йөри торган гадәте юк иде. Шуңа күрә, театр җитәкчелеге вәгъдә иткән фатирны алмый торып, аның бу турыда берәүгә дә әйтәсе килмәгән иде.

Ә менә бу юлы әйтте. Кысан фатирда алты җан яшәп азапланган газиз туганнарын тагын бер кат сөендерү өчен әйтте:

—Сез килгәндә инде минем дә Питер каласында үз фатирым булыр, шәт.

Театрга эшкә алганда шулай дип ышандырдылар.

Көтелмәгән бу хәбәр өйдәгеләргә шифалы тәэсир итте:

—Чынлапмы, улым?

—Булдыргансың, энекәш!

—Менә бу, ичмасам, сөенеч!

Дөрестән дә, куанмаслык идеме соң?! Алар Уфадагы кысан фатирда ничә жан һәм ничә ел газап чигәләр. Ә Рудольф, әле кайчан гына өстәл астында мүкәләп йөргән малай, укып бетерүгә үк, Ленинград хәтле Ленинградта берүзенә бөтен уңайлыклары булган аерым фатирга ия булсын әле! Әйе, Уфадагылар өчен шаккатыргыч хәбәр иде бу.

Энесенә тиздән биреләчәк яңа фатир турындагы хәбәргә иң сөенгән кеше өлкән апасы Роза булгандыр, мөгаен. Ана инде утыз тулып килә. Ә үз оясын һаман әле кора алганы юк. Тар тишектә кысылып яшәүдән ул инде тәмам гарык булган һәм аның күптән бу газаптан каядыр чыгып качасы килә иде. Менә бит, жан биргәнгә—жүн бирер дигәндәй, жае чыгып тора түгелме соң, Ходаем! Энесе Рудольф яшәсен инде, энесе! Һәм өлкән апасының күптәнге теләгенә каршы гына килә күрмәсен!

—Энем жаным, булачак ул яңа фатирыңа мин дә сыя алмам микән?—диде ул, ниһаять, икәү генә калгач.

—Ә ник сыймаска?—диде Рудольф, бу тәкъдимгә шундук риза булып.— Һәм син бик дөрес әйтәсең, Роза апам! Ник дигәндә, балалар бакчасындагы тәрбиячелек эше Питерда да табылмый калмас, чөнки педучилищеда укып алган махсус белемең бар. Аннары, үзең әйтмешли, мондагы кысырык та аз гына кими төшәр.

Үзе дә кечкенәдән бию түгәрәгенә йөреп, сәнгать дөньясына тартылып үскән Роза апасы газиз энесен чын күңелдән якын итеп жылы кочагына кысты:

—Нинди генә рәхмәтләр әйтим икән инде сиңа, и энем-бәгърем! Бу изгелегеңне өлкән апаң һичкайчан онытмас—менә күрерсең...

—Шулай була күрсен инде, Роза апам!

## 14

Киров театрында эшли башлавының беренче көннәрендә үк Рудольф буйсыну һәм баш июне белмәс горур холкын күрсәтеп өлгерде.

Күпләрне, аеруча урта һәм олы яшьтәге артистларны шаккатырган бу хәл иртәнге якта—театрның күнегүләр ясау залында булды. Еллар буе кабатлана килгән күптәнге гадәт буенча, үз урыннарының кайдалыгын яхшы белгән юка-жинел триколы биючеләр рәт-рәт тезелешеп бастылар. Картрак «аксакал»лар—сәхнәнең иң алгы өлешендәге беренче рәткә, урта яшьтәгеләр—бераз арткарак, ә Рудольф Нуриев белән Юрий Соловьев кебек берничә көн элек кенә эшли башлаган яшь әтәчләр—гомер-гомергә кордебалет чайкалган иң арткы рәткә.

Инде күнегүләр ясый башлыйбыз икән дип торган яшь биючеләрне гаҗәпкә калдырып, менә сәхнә уртасына... бер ләгән су чыгарып куйдылар. Сикерә-сикерә бии башлагач, балта элеп куярлык тузан күтәрелмәсен өчен, башта әнә шул суны сәхнә идәненә сибеп чыгарга кирәк икән! Һәм, әлбәттә инде, мондый «кара» эшне моңарчы гел яшь-яшелләр генә башкарып килгән. Нишләтәсең, күптән ныгып урнашкан гадәт! Аңа каршы берни кыла алмыйсың.

Менә театрның баш балетмейстеры Константин Сергеев сәхнә алдына чыгып басты:

—Күптәнге традицияне бозарга беркемнең дә хакы юк! Йә, кемнән башлыйбыз? Юрий Соловьев, Рудольф Нуриев?.. Кайсыгыз кыюрак—сулы ләгән янына рәхим итегез!

Мыскыл итүгә корылган мондый гадәтләрне Рудольфның кечкенәдән жене сөймәде. Шуна күрә, йодрыкларын төйнәп, ул шыпырт кына арткы рәттә басып торуын белде. Башта Юра сибеп күрсәтсен әле! Ә иртәгә, кирәк дип тапса, ул сибәр.

Менә озын-төз гәүдәле, гөнаһсыз һәм юаш-зәңгәр күзләреннән әүлиялек сыйфатлары бөркелеп торган, Киров театрында Рудольфның булачак бердәнбер көндәше Юрий Соловьев сулы ләгән янына килеп басты. Һәм, бернинди кружка-фәлән кебек савыт булмаганлыктан, ул суны ничек сибәргә белмичә, аптырап тора башлады.

Ә карт артистларга теш агарту өчен шул гына кирәк тә:

—Яшь биюченең осталыгы идәнгә су сипкәндә күренә дә!

—Сип, әйдә, сип!.. Беләсең килсә, тузан чыгартмас өчен генә түгел, яшь биючеләрнең ныгып житмәгән табаннары таеп егылмас өчен дә кирәк ул.

—Ха-ха-ха!.

Аксакал артистларның шаркылдый-шаркылдый көлүләре Рудольфны тәмам чыгырыннан чыгарды. Менә ул кызларныкы төсле матур күз төпләреннән инде тозлы тамчылар тәгәрәп төшә башлаган Соловьев янәшәсенә чыгып басты да сулы ләгәннең бер тоткасына ябышты:

—Ә син, Юра, иртәгә сибәрсең. Бүген—минем чират!

Рудольф сулы ләгәнне ике колагыннан тотып күтәрде дә башта үзе басып торган турыга илтеп куйды. Аннары ләгән төбендә яткан леперддәвек яфраклы мунча себеркесен селки-селки, үзе күнегүләр ясый торган нибары бер карыш урынны гына чылатып чыкты. Һәм шул себеркесен тамашачылар бүләк иткән чәчәк бәйләмедәй күкрәк турысына кысты да, эшнең тәмам икәнлеген белдереп, керпе энәсе кебек тырпайган тынлаусыз чәчле башын аска иде. Ягъни мәсәлән, бушлай тамаша тәгәлләнде—карап торуыгыз өчен зур рәхмәт!

—Ә калган жиргә кем сибә?—диде шулчак кемдер, ачулы тавыш белән.

—Мин үземә тиешлесен сиптем. Ә калганына инде, кемнең тузанда биисе килми, шул сипсен!—диде Рудольф һәм, Чайковскийның мәшһүр балетында биегән горур аккошлар шикеле аяк бармаклары очларына вак-вак басып, күнегүләр залыннан ялт кына чыгып та китте.

Ишек каты итеп ябылуга, күнегүләр залында шау-шу купты:

—Ну и артист та соң бу мактанчык татарчонок!

—Артист кынамы—өлкәннәрне чүпкә дә санамаган чын эгоист!

—Театрга бер аягы кереп өлгермәгән, инде мөгез чыгарып маташа.

—Куарга кирәк андыйларны театрдан!.. Ничу монда...

Шулчак театр артистларын тетрәндергән тагын бер гажәеп хәл булып алды. Үзе укыткан хореография училищесын тәмамлап, күптән түгел генә биредәге балет труппасына кабул ителгән шәкертләренең хәлен белешеп кайту өчен килгән изге күңелле Александр Пушкин, эшне зурга жибәрмәс өчен, сулы ләгән янына чыгып басты һәм кулына баягы себеркене алды. Аннары, леперддәвек яфраклардан агып төшкән су тамчыларын идәнгә чәчрәтә-чәчрәтә, әрле-бирле йөренә башлады. Ул юеш себеркесен селкеп жибәрә дә, ниндидер сүзләр пышылдап, үз-үзенә әйтеп куя иде:

—Руденька өчен!..

Аннары тагын себеркесен селкеп куя:

—Сез ана, зинһар, үпкәли күрмәгез инде, хөрмәтле коллегаларым!

Кемдер: «Ә ни өчен әле...» дип каршы төшә башлаган иде дә, Александр Пушкин аны ярты сүздән бүлдерде:

—Чөнки Рудольф Нуриев—булачак бию тажы!

—Таж, имеш... Аңа бию тажы түгел, чыбыркы чажы кирәк!

Ә остаз хореограф, изге теләкләрен дога кебек пышылдый-пышылдый, яраткан шәкерте өчен идәнгә су сибүен дәвам иттерде:

—Руденька хакына... Зинһар, сез аны кичерегез!.. Чөнки ул—булачак гений!..

Остаз Пушкинның бу театрда кайчандыр үзе укытып чыгарган шәкертләре дә байтак иде. Менә шулардан берсе яраткан укытучысын гомер булмаган бу сәер гамәленнән туктатмак булып та карады:

—Иваныч дим... Йомырка тавыкны өйрәтми дисәләр дә, гафу итегез, әйтергә мәжбүрмен.

—Нәрсәне, Акимов?

—Ул артык горур Нуриевны яклаган булып, үз горурлыгыбызны югалтмыйк инде!

—Юк! Теләсә нәрсә диегез... Тик мин Руденькага сүз тидертмим!

—Нигә, Иваныч? Әллә ул Алланың кашка тәкәсеме?

—Әйе, кашка тәкәсе! Мин аның дөньядагы иң оста, иң мәшһүр биюче булачагын, беләсегез килсә, моннан өч ел элек үк күреп алдым.

—Ай-һай... Арттырмыйсыз микән, Иваныч?

—Менә аз гына сабыр итегез. Моның шулай икәнлегенә үзегез дә күреп ышана башларсыз.

—Карарбыз, Иваныч, карарбыз...

Александр Пушкин башлаган эшен тәки азагынача җиткерде. Гаҗәеп талантлы һәм кабатланмас холыклы иң яраткан шәкерте өчен бөтен күнегүләр залын су белән чылатып чыкты. Киров театрынын бик күп биючеләре үз шәкерте өчен җанын да кызганмаган, алтмышын ваклый башлап, инде шактый олыгая төшкән чын остазның бераз сәер дә, ләкин шул ук вакытта ифрат гүзәл дә булган бу гамәлен, гаҗәпләнү катыш соклану белән башларын чайкый-чайкый, байтак озак карап тордылар.

Һәм яшь биючеләргә сулы ләгән күтәртеп, идән чылаттыру кебек мыскыллы шөгыль шуның белән туктатылды. Бу эшне, су торбаларындагы кранга шланг тоташтырып, нәкъ тиешле кешеләре—сәхнә эшчеләре башкара башлады.

Әйе, ни генә әйтмә, инде күптән чәчрәп торган үз холкы, үз иҗат йөзе булган яшь биюче Рудольф Нуриевның Киров театрына эшкә килгәч яуланган беренче җиңүе иде бу!

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Шәүкәт Галиев



# ХАЛКЫМ, СИН МОҢНАН ЯРАЛГАН...

## Бәлкем әле...

Үземне мин тыеп яшәдем,
Күп бурычлар куеп яшәдем.
Кайчак гөнаһ җыеп яшәдем—
Үз-үземә шулай бәйләндем—
Тәмам ревизорга әйләндем.
Белеп торам бит мин хәйләмне,
Нинди чакта дәшми калганны,
Фаш итмичә ата ялганны.
Сәбәп тапканымны акларга,
Сер бирмичә җиде ятларга
Үз гамәлләремне сакларга.
Үземнән мин туеп яшәдем—
Нигә болай дөртләп кабынам, дип,
Дәшмәс чакта телгә салынам, дип,
Эш узгачтын шулай күзәттем,
Алай булмам, диеп, төзәттем...
Мондый позиция уңайлы.
Бер мин генә әллә шулаймы?
Бәлкем әле мин дә түгелдер,
Уйлап кара, чордаш, бүген бер?

*Гыйнвар, 2001*

## Ни борчый?

Эч поша, бәреләм-сугылам,
Ник болай, ни җитми күңелгә?
Өченче көн илдә тантана—
Ә минем җан тыныч түгел лә...

Бәйрәмнәр күп бездә, алҗыта,
Ялкаулык, иңемнән төш тизрәк—
Каныммы уяткан, уйнаткан,
Канәгать булырлык эш кирәк!

---

Шәүкәт ГАЛИЕВ (1928)—*Татарстанның халык шагыйре; күпсанлы китаплар, шул исәптән биш томлы «Сайланма әсәрләр» авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Кешене хезмәттән аерсак,
Ни мәгънә кала бу дөньяда?
Төрмәдә гомергә эш бирмәү—
Үлемнән катырак зур җәза.

Күңеле йоклаган адәмнәр,
Хөрәсән йөрәкләр юк түгел.
Әмма бит гаепсез затларның
Җан асрар эшләре юк бүген...

...Дөньяның, илеңнең хәлләре
Тынычлап яшәрлек түгел дә—
Шәфкатьсез заманда һич кенә
Битараф булалмый күңел дә!

*Август, 2004*

## Ташлар ташламый

Туган җиремдә
Ташулар ташый,
Ташлар кубарып
Ярларны ашый.

Еракка китә—
Елга ашкына.
Төпкә ябышып
Кала таш кына.

...Бабайларыңның
Исемен сора—
Таш хәтерендә
Тарихлар тора...

Югалмыйм, дисәң,
Ташлама ташны—
Үкенеп ташка
Бәрмәссең башны!

*Июль, 2006*

## Заманча көрәш

Яхшы белән Яман
Алышалар һаман,
Ярышалар яман!
Авышалар һаман
Кайсы кая табан:
Берсе—алга табан,
Берсе—артка табан.

Кайчак адашалар,
Әллә алдашалар,
Исем алмашалар?

Көрәш бара һаман:
Яхшы аста калган,
Яман җиңеп салган—
Яман җисем алган...

Инде танып бакчы:
Кайсы аның Яхшы?
Кайсы аның Яман?
Көрәш бара һаман...

*Август, 2004*

## Табигать шаяртамы

Күз алдында, үсә кеше,
Вакыты җиткәч, туктый.
Ә бердәнбер әгъзасына
Андый чикләнү юк, ди.

Кызыксынып котәсездер—
Үсә кайсы урыны?
Юк, сез уйлаганы түгел,
Үсә икән... борыны!

Борын белән бергә үскән
Була кайбер түрәләр—
Түбәндәрәк калганнарны
Борын аша күрәләр.

Нигә нәкъ борыннар үсә—
Табигать шаяртамы?
Түрәләрдән көләме ул,
Әллә соң яратамы?

Тәнкыйть-мазар дип ялгышып
Чиртә күрмә борынга,
Тешең коелмасын дисәң,
Зур борынга орынма!

*Июль, 2004*

## Картаю—карт аюмы?

Кай арада килеп җиткән,
Искәрми, белми калдым,
Беренче күрүем ласа,
Беразрак шүрли калдым.

Туктале, дидем аннары,
Миннән артык төше юк,
Чепиләнгән күзләре дә,
Авызында теше юк.

Аяклары дер-дер килә,
Кинәт ташланмас әле,
Ходай үзе ташламаса,
Аю ашамас әле!

Бер дә куркыныч түгел лә,
Бигрәк инде бөрешкән,
Йоннары очкан, йончыган,
Үз хәле—хәл, бирешкән.

Менә нинди була икән,
Ул чын-чынлап картаю,
Минеке түгел, адашкан,
Бу хәтерсез карт аю!

Картаю—карт аю шул, дим,
Кызгандым чын йөрәктән.
Кызгандым да, оныттым да—
Кызлар кайта җиләктән!

*12 апрель 2002*

## Мәңгелек җыр

*Илдар Юзеевкә*[1]

Халкым, син моңнан яралган,
Җырда телең ачылган—
Язмышың булып тезелгән
Шагыйрьләр һәм гасырлар.

Халкым, син моңнан яралган,
Җырда рухың чагылган—
Канатларың күтәрелгән
Кол Гали кочагыннан.

Халкым, син моңнан яралган,
Җырыңда кайнар каның—
Һәр яңа чорда яктырып
Балкый Тукайның даны.

Халкым, син моңнан яралган,
Җырыңда йөз аклыгы—
Җәлилләрнең, Туфаннарның
Батырлыгы, сафлыгы.

Халкым, син моңнан яралган,
Җырың гел яңарасы—
Бездән киләчәккә үтеп,
Мәңгелеккә барасы!

*15 гыйнвар 1983*

## Сурәт гомер сорый...

Бу шомлы тыю-кисәтү
Әүвәл-әүвәлдән килгән:
Сурәт ясама, дигәннәр,
Ул гомер сорый, синнән!—

Сүзсез дә, җанлы шикелле
Күзләрен текәп карый,
Кайсы якка борылсаң да
Карашы синнән калмый.

Сихерме бу, тылсым мәллә,
Хикмәтләрен кем белгән?
Үземнән соң да яшәр дип,
Рәссам аңа җан өргән.

*Июнь, 2000*

---

[1] 50 яшьлегендә укылды.

## Оча торган кешеләр

Бала чактан бирле күрәм
Оча торган төшләрне—
Кул-канатларны кагынып,
Күктә очып төшкәнне.

Канатсыз да күтәреләм,
Сикерәм кыялардан—
Мондый хозур иркенлекне
Бөркетләр тоялардыр!

Эзәрлекләү янаганда
Котылам очып кына,
Алдымда ерак офыклар
Колачын ачып тора.

Елга,болыннар өстеннән,
Тауларны урый-урый,
Илһамланып гизеп йөрим,
Күкләрдә җырлый-җырлый.

...Борын заманда булган ди,
Оча торган кешеләр,
Бәлкем канатсыз очкандыр
Улчак минем ишеләр?

Ахрысы безнең каннарда
Шул могъҗиза саклана—
Сине күкләргә күтәреп
Илһамың канатлана!

*Июль, 2004*

## Теләк

*Исәннәрнең кадерен бел,*
*Үлгәннәрнең каберен бел!*

Зират диварында бу сүзләрем.
Күпме тарих монда күмелгән.
Исмем югалса да шул гыйбарәм
Калыр бәлкем халкым күңлендә:
Исәннәрнең кадерен бел...

Мәкаль булып очты бу шигырем,
Гомере бар чаклы яшәсен.
Минем сезгә үз тавышым белән
Үткәннәрдән килә дәшәсем:
Үлгәннәрнең каберен бел...

Казанымда «Татар зираты» бар...
Шом-сагышлар белән керәсең:
«Без китәрбез, сез каласыз», диеп
Милләт күмелер көн килмәсен...
Исәннәрнең кадерен бел,
Үлгәннәрнең каберен бел!

*30 октябрь, 1996*

Марат
Кәбиров

# ЕЛМАЮ

* * *

Сүзен тәмамлагач, Рөстәм Газизович мыек астыннан гына елмаеп куйды. Никадәр генә сиздермәскә тырышса да, телетапшыруны алып баручы кыз беркадәр дулкынлана иде. Гадәттә туры эфирда бара торган тамашаны алдан яздырып куярга уйлавы да шуннандыр. Әнә бит, бармак очларына кадәр сизелерлек дерелдәп тора. Укуын тәмамлау белән телевидениега килгән яшь кызның кичерешләрен анларга була, әлбәттә. Ниндидер җырчы яки колхоз алдынгысы белән әңгәмә үткәрү тенә түгел бу сина. Галимнәр республикада җитәрлек, анысы. Хәтта артыгы белән. Әмма монa кадәр беркемнен дә Нобель премиясен алганы юк иде әле. Рәсәй составындагы республикаларның берсендә дә юк андыйлар. Аннан сон, Рөстәм Газизовичның ачышы да башкалар белгән чагыштырырлык түгел, ул ясаган ачыш кешелек дөньясын бөтенләй икенче юлга, югарырак һәм яктырак баскычка борып җибәрергә сәләтле...

Карт галимне уйларыннан бүлдереп, алып баручының соравы ишетелде:

—Рөстәм Газизович, әйтегез әле, шундый зур уңышка ирешүегез белән үзегезне кемгәдер бурычлы дип саныйсызмы? Сезгә нәрсә этәргеч бирде?..

Галим дертләп китте, һәм аермачык булып күз алдына анын сыны басты. Мондый тапталган сорауларга шундый ук тапталган ярым рәсми җавап бирергә кирәклеген белсә дә, Рөстәм Газизович хисләрен йөгәнли алмады.

Фәрештә!

Көтмәгәндә юлына очраган таныш түгел гүзәлне күнеленнән генә шулай дип атады ул...

Әлеге хәлләр еракта, берничә дистә еллар артында калса да, Рөстәм Газизович аны янадан кичергәндәй булды...

* * *

...Ул күзен ачты. Томан аша акаеп караган дөньядан рәхим-шәфкать көтмәле түгел иде. Җәйнең кояшлы якты көне булса да, бөтен тирә-якны соры томан төргән, җитмәсә, ул томан бер урында гына да тормый, су өстендәге чоңгыл сыман булып бөтерелә, үзенә суырып алырга теләгәндәй тоела. Хәтта кояш нуры да шул вак соргылт кузәнәкләргә бәрелеп кечкенә кисәкчәләргә таркала һәм күңел болгаткыч бер төскә кереп өерелә башлый. Көтмәгәндә җил исеп куйды. Баш очында гына тупыл яфраклары бер-берсенә ышкылган калай тавышы чыгарып шаулаштылар. Ул хәтта җилнен дә земберләгәнен ишеткәндәй булды. Ул да булмый борынына чамасыз сасы ис килеп бәрелде. Шушы көтелмәгән дәррәү һөҗүмнән башы әйләнеп китте һәм ул үзе яткан эскәмиянең читенә чатырдап ябышты. Кинәт хәрәкәтләнүдән буыннары чиксез әрнеп алды, тик аны шундук башының сулкылдап-чатнап авыртуы кире каккысыз көчле дулкын булып күмеп китте. Бер мизгелгә дөнья һушын

жуйды. Тиздән, ярга бәрелеп кирегә агып төшкән дулкын сыман, барсы да үз урынына кайтты. Соры дөнья, ямьсез тавышлар, сасы исләр... Газаплар, Сызланулар...

Бераздан ул көч-хәл белән торып утырды. Тирә-якка карангалап алды. Бернәрсә дә күрмәде. Бу дөньяда көчле баш авыртуы белән буыннарның хәлсезлегеннән башка бернәрсә дә юк иде.

Озак утырды.

Бармак очларында кан йөгергән сыман булгач, кулларын кыбырдатып карады. Сулы белән эскәмиягә тотынган хәлдә, уң кулын акрын гына түш кесәсенә китерде. Бармаклары салкынча пыяла савытка тиюгә, бөтен тәнен рәхәт дулкын ялмап үткәндәй булды. Шешә!

Куенынннан чүлле шешәне тартып чыгарганчы ярты гомер үтте. Көчәнүдән аның чыраендагы мускуллар җыерылды, буыннары сызларга тотынды, маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Ә йөрәге, йөрәге дөньяның бөтен читлек-киртәләрен җимереп, әллә кайларга атылырдай булып типте. Кулларында калтыранган шешәне иренենә тидергәндә ул көчәнүдән шартлар сыман иде.

Салкын сыекча үнәчләрне кытыклатып төшеп китте. Ул аракының ачысын сизмәде, киресенчә, ничектер баллырак сыман тоелды. Бу тәмнән күңеле болгангандай итте. Әмма шундук бөтен күзәнәкләре хәмернен сихри көченә бирелеп ләззәтле тибрәнергә тотынды. Күзләрне томалап алган томан акрын гына тарала башлады, бераздан ул бөтенләй юкка чыкты да дөнья кабат үз хәленә кайтты. Дөнья ул кадәр үк котсыз түгел иде.

Кеше, моның чынлап та шулай икәненә ышанырга теләгәндәй, тирә-ягына каранып озак утырды. Күзләре ачык күрсә дә аның башы эшләми иде әле, ул бернәрсә дә аңлый алмады. Шул хәлендә аңгыраеп утырды да шешәсен янә авызына китерде. Бу юлы ул кадәр үк изаланмады.

Су эчкәндәге бер җинеллек белән ул шешәнең төбенә төште дә шакмаклы буш чүллегә бертын карап торды һәм бик кадерле нәрсәседәй йомшак кына итеп үләнгә ташлады, һәм елмаеп куйды. Хәзер аңа кыен түгел иде.

Аяк-кулларына җан кергәндәй булгач, акрын гына торып басты. Чайкалып куйды. Уң кулын чалбар кесәсенә тыгып, аның төбеннән вак акчалар сөзеп чыгарды. Учларына таратып санады да, канәгать елмаеп якындагы киоскка табан атлады. Каршыдагы тугыз катлы йортның почмагына житкәндә дә ул авызын җыя алмаган иде әле. Башын төзәтте, хәзер тәмәке алып көйрәтеп тә җибәрсә... Кыскасы, бүген ул бәхетле иде.

Йорт почмагыннан киоскага табан борылып бер-ике адым атлау белән ул кинәт катып калды. Гаҗәпләнүдән зур ачылган күзләрен тирә-юньгә йөгертеп алды. Урам—шул ук урам иде. Ул саташмый иде. Ул карашларын урам буйлап каршысына килүче гүзәлгә кабат төбәде.

Ул!

Горур бер назлылык белән атлап барышлары... Иңнәренә таралган кара чәчләре дә, сызылып киткән кашлары да, леп-леп килгән керфекләре дә... елмайганда чокырланып киткән бит очлары да... Барсы-барсы да аныкы...

Ул!

Тик моның булуы мөмкин түгел!

Түгел!

Кыз инде аның янына килеп җиткән иде. Сабыйларча ихлас шатлык катыш гаҗәпләнү белән үзенә төбәлгән кешегә ул бер мизгелгә генә караш ташлады да... карашын бер генә мизгелгә аннан ала алмый торды да... сизелер-сизелмәс кенә елмаеп узып китте. Таушалып-пычранып беткән киемгә уралган (моны киенү дип әйтеп булмый) бу кешенең битен-башын сакал-мыек баскан, чигәдән агара башлаган чәчләре күптән юылмаганлыктан керләнеп-ялтырап тора. Ярты чакрымнан ачып-күгәреп беткән сасы аракы исе аңкып тора. Шулкадәр чиркангыч бәндә... Һәм шулкадәр... Юк, ул кадәр үк түгел... Күзләрендәге ягымлы моңсулык кына ничектер игътибарыңны җәлеп итә... Һәм үз-үзен тотышындагы нindидер иркенлек... Әйе, шулкадәр мескен

кыяфәттә булса да, ул хөрлеген югалтмаган, аның һәр хәрәкәтеннән ниндидер горурлык сибелеп тора... Кыз, узып киткәч, тагы бер борылып карады.

Ул!

Ул хәтта узып киткәч тә борылып карады.

Бер дә юктан гына түгел бит инде бу. Кыз да аны таныгандай итте. Юктыр... Танымагандай итмәгәндер... Бары тик үзенә текәлеп каткан юләргә аптыравы гына булгандыр. Әлбәттә, шулайдыр. Башкача ничек булсын инде.

Ул тагын елмайды. Керфек очларына таралган дымлы дулкынны яшерер өчен генә. Һәм кинәт дөньядагы иң мөһим эшен исенә төшергәндәй, кибет ягына атлады. Киоск янына килеп житкәч, янә бер тапкыр артына борылды. Әлеге гүзәлнең бары тик күзгә генә күренүенә, аның чынбарлык түгеллегенә ышанасы килде. Бу бары тик хыял гына булырга тиеш иде. Күп дәверләр буена хәмер белән агуланган аңда калкып чыккан өрәк кенә. Кыз аның яныннан узып китү белән юкка чыгар, парга, төтенгә әверелеп эреп таралыр. Ул инде күздән югалгандыр. Борылып караганда шушы уйларына ышанычы зур иде аның. Әмма кыз юкка чыкмаган иде. Ул урам буйлап атлап бара иде.

Ир бер мәлгә катып калды. Күзләрен ачып-йомып алды. Башын чайкап куйды. Күренеш юкка чыкмады. Күренеш... юкка чыкмады... Күренеш... Кинәт аның фикер җебе өзелде дә монда нигә килгәнен дә, нәрсәгә чиксез гажәпләнгәнен дә, хәтта әле генә кая карап нәрсә уйлаганын да тиз генә хәтерли алмый торды. Ә хәтерләгәч, бар дөньясын онытып, якындагы тукталышта торган теге кыз ягына йөгерде.

—Тәнзилә!—дип кычкырды үзе шул унайга,—Тәнзилә! Китми тор... Сина бер сүзем бар... мен сүзем бар. Китмә...

Кыз аны ишетмәде. Меңәрләгән кешенең, йөзләгән машинаның һәм тагы санап-исәпләп бетерү мөмкин булмаган миллионлаган нәрсәләрнең яшәү авазы белән тулган шәһәр урамында бер-беренне ишетү жинел түгел иде. Кыз тукталыштагы белдерүләргә күз салып чыкты, аннан соң нидер килеп сораган хатынга җавап бирде, тагын белдерүләргә төбәлде... Ул аны ишетмәде. Ул тавыш килгән якка борылып та карамады.

—Тәнзилә!—дип кычкырды ул.—Тәнзилә, китмә! Китмә...

• • •

—Карале әнә тегендәге бер исерекне, дөнья бетереп акыра,—диде Шәмсикамал карчык, ахирәтенә нидер сөйләп барган жиреннән туктап.—Хатыны ташлап киткәндер инде...

Мәрҗәм җиргә тартыла башлаган аркасын турайта биребрәк ул күрсәткән якка карады.

—Моны ташлап китмәслек тә түгел шул,—дип дәвам итте Шәмсикамал,—Өсте-башын кара син аның... Бумжы! Шәһәр ирләре дә усал эчә икән. Берәр урыстыр инде.

—Бәй, бу Рөстәм түгелме соң?!.—Мәрҗәм карчык күзләрен кыса биреп, теге ирне танырга тырышты.—Рөстәм шул! Әй, бахыркаем... Менә дигән егет иде.

—Син аны каян беләсең?

—Мин эшләгән тулай торакта яши ул. Менә дигән егет иде. Өйләнергә йөргән жиреннән...—Мәрҗәм карчык йомшаграк сүз сайлап бер мәлгә туктап калды.—Өйләнергә йөргән жиреннән кәләше китеп барды...

—Тиле...—дип куйды Шәмсикамал карчык.—Кәләше киткәнгә дә шушы хәлгә төшәрлек булгач... Дөньяда хатын-кыз беткән мени...

—Бик матур йөриләр иде шул. Сокланргыч парлар иде... Хәзер менә...—Шәмсикамал карчык тагын Рөстәм ягына карап алды.—Акылыннан шашкан дип сөйлиләр иде. Дөрес икән.

—Кәләшен әйтәм, Тәнзилә исемле булгандыр инде... Шулай дип кычкыра бит.—Шәмсикамал карчык тагы бер тын колак салып торды да шушы яшендә дә дөрес ишетүе белән горурлангандайрак итеп өстәп куйды.—Әйе, әнә Тәнзилә дип кычкыра.

—Тәнзилә исемле... Бик матур, бик акыллы кыз иде.

—Шул акылы булганга ташлап качкандыр инде моны. Акылы булмаса...

Мәрҗәм карчык туктап калды. Бер тын ахирәтенә текәлеп торды. Аның баядан бирле аркылы-торкылы сөйләп, Рөстәмне кимсетергә тырышып килүе ана ошамый иде.

—Ә кем әйтә ташлап качкан дип?!

—Үзең шулай дидең ләбаса. Китеп барды, дидең.

—Теге дөньяга китеп барды.

—Ә?! Үлде мени?!

—Үлде.

—Ә?!

Шәмсикамал карчык автобуслар тукталышына якынаеп килгән сакаллы иргә тагын бер карап алды да, калтыранган тавыш белән сыгып чыгарды:

—Бахыркаем...

Тын калдылар.

Карчыкларның бер мизгелгә генә тынып калган дөньяларын давылга урап, ялгыз аккош җыры яңгырады:

—Тәнзилә, дим! Китмә! Китмә! Китмә!

Һәм бу сүзләр, күңелләрнең тирәненә кереп тибрәнде дә, инде соңгы елларын ваклап барган карчыкларны яшьлек илләреннән, саф сөюле якты мизгелләрдән уратып алып килде, һәм үзләренең яшьлек тавышы булып кабат яңгырады:

—Китмә! Китмә! Китмә!

Ике карчык та яулык читләрен күзләренә тартты. Керфекләрдә инде дым юк иде. Тик күңелләр барыбер елый иде.

—Китте шул инде...—дип куйды бераздан Мәрҗәм карчык, әллә үзенең яшьлеге, әллә Рөстәмнең Тәнзиләсе хакында уйлап.—Мәңгегә дә кайтмас җиргә китте.

* * *

—Тәнзилә, дим! Китмә! Китмә! Китмә!—Рөстәм шулай дип кычкырды да, кинәт үз тавышыннан үзе айнынды. Нәрсә дип болай урам уртасында акырып йөри әле ул? Кемне чакыра? Тәнзилә юк бит инде. Китте ул. Мәңгегә дә кире кайтмас өчен. Ләкин теге гүзәл... Ул... Ул Тәнзиләгә шул тиклем нык охшаган иде... Тик ул Рөстәмне ишетмәде. Әнә бит, автобуслар тукталышында беркадәр басып торды да үзенә кирәкле маршрутка кереп утырды. Ул Рөстәмгә борылып та карамады. Ул Рөстәмне ишетмәде. Тәнзилә ишетер иде.

Таныш түгел кыз утырган автобус Рөстәмнең тәңгәленә килеп җитте дә алдагы светофорга тукталган машиналарны кәтә биреп тизлеген әкренәйтте. Егет автобуска табан омтылып куйды һәм, үзенең бу тилелегеннән кыенсынып, тыелып калды. Бары тик карашлары гына тимер ишекләр аша үтәр көч белән таныш түгел кызны эзләде.

Кыз бу як тәрәзә янына утырган иде. Ул билет алды да, күзләрен аска төбәп тынып калды. Китапмы шунда, гәзит-фәләнме—берәр нәрсә укып барадыр, күрәсең.

Ташла укуыңны! Башыңны күтәреп бер генә кара бу якка. Тик бер генә кабат. Кер генә. Кемлегеңне белү өчен күзләренә бары тик бер карау да җитәчәк. Кара инде бу тарафка. Зинһар кара...

Рөстәм бөтен өмет-ышанычын йодрыгына туплап, үтенеп-ялынып-ялварып теләсә дә кыз башын күтәрмәде. Инде автобус кузгалып китте. Аның саен егетнең йөрәге әрнеп типте, әйтерсең, ул йөрәкне ниндидер күзгә күренмәс җеп белән шул автобуска бәйләп куйганнар иде дә, хәзер ул хуҗасының күкрәгеннән суырылып чыгып бара иде. Рөстәм, суырылып барган йөрәгенең әрнүләрен җиңеләйтергә теләгәндәй, автобус артыннан атлады, аның белән бергә адымнарын тизләтә барды һәм йөгерүгә күчте. Баягы киоск янына җитәрәк кыз башын күтәреп карады, карашлары белән кемнедер эзләде дә

Рөстәмне күргәч, елмайды, төннәрне балкытырлык якты елмаю белән елмайды. Нәрсәдер әйтте дә бугай. Тик егет аны ишетә алмады. Автобус тизлеген арттыра башлагач, кыз кул болгады. Ничектер назлы итеп. Һәм кабат китабына кадалды.

Елмаеп кулын болгаган хәлдә Рөстәм озак басып торды. Үткән-сүткәннәр үзенә карап бармак төртеп күрсәтә башлагач кына һушына килде.

Ул кулларын селтәргә дә куркып атлады бугай, аларны аз гына ян-якка җибәрсә, канатка, бәхет канатына әйләнер дә, егетне күккә күтәреп, очыртып алып китәрләр сыман тоелды. Күрде аны теге кыз! Елмайды! Шатланып, яратып елмайды! Кулын да болгады. Шундый назлы итеп һәм... аерылуларына үкенгәндәй итеп тә. Алар аңлаштылар. Күңелләрдә сөю бөреләнде.

Киоск янына җиткәч, тәрәзә пыяласында үз чагылышын күрде дә, катып калды. Бөтен куанычлары бер мизгелдә юкка чыкты. Әле генә күргәненең чынлап та булуына, нәкъ шулай булуына, ышана алмый торды. Юктыр ла, кыз аңа борылып карамагандыр, борылып караса да елмаймагандыр, елмайса да кулын болгамагандыр, кулын болгаса да аңа, Рөстәмгә, түгел, ә бөтенләй башка кешегәдер. Бите-башы керләнеп беткән, йөзен сакал-мыек баскан, таушалып беткән сәләмә киемгә төренгән бу бәндәгә дөньяның бер генә гүзәле дә шулай якты йөз күрсәтә алмас иде. Ирештереп, үзенчә мыскыл итеп кенә кыланмаса, берәү дә аңа яратып елмая алырлык түгел.

Кинәт аңа шулкадәр кыен булып калды. Берчә, үзен-үзе өзгәләп ташларлык булып рәнҗеде, берчә, баягы автобусны куып тотып аны теге гүзәле-ние белән күтәреп алып болгый-болгый атып бәрәсе килде.

—Сезгә нәрсә?

Көтмәгәндә яңгыраган бу тавыштан ул сискәнеп китте. Ниндидер афәт көтеп як-ягына борылып карады. Афәт юк иде. Сатучы кыз икән.

—Нәрсә алырга телисез?—дип кабатлады ул, битараф тавыш белән.—Мин ашыгам.

—Тәмәке...—Рөстәм кабаланып кесәсенә тыгылды да вак акчаларын көрәп чыгарды.—Бер кап «Петр»... Шырпы... Аннан соң ни... Сыра... Юк, кырынгыч... Әйе, кырынгыч... бер тапкыр кырына торган...

Тәмәке кабызгач, уйлар агышы бер мәлгә бөтенләй туктап калгандай тоелды. Шуның белән бергә әрнүләр дә кими төште. Бераздан ул ниндидер зур ачыш ясагандай борын төбеннән генә кабатлады:

—Юк, бу Тәнзилә түгел иде. Түгел иде.

Тора-бара таныш түгел кызның Тәнзиләгә бөтенләй дә охшамаганлыгын да аңлады. Әйе, ул Тәнзиләгә якын да килмәгән иде. Тик ни өчен... Ни өчен ул аларны охшатты соң? Нәрсә бу? Хәмер тәэсиреме, әллә тагы берәр сере бармы?

Охшатып кына да калмады бит әле, аның Тәнзилә икәненә бер мәлгә бар күңеле белән ышанып бетте. Теге дөньяга киткәннәрнең кире кайтмавын белсә дә. Бу кызның үзенә бик кадерле икәненә ышану теләге бөтен кануннарны җимердеме? Әллә ул кайгыдан һәм хәмер шаукымыннан акылын җуеп барамы? Кайгы дигәне беркадәр басыла да төште бит инде. Басыла төшкән кебек булды, һәрхәлдә, шулай булып тоелырга тиеш—киткән артыннан китә алмыйсың икән, үткәннәргә карап кына яшәргә ярамый. Иң кадерле кешеңне җирләгәннән соң, йә үзең дә аның янына китәргә, йә аннан башка яшәргә өйрәнергә тиешсең. Икенең бере—башкача мөмкин түгел.

Рөстәм сөйгәне артыннан китә алмады. Ул яшәргә тиеш. Гомумән, адәм баласы алдында ике генә юл бар: яшәргә көче җитмәгәннәр—үләргә, үләргә көче җитмәгәннәр—яшәргә тиеш.

Ә кем белә, әлеге гүзәлне сөйгәненә охшатуы, бәлки, Тәнзиләнең фатихасыдыр, «Минем хакта гына уйлап ятма, үз тормышың турында да уйла. Сиңа яшәргә кирәк бит әле,»—дип әйтергә теләведер.

Мөгаен, шулайдыр.

* * *

Фәрештә!

Көтмәгәндә юлына очраган таныш түгел гүзәлне күңеленнән генә шулай атады ул. Кыз чынлап та фәрештә, Ходай тарафыннан Рөстәмне бәла-казалардан, кыеш сукмаклардан саклап калу өчен җибәрелгән бер изге зат сыман иде.

Шушы таныш түгел кызны очратканнан соң ул үзендә ниндидер якты үзгәреш тойды, тормыш бөтенләй бүтән төсләргә кереп балкый башлады.

Теге көнне башкача бер йотым да сыра-фәлән алмады ул. Сәрхуш танышларына да кагылып тормады. Туп-туры өенә кайтты. Бүлмә ишеген ачып керү белән борынына чамасыз сасы ис килеп бәрелде. Ул йөгереп барып тәрәзәне ачты, җилләткечне кушып куйды, һава сафландыргыч алып сибәргә дә теләгән иде дә, таба алмады, шуна үзенен күз карасы кебек кенә саклап йөргән хушбуен сипте, һәм кәефләрне күтәреп җибәрерлек якты ис таралгач, елмаеп куйды. Бу Тәнзиләнең бүләге иде. Әмма хушбуй исен шундук бүлмәгә сеңгән яман сасылык күмеп китте. Ай буена хәмер, тәмәке, сидек, косык һәм башка яман исләргә күмелеп яшәгән бүлмә тиз генә адәм рәтенә керергә ашыкмый иде.

Рөстәм кинәт чыраен сытып куйды. Ул үзенең нинди хәлгә төшкәнлеген шушы мизгелдә генә тулысынча аңлады булса кирәк. Чучка булып чучка абзары да бу кадәр үк пычрак, бу хәтлем үк сасы була алмыйдыр. Тик Рөстәм бит дуңгыз да, башка мәхлук та түгел. Ул кеше. Остазларының зур өметен яулаган талантлы яшь галим. Шул башың белән менә мондый көнгә төшеп яшә әле! Адәм тәганәсе! Ярый әле, үз исәбенә ай ярымлык ял алырга башы җитте. Ярый әле барсын да авылга кайтып китәчәге хакында кисәтеп куйды. Әгәр хезмәттәшләре яки танышлары килеп, аның менә шушы бүлмәдә яшәгәнен күрсәләр, бүлмәне шушы дәрәҗәгә җиткергәнен белсәләр, гарьлегеннән җир тишегенә кер дә кит кенә.

Оят! Гарьлек!

Ләкин бүгенгә кадәр ул шушы бүлмәдә яшәгән бит әле. Үзенең ни көнгә төшкәнен күрмәгән, бу хакта уйлап та карамаган, һәм тагы да шулай дәвам итәр иде. Дәвам итәр иде... Әгәр дә... Әгәр дә юлында теге таныш түгел кыз очрамаса. Сизелер-сизелмәс кенә елмаймаса, үтеп киткәч борылып карамаса. Үзенең тыйнак назлылыгы белән Тәнзиләне хәтерләтеп, тетрәнергә мәҗбүр итмәсә. Ул бит инде, югыйсә, бөтен дөньясына кулын селтәп, тормыш агымына буйсынган, ниндидер бер шарлавыкта көтеп торган әҗәленә әзерләнә башлаган иде.

Фәрештә!..

Кыз хакында уйлауга үзенең көчсезлеге өчен, башына төшкән беренче чын кайгыны җиңеп чыга алмаганы өчен тагын бер кыенсырады. Шул ук вакытта, үзенең нинди хәлгә төшкәнлеген аңлый алуы өчен ул шат та иде. Әйе, ул әле бөтенләй үк беткәнбаш түгел икән, үз хәленә бәя бирә белә. Гарьләнә белә.

Рөстәм җиңнәрен сызганып куйды да бүлмәне җыештыра башлады. Почмакта өелеп яткан сыра банкаларын, аракы шешәләрен капчыкка тутырды. Хәтсез җыелып киткәннәр икән. Сатсаң ару гына акчасы да чыгар иде дә бит... Бу уеннан Рөстәм елмаеп куйды. Урам буйлап капчык күтәреп шешә сатып йөрисе генә калды хәзер. Шул гына җитми тора иде. Һәм ул шыплап тутырылган ике капчыкны да алып коридорның теге очындагы чүплеккә чыгарып куйды. Каттан-катка сузылган торба буйлап контейнерга ташлагач, ничектер күңеле җиңеләеп калгандай тоелды. Әйтерсең, шушы капчыкларда аның бөтен бозык гадәтләре иде. Аннан соң стеналарга чәчрәгән пычрак тапларны тазартып чыкты. Катып-саргаеп беткән савыт-сабаны чистартты, идәннәрне юды. Ахыр чиктә каешланып беткән киемнәрен капчыкка тутырып кер юу бүлмәсенә китте. Адәм рәтле җиргә киярлек бер генә киеме дә калмаган икән. Өстендәгеләре дә адәм гарьлеге булып беткән, аек баштан өстенә ябу түгел, борылып карарлык та җире юк. Сәгать ярым чамасы юарга

туры килде. Идән юу, кер уу, бер карасаң, авыр эш тә түгел, әмма Рөстәм шабыр тиргә батты, йөрәге дарслап типте, муен тамырлары тартышып-тартышып куйды. Бөтен тәне буйлап саркылган салкын тирдән сасыган аракы исе килгән сыман иде. Аның саен үзенең эчкечелеккә чумуы өчен гарьләнү ачысы чиксез үкенеч булып җанын кимерде. Бөтенләй эздән чыга язганмын бит, дип уйлады ул, кешелегемне җую чигенә җиткәнмен.

Киемнәрен юып элгәч, футболка-трикосын үтүк белән киптереп өстен алыштырды да, урын җәймәләренә тотынды. Эше тәмам булгач, бүлмәсенә карап сокланып торды. Барсы да ялтырып, матурланып, янарып киткәндәй тоелды ана. Бары тик теге яман ис кенә һаман борын төбендә бөтерелә иде.

Һәм ул әлеге иснең бүлмәдән генә түгел, ә үзеннән дә аңкып торуын аңлап, мунчага китте. Бу юлы адымнары хәлсез-ышанычсыз иде, карашлары барып сарылыр урын табалмый газапланды, барсы да аны танып-белеп торалардыр, исереп йөргәнен күргәннәрдер, хәзер аны гаепллиләрдер, эчләреннән генә көлеп-мыскыллап торалардыр сыман тоелды. Ул урам буйлап түгел, ә урам аның буйлап атлыйдыр, менә-менә ул Рөстәмнең йөрәгенә китереп басар да аны таптап-сытып узардыр төсле иде. Ләкин шул хәлендә дә ул урлап-урлап кына тирә-якка күз атты. Кырмыскалар өередәй кайдадыр ашыгучы төркемнән тыйнак назлылыгы белән карашларын суырып алыр затның җанга якын чалымнарын көтте. Ул чалымнар кай арададыр чагылып та алгандай булды һәм Рөстәм бар булмышы белән катып калды, ургылырга торган вулкан булып бер мизгелгә генә тынып калды да, үзенең алдануын аңлады. Ул әрнеде. Тик бу әрнү, атылмыйча калган вулкан булып бар җанынны утка ураса да, әллә нинди татлы әрнү иде. Рөстәм табышларга мохтаҗ түгел иде. Ул эзләнүләре, омтылышлары, ялгышу һәм алданулары белән дә бәхетле иде.

Фәрештә!

Күңеленнән генә шулай кабатлады ул. Үзен айнырга, уянырга, уйланырга мәҗбүр иткән гүзәл затка ул шулкадәр рәхмәтле, мәхәббәтле, ул аның алдына егылып гомер буе табынырга да әзер иде кебек.

Якындагы мунчага илтә торган трамвайга утыргач та ул тәрәзәдән күзен алмады. Карашлары белән һәр гүзәлне тикшереп үтте. Ләкин аны тапмады. Ул юк иде. Ә башкача булуы мөмкин дә түгел. Нәкъ шулай булырга тиеш. Миллионлаган кеше яшәгән кала урамында аны кабат очрата алуына ул ышанмый да иде. Очрашуны ул көтми, ана өмет итми, ул эзли алуы белән дә бәхетле иде.

Кинәт!..

Кинәт трамвай сикереп куйгандай тоелды. Юк, бу трамвай түгел, бу Рөстәмнең йөрәге шулай талпынды, һәм ул бер мизгелдә үз күзләренә үзе ышанмыйча торды, ә ышангач, моның чынлап та була алуына гаҗәпләнде. Юл буендагы киоск алдында Ул басып тора иде. Фәрештә! Рөстәм яшен тизлегендә тәрәзәгә үрелде, аны ачып куйды да ярты гәүдәсе белән урамга үрелеп дөнья яңгыратты:

—Фәрештә! Туташ! Чибәр туташ!

Мондый сүзләрдән таныш түгел кыз бернәрсә дә аңлый алмый иде, билгеле. Тәгәрмәчләр тыкылдавы, машиналар шавы Рөстәмнең тавышын басып китә иде. Шулай булырга тиеш иде. Әмма кыз аны ишетте. Ишетте дә борылып карады. Бер генә мизгелгә йөзеннән гаҗәпләнү күләгәсе шуып үтте дә аны шундук якты елмаю алыштырды. Рөстәм бәхетле иде. Күрде. Таныды. Фәрештә аңа елмаеп кына калмады, кулын да болгады. Нәрсәдер әйтте дә бугай әле. Әйе, нәрсәдер әйтте ул, тик Рөсәм генә ишетмәде.

• • •

—Алла диванасы! Үләсең киләме әллә?!

Көтмәгәндә яңгыраган ачы тавыштан Рөстәм тертләп китте. Аны-моны уйлап өлгергәнче, аны беләгеннән тартып алдылар. Кондуктор ханым икән.

—Үләсең килсә, башка җирне сайла,—диде ул, Рөстәмнең беләгенә чат

ябешкән кулын һаман җибәрмичә,—Минем ике балам бар. Бәлагә ураласым килми.

—Гафу итегез...

—Урамда кызлар бетмәс ул, башынны сакла.

Шул сүзе белән кондуктор ханым алгы ишек ягына юнәлде.

Рөстәм үзе ачкан тәрәзәне ябып куйды да тукталышка житү белән атылып төшеп калды. Юл аша чыкканда машина астына керә язды. «Волга» хуҗасы тәгәрмәчләрен чыйнатып тормоз бирде дә, пипләтеп йодрыгын болгады. Боларны Рөстәм күз кырые белән генә күреп калды да онытты. Анын кайгысы юк иде. Ул бар көченә кирегә, кыз басып торган киоскка йөгерде. Ә көче чамалы иде. Ике багана арасы да үтмәстән салкын тиргә батты, сулышы капты, буыннары камырга әйләнде. Анын хәле калмаган иде. Аны бары тик ихтыяры гына әйди иде.

Бу язмыштыр. Рөстәм әлеге гүзәл белән танышырга тиештер. Югыйсә, ник әле юллары гел кисешеп кенә тора аларнын?! Монарчы андый хәлнен булганы юк иде, ләбаса. Бер генә кыз белән дә болай көненә әллә ничәшәр кат очрашканы, очрашып, бер-беренә игътибар итешеп тә танышалмый изаланганы юк иде. Ә әле... Әлбәттә, язмыш бу. Үзенчә ирештерә, шаярткан була. Әйдә, бераз каңгырашыбрак йөрегез әле, янәсе, сонрак, ныклап якынаеп киткәч, бер-берегезнен кадерен белергә яхшырак булыр. Сынавы да шулдыр. Очрашкан чакта, танышу мөмкинлеге булганда, авызынны ачып калсан, бәхетеннән колак кактым дип уйла. Йөгерергә, ныграк йөгерергә кирәк. Ашыгырга. Мондый мөмкинлекнен башкача булмавы, беркайчан-беркайчан кабатланмавы да мөмкин бит әле.

Рөстәм йөгерде. Аракы эчеп хәлсезләнгән организмны куалау, бар көченә эшләтә алу авыр иде. Махмыр газабыннан йөрәге чәбәләнсә, арка үзәкләре боздай салкын тиргә, әллә нинди чиркангыч ябышкак сыекчага күмелде. Шул тир салкынлыгы бу дөньяда кешенен ялгызлыгы хакында сөйләгән сыман, үз-үзенә баш була белмәсән, үз язмышына колак салып тормышынны көйли белмәсән, син беркемгә дә кирәкмисен дип кисәткән дә сыман булып куйды. Хәер, монсы ин кирәк вакытта үзенен көчсезлеге өчен, көчен саклый белмәгәне өчен үкенү тойгысыннан гына булгандыр. Үкенерлек тә иде шул. Йөгерү ана чиксез авыр иде. Һәр адымнан бөтен мускуллары шартлап ярылыр сыман тоелды. Йөрәге күкрәктән атылып чыгып аяк астына төшеп сытылыр кебек булды. Ә тын юллары... Тын юлларыннан һава үтмидер, аны тупас бер игәү белән игиләрдер кебек иде.

Ул йөгерде.

Анын бөтен бәхете, бөтен тормышы, бу дөньядагы миссиясе бары тик шушы таныш түгел кыз белән күрешү, якынаюдыр сыман иде. Шул максатына ирешә алмаса, тормыш анын өчен мәгънәсен югалтыр, яшәвенен бер фәтвәсе дә калмас шикелле тоелды.

Ул бу хакта уйламады. Уйласа да сизелерлек, истә калырлык итеп түгел. Ул бернәрсә хакында да уйламады. Ул барсын да белде генә, һәм тойды, һәм йөгерде.

Борылманы узгач, Фәрештәне күрде. Ерак кына иде әле. Хәтсез йөгерәсе бар иде. Әмма Ул күренә иде. Аны күрүдән йөрәгенә ләззәтле бер дулкын үрелде. Сөйгәненнен куенында, чиксез сөю назларына бирелгәндә генә була торган рәхәт дулкын. Ул дулкын бөтен тәненне ялмап ала да күзәнәкләренә канат куя, аларны бәхет күгендә тибрәнергә мәҗбүр итә, үзенне күз йомган арада миллионлаган кисәкләргә таралып кабат җыелгандай сизәсен. Янадан тугандай буласын, һәрбер күзәнәгеннән сафлык, матурлык, наз сирпелеп тора. Рөстәм дә шундый халәттә иде. Фәрештәгә якынайган саен ул үзенен гайрәтләнә баруын, көч-куәтенен кабат кайтуын тойды, әйтерсен, ул адымнан-адымга, мизгелдән-мизгелгә янара иде. Ул янара иде.

—Гражданин!

Кемдер эндәште бугай. Рөстәм колак яфрагы белән генә ишетеп калды. Игътибар итмәде.

—Стоять! Кому я сказал!

Рөстәм аны-моны аңлап өлгермәде, кыскыч кебек көчле куллар беләгеннән эләктереп алды. Ул селтәнеп карышып маташмакчы иде, кемнәр белән эш иткәнен сизеп тукталып калды.

—Мин ашыгам. Зинһар, тоткарламагыз. Мин...

—Документларын?!

Рөстәм, кинәт һавадан бәреп төшерелгән кош сыман, исәңгерәп калды. Бер мизгелдә ялкыны таралып көл төсенә кергән күзләрен тәгәрәтеп алды. Милиционерлар ашыкмый һәм аның ашыгуына да исләре китми иде. Һәр күзәнәгеннән өйрәнеп караган салкын күзләре дә, дубинка сабын сыйпаган бармаклары да юньлелек вәгъдә итми иде.

—Документларыңны күрсәт.

Рөстәм кесәсенә тыгылды. Әмма футболкасының да, трикосының да кесәсе юк иде. Документларын да алмаган иде ул.

—Документлар үзем белән түгел,—диде ул, бөтен дөньядан бизгән бер кыяфәттә,—Мин мунчага бара идем...

Һәм Фәрештә ягына күз атты. Ул һаман урынында тора иде әле. Күңелен әрнеткеч бер ялкын кисеп узды. Житешә идем бит... Янына барып өлгерә идем... Эх... Ләкин хәзер үкенүдән файда юк иде.

—Участокка узарга туры килер.

—Мин ашыгам...

—Озак тотмыйбыз. Шәхесеңне генә ачыклыйбыз да...

—Ә мунча сәгать унберга кадәр эшли,—дип ютатты икенчесе.

Рөстәм, УАЗ-ның арткы ишегенә кереп югалганчы тагын Фәрештә ягына карады. Кыз китмәгән иде. Кемнедер көтә, ахрысы. Бәлки, Рөстәмнедер...

Милиция участогында аны озак тотмадылар. Шәхесен ачыкладылар да машинага утыртып бая кыз басып торган урынга кадәр китереп куйдылар. Хәтта гафу да үтенделәр әле. «Кичер инде, туган... Эшебез шундый...»

Ләкин Рөстәм өчен милиция участогында үткән ярты сәгать тоташ гомердән дә озынрак булып тоелды. Аның һәрбер мизгеле югалту хисеннән, шул югалтулары өчен әрнү, үкенү ачысыннан тора иде. Бу кадәрле дә газаптан котылу юктыр сыман тоелды.

Ләкин машинадан төшү белән боларның барсы да юкка чыкты, күңелен әллә нинди бер сәер хис биләп алды. Бая кыз басып торган урында жил генә иссә дә Рөстәмнең күңеле күрәэп киткәндәй булды. Фәрештә... Бу урамда Аның рухы калган иде, искән жилдә аның назы, һавада ул сөртенә торган хушбуй исе, ә асфальтта аның аяк жылысы саклана, һәр адымда, һәр мизгелдә аның барлыгы сизелә, дөнья аның белән тулы иде.

Дөнья бәхет белән тулы иде.

Бер карасаң, адәм баласына күп тә кирәкми икән. Бары тик жаның аңлар кешесе булу да житә. Хәтта аның янында булуы да мөһим түгел, ул бары тик яшәсен, син яшәгән дөньяда яшәсен, син караган күккә карасын да, син атлаган жиргә басып йөрсен, син сулаган һаваны сулап, син эчкән суларны эчсен... Шул да житә.

Бәхет өчен жирдә күп кирәкми...

Ләкин Рөстәм аны күрүдән өметен өзмәде. Башта урам буйлап эзләде, аннан соң якын-тирәдәге кибетләргә сугылып чыкты. Юлында очраган һәрбер хатын-кызны ул түгелме дип, карашлары белән жентекләп тикшереп узды. Кибетләрдән соң аптекага, аннан якындагы оешмаларга кереп чыкты. Шул рәвешле байтак гомер узды. Бәлки, менә бу тыкрыктан ул күрше урамга киткәндер дип, Рөстәм дә эзләнүен шул якка күчерде. Күз бәйләнде. Ярты төн житте. Әмма кыз табылмады.

Аякларын көчкә сөйрәп өенә кайтып кергәч, дөресрәге, тулай тораклагы бүлмәсенең ишеген ачып жибәрү белән, ул үзен бөтенләй башка дөньяга күчкәндәй итеп тойды. Кичә кич кенә ул күгендә кояшы шартлап тоташ сөрем белән капланган Кайгы планетасында газап сулап һәлакәт юлыннан атлый иде. Кичә ана бернәрсә дә, беркем дә кирәкми һәм ул үзе дә берәүгә

дә хаҗәт түгел иде. Төнге урам буйлап атлаган ике милиционерга бәреләязып узып китсә дә, кичә аны хәтта тәртип сакчылары да туктатмады. Ачып беткән бомжга тиюне үзләре өчен түбәнлек санадылар, ахры. Бүген туктаттылар... Ләкин мәсьәлә монда гына түгел иде. Мәсьәлә тирәндә иде. Кичә ул бүтән дөньяда иде. Бүтән кеше иде.

Һәм барсына да теге кыз... Фәрештә сәбәпче. Ул үзенең күз карашы белән, елмаюы белән, кул болгавы белән ДӨНЬЯНЫ ҮЗГӘРТТЕ.

Рөстәм табачак аны. Бу—язмыш. Ул гүзәл Рөстәмнеке.

«Мин аны табачакмын!—дип уйлады егет караватына аркылы ятып йоклап киткәндә.—Мин аны табарга тиеш. Мин аны табачакмын.

* * *

Эзләде аны Рөстәм. Икенче көнне иртүк торып теге киоск янына барып басты. Бу юлы ул кырынган-юынган, яхшы киемнән иде. Шул киосктан алып кичә кыз басып торган урынга кадәр һәркемне игътибар белән күзәтеп көне буе урам әйләнде. Өченче көнне тагын... Шулай атналар буе сузылды. Хәтта болай йөрүенең файдасызлыгын аңлагач та тирә-якны күзәтүдән туктамады, күнеленнән: ул түгелме?—дигән уй китмәде. Таныш түгел кызның көннәрне төн иткән елмаюы, нәрсәдер әйтеп кул болгап калулары төшләренә кереп уятты. Тик кыз табылмады.

Табылмады...

Айлар, еллар үтте.

Рөстәм инде гади яшь егеттән абруйлы галимгә әйләнде. Гаилә корды. Балалары булды. Балалары үсеп буй җиткерде. Яшьлектәге кайнар хисләр сүрелеп бетте, әмма таныш түгел кызны онытмады. Аны күреп рәхмәт әйтәсе, шундый авыр мизгелендә очрап, сазга батып барган яшь кешене адәм иткән елмаюы өчен нинди дә булса изгелек эшлисе килде.

Тик кыз очрамады.

Хәзер инде очрашсалар да ул аны таный алмас иде. Таныш түгел кыз да картайгандыр, әби булгандыр. Әмма Рөстәм Газизовичның моңа ышанасы килмәде, шулкадәр якты елмаю белән, дөньяны үзгәртә алырлык елмаю белән елмая белгән гүзәл затлар картаймыйдыр, алар гүзәллекнең үзе кебек мәңге яшь, мәңге саф килеш калалардыр сыман тоелды.

Телетапшыруны алып баручы яшь кызның кыюсыз тавышы еллар төпкеленнән урап килеп кабат ишетелде:

—Рөстәм Газизович... Нәрсә сезгә этәргеч бирде?

Галим бер мизгелгә тынып калды.

—Елмаю...—дип авыр сулады ул, һәм керфек очларына күз яше саркылып чыкты. Галим күз яшьләренең якты да, ачы да икәнен белә иде.

♣



Илдус
Гыйләҗев

## ИЛ-КӨН КАРШЫНДА

### Үзем үзгәрермен

Мине үзгәртергә тырышма син,
Тискәре мин малай чагымнан.
Үзсүзлелек минем геннарыма
Күп гасырлар буе салынган.
Төгәл генә әйтеп бирә алмыйм,
Кемнән күпме өлеш кергәндер.
Бабаларым иркен дала буйлап
Ил хөрлеге даулап йөргәндер.
Шәҗәрәмнең очын табалмадым,
Гарасатлар кереп кискәндер.
Баскынлыкны кабул итә алмау
Шул еллардан ахры күчкәндер.
Идел кебек тулып елмаермын,
Хыялымны мәхрүм иттермәм:
Ирек кенә килсен... гөлт кабынып
Яктырырмын, һич тә көттермәм.

### Үзгәрмәдеңме?

Гаделлекне сөйгән яшьләр әлек
Куылганнар ерак Себергә...
Безне җибәрделәр бер салага—
Маллар көтеп, басу сөрергә.
Хәрби киемнәрне салган чакта
Хыяллар бик матур иде лә.
Әмер биргән төсле, каты гына
«Син—коммунист? Кирәк!»—диделәр.
Нинди капкыннарга эләккәнне
Барып күргәч кенә аңладым...

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946) — *шагыйрь; «Җыр китабы», «Мәгарә», «Кадерле китап» һ. б. шигырь җыентыклары авторы. ТР Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге премиясе лауреаты. Азнакай районы Түйкә авылында яши.*

Нәкъ декабрист хатыннары кебек,
Рәхмәт сиңа, миннән калмадың.
Дүрт мәртәбә күчеп җәфаландык,
Алышынып торды «агымнар».
Бетә торган түгел икән лә, әй,
Рәсәендә хөрти авыллар.
Янәшәңдә торса фикердәшең,
Мөмкин икән басу сөрергә.
Сагындыра... әллә, олгайсак та,
Китәбезме кабат «сөргенгә»?..

## Идел-Урал арасы

Без—Иделнең уртасында!
Муллык белән тулы үзән.
Байлык читкә агылса да,
Күңел иркен—татар түзә.
Без—Рәсәйнең уртасында!!
Зур алманың үзәк төше:
Ул бозылса (беләләрме?),
Җимешнең бит бетә көче...

## Аерма бар

Зур гөнаһлы булмый микән
Пьесалар язган кеше?—
Язмышлар уйлап чыгара...
Бу эш бит—Күкләр эше!
Дөрес, әхвәл-вакыйганы
Тормыштан ала, кана.
Безгә уйлап, чагыштырып
Карап утыру кала.
Аерма шул: таралсак та,
Гыйбрәтле фикер алып,
Язмыш—үлеп тәгәлләнә,
Ә тамаша—кул чабып...

## Табылырмы

Бик кибегеп йөргән чагым булса,
Ашыкмагыз чиләк асарга.
Бер йотым су... шул да җитә миңа
Көчле сусынымны басарга.
Туңып, өшеп йөргән чагым булса,
Ташламагыз илтеп чүлләргә.
Кояш нуры төшкән почмак тапсам,
Җылынырмын туган илләрдә.
Бик эсселәп йөргән чагым булса,
Җибәрмәгез куып котыпка.
Агач күләгәсе саклап калыр,
Котылырмын шалаш корып та.
Ямансулап йөргән чагым булса,
Борчылмагыз, кылмам явызлык.
...Хәсрәтләргә йөгән кигертергә
Каян гына табыйм авызлык?

***

Яралган чактан ук кеше
Табыну калыбында:
Сәҗдә кылган төсле ята
Анасы карынында...

## Төп комачау

Парламентлар гөҗләп эшләп тора,
Сүз боткасы, түгел чыдарлык.
Сайлап куйган ханым, абзыкайлар
Утыралар закон чыгарып.
Кануннарсыз, әйе, яшәп булмый,
Җәмгыятьне шулар үстерә.
Ә нигә соң алар, киеп салган
Күлмәк төсле, бик тиз искерә?
Күктән иңгән тәртипләр бит әнә
Мәңге яши, мәңге бозылмый.
Кеше кунак кына... шуңа микән,
Зур гомерле канун язылмый?!.

## Тутыкмас тотка

Бер үк суга ике тапкыр
Кереп булмый, дигәннәр.
Акыл сеңгән гыйбарәләр
Борынгыдан килгәннәр.
Әүвәл башлап кем әйткәне
Онытылган, билгесез.
Кулланышта шомарганнар—
Чуерташка биргесез:
Татар булып яшим дисәң,
Ятлап алып отасы.
Сүзләр телнең күрке булса,
Мәкаль—телнең тоткасы!

## Татлы күренеш

Туйкә тауларында җиләк пешкән,
Ярты шәһәр халкы шунда күчкән.
Күз күреме җиргә сибелгәннәр,
Әйтерсең лә Мамай явы төшкән.
Күктә кояш юкса бара баеп,
Ник китмиләр? Исәп—кайту баеп!
Бик уңган шул җиләк, ялгыш бассаң,
Егылырсың төсле аяк таеп.
Баш әйләнә мәмрәү-кызыл төстән,
Бу хозурлык безгә бүләк—өстән!
Күз алдына килә, кызыктырып,
Тәм-том белән тулы кышкы өстәл.

## Без

Без җырласак, җанием-бәгърем лә,
Күбәләгем диеп җырладык.
Бер күрешү—үзе бер гомер, (их!),
Бәйрәм саен табын җыйнадык.

Без биесәк, идән такталарын
Талчыбыктай бөгеп биедек.
Күренерлек итеп бар дөньяга,
Сәхнәләрнең сайлап биегән.
Без эшләсәк, җиренә җиткердек лә—
Тел-теш тидермәслек эшләдек.
Ярышларда беркем узалмады,
Мактау тактасыннан төшмәдек.
Без яратсак, шашып, онытылып,
Ләйлә-Мәҗнүн кебек яраттык.
Олы хисләр һаман кайнар килеш,
Суынмаслык итеп яңарттык.
Без кайгырсак, тышка чыгармадык,
Эчтән генә сызып кайгырдык.
Тормыш бит ул тоташ шатлык түгел,
Сагышларны суга агыздык.
Картлыктан да шуңа курыккан юк,
Килсә килсен, әйдә, күтәрбез.
Бездән башка дөнья моңсу калыр,—
Сагынырлык итеп китәрбез...

## Дөньяныкы—дөньялыкта

Оныту бик авыр икән
Зыян салган кешеләрне.
Гафу итү мөмкинме соң
Карак, баскын ишеләрне?
Язмышыңны уңга-сулга
Тарткалаган түрәләрне?
(Кеше өсләреннән йөреп,
Әллә рәхәт күрәләрме?)
Яманлыкны Изге Китап
Куша һәрчак кичерергә.
Һай, кыен эш... Буйсын, акыл!
Мөмкинбез ич кичегергә...
Мин үзем дә—җен токымы—
Хали түгел хаталардан.
Зәһәрлектә калышмадым
Базардагы апалардан.
Тик гаепсез рәнҗетмәдем,
Көчсез белән чарлашмадым.
Дөньяныкы—дөньялыкта!
Гафу рахим, чордашларым...

## Бөтенләйгә китеп булмас кебек

Күп тапкырлар тагын кайтырмын күк,
Оныталмам монда булганны.
Газап-шатлык тулы җир тормышын
Кырып ташлап җаннан буламы?!
Азагы юк матур бер җыр булып
Калсаң иде ил-көн каршында.
...Килгән белән киткән елны язу
Кирәк микән кабер ташында?

Фәнзәлия
Мәснәвиева

# АЧЫ АЛМА

Моңа кадәр мин бала гына—бу дөньяның мең төрле мизгелләреннән, халәт-кичерешләреннән азат, ваемсыз сабый гына булганмын. Дөнья мина үзенчә матур күренгән. Әнә җәйге кояшның нурлары кочагында изрәп яткан тау буйлары, мең төрле чәчәк-үләннәре белән күзне камаштыра торган җиләкле урман болыннары—барысы да колачын җәеп үзенә чакыра. Иртә-кичен тау битенең чыклы үләне ялан тәпиләрне әллә нинди затлы сабыннардан да чиста итеп йомшак кына назлап юа. Әй, ул җиләкле болыннар... Урманнан кайтканда җиләк сутыннан алсу төскә кергән нәни кулларыбыздагы баш әйләндергеч татлы исне һаман хәтерлим икән әле мин. Ә ул җиләк җыйган көннәрне кичен йокыга китүе... Күз алдында берсеннән-берсе кызыл җиләкләр җемелди, гүя үзенә алан төпкеленә чакыралар. Без үз җиребезнең-төягебезнең гөлләре булганбыз. Бала күнеле моны аңлый да алмагандыр. Белмим. Бәлки... Тик без үз авылыбызның балалары икәнлегебезне тоя идек.

Бу җәй дә шулай балалык ваемсызлыгы белән үтеп киткән булыр идеме икән. Әллә нинди булса да башка берәр вакыйга безне сабыйлыктан башка, үзгәрәк дөньяга алып керер идеме.

Кеше күзенә әллә ни чалынып бармаган Кәрим бабайларга кунаклар кайтты. Авыл җирендә җәй көннәре килем-кунак чоры инде. Ят кешеләргә артык исебез китеп тормаса да, боларны урам башыннан күренгәч тә, карашларыбыз белән капкага кадәр озатып куйдык. Буй-буй бизәкле ефәк күлмәк кигән тулы гәүдәле хатынга игътибар да итмәдек. Анысы, билгеле, әниләре булырга тиеш. Ә менә безнең яшьләр чамасындагы кызы иртәгә үк уенга кушылачак. Кызларның өлкәне—вак чәчәкле килешле күлмәк кигәне бик тә сылу һәм гүзәл иде.

Иртәгәсен әни белән әтинең чәй янында сөйләгән сүзләре йокы аралаш кына колакка кереп калды.

—Кәримнең үзбәктәге сеңелесе кайткан. Ике кызын ияртеп.—Әни тавышы. Әти гадәтенчә, тыңлап кына утыра.

—Үзбәге ничек җибәргән, бер дә күренгәне юк иде бугай.—Әтидән җавап ишетелмәгәч, сүзне үзе үк тәгаллләп куйды.

—Туган җир тарта, күрәсең.

Йокы аралаш тыңлангангамы, әллә инде әни үзе сүзләренә яшерен мәгънә кушты, бу хәбәр минем күңелдә әлеге кунаклар вакыйгасына карата ниндидер серлелек өстәде.

Кунак кызларның кечерәге белән без, чынлап та, икенче көнне үк дуслаштык. Рәйлә сүзчән, ачык кыз булып чыкты. Аның татарча сөйләшүен

тыңлау үзе үк рәхәт. Сүзләренең һәр иҗегенә басым ясап, тырышып кабатлый. Үзбәк телен дә, яхшылап тыңласаң, аңлашылып тора икән.

Шулай итеп, безнең очтагы биш-алты гына йортлык кечкенә урам берничә көн эчендә җанланып, хәтта ямьләнеп үк китте. Җәен -көзен су аръягыннан яшел үлән кыркып, елга суында коенып кайтышлый ял итеп утырган оя-оя каз-үрдәкләргә дә тынгы бетте монда быел. Бала-чага чыр-чу килеп шушында кайнашабыз. Хәер, өлкәнрәк кайберәүләр дә биредә еш күренә башлады бит әле.

Әйткәнемчә, Рәйлә белән икенче көнне үк танышып алган идек. Шулай да сабый күңелебездә нииндидер серле гүзәллек иясе булып урын алган Нәфисә апа безне ныграк кызыксындыра иде. Рәйләдән шундый да матур апасы булганы өчен бераз көнләшеп тә куябыз.

—Апам быел пединститутны бетерде. Тик эшләтерләрме, юкмы. Аны бит бездә беренче кәләш дип йөртәләр.

Рәйләнең тавышында ниндидер моңсулык чагылып китте:

—Аны быел кияүгә бирәчәкләр.

Яңа дустыбызның соңгы сүзләре матур әкиятнең күңелсез дәвамы сыман ишетелде. Ни өчен «бирәчәкләр»? Нишләп әле ул әкияттәге гүзәл кызлар кебек, алтын яллы, көмеш тояклы атка атланган хан егетенә каршы колач җәеп үзе чыкмый?

Нәфисә апаны без беренче күрүдән үк якын иттек. Ул үзе дә бик гади, ягымлы булып чыкты. Гадәттәгечә, кояш түбәнәеп, офык артына тәгәри башлагач, без Гөлгайшә әбиләр турындагы өелгән бүрәнәләр өстенә менеп кунакладык—көтү каршыларга җыелдык. Бүген бераз иртәләгәнбез, әллә көтүчеләр вакыт чамасын югалткан.

—Безнең Рәйлә күпме дуслар тапкан.

Ят тавыш бик тә йомшак һәм ягымлы булып ишетелде. Нәфисә апа да сүзләрне ачык итеп, матурлап әйтә икән. Вак бизәкле гади ситсадан татар кызларыныкыдай бөрмәләп тегелгән килешле күлмәге, кояшта бөтенләй диярлек янмаган ак, матур аяклары белән ул бөтенләй көньяк кешесенә охшамаган иде. Ә алсу-ак йөзеннән нур балкытып торган коңгырт-кара күзләре, җәйге яңгыр болыты төсендәге кабарынкы толымы белән ул мина әкияттәге гүзәл татар кызларының берсе булып тоелды. Нәфисә апаны мин таңга, аннан тагын кичке шәфәкъ нурына охшаттым. Сылулыгы, нәфислеге белән менә-менә әле дә кичке шәфәкъ балкышы кебек эреп югалыр да таңгы томан аша яңадан терелер сыман. Әллә инде үзен күргәнче үк серлелек пәрдәсенә урап телгә алгангамы, мин аны бу дөньяның гади кешесе итеп кабул итә алмадым.

Нәфисә апа барыбызның да исемнәрне сорашты, үзе кабатлап әйтә барды. Яна укытучы дәрестә балалар белән танышамыни. Әйе, чынлап та, мондый укытучыны без бик яратыр идек.

Шул чак безнең янга мотоциклы белән агроном Илсур абый килеп туктады.

—Нихәл, кызлар, егетләр, үсеп буламы?

Кара, әллә без озак күрми торганбыз, әллә... Моңарчы акны карадан аермыйча матаенда чапкан Илсур абый ничек үзгәргән. Безнеңише бала-чага белән сөйләшергә, шаярырга да вакыт тапкан ласа. Тик сүзе безнең тирәдә уралса да, бәхет кошының үзен тоткан әкият батырыныкыдай бәхеттән балкыган күз карашлары Нәфисә апа тарафларында. Үзе ак, тигез тешләрен күрсәтеп елмаюдан бушамый. Юк, юк тикмәгә генә түгел бу. Мондый елмаюларның, мондый серле карашларның юкка гына булмавын аңлар яшьтә инде без дә. Бераз кырысрак, җитдирәк кеше дә соң Илсур абый. Юк, шулай тоелган гынадыр ул.

Мина чак кына күнелсез булып китте. Хыялымдагы әкиятем өзелде ич... Нәфисә апа белән Илсур абый су буена юнәлделәр, ахры.

Авыл бер тында җанланды. Урам тутырып малкайлар көтүдән кайта башлады. Без дә һәркайсыбыз үз капкасына табан тараддык. Җәйге эш вакытында сыер-сарыкларны барлап ябу безнең бурыч инде ул.

Көннәр шулай үтә торды. Август урталары иде. Авылда уракның иң кызган мәлендә көннәр тоташы белән яңгырга кереп китте. Өлкәннәрнең телендә бер генә сүз—ашлык әрәм була. Авылның урамнары да котсызланып калгандай булды. Туктаусыз койган яңгырлардан юллар ерып чыккысыз баткакка әйләнде.

Тик табигатьнең көйсезлеге ике яшь йөрәкнең уртак хисләренә генә кагылмады. Мона кадәр бер-берсенең барлыгын да белми яшәгән бу икәү авыл халкын сокландырып көннән-көн якынайды, дуслашты. Тик кунакларның китәренә дә күп калмаган икән. Без Рәйлә аша бар яңалыкны ишетеп-белеп торабыз. Илсур абый Нәфисә апаны сорап та килгән. Тик мона әле җылы җавап кына булмаган. Әллә ни озак вакыт та үтмәде, югыйсә. Әмма егет белән кыз мәхәббәтенең ныклыгына, чынлыгы һәм тирәнлегенә шик юк иде. Нәфисә апа да кеше гомерендә бер генә тапкыр була торган шушы тирән хиснең язмышы икәнен тойгандыр.

Мәхәббәт дигәч тә... Тик тормыш үзенең ваклыклары, бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләре белән дә алдына килеп баса бит әле. Сыер савасы, кош-корт белән мәш киләсе, яшелчә-җимеш үстерәсе.... Шәһәрдә иркәрәк үскән кызны менә шундыйрак эшләр дә көтә. Кайнана буласы кеше авызыннан:

—Андый мәшәкатьләр өчен генә риза булмаска әйтсәләр, һич кыенсынмасыннар, курыкмасынннар да, әле көчемдә чакта үзем булышырмын, азак тагын үзләре карарлар,—дигән сүзләр дә кодагый буласы кеше тарафына ирештерелгән. Ә инде Илсур абыйның сыерны мин аны үзем дә савам, дигән сүзләрен Рәйлә дустыбыз үз колаклары белән ишетеп торган.

Киленнәрнең ялкаулыгын авылда бик өнәп бетермәсәләр дә, бу юлы нидер гаеплән авыз ачкан, сүз ишеттергән кеше булмады. Ят туфракта үскән бу иркә гөлнең үз ягыбызда төпләнеп тамырланырына өмет иткәннәрдер инде. Авылым акылы булган бу. Яна борын тәрткән яшел үләндәй нәфис, ургып чыккан чишмәдәй саф хисне түбәнлектән, ваклыктан сакларга тырышкан.

Олы мәхәббәт, анардан туган бәхет чынлап та соклангыч икән ул. Өлкәннәр белән без—бала-чага да, Нәфисә апаның авылда калуын, Илсур абый белән икесенең яна гаилә булып яшәүләрен бик тели идек.

Ә ана кеше кызының күңелендә кайнаган хисләрен йөрәгә аша ничек кабул иткәндер. Туган авылында үткән балачагын, тәүге мәхәббәтен хәтерләү белән ул да Нәфисә апаның бәхетенә ризалык бирергә теләгәндер, бәлки. Тик ят җирнең галәт-йолалары канына ныграк сеңәргә өлгергәндер шул. Рәйлә белән дуслашкач та аның сөйләгән хәбәре хәтеремә килде.

—Нәфисә апаны йә Илемҗанга, йә Сөләйманга бирәчәкләр. Илемҗангадыр инде. Ресторан директоры ул. Аның әтисе белән минем әти күптән дуслар.

Боларга өстәп калым, йола дигән сүзләрне дә кушкан иде. Ул вакытта Рәйләнең сүзләрен чынга алмый гына тынлаган идем. Янәсе, безнең заманда андый хәл буламыни?!.

Бүген төштән соң яңгыр яумады. Болытлар күктә агыла да агыла. Без көзгә тартылган кояшның җылы нурларын тансыклап урамга сибелдек. Мин килгәндә Рәйлә безнең яраткан урыныбыз—өелгән бүрәнәләр өстенә менеп утырган иде. Һәрвакыт шаян, сүзчән, житез кызыкай бу юлы күнелсез генә утыра.

—Иртәгә без китәбез.

Ул балаларча беркатлылык белән хәбәрен ярып салырга ашыкты.

—Нәфисә апа дамы?

Юк, дигәнне ишетергә теләп дустыма төбәләм.

—Әни бит... Резина итек өстерәп, бер очтан икенче очка йөрисең киләдер шул, дип ачулана.

Димәк, һаман килешеп бетмәгәннәр. Килешеп дигәнем Нәфисә апа мәхәббәтен калдырырга теләми, ә ана кеше гаиләсендәге кануннарны бозарга курка.

—Үзе гаепле апам. Мәмәй бит ул. Мин булсаммы?! Илемжанын да, Сөләйманын да яратмый ул. Бер кайтып китсә, бүтән җибәрмәячәкләр аны. Белеп торам.

Йомшак холыклы, бигрәк басынкы табигатьле шул Нәфисә апа. Гадәт-йолалар кысымында тәрбияләнгән кыз бала анасы белән әлеге тартышка да каян көч, кыюлык ала торгандыр әле. Мәхәббәте көчле булуы, канында ата-бабасыннан күчкән туган җир чакыруы уянуы, мөгаен, көч бирәдер.

Кичкә табан көн бөтенләй ачылды. Ә кояш баерга якынлашканда күктә ник бер болыт әсәре калсын. Күк йөзе белән бергә авыл кешесенең дә күзе ачылды, күңеле күтәрелде. Җәй уртасындагы сыман йомшак, җылы кич килде. Әле көзгә кадәр ерак ич. Бөтен офыкны алсу-кызыл төскә буяган кояшы белән тантана кылган табигать, гүя, тагын әллә ниләр вәгъдә итә кебек. Мондый чакны өйгә керәсе килә мени. Бакчадагы урам як койма буенда үскән алмагачның болай да алсу төскә керә башлаган алмалары шәфәкъ нурында кып-кызыл булып күренәләр. Нәкъ әкиятләрдә сөйләнә торган серле кич инде бүген. Күңелгә дә гади, көндәлек тормышта ят булган нәрсәләр хакындагы уйлар килә. Матурлык, мәхәббәт. Хатын-кыз гүзәл, табындырырлык дәрәҗәдә сокландыргыч та, шул ук вакытта гаҗәп көчле дә булырга тиеш. Нинди көч, каян алырга аны—монысын мин аңламыйм, ә тоя гына идем. Әнә кичке эңгер ышыгында агач яфраклары да нидер пышылдаша, ә кошлар өзелеп-өзелеп әле мин бик төшенеп тә бетмәгән илаһи дөнья хакында сайраша. Төннең серле канаты әллә кемнәрне ямьсез күзләрдән, яман телләрдән саклар булып караңгы-күгелҗем пәрдәсен тартты. Кошлар да үз теләгәнен тапты, ахры. Бераздан бөтен тирә-як тынып калды.

Акрын гына атлаган аяк тавышлары тынлыкны бозды. Яшьләр койма буендагы эскәмиягә утырдылар. Беренче сүзләреннән үк таныдым—Нәфисә апа белән Илсур абый ич. Гашыйкларны куркытырмын, дип мин урынымнан да кузгалмадым. Сөйләшер сүзләре сөйләшенеп беткән, ахры. Аңлашуы гына бик авыр булгандыр инде.

—Их Нәфисә, белсәң икән... Иртәгә көн аяз булачак бит. Тагын бер-ике көн яуса бу яңгыр ярты басу ашлык юкка чыгасы иде. Көне нинди матур булмакчы. Ә син китәбез дисең...

Илсур абыйның бу сүзләре әлеге яшәвенең бер мәгънәсе, соңгы юанычы, соңгы яме булып ишетелде миңа. Димәк, Нәфисә апа китә. Илсур абый да моның белән килешкән, күрәсең. Хәер, килешми ни хәл итсен соң. Аны иртәгә игене җыелмаган басулары көтә. Күпмегә онытгырып икән аны эше? Җәйнең сихри кичләре белән гомер буе шушы моңсу хушлашуны хәтерләмәсме ул?

Бертөрле тынлыкка җан өрергә теләгәндәй, талгын гына исеп куйган җил өлгереп килгән алма исен таратты. Баш әйләндергеч бу хуш ис—авыл көзенең бер авазы, гүзәл бизәге.

—Илсур, карачы, нинди хуш ис. Алмасы бигрәк тәмледер аның.

Нәфисә апаның йомшак тавышы бу.

—Кыргый алманың исе шундый була. Тик алмалары ачырак аның.

Илсур абый тавышында ул сагыш...

Сүз минем алмагачым турында бара. Поскан урынымнан атылып чыга яздым. Әйе, кыргый алмагач ул. Минем яраткан агачым. Әле алмалары бераз ачырак. Тик аз гына сабыр итегез, күзгә ничек кенә булып балланыр. Үзе әчкелтем, үзе татлы. Әйтерсен, Нәфисә апанын калу, калмавы шул алмаларга бәйләнгән. Әгәр дә ул жылы якнын сылу, иркә гөле ата-бабасы төягендә үскән шул әчкелтем алмаларнын тәмен татыса, бу жирләрне дә гомерлеккә яратыр кебек   тоелды мина шул чакта.

Ул елны Нәфисә апаны да, Рәйләне дә башкача күрмәдем. Иртәнге автобуска житешергә дип таннан кузгалганнардыр, күрәсен. Илсур абый да сөйгәнен озатырга килгән. Ничек аерылышып киткәннәрдер дә, ниләр сөйләшкәннәрдер?!.

Авыл халкында, янәсе, кыз ата ризалыгын ала да кабат килә икән, дигән сүз бер тын ишетелеп калды да тынды.

Ә Рәйлә берничә елдан сон өйләнеп кайтты. Элеккеге шаян, тиктормас кыз урынына горур, сөйкемле сылуны күрдем. Беренче тартынулар үтеп, балачак хатирәләрен барлау белән үк Нәфисә апаны сораштым. Ул күнелсезләнеп китте.

—Кайткач та кияүгә бирделәр аны. Илемжанга. Улы туды. Шуннан чирләде, ябыкты, сулды. Шинган чәчәк кебек ул хәзер. Бәхетле булалмады инде Нәфисә апам.

Мин дә кабат сүз кузгатмадым. Чын мәхәббәтнен кечкенә шаһите чагымнан ук заманында бу аерылу, гаделсез язмыш законы белән килешергә теләмичә байтак өзгәләнгән иде сабый күнелем. Еллар үтеп дөньяны башка күзлектән күрә башлагач та күз алдыма Нәфисә апа белән Илсур абыйны гел янәшә куеп карыйм. Әлеге икәү бу тормыштагы ваклыклардан бераз югарырак, үзләре дә тирә-ягымдагы кешеләрдән матуррак булып тәсмерләнә. Саф мәхәббәт керләми иде аларны. Болар хыялымда, ә чынында... Нәфисә апа өзелгән гөлдәй сулган... Илсур абый бераздан өйләнде. Гади генә, унган авыл кызын сайлады. Тупылдап торган матур уллар, кызлар үстерәләр. Үзе бәхетлеме икән? Жәйге тын кичләрдә хәтерендә ниләр уяна икән?

Шул ук елны минем кыргый алмагачым корыды. Кышы да әллә ни салкын түгел иде. Хәер, төбеннән яшь ботаклар янарып килә килүен. Күпме аралар үтеп берсен-берсе тапкан ике яшь йөрәкнен аерылуын күтәрә алмады ахры ул да. Яраткан агачымны бигрәк юксынам. Көзге кичләрдә басулардагы өлгергән игеннәрнен туклык бөркегән татлы тәме белән тау итәгендә үскән әремнен әрнүле ачы исенә кушылып, авылымнын үземә генә кадерле таныш ямен тудырган шул кыргый алма исен, анын әчкелтем-татлы жимешләрен сагынам.

⁂

*Кырымтатар шагыйрьләре*

## Бәкер Чабан-Задә

### ТУГАН ТЕЛ

**Сине мин Кырымда, Казанда таптым,
Йөрәгем кайнап ташканда таптым.
Ят илдә моңаеп, ачынып йөргәндә,
Өметем, хыялым, күңелем сүнгәндә,—**

**Муеныңа сарылдым дәртемне әйтеп,
Бер гүзәл сүзеңнән үземә кайтып.
Җырларың булмаса, мәгънәң булмаса,
«Йорт» дигән сүзеңнән күңел тулмаса,—**

**Аһ, ничек йөрермен бу горбәт якларда.
Танышсыз, белешсез ят сукмакларда.
Белмимен: түрекме, татармы атың,
Бик яман татлысың, Тәңредән дадың.**

**Түрек тә, татар да синең сүзләрең,
Икесе дә нур сибә—моңлы күзләрең.
Аңласа бер сине, дошман да сөяр,
Бер гади сүзеңә ул башын ияр.**

**Каберемдә мәләкләр җавап сораса,
Газраил телемне кырык кат борса да,
«Үз туган телемдә әйт миңа!»—диярмен,
Үз туган телемдә җыр җырлап үләрмен.**

**Йөрәкне кайгылар кимереп торганда,
Күгемнән күрмәгән йолдызлар узганда,—
Туган тел! Башкасы акылыма килми,
Бер бөек серем син, дошманнар белми.**

**И суык шул горбәт, ялкынсыз, нурсыз,
Тормышны безләргә күңелсез, җырсыз.**

**Былбылы җырласа, моңнарым арта,
Тавышы аз гына «Борлы»га[1] тарта.**

[1] Халык җыры

Тауларга карыймын—чатырга охшый,
Күзләрем яшьләнә, калебем йомшый.

Болытлар карала акырын-акырын,
Таптыймын ялгызым тозлы юлларын.

Уйлыймын анамның ул күз яшьләрен,
Аулымның еракта күмелгән яшьләрен:

Юлымда елмаеп карый кызлары,
Күзләрдә уңганлык, сөю эзләре.

Охшатып аларны бәхетсез Әсмага[2],
Карамый үтәмен, кайгыра-яна...

Гөлләре бик кызыл, аһ, ничек кызыл!
Кызылны ни өчен сөямендер быел?

Кызылдыр—«Йорт!» дигән бөек маңгайлар
Ул «Яшел атау»ны кызылга маналар.

Сөямен бу төсне ирәннәр рәнке[3] дип,
Ирәннәр беттеләр йорт үрнәге дип.

Минем дә кызылга буялсын маңгаем,
Яшерен күмсеннәр, күрмәсен анаем.

Кызарсын канымнан йортымның гөлләре,
Иснәсен былбыллар, тотылсын телләре.

Бәйрәмдә, сәйранда татарның кызлары—
Көн күреп уңмаган таң йолдызлары,

Өзсеннәр, таксыннар күкрәкләренә,
Йорт гыйшкы тиз тулар йөрәкләренә.

Үләбез аларны уңармак өчен,
Татарны тәхтенә чыгармак өчен,

Йә йортны корып, без сөрәбез гомер,
Йә «Йорт!» дип җан атып булабыз күмер.

*1918*

---

Чәләби
Җиһан

## АНТ ИТКӘНМЕН

Ант иткәнмен татарларның ярасын бәйләргә!
Ничек болай—бу бичара кардәшләрем чересен?
Алар өчен үкенмичә, кайгырмыйча яшәсәм,—
Йөрәгемдә типкән каным кайнамасын, сүрелсен.

---

[2] Шагыйрьнең сөйгән яры

[3] Рәнк—төс

Ант иткәнмен бу караңгы йортка якты өстәргә.
Ничек болай—ике кардәш бер-берсенә ук атсын?
Моны күреп ярсымасам, кайгырмасам, янмасам,
Күзләремнән аккан яшьләр диңгезләрне уятсын!

Ант иткәнмен, сүз биргәнмен милләт өчен үләргә.
Белеп, күреп милләтемнең күз яшьләрен үбәргә.
Белми, күрми мең яшәсәм югары тәхетемдә,
Килер бер көн—мазарчылар килер мине күмәргә.

---

## Әмди Гәрәйбәй

# ТУКАЙГА

И төрк-татар дөньясына якты нур чәчкән Тукай,
Кара халыкка ана теленең юлын ачкан Тукай.
Дәртебезне, хәлебезне җырлаган, әйткән Тукай,
Бик вакытсыз, гөлдәй сулып, асылына кайткан Тукай!

Тукай, синең кыйммәтеңне яшәгәндә белмәдек,
Безнең өчен җан талаштың, җырладың да сайрадың.
Язмыш сине хурлаганда күз яшеңне сөртмәдек,
Үз башыңа соңмы әллә дошманга теш кайрадың?

Ничөн, Тукай, арабызда таң атканчы калмадың?
Ничөн, Тукай, калып янә юлбашчыбыз булмадың?
Бүген матәм тотабыз без, ишетәлми сүзеңне,
Юклыгыңны бик тоябыз, хәтерлибез үзеңне.

Остазыбыз, Чулпаныбыз, син башыбызсың, Тукай,
Юл күрсәттең син милләткә ул болытлы көннәрдә.
Бүген янә хуҗабызсың, юлбашчыбызсың, Тукай,
Бер яктыдай күрдек сине без караңгы төннәрдә.

Дәртле Тукай, моңлы Тукай, гомере кыска яшь Тукай,
Халыкчан әдип, шагыйрьләр урдасына баш Тукай.
Синсең, Тукай, кальбебездә халык сөюе яраткан,
Синсең, Тукай, бүген безне кара халыкка караткан.

Хөрмәт сиңа халкыбызның янып сөйгән Тукае!
Хакыйкатькә, акка була янып көйгән Тукае!
Тарихыбыз бәйрәм итсен, тантаналар ясасын,—
Синдәй шагыйрь җитештерде. Тукайизм яшәсен!

*Акмәчет, 13 апрель, 1920 ел.*

## Әшраф Шәми-Задә

# ЙӨРӘГЕМӘ

Чараң булса, туктамый тор, тип ничәдер ел тагын,
Туган анам карынында тормыш алган йөрәгем!—
Көчтән калып туктасаң да, һич тә үпкәм юк сиңа,
Чөнки син дә минем кебек бик алҗыдың, йөрәгем.

Авыр, кара бу елларны без дә баштан үткәрдек,
Күрдек агын, кызылын да... Террор китте ялганып.
Иярде мәгърур халкыбыз ялганчы хаин «вождь»ка,
Аның купшы, ялтыравык сүзләренә алданып.

Егерме сигез, утыз ике, утыз җиде, кырык дүрттә
Золымнарның иң яманын икенче «вождь» җиткерде.
Бар халыкны хаста дими, бала-чага, карт дими,
Төн эчендә ватаныннан горбәтлеккә сөрдерде.

Минем белән син дә чиктең хурлык-җәбер газабын,
Төрмәләрдә, лагерьларда, сөргенлектә, горбәттә.
Мин «аһ!» дисәм, син көрсендең, мин еласам—еладың.
Җәбер золымы бер булгач, тәкъдир дә бер, әлбәттә.

Көчең җитсә, туктамый тор, чыда, йөрәгем, чыда!
Хөр халкымның ватанына җирләшкәнен күрим мин.
Күп хәсрәтләрне кичергән йортыбызда кавышып[1],
Кендегемнең каны тамган туфрагымда үлим мин!

*1978*

---

## Сәйтүмәр Әмин

# КАЙТАЛМАДЫМ

Бер заманнар сине бик сөя идем.
Киттем, озакларга аерылдым синнән.
Хәзер янә кузгалды минем дәртем—
Күрергә телим! Чыкмыйсың исемнән.

Очрадым бәлаләргә—юлда егылдым.
Кайталмадым сиңа, аһ, кайталмадым.
Кайнар комнарда яндым, ягылдым.
Җан серләремне сиңа әйталмадым.

Хыялымда җанланыр синең йөзләрең,
Күзләремә багар зәңгәр күзләрең.
Дулкынланыр гүя Кара диңгезем...
Колагымда чыңлар татлы сүзләрең.

---

[1] Кызганычка, шагыйрьнең бу теләге кабул булмады, җәсәде Мәскәү туфрагында калды...

Аерылдым синнән—ерак юлларда талдым.
Йөрәгемнән кан,
Күзләремнән яшь тамды.
Мәхрүм калдым Ата-ана йортыннан...
Кемнәр аңлар
Минем хәсрәтле җанны?!

---

## Шәүкый Биктүрә

# ТАТАРЛЫГЫМ

Татарлыгым, туган җирем,
Балалыктан сөямен.
Аның өчен күп вакытта
Елыйм, янам, көямен.

Күп эзләдем, кая барсам
Күрдем: татар чәчелгән.
Үз йортында тик хуш исле
Юк бер гөле—ачылган...

И татарым, үз ягыңда,
Үз илеңдә син гариб.
Ләкин кемгә әйтеп була
Бу турыда таш ярып?

Күчте җаны мәзлумнарның
Таута, ташка йә ярга.
Ярты дөнья мазар булган
Татарлыкка, татарга.

Һәр мазарның баш очында
Туктап түктем күз яше.
Һәр беренә аһларымнан
Ясадым кабер ташы.

Кул күтәреп дога кылдым
Йөрәгемнән Ходайга,—
Озын, котлы гомер бирсен
Безнең гариб анайга...

---

## Леман Сөләйман

# ТӘҮГЕ ҖЫР

Иртә уяндым, чыктым тышка мин,
канат алдым да хыялларыма,
ак юл теләдем киткән кышка мин,
яулык болгадым гүя ярыма.

Ишетелде җыр, әтраф җанланды,
сүнек йолдызлар хәтта көлделәр,
алтын шәл япкан офык түрендә
чая кошчыклар талга менделәр.

Былбыл түгел лә, җиләс җил иде
язның бу тәүге җырын җырлаган:
«Шагыйрь, йоклама, син дә кил,—диде,—
син дә илһам ал киң чүл, кырлардан».

*Ркаил Зәйдулла*
*тәрҗемәләре*

Флүн
Мусин

# МИЛЛӘТ САГЫНДА

**Г. Исхакыйның гаять күпкырлы эшчәнлеге үз чорындагы милли яшәешнең төрле-төрле якларын колачлавы белән татар дөньясындагы феноменаль күренешкә әверелә, бик күп өлкәләрдә ул башлап йөрүче яки юл күрсәтүче була. Боларның барысы уртак бер максатка—милләтне инкыйраздан саклап калуга һәм үстерүгә хезмәт итә.**



Аның әлеге эшчәнлегенең үзара тыгыз бәйләнгән һәр тармагы бик мөһим булса да, без Исхакый исемен телгә алганда, аны беренче чиратта әдип итеп күз алдына китерәбез. Әмма ул— гадәти язучы түгел, бәлки исляхчы, новатор каләм иясе. Монысын аңардан тарихи мәҗбүрият тә таләп итә. Эш шунда: үзе яшәгән борылыш заманының татарны милләт буларак саклап калуны бөтен житдилеге белән көн тәртибенә куюын аеруча тирәнтен аңлап, ул бу милли-тәкъдири әһәмиятле мәсьәләне хәл итүдә әдәбиятка аеруча зур өметләр баглый. Ә бу өметне аклау өчен башта әдәбиятның үзен яңа заман рухында һәм милләтнең ышанычлы таянычы булырлык итеп яңартырга кирәк иде. Шул ук вакытта Исхакый, алга киткән башка халыклар тәҗрибәсеннән чыгып, заманча житлеккән әдәбиятның милли үсеш дәрәҗәсен билгели торган фактор булуын да яхшы аңлый. Чөнки үсешкә ирешкән француз, инглиз, рус кебек халыкларда аларның шулай ук киң танылган әдәбиятлары милләтне әйдәп баручы ижтимагый-рухи көч булып тора. Г. Исхакый узган гасырның тәүге елларында, төгәлрәге 1905 елда, Петербургтагы "Нур" газетасында чыккан, тел мәсьәләсенә багышланган мәкаләсендә: "Моннан соң безнең халыкның тормышында да әдәбиятка иярү, әдәбият күрсәткәнчә йөрергә, булырга тырышу күренәчәктер",—дип белдерә. Татар әдәбиятына да башкалардагы кебек халыкның рухи юлбашчысы вазифасын йөкләп, Исхакый туган әдәбиятын ничек шундый зур һәм җаваплы вазифаны башкарырлык итеп үстерү турында уйлана гына түгел, бәлки үзе бу эшне башлап җибәрүчеләрнең берсе дә була. Исхакыйның туып килүче яңа заман татар әдәбиятының идеологына әверелүенең һәм ижатының новатор төс алуының нигезендә әдәбиятның милли мөстәкыйль сүз сәнгате булуы өчен көрәшү ята иде. Ә мондый мөстәкыйльлек ахыр чиктә татарны милләт буларак саклап калу өчен кирәк иде. Бирегә Исхакый болай фикер йөртә: "Монгача кадәр һәр халык, дустлык, дошманлык мөнәсәбәтендә үзенең киемен кие-

неп, гадәти диненә бөркәнеп кенә мәйданга чыкканга, ... һәр халыкның мәгънәвияте, эчке тормышы үзеннән-үзе бер юл берлән акканга, әлбәттә, "үзлекне саклау" авыр булмаган."

Хәзер исә башка халыкларның, шул исәптән татарларның да, ассимиляцияләшү сәясәте көчәйгәннән-көчәя барганда, "аның әдәбияты, театры, фәлсәфәсе, музыкасы, фәне, сәнаигы нәфисәсе рухымызга туктамаенча төртелеп торганда", сәясәт һәм икътисад өлкәләрендә дә шундый ук хәл күзәтелгәндә, татарның әлеге "үзлеген" ничек саклап калырга? Шундый сорауны алга куеп, Исхакый аңа җаваплар да эзли. Ул үзгәрә башлаган татар мәгыйшәтендә әлеге басымга каршы торырлык көчләр хасил булуын да күрсәтә. Боларга мисал итеп ул мәгариф өлкәсендәге ярышны, татар сәүдәсенең яңадан терелеп һәм куәтләнеп китүен, авылда икътисади үзгәрешләр башлануын, яңа буын морзаларның да халыкка йөз белән борылуын, күптөрле милли җәмгыятьләр хасил булуын һ.б. ала. Саналган факторларның һәркайсы үз урынында мөһим булуын искәртү белән бергә, Исхакый татарның "үзлеген", ягъни милли асылын саклауда әдәбиятка һәм аның белән бәйле театрга, музыкага аерым бер урын бирә. Чөнки алар турыдан-туры милли рух белән сугарылганнар, "без бер халык, без бер милләт!"—дигән фикерне үзләренә идеал итеп алганнар. Шушы идеал татар әдәбиятына үз юлын булдырырга ярдәм итә.

Татар дөньясының һәм мәдәниятенең европача глобальләштерүгә каршы тора алуында тагын бер мөһим чара итеп Исхакый Европаның төрле өлкәләрдәге казанышларыннан файдалануны саный. Европалашуны "француз хәятының беркатлы әдәбин, тышкы мәдәниятен" генә турыдан-туры күчерү белән шөгыльләнгән төрекләрдән аермалы буларак, Исхакый: "Без исә, Аурупаның фикерен, фәлсәфәсен, эшчеләр хәятын өйрәнеп, бүлешеп, аларга татар рухы биреп, тәгъбир ясасак, аларга татар киеме кидереп, татар исе сеңдереп шулай кабул итәргә телимез". Ачыграк әйткәндә, әдәбият ярдәмендә татар хәятын заман таләп иткәнчә европалаштыруны Исхакый "татарларны татар булып калган хәлдә аурупалаштыру, ягъни татарларны тумыштан килгән милләтлекләрен саклаган хәлдә Аурупа мәдәнияте эченә кертүдер" дип аңлый.

Татар әдәбиятының милли мөстәкыйльлеген саклау һәм үстерү, икенче яктан, аның милләткә тагын да нәтиҗәлерәк хезмәт итүе өчен кирәк. Әдәбиятның милли максатчан төс алуы "халкымызның нәрсәләргә мохтаҗ булуын тәмам ап-ачык" күрсәтергә, "язучыларымызга шул иң кирәкле мәсьәлә хакында" язарга булышачак.

Татар әдәбиятының милли мөстәкыйль булуының ни өчен кирәклеген һәм моңа ирешү юлларын шул рәвешле билгеләп, Исхакый үз иҗатын тулысынча әлеге идея-эстетик фаразларны гамәлгә ашыруга багышлый. Аны аеруча милләтне инкыйраздан саклау һәм үстерү буенча әдәбият алдында торган бурычлар кызыксындыра. Мондый бурычларны XIX йөзнең соңгы чирегендә мәгърифәтче әдипләр дә алга куя һәм хәл итә башлаганнар иде. Яңа гасыр башы шартларында Исхакый аларның эшен тагын да конкретлаштыра төшеп һәм реаль тормышка ныграк нигезләнеп дәвам итә. Шул рәвешле ул милли әдәбият һәм милли әдип нинди булырга тиешлегенә ныклы ачыклык кертә.

Яңа заман татар әдәбиятының ул замандагы аеруча әһәмиятле яки борчу уята торган дип исәпләнгән милли мәсьәләләрне яктыртырга тиешлегенә басым ясап, Исхакый үз иҗат эшчәнлеген әнә шул юнәлештә җәелдерә. Бу яктан ул башкаларга үрнәк тә күрсәтә. Мәгълүм ки, Исхакый әдәбияттагы беренче адымнарын кин милли-тәкъдири әһәмиятле мәсьәләне—милләтнең киләчәген, ягъни яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсен яктыртудан башлый. Яшь әдипнең беренче ике әсәре "Тәгаллемдә сәгадәт..."тә һәм аннары "Бай углы" повестьларында яшь буынга дөрес тәрбия бирүнең иң мөһим шарты дип аны аң-белемле итү карала. Әсәрләрдә шушы мәсьәләгә төрле мөнәсәбәткә нигезләнгән ике төрле язмыш сурәтләнә. Беренче повестьта яшь герой Хәлим, иске карашлы әтисенең каршылыгын җиңеп Казан мәдрәсәсендә уку теләгенә ирешә. Яшь героеның бик тырышып укып күп

белемле кеше булуының сәбәбен автор тагын Аллаһе Тәгаләнен Хәлимгә әлеге белемнәрне үзе өчен генә түгел, бәлки кавемен, ягъни туган халкын ан-белемле итү өчен дә бирүе белән бәйләп аңлата. Яшь герой мәдрәсәне тәмамлагач шулай эш итә дә.

"Бай углы"ндагы Фатыйх байның бердәнбер улы Кәрим, киресенчә, иске карашлы ата-анасы һәм урам йогынтысына бирелеп мәдрәсәдә укымыйча надан булып кала һәм бу наданлыкның ачы фаҗигасен кичерә. Ягъни тормышта ялгыш юлга басып, бик яшьли дөньядан да китеп бара.

Беренче әсәрләрендә ан-белемле булу яки булмауның шундый нәтиҗәләрен әле күбрәк мәгърифәтчеләрчә яктырту белән бергә, Исхакый алга таба иҗатында мәдрәсәләрдә яшьләргә белем бирүнең торышы белән дә якыннан кызыксына. Ул әлеге мәсьәләне танылган ике әсәрендә—"Тормышмы бу?" һәм "Мулла бабай" романнарында конкретрак итеп чагылдыра. Һәр ике очракта да әдип мәдрәсәләрдәге уку-укыту системасын шактый тәфсилле сурәтләп, уртак бер нәтиҗәгә килә. Бу нәтиҗәне "Тормышмы бу?" романының мәдрәсәне тәмамлаган үзәк героеннан болай дип әйттерә: "Мин хәзер аз гына русча, аз гына төрекчә, аз гына гарәпчә, фарсыча, аз гына үз телем татарча беләм... Шуның өстенә, тарихтан аз гына, җәгърафиядән аз гына, хисап, һәндәсәдән аз гына, әллә нинди үләннәр, хайваннар хакында, аз гына өй тәрбия кылу, бала укыту, мәктәп идарә кылу хакында, аз гына дин вә игътикад хакында, аз гына тәфсир хәдис хакында, аз гына мантыйк вә хикмәт хакында—кыскасы гына һәр нәрсә хакында аз гына мәгълүматым бар. Боларның һәммәсене өстән кенә белсәм дә, берсене дә чынлап белмим." Башта зур романтик хыяллар белән яшәгән шәкерт, әлбәттә, мондый белемнән һич тә канәгать түгел. Чөнки моннан соң аңа әлеге хыялларыннан баш тартып, әтисенең генә теләгеген канәгатьләндерергә, ягъни авылга кайтып мулла булырга гына кала. Әсәр битләреннән ул олыгайгач үз тормышыннан үзе канәгать булмаган хәлдә чыгып китә. "Мулла бабай" романы герое Хәлим исә шул ярты-йорты белгәненнән канәгать. Чөнки аны күбрәк икенче нәрсә кызыксындыра: "Шул мәгълүмат, шул рухани азык белән бер авылны, бер мәхәлләне агартырга хәзерләнә, бернечә мең кешегә үрнәкче, житәкче булырга уйлый иде. Шул халыкны үзе кебек үк итә алмаса да, үзе кебирәк уйларга өйрәтергә, үзе кебирәк күздән дөньяга вә ахирәткә карарга өйрәтергә хәзерләнә вә шул өйрәнүдә чынында әллә никадәр файда, әллә нинди зур эш дип игътикад итә иде."

Гомумән алганда, бу ике әсәрдә дә революциягә кадәрге мәдрәсәләрдә шәкертләргә ярты-йорты белем бирелү алардагы уку-укыту системасының баланың реаль мөмкинлекләрен искә алмавы белән бәйләп аңлатыла. Әйтергә кирәк, мондый система әле безнең заманга кадәр яшәвен дәвам итә. Хәзерге мәктәпләрдә дә укыту баланың мөмкинлекләренә индивидуаль карашны күздә тотмый, ул укучыларның бөтенесе дә энциклопедик сәләткә ия дигән фаразга корылган кебек. Дөрес, соңгы вакытларда әлеге системаның әнә шул зур кимчелеген, ниһаять, танып һәм Көнбатыш мәгарифе тәҗрибәсенә нигезләнеп, баланың шәхси сәләтен искә алуга корылган профильле укытуга күчү башланды.

Үзенең публицистикасында, аерым алганда, "Мөгаллим вә мөгаллимәләремезнең бу көнге вазифалары нәрсә?" дигән программ характердагы мәкаләсендә (1914), татар мәгарифе алдына бик зур бурычлар куюе белән бергә, Исхакый үз әсәрләрендә бу системада эшләүчеләр, ягъни мөгаллим һәм мөгаллимәләр белән дә якыннан кызыксына һәм әлеге мәсьәләгә "Мөгаллим" һәм "Мөгаллимә" дигән пьесаларын багышлый. Әсәрләренә шундый гомуми төстәге исемнәр биреп, әдип аларның үзәк герой образларында шул вакыттагы мөгаллимнәр кавеменең ниндидер гомум сыйфатларын чагылдырырга теләгән, күрәсең. Әмма мәсьәләне ничектер, полемикрак рухта яктыртулары аркасындадыр ахры, әлеге пьесалар, бигрәк тә сәхнәгә куелып киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгәч, матбугатта шактый бәхәсләр тудырды. Әсәрләрдә күбрәк үзәк геройларның шәхси тормышы белән иҗтимагый вазифалары арасындагы мөнәсәбәтләрне ачуга

дикъкать итела һәм ул мөнәсәбәтләрнең төрлечә булуы күрсәтелә. "Мөгаллим" драмасында мөгаллим Салих башта үзенең яшәү мәгънәсен һәм максатын халыкка мәгърифәт ярдәмендә хезмәт итүдә күрә һәм шундый ният белән авылда балаларны җәдитчә укыта башлый. Әмма бераздан ире идеалларыннан бик ерак торган хатыны йогынтысына бирелеп, Салих үткәндәге уй-хыялларын оныта һәм көндәлек тормыш мәшәкатьләре белән генә яшәүче гадәти обывательгә әверелә, ягъни һәм иҗтимагый, һәм рухи яктан "үлә". Әсәр ахырында аны бу аянычлы хәлдән шәһәрдән килгән иптәше Фазыл коткара. Ул Салихны уятып җибәрә һәм аңа хәзерге хәленә аек күз белән карарга булыша. Болай яшәвенең мәгънәсезлеген аңлап һәм тормышта кабат иҗтимагый мәгънәле юлга басырга теләп, ахры, Салих семьясын ташлап авылдан китеп бара. Кыскасы, пьесада мөгаллим кеше шәхси тормыш белән генә канәгатьләнмәскә, бәлки барыннан да элек иҗтимагый мәгънәле тормыш белән яшәргә тиеш дигән фикер үткәрелә.

"Мөгаллимә"дә исә әлеге пьесадагыга капма-каршырак ситуация сурәтләнә. Аның героинясы Фатыйма Казанда укып мөгаллимә булгач, ерак Себердәге кечкенә бер шәһәргә барып андагы милләттәшләренә ан-белем бирү белән шөгыльләнә, ягъни милләткә файда китерә. Әмма үзен тулы бәхетле итеп сизә алмый. Чөнки аның шәхси тормышы барып чыкмаган. Эш шунда: Казанда яшәгәндә ул бер егеткә гашыйк була, әмма тегесе аның мәхәббәтенә җавап бирми. Шушы җавапсыз мәхәббәтеннән качарга теләп тә кыз Себергә китеп бара. Ләкин кыз анда икенче бер мәхәббәт газабына дучар була. Биредә аңа шул ук мәктәптә укыткан Габдулла үлеп гашыйк була, аңа Аллага табынгандай табына башлый. Кыз исә бик акыллы бу егетнең илаһи мәхәббәтен кабул итә алмый, чөнки ул һаман Казан егетенә булган мәхәббәт утында яна. Габдулланың җавапсыз мәхәббәттән газаплануын күтәрә алмыйча ул әсәр ахырында бу шәһәрдән дә китәргә җыена.

Милләт яшәеше һәм язмышы турында уйлаганда Исхакыйны нык борчыган тагын бер мәсьәлә—гаилә. Гаилә тормышын ул милләт яшәешенең нигезе дип исәпли. Милләтнең ныклыгы һәм яшәүчәнлеге гаиләдән башлана дип инанган, Исхакый татар мәгыйшәтендә милли мәнфәгатьләргә хезмәт итми генә түгел, бәлки зыян китерә торган гаиләләр белән еш очраша һәм иҗатында да шуларга игътибарын юнәлтә. Милли күзлектән караганда әдипне бигрәк тә күп хатынлы һәм катнаш гаиләләр борчый. Үзенең бу борчуын ул "Өч хатын белән тормыш" пьесасында һәм "Ул әле өйләнмәгән иде" повестенда чагылдыра. Искә алынган пьесада Кәрим бай гаиләсе мисалында Исхакый мөселман дөньясында бик борынгыдан яшәп килгән күп хатынлы гаиләне XX гасыр башында татарлар өчен инде үзен акламаган һәм кирәксез дип таба. Чөнки андый гаиләдә татулык, бердәмлек юк, шунлыктан ул нык түгел. Шул сәбәпле, пьесада Кәрим бай гаиләсе таркала. Милләт өчен кирәкле гаилә итеп пьесада Кәрим байның антиподы Риза корган гаилә күрсәтелә. Ул яраткан бердәнбер хатыны белән матур гаилә кора һәм тормышта да бөтен теләкләренә ирешә.

Катнаш гаилә мәсьәләсе исә "Ул әле өйләнмәгән иде" повестенда яктыртыла. Безнең заманда үзенә бер модага әверелгән һәм киң пропагандалана торган мондый гаиләне Исхакый XX йөз башында милләтнең киләчәгенә куркыныч яный торган афәт дип бәяли. Әсәрнең үзәк герое булган зыялы егет Анна Васильевнаны яратып гаилә корса да, чынлыкта үзен бәхетле итеп сизә алмый. Чөнки бу гаиләдә туган балалар баштан ук татарлыктан читләштереләләр. Повесть татар дөньясына зур зыян китергән күңелсез бер традицияне чагылдыра.

"Ул әле өйләнмәгән иде"дә Шәмсинең рус хатыны белән гаилә коруының сәбәбе дә игътибарга лаеклы. Эш шунда: егет татар кызлары арасыннан Анна Васильевнага тиңне тапмый. Моның төп сәбәбе исә татар кызларының беркайда да укымаган һәм надан булулары белән бәйләнгән. Шул сәбәпле, узган гасыр башында татарның күп кенә ан-белемле егетләре башка халыкларның ан-белемле кызларына өйләнә. Бу хәлнең бик күңелсез нәтиҗәләргә китерәчәген аңлап, ул елларда татар кызлары өчен махсус мәктәпләр дә ачыла.

Мәгърифәтчеләр заманыннан алып киң җәмәгатьчелекне борчый башлаган татар хатын-кызы язмышы Исхакый иҗатының да иң мөһим мәсьәләләреннән берсенә әверелә. Үзенең публицистикасында ул, мәсәлән, татар дөньясында милли янарыш заманының иң зур казанышларыннан берсе дип шуны саный: хатын-кызларның "үзләрен-үзләре кеше иттереп күрү, аларның үзләренең күзләрендә кыйммәтләре арту, үзләренең урыннарын белү, үзләренең тормыштагы вазифаларын аңлау булды". Шуннан алар аң-белемгә омтылалар һәм, гомумән, милли-иҗтимагый яшәештә активрак катнаша башлыйлар. Моннан тыш Исхакый хатын-кызларның милләт яшәешендәге күркәм бер вазифасын—аларның үткәннән килә торган милли рухи-әхлакый кыйммәтләрне ирләргә караганда да ныграк саклаучы булуларын ассызыклый. Әдип мәгариф өлкәсендә дә хатын-кызның өстенлекле бер сыйфатын ачыклый. Исхакый фикеренчә, "табигать аның күнеленә бала сөюне, бала тәрбия кылуны туганда ук сибеп тудырганга, мөгаллимәнең тәрбия ягы шөбһәсез мөгаллимнән әллә ничә мәртәбә артык булачактыр".

Әгәр публицистикасында Исхакый хатын-кызлар даирәсендә күзәтелә башлаган гомум уңай күренешләр турында яки киләчәкне фаразлап язса, әдәби әсәрләрендә исә ул героиняларының тормыштагы язмышларын конкретрак чагылдырырга алына. Әмма биредә дә реализм белән романтизм элементлары еш кына үрелеп китә. "Кәләпүшче кыз" повестенда ул әле шактый дәрәҗәдә реалист. Чөнки Камәрнең ничек фахишә булып китүе дә, моның ачы нәтиҗәсе дә сурәтләнә. Ләкин, Й. Акчура әйткәнчә, милләтнең "иң агулы бер чобанын" ачарга алынып, Исхакый бу хакта тыныч кына яза алмаган, бәлки, Г. Сәгъди сүзләре белән әйтсәк, "һәр мөселман егларлык рәвештә ялкынлы хис белән, сентименталь рәвештә янып, көеп тасвир иткән".

"Теләнче кызы" романында Сәгадәт язмышын яктыртуда реализм белән романтизм элементлары тагын да ныграк үрелә. Героиняның ятимлектә үткән яшүсмер чагын сурәтләгәндә автор әле реаль тормышка якынрак тора. Ә менә аның Габдулла байдан алдану һәм гаилә дә корып җибәрүләреннән соң Сәгадәт язмышын тасвирлауда романтик башлангыч көчәя. Биредә инде әдип үзенең хатын-кыз идеалын чагылдырырга тотына. Зыялы егет Мансур ярдәмендә Сәгадәт иҗтимагый-мәдәни хәрәкәттә катнаша башлый һәм бу хәл геройның дөньяга карашларына, уй-омтылышларына уңай тәэсир итә. Үзенең аң-белем ягы бик чамалы икәнен аңлап, ул Казандагы кызлар гимназиясен тәмамлый. Габдулладан аерылганнан соң ул, "тәмам ялгыз, үз көченә таянып алга таба барырга тели торган бер татар хатыны"на әверелә. Әсәр ахырында ул тагын да зуррак белем алырга теләп Петербургка китә. Сәгадәтнең бу гамәле әсәрдә аның "кояшка таба" юл алуы дип бәяләнә. Әлбәттә, тормыш төбенә тәгәрәгән ятим авыл кызында хасил булган мондый кардиналь үзгәрешләр күбрәк автор хыялыннан чыгып, ягъни романтик планда сурәтләнә.

Татар хатын-кызы язмышын мәгънәви яктан тагын да масштаблырак итеп, ягъни гомуммилли янгыраш биреп сурәтләү белән без "Зөләйха" трагедиясендә очрашабыз. Аның героинясы Зөләйха гади татар хатыны гына булып калмый, аңа милләт анасы вазифасы да йөкләнә. Әсәрдә героиняны чукындырып диненнән, иманыннан ваз кичтерергә тырышу гомумән татар милләтен шул юл белән юкка чыгарырга омтылу булып аңлашыла. Әмма көчләп чукындырылып монастырьда һәм каторгада бик зур газаплар кичерүенә дә карамастан, Зөләйханың динен, иманын саклап кала алуы татар милләтенең үзен саклап кала алачагына тирән ышаныч уята.

Россиядә татарларның авыр язмышын, еш кына бик зур гаделсезлекләргә һәм югалтуларга дучар ителүен шулай сурәтләве аркасында, патша цензурасы пьесаны сәхнәләштерүне каттый тыя. Аңа бары 1917 елгы Февраль революциясеннән соң гына сәхнәгә юл ачыла. Әсәр беренче тапкыр "Сәйяр" труппасы тарафыннан 1917 елның 17 мартында Казанның Зур драма театры сәхнәсендә уйнала һәм җәмәгатьчелекнең киң игътибарын җәлеп итә, матбугат битләрендә аңа

багышланган күп кенә мәкаләләр була. Бу вакытта Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнарының беренче съездын әзерләү эшләренә чумган Г. Исхакый күптән көткән спектакльне күрер өчен махсус рәвештә Казанга килә. Спектакльне караганнан соң "Новый клуб" залында Г. Исхакый хөрмәтенә зур банкет үткәрелә. Ул мәҗлестә унбиштән артык татар оешмасыннан 160 тан күбрәк вәкил катнаша. Үзенә бер милли кинәшмә төсен алган бу чара Г. Исхакыйның программ характердагы тарихи чыгышы белән дә игътибарга лаек. Аерым алганда, ул чыгыш күрәшче әдипнең иҗтимагый-сәяси карашларындагы эволюцияне күзаллау ягыннан кызыклы. Мисал өчен, беренче рус революциясе чорындагы сыйнфыйлык позициясеннән үзенең хәзер милли бөтенлек байрагы астына күчүен әдип болай аңлата: "...1905 нче ел революциясе вакытында без җимерү хезмәтен итәргә тиеш идек: яңа тормышны төзер өчен безгә ул вакытта җимерергә, җимерергә, тагы бер кат җимерергә тиеш вә моның өчен хөкүмәт белән дә көрәшергә, аңар терәк булып торган сыйныфлар белән дә көрәшергә тиеш идек ки, моның өчен иң мөнасиб байрак сыйнфый көрәш байрагы иде, менә шул байракны күтәреп без хәрәкәт итә идек... Әмма хәзер, хәзер исә җимерелергә тиеш нәрсә җимерелде, аның урынына хәзер бер хәрабәнең чүпләре генә калды. Безнең милләтемезнең хәзерге вазифасы, инде шул хәрабәнең урынын чүпләрдән арчып, аның урынына милли мәдәният иҗат итү, милли рәфаһиятемезне (иркен тормышыбызны) торгызудыр. Иҗади эш, мәдәни эш һичбер вакытта бер сыйныфның көче белән генә эшләнә алмый, аны бөтен сыйныфлар эшләргә тиеш, анар бөтен сыйныфларнын көчләрен бергә кушып тотынганда гына бик таманга гына киләчәк. Менә шунар күрә дә без бу көндә милләтемезнең бөтен сыйныфларын: зыялыларын, демократиясен, руханиларын, байларын, укытучыларын, хатын-кызларын—һәммәсен-һәммәсен шул иҗади эш юлында берләшергә чакырамыз, берләшкән көч белән шул иҗади эшкә керешергә дәгъвәт итәмез"...

Татарларны берләшеп, үз дөньяларын яңартырга чакыру белән бергә, Исхакый зыялыларыбызны тугандаш халыкларга, бигрәк тә Төркестанга мәдәни ярдәм күрсәтергә дә өнди. Әдипнең бу чыгышы залдагыларга ничек тәэсир иткәнен Ф. Әмирхан тыңлаучылардан берсенең сүзләре белән болай тасвирлый:

"Тургеневның Пушкин һәйкәлен ачкан вакытта сөйләгән нотыгы вакытында рус зыялылары тарафыннан ничек каршы алынган булса, бу нотыкны да без шулай каршы алырга тиешләрмез".

1917 елның 1-11 маенда Мәскәүдә әлеге съездны, шул ук елның 22 ноябреннән 1918 елның 11 гыйнварына кадәр Уфада Милләт мәҗлесе үткәрүдә актив катнашканнан соң большевикларның бөтен татар милли оешмаларын туздырулары нәтиҗәсендә Г. Исхакый мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр була... Һәм анда әдип иҗатының татар әдәбияты өчен үзгә әһәмияткә ия булган яңа этабы башлана. Эш шунда: 1917 елдан соң илдә урнаштырылган совет системасы һәм аның идеологиясе «Октябрь революциясе һәм социализм патша заманында хәл ителмәгән милли мәсьәләне, ниһаять, тулысынча хәл итте, ягъни элекке изелгән һәм хокуксыз халыклар ирекә чыктылар, тулы хокуклыга әверелделәр» дигән фикерне алга сөрделәр. Нәтиҗәдә, милли мәсьәлә нигездә җәмгыятьнең көн тәртибеннән алып ташланды. Дөрестән дә, совет чорында рус булмаган халыкларны иҗтимагый-мәдәни яктан үстерү буенча байтак эш башкарылды. Әмма бу эшләр совет идеологиясенә буйсындырылган иделәр. Халыклар советча глобальләштерү сәясәте кысаларында яшәделәр. Бу сәясәтнең максаты исә халыкларны төрле яктан ассимиляцияләп, алар урынына бербөтен совет халкын булдырудан гыйбарәт иде. Сиксәненче елларда, ягъни нык үскән социализм чорында: бездә кешеләрнең яңа тарихи берлеге—совет халкы—формалашты дип рәсми рәвештә игълан ителде. Әлбәттә, мондый шартларда аерым милләтләрнең чынлыкта хәл ителмәгән мәсьәләләре, социализм заманы тудырган яңа борчулы проблемалары турында сүз алып бару мөмкин түгел иде. Чөнки әдәбият-сәнгать бары халыкларның совет чорындагы яңа бәхетле яшәеше һәм язмышы хакында гына сөйләргә тиеш булды.

СССРда менә шундый кампания алып барылганда мөһаҗирлектәге Исхакый татар совет әдәбиятында мөмкин булмаганны эшли, ягъни татарны милләт буларак саклап калуга караган мәсьәләләрне яки большевикларның аерым милләтләргә, бу очракта татарларга карата кылган гаделсез гамәлләрен яктыртуны дәвам итә. Мисал өчен, "Жан Баевич" комедиясендә ул татар сәүдәгәре Шакирҗанның заманча "образованный" булам дип аферистка булып чыккан "графиня" белән гаилә корырга маташуын, акыл җитмәс мәгънәсез бер гамәл дип, сатирик планда сурәтли.

Милләтне кайгыртуын дәвам итеп, Исхакый мөһаҗирлектә дә әлеге күпкырлы мәсьәләнең XX йөз башында киң җәмәгатьчелекне, шул исәптән әдипләрне дә, уйландырган, борчыган тагын бер ягына кабат әйләнеп кайта. Сүз тарихи миссиясе буенча татарның интеллектуаль җегәре һәм иҗтимагый-рухи юлбашчысы булырга тиешле морзалар катлавының аянычлы язмышы турында бара. Революциягә кадәр публицистикада да, матур әдәбиятта да шактый киң чагылыш тапкан бу мәсьәләне Исхакый үзенең "Көз" повестенда яктырта. Үткәндәге әсәрләрдә, мисал өчен Ф. Әмирханның "Бер хәрабәдә" хикәясендә (1912), Г. Ибраһимовның "Яшь йөрәкләр" романында (1912) яки С. Җәлалның "Дим буенда" повестенда (1914) морзалар, ничектер, үзеннән-үзе бетүгә дучар ителгән кавем дип каралса, Исхакый бу инкыйразның конкрет тарихи сәбәпләрен ача. Боларның барысын автор беренче чиратта морза кызы Гөлсем образында чагылдыра. Героиняның бәхетсез язмышын аның гаиләдә алган тәрбиясе белән бәйләп аңлата. Эш шунда: балачактан ук ул рус дөньясында яши һәм русча тәрбия ала. Үз милли дөньясыннан аерган әлеге яшәеш героиня өчен ерып чыкмаслык сазлыкка әверелә. Моның өстенә, шулай ук морзалар нәселеннән булган эшлексез һәм эчкече бер офицерга кияүгә чыгу героиняны бөтенләй бетереп ташлый һәм ул утыз яшендә "җимерелгән, кипкән карчыкка" әверелеп кала. Хәзер аны күбрәк балалары язмышы борчый. Алар алкоголик балаларыннан һәм тумыштан ук үз милләтеннән аерылганнар. Гомумән алганда, әсәрдә морза кызы Гөлсем үз катлавының милләтеннән аерылганы, аның алдындагы вазифасын үтәмәгәне өчен җәзалана кебек.

Әйтергә кирәк, бу әсәрдә сурәтләнгәннәр безнең кайбер замандашларыбыз өчен дә сабак алырлык. "Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?" дигән программ характердагы мәкаләсендә (1927) Г. Ибраһимов 1917 елдан соң бездә совет чоры морзалар катлавы барлыкка килүен һәм аны татар совет чиновниклары хасил итүен билгеләп үтә. Бу чиновникларга да еш кына руска мөкиббән китү һәм үз милләтеннән йөз чөерү хас иде. Гәрчә Ибраһимов алардан бөтенләй өметен өзмәсә дә, алар барыбер "татарның телен, әдәбиятын, тормышын өйрәнергә, татар халкы белән даими мәдәни бәйләнеш ясарга мәҗбүр булачаклар", дип уйласа да, совет системасы аның бу өметен, нигездә, юкка чыгарды. Яңа хакимият төрле милләтләрдән үзенә кирәкле кадрларны үз рухында әзерләде, ягъни аларны милли хистән азат итеп, интернационализм байрагы астында аларның үз милләтләреннән аерылуларын, руслык алдында баш июләрен куәтләде.

Әйтергә кирәк, бу күңелсез традиция хәзер дә дәвам итә. Ул бигрәк тә башка төбәкләрдә яшәүче татар чиновниклары арасында киң таралган. Республикабыздагы татар чиновниклары да үз милләте турында кайгыртырга бик ашкынып тормыйлар. Шуңлыктан Г. Исхакыйның "Көз" повесте бүген дә актуаль яңгырый.

Үзе яшәгән чорга караган милли мәсьәләләрне яктырту белән бергә, Исхакый мөһаҗирлектә дә милләт язмышы турында борчылып, тарихка мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, "Өйгә таба" повестенда рус-төрек сугышларының берсендә рус армиясе составындагы мөселман дивизиясе язмышы аша милли яктан мөһим булган берничә мәсьәләне яктырта. Бердән, 1919 елда Казанда югарыдан әмер буенча төзелгән беренче татар бригадасының Урта Азиядә совет властен урнаштыру өчен алып барган һәм хәзер әлеге мөстәкыйль илләрдә башкачарак бәяләнә торган көрәшен күздә тотып язылган бу әсәрдә үткәндә патша хакимиятенең рус булмаган

халыкларны, бигрәк тә мөселманнарны үзара ызгыштыру сәясәте фаш ителә. Әлеге мөселман дивизиясе дә руслар тарафыннан шундый максатта файдаланыла. Шул ук вакытта повестьта рус хәрби начальникларының рус булмаган халык вәкилләрен төрлечә җәберләүләре дә күрсәтелә. Әйтик, армия штабындагы бер генерал: "Монда мина өч елга гаскәри куәтне бирсәләр, мин күрсәтер идем... Грузиныннан, татарыннан, дагыстаныннан көлләр очырыр идем",—дип хыяллана. Боларның барысын үзе ишеткәч, мона кадәр аның бит исеме-аты бөтен хәрби мәктәпләрендә авыздан-авызга йөриячәк, ул бит каһарман булачак... Дәрәҗәдә үсәчәк, ул генераллык (пашалык) дәрәҗәсенә менәчәк", дип хыялланган дивизия командиры—татар полковнигы Тимергалиев—ничектер айнып китә. Моннан соң ул төрек канкардәшләренең башын кисәргә әзерләнгән рус балтасының сабы булудан баш тарта һәм патшага биргән хәрби антын бозып, үз дивизиясе белән төрекләр ягына чыга. Шул вакытта каты яраланган Тимергалиев үз халкы алдындагы вазифасын үтәгәнен аңлап үлә: "Шул милләтемне сакладым кәефеннән чыккан көлү, елмаю аның рухын күкләргә кадәр озатты—елмаеп җаны чыкты". Боларны сурәтләү белән бергә, Исхакый, икенче яктан, патша заманында да, совет чорында да кире кагылган пантюркизм, ягъни төрки халыкларның бердәмлеге идеясен яклап һәм хуплап чыга. Ул төрки милләтләр бердәм булганда гына аларның һәркайсы үз максатына ирешә алачагын яхшы аңлый. Белгәнебезчә, канкардәш төрки халыкларның бердәмлеге идеясе безнең көннәрдә тагын да актуальрәк төс ала. Панславянизм идеясе, ягъни славян халыкларын берләштерү омтылышы, көчәйгән вакытта бигрәк тә.

Иҗади гомеренең ахырындарак үзен борчыган сорауларга җавап эзләп, Исхакый тарихыбызның борынгырак дәверләренә дә мөрәҗәгать итә һәм 1944-47 елларда үз иҗаты өчен принципиаль әһәмияткә ия булган, безнең көннәрдә дә игътибарны җәлеп итә торган "Олуг Мөхәммәд" дигән тарихи пьесасын яза. Шунлыктан бу әсәр аерым игътибар сорый. Анда берничә максат алга куела. Барыннан да элек, әсәр ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 ел 9 август карарына җавап рәвешендә языла. Мәгълүм ки, әлеге карар татар әдип-галимнәрен Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларын, аларның хакимнәрен идеаллаштыруда гаепләп, асылда әлеге тарихи дәверләрне объектив яктыртуны тыйган иде. Исхакый мөһаҗирлектә тарихи фактларга, беренче чиратта рус тарихчысы М. Худяков хезмәтләренә нигезләнеп, әлеге әсәрендә Россиядә элек-электән гел тискәре бәяләнгән Казан ханлыгы, аның тарихка кергән күренекле хакимнәреннән берсе турында объектив сүз әйтергә алына. Икенче яктан, биредә дә төрки бердәмлек идеясе үткәрелә. Автор фикеренчә, элекке вакытларда төркиләрне берләштергән, бербөтен иткән Чыңгыз хан империясе һәм аның дәвамчысы булган Алтын Урда таркалганнан соң, Чыңгыз оныкларыннан һәм Алтын Урда ханнарыннан берсе булган, әмма дошманнары тарафыннан Сарайдан куылган Олуг Мөхәммәд әлеге бергәлекне кабаттан торгызу максатында гаиләсе һәм гаскәре белән Болгар-Казан иленә юнәлә. Ул бу юнәлешне очраклы гына сайламаган икән. Әлеге илнең үткәннән килә торган тарихи миссиясен әсәр геройларыннан берсе—Тимур командан болай аңлата: "Болгар иле безнең бабайлар бу илләргә килгәндә гаскәрлек ягыннан зәгыйфь булса да, бик күп эштә бабаларымызга остазлык итте, динемез мөселманлыкны без Болгар иленнән алдык, китабымыз, язуымызны болгарлардан өйрәндек, шәһәр төзү үрнәген алардан алдык, олуг ханнарымыз заманында да акчаларымыз Болгар шәһәрендә сугыла иде. Безнең кара корымнан, уйгыр иленнән, Себердән килгән аеры-аеры уймакларымызны (төркемнәребезне) берләштерүдә Болгар иле җилем булды. Тәңре боерса, Болгар иле шул таркау илләремезне берләштерүдә тагы да җилем булачак." Ачыграк әйтсәк, биредә Алтын Урда дәүләте төзелүдә һәм үсешендә Болгарның нинди роль уйнаганлыгы турында сүз бара. Төрки бергәлегенә ирешүнең төп чарасы итеп Г. Исхакый кабат көчле төрки дәүләте төзүне саный. Шунлыктан Олуг Мөхәммәднең Болгар-Казан иленә килеп чыгуын да ул шушы максат белән бәйләп карый. Мондый максатны нәкъ менә биредә тормышка ашырырга теләү исә бу

илнең икътисади һәм мәдәни үткәне белән бәйләп аңлатыла. Үткәннәр хакында Казан шәһәренең аксакалы, Олуг Мөхәммәдкә мөрәҗәгать итеп, болай ди: "Бабаларыңыз хан хәзрәтләре вакытында безнең Болгар, Биләр шәһәрләребез дөньяның иң зур бай шәһәрләре иделәр. Сатучы-алучыларымызның көймәләре бөтен Идел өстен болыт кебек каплый иде. Күрше илләрдә генә түгел, озак кяфер мәмләкәтләренә кадәр малымыз-туарымыз тарала, комачымыз, камкамыз (бөрчекле ефәк комач), көмеш эшләребез, агач савыт, табакларымыз, олтаныбыз, күнебез бөтен дөнья базарында дан тоталар иде. Ислам нуры берлә күңелләребез нурлангач, шәһәрләребез мәчетләр, мәдрәсәләр берлә бизәкләнгән гыйлем, белем, һөнәр үзәге булган иде." Болгар иленең үткәндәге бай тәҗрибәсен күздә тотып, әсәрдә Олуг Мөхәммәд төркиләрнең Чыңгыз һәм Батый заманнарындагы куәтен кабат торгызу эшен нәкъ менә шушы илдә башкарырга омтыла. Үзенең максатын ул болай бәян итә: "Уемыз, тынычсызлык көннәрендә аерылган, таралган илләребезне бергә җыеп, бабаларымыз вакытындагы кебек көчле бер дәүләт кору, халкыбызны тәңренең биргән нигъмәтләреннән файдаландырып, балаларыбызга көчле, куәтле бер дәүләт мирас итеп калдырудыр. Мул ага торган илебезнең Идел, Ак Идел, Чулман су юлларыны алыш-биреш көймәләре өчен һәрвакыт ачык тотып, юлларыбызның тынычлыгын саклау, күрше халыклар берлә дә алыш-бирешне күңел тынычлыгында йөртүдер. Сарай киң илебезнең тынычлыгын саклауны, юлларыбызның каравылчылыгын үти алмас хәлгә килде. Илебезнең һәр почмагына урыс агыла башлады. Хәзер без төп тупрагыбызны саклар өчен Чыңгыз байрагыны Казанда күтәреп, монда дошманнарга каршы кала корабыз, Казан каласы безнең кулыбызда чакта һичбер урыс-дошман суын үтә алмаячак. Безнең аркабыздагы илләребез—Себер, Урал, Чыгтай йорты (үзбәк иле) анасының кочагындагы бала кебек рәхәт итәчәк. Бу кала—Казан каласы бабаларыбызның бөтен илләрен, безнең мөселман халкыбызны, ислам динебезне, безнең гыйлемебезне, һөнәребезне, сату-алуыбызны саклаучы, нәүбәтче булып торачак, бу кала изге кала булачактыр."

Әсәр геройлары төркиләрне берләштерерлек һәм дошманнарга каршы торырлык шундый көчле дәүләтне ничек һәм нинди нигездә төзү турында да уйланалар. Алар аеруча дәүләтнең ныклы, гадел һәм халыкчан нигезгә корылырга тиешлегенә басым ясыйлар. Казан каласы хакиме Галим бәк, мәсәлән, болай ди: "Әйе, без яңа дәүләт корабыз, зур тарихи бер эш. Әгәр шуның нигезен нык, таза сала белсәк, бу дәүләтебез озын еллар яшәячәк. Урыны зур сату юлы өстендә, халкы тырыш, аек. Хөкүмәтне дә тугрылык, гаделлек өстендә җирләштерә алсак, бу дәүләтне урыслар бөтен дөнья шайтаннарын җыеп килсәләр дә, берни эшли алмаячаклар."

Казан ханлыгын ничек төзү һәм ныгыту мәсьәләләрен ачыклаганнан соң, пьесада алга таба бу дәүләтнең тиз арада аякка басып һәм ныгып китүе, һәм бу процесста Олуг Мөхәммәднең зур роль уйнавы күрсәтелә. Шул ук вакытта татар илендә мондый үсеш-яңарышның җитди каршылыкларга да очравына игътибар ителә. Аерата руслар бу илгә тыныч кына яшәргә мөмкинлек бирмиләр, ана даими һөҗүм итеп торалар. Әсәрдә рус кенәзе Василийның Казан ханлыгына каршы оештырган басып алу походларының берсе үзәккә куеп сурәтләнә. Дөресрәге, әлеге походның руслар өчен күңелсез финалы күрсәтелә. Ул сугышта үз илләренең иминлеге өчен көрәшкән казанлылар басып алучы русларның күпсанлы гаскәрен җиңәләр, кенәз Василийны, аның боярларын һәм исән калган сугышчыларын әсирлеккә алалар. Сугыш кырында полководец осталыгы күрсәткән Олуг Мөхәммәднең җиңүдән соң тагын бер күркәм сыйфаты ачыклана. Ул киң мәрхәмәтлек күрсәтеп, үткәндәге ант-вәгъдәләрен онытып татар илен басып алу нияте белән килгән кенәз Василийга, аның боярларына һәм сугышчыларына ирек бирә. Әмма Василийны бүтән "Казан иленә баскын итмәскә, яу җибәрмәскә..., Казан иленең дусты берлә дус, дошманы берлә дошман булырга, Казан иле сатучысы-алучысының урыс иленең һәр почмагында тамгасыз сату-алу итүенә киртә куймаска, ике ил арасындагы күршелекне дуслык нигезендә алып барырга

тәнре исеме белән ант" иттерә. Әмма тарих күрсәткәнчә, монысы да рус хакимнәренең чираттагы буш вәгъдәсе генә була. Алар алга таба да үзләренең басып алу сәясәтен дәвам итәләр һәм, ниһаять, 1552 елда күптәнге максатларына ирешәләр. Г. Исхакый исә әсәрен ерак бабаларыбызның сүзләрендә тора белмәгән күршеләренең коры вәгъдәләренә артык ышанучан булуларын ачу белән тәгәлли. Пьесаның мондый финалы белән автор, ил, халык язмышы мәсьәләләрендә беркатлы булмаска, аеграк, саграк эш итәргә кирәклегенә дә ишарә ясый. Ерак тарихыбызның әлеге тәҗрибәсе һәм сабаклары бүгенге көндә үз дәүләте булмаган һәм бик таркалып яшәгән халкыбызны хәзерге глобальләштерү шартларында үзен милләт буларак саклап калу өчен барыннан да элек бердәмлеккә ирешү кирәклеген искәртә. Димәк, Исхакыйның "Олуг Мөхәммәд"е дә безнең көннәрдә дә заманча янгырый дигән сүз.

Гомумән алганда, мөһаҗир Г. Исхакый 1917 елдан соң татар әдәбияты өчен яңа бер тарихи әһәмиятле миссия башкарды. Әдәбиятыбызның үткәндәге милли асылына һәм максатчанлыгына тугрылыклы булып калып, ул совет илендә мөмкин булмаганны эшләде, ягъни милләт яшәеше һәм язмышының мөһим мәсьәләләрен яктыртуын дәвам итте, моның белән Октябрь инкыйлабыннан соңгы әдәбиятыбызны милли-мәгънәви яктан тулыландырды, баетты. Болар барсы Г. Исхакыйның XX йөз татар әдәбияты тарихындагы феноменаль урынын билгели.

Яңа заман әдәбиятыбызның гына түгел, бөтен татар җәмгыятенең милли идеологы һәм лидеры булып милләт сагында торган, ягъни җәмгыятьнең дә, үзенең дә төп бурычын милләтне саклауда һәм үстерүдә күргән Исхакый үзенең туган халкына васыятен дә шундый рух белән сугара. 1954 елның 12 апрелендә Финляндиянең Тампере шәһәрендә яшәгән татар кызы Халидәгә язган һәм тарихка әдипнең милли васыяте булып кергән хатта Исхакый үзенең бөтен аңлы гомерен күз алдыннан үткәрә һәм аның бер максатка—милләткә хезмәт итүгә, аның азатлыгы өчен көрәшкә багышланганын икъралый. Шушы максат белән бәйле рәвештә, хатта татар халкының бик борынгы легендар заманнарга китә торган озын һәм катлаулы тарихы күздән кичерелә. Бу тарихны күзәткәндә, Исхакый туган халкының төрки дөньяда мәдәни юлбашчылык итүенә басым ясый. Мондый миссияне әдип төрле вакытларда төрле исем белән йөртелгән безнең халыкның асылда борынгы төрки халык булуы белән бәйләп аңлата. Шуның белән бергә, хатта татарның катлаулы язмышлы халык булуына игътибар итела һәм мондый язмышка дучар булуның мөһим сәбәпләреннән берсе итеп аның бик таркау хәлдә, дөньяда сибелеп яшәве карала. Бирдә тулаем төрки дөньяның таркаулыгы да мәгълүм роль уйнаганлыгы күрсәтелә. Шушы ачы хакыйкатьне аңлап һәм милләтне саклау, яшәтү ниятендә XX гасыр башыннан татарны берләштерү идеясе көчәеп китә, бу хәрәкәттә Исхакый үзе әйдәп йөрүчеләрдән була. Шул ук вакытта әдип әлеге хәрәкәтнең агымдагы гасырда, бигрәк тә совет дәверендә, яңа зур каршылыкларга очравын, җитди югалтулар кичерүен күрсәтә. Әмма үзенең күнелендә көчәйгәннән-көчәя генә барган әлеге хыялны—төрки бердәмлеге нигезендә татарны берләштерү идеясен—гамәлгә ашыруны Исхакый татар кызы Халидә туташка язган хатында хәзерге һәм киләчәк буыннарга мәгънәви васыяте итеп калдыруын белдерә.



Локман
Закир

## Казан шәһәренең исемен ни өчен үзгәртмәгәннәр?

Бу сорауга ачыктан-ачык ни руслар, ни татарлар, хәтта фактларда казынучы тарихчылар да ни өчендер җавап эзләмәгәннәр. Патшалар һәм генераль секретарьләр рус шәһәрләренең исемен даими диярлек алыштырып торган манзара фонында бу бит ифрат тирән һәм кызыклы сорау.

Андый шәһәрләр Идел-су буйларында гына да пачкасы белән: Сталинград, Куйбышев, Ульяновск, Горький, Калинин һ.б. Ә менә үтә «начар» саналган, борынгы рус мәкалендә «Чакырылмаган кунак татардан да яманрак» дип чагылыш тапкан Казан башкаласы ничектер исән, үзгәрешсез калган. Шәһәрнең әллә ничә йөз еллык тарихы сәбәп була алмый: Брежнев бит әнә Казанның 800 еллык тарихын, тантаналар өчен гәрчә орден-значоклар әзер булса да, мизгел эчендә юкка чыгарды.

Башкалары арасында Саратов шәһәренең исән калуы да гаҗәпләндерә. Бу исемнең рус фамилиясенә охшаш рәвештә ифрат матур яңгыравы да билгеле бер роль уйнагандыр, күрәсең. Алтын Урда заманында «Сары тау» дигән авыл булган, Саратов шәһәре әнә шул урында утыра. Руслар яулап алганнан соң бу исем шомара-шомара Саратов (Сарытав)ка әверелгән.

Шулай да Казанның исеме ничек, нигә сакланып кала алды икән? Юкса бит шәһәрне яулап алганнан соң Иван Грозный (ИГ) аны бик тиз үзгәртә алган булыр иде түгелме (әйтик, Иваново)? Моңа берәү дә каршы килә алмас иде, шәһәрнең борынгы исеме әллә кайчан онытылыр иде. Биредә бер дилемма килеп баса: онытыргамы, әллә истә тотаргамы? Бактың исә, Казанны оныту-оныттыруга караганда истә тоту хәерлерәк икән. Бу хәлне бик тиз чамалаганнар булса кирәк: коры җирнең алтыдан бер өлешен биләп торачак империя нәкъ менә Казанны яулап алудан башлана. Рус баскыннарының тере-данлы музее буларак, аны бер генә патша да үзгәртү турында уйламаган. Генераль секретарьлар да мондый юлга басмаган. Гәрчә коммунистлар патша Россиясен «халыклар төрмәсе» дип атасалар да, империянең колониаль сәясәте дөнья революциясе идеясе белән тач тәңгәл туры килеп тора!

Күпмедер вакытлар узганнан соң совет Россиясе үзе архипелаг ГУЛАГка әверелде, иске һәм яңа Россия асылда һаман да халыклар төрмәсе булып кала бирде.

Казан әнә шулай рус патриотизмы «тәрбияләүдә» тарихи бер чыганак булып кала бирә. «Иван Грозный» дигән трилогия Сталинның өстәл китабы булган, шул исемдәге кинофильмны карап та тиран полководец рухи ләззәт алган. Асылда бу фильм аның режиссурасы нигезендә төзелә, ул ИГ чалымнарында үзен күргән, әлбәттә. Әгәр Казанның исеме үзгәртелсә, ай-һай, шундый киношедевр куеп булыр иде микән? Киноның бит бөтен пафосы Казанны җимерүгә, яулап алуга корылган. Актер Михаил Жаровның: «Казан—зур, Мәскәү—

бәләкәй!»—дип әйтүе ничек килеп кергәндер, гаҗәп хәл. Бәләкәй Мәскәүнең ничек итеп зур Казанның яулап алуын ассызыкларга теләүләре булгандыр. Чыннан да, Казан ул чакта Мәскәүдән бер дә ким булмаган. Совет тамашачыларына Жаровның зур йодрыгы, махмырлы йөзе арык-мескен, рус телен белмәгән татар каршында күрекле күренгәндер шул.

Совет власте елларында, гәрчә Казан ябык шәһәр булса да, миллионлаган совет һәм чит ил туристлары Казан Кремлен (КК) тамаша кылалар иде. Алар махсус укыган-өйрәтелгән, яхшы хезмәт хакы алучы экскурсоводлар җитәкчелегендә төркем-төркем узалар. КПСС өлкә комитетының идеология бүлеге әзерләп биргән текстны әлеге экскурсоводлар чатнатып яттан сөйләр иде. ККда эшләгәндә миңа рус-патриотик легендаларын ишетергә, Казанның идеологик тәрбия өлкәсендә зур чыганак икәнлеген якыннан тоярга туры килде.

Ләкин, үзгәртеп кору җилләре исә башлагач, экскурсоводларның бу патриотик ялганнары үтми башлады. КК үзенең элеккеге бөекдержавачыл әһәмиятен югалтты. ИГ тарафыннан җимертелгән Кол Шәриф мәчете дә аякка басты. Биредәге хәрби гарнизон һәм солдат казармалары бетерелде. Иң мөһиме—инде ничә еллар Сөембикә башнясының очында ярымай балкып тора. Мәскәү Татарстанның Конституциясен сүтеп җыя алды. Ләкин ККның патриотик кимәлдәге элекке данын, нафталинлы сәхифәләрен кире кайтару мөмкин түгелдер—моның өчен бик күп вакыт, чыгымнар кирәк, зур җәнҗаллар да чыгарга мөмкин.

Вакытны югалтмас өчен бөекдержавачыл әһелләр башкалабыздан 50 чакрым ераклыкта Казанны алуга бәйле икенче бер патриотик почмак таптылар. Элекке татар авылында (хәзерге Свияжск шәһәре) моннан 450 ел ИГ төзеткән форпостны торгызу-яңарту эшләре бара. ИГ сугышчылары аны бик озак төзегән, чөнки 150 меңлек гаскәрне, 200 дары бочкалары һәм бүтән кирәк-яракларны су агымы белән Идел өсләтеп ташыр өчен айлар кирәк булган...

Бик урынлы сорау туа: ИГ татар авылында форпост төзегән чакта Казан ханы нәрсә караган? Димәк, ул дөрес якка карамаган һәм... баш белән уйламаган.

## Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә?

2001 елның 20 июнендә «Эфир» телекомпаниясе Казан халкына әнә шундый сорау белән мөрәҗәгать иткән иде. Һәм әлеге сораштыруны оештырган кешеләр мактауга лаек, чөнки совет заманасында бу нәрсә өчен шунда ук «психушка»га эләгүең мөмкин иде. Ул вакытларда бар халык өчен яшәүнең мәгънәсе бөтен дөньяда коммунизм төзүдән гыйбарәт булган. Шуңа да карамастан, бу сорау озак гасырлар буена кешеләргә тынгы бирмәгән, әмма аңа беркем дә җавап таба алмый, хәлбуки, кешенең килеп чыгышы, аның галәмдәге билгеләнеше хакында рәтләп белүчеләр юк. Табигатьтә бернәрсә дә юкка гына бар кылынмаганлыктан, җирдәге тереклек тә кемгәдер, әйтик, Ходай Тәгаләбезгә кирәктер, һәм Ул аны галәм питомнигы итеп файдаланадыр, дип исәпләргә мөмкин. Тере затларның берөзлексез туып һәм үлеп торулары нәтиҗәсендә, Ул кыйммәтле үлемсезлек эликсиры аладыр, мөгаен. Ул бит Үзе мәңгелек. Иң акыллы җан иясе булып кеше санала, шуңа күрә дә алга таба сүзебезне аның хакында гына алып барырбыз.

Дөньяга килү һәм үлү процессы беркайчан да тукталмасын өчен, Тәңребез бик зирәк эш иткән: кеше аннан да татлырак нәрсә булмаган оргазм вакытында ярала, ә үлгәндә газапланып үлә. Кеше 40-50 яшенә кадәр үз үлеме турында да, балаларының үләчәге турында да уйламый, гәрчә дөнья белән хушлашуның котылгысызлыгы хакында яхшы белсә дә. Безгә билгеле булганча, Аллаһы Тәгалә—тоталитар зат, ул бала төшерүләрне һәм үз-үзеңә кул салуларны тыйган. Аңлашылсын өчен шундый мисал китерик: Җирдәге барлык кешеләр дә кинәт, яшәүләренең мәгънәсезлеген аңлап, үз-үзләрен үтерсәләр—Ул да юкка чыгар иде. Мондый хәл килеп чыкмасын өчен, кеше үз үлеме хакында әллә ни уйланмый. Ул ләззәтләнүнең мәгънәсезлеген гомеренең иң ахырында гына, мәсәлән, рак белән чирләүчеләр шифаханәсенә эләккәч кенә аңлый.

Әмма хәзерге заман кешесенең фикерләве борынгы гомосапиенсныкыннан аерылып тора, һәм ул Аллаһның тоталитар кануннарына әһәмият бирми, бу

дөньядан башка берәү ихтыяры буенча түгел, ә үзе теләгән вакытта китәргә омтыла башлый. Бу хакта хәтта Лев Толстой да үзенең «Исповедь» китабында: «Үз-үземә кул салу турындагы уй башыма, элегрәк тормышны яхшырту хакындагы уйлар кебек үк, бик табигый килде»,—дип язып калдырган.

Әле күптән түгел ТВ буенча битлек кигән кеше, үз-үзен үтерергә теләп киллер яллавы, тегесенең, акчаны алып, качуы турында сөйләгән иде. Хәзер инде бу кеше яңа киллер эзли, үзен генә түгел, теге каракны да атып үтерсен өчен, ул аңа икеләтә күбрәк акча тәкъдим итә икән. Күргәнегезчә, үлү теләге кешедә дәвалап булмаслык чире булганда гына түгел, ә алга таба яшәешенең кирәксезлеген аңлаганда да туа. Ул классик вариантта ир-ат үтәргә тиешлесенең барысын да эшләгән—өй салган, агач утырткан, балалар үстергән... Бездә якты дөнья белән җиңел генә хушлашу мөмкин түгел, рәсәйлеләр ату коралы йөртми, шуңа күрә бау, дару төймәләрен күпләп йоту яисә балконнан сикерү кебек ысуллар гына кала. 70 яшьтән узганнар арасында үләргә теләүчеләр шактый, ләкин гомерен ничек һәм нәрсә ярдәмендә өзүне сайлау бик катлаулы нәрсә. Күпләр, мәет өчен тереләр хакында уйлануның әһәмияте юк, диләр. Әмма бу алай түгел, һәркемнең матур, һәм лаеклы итеп үләсе килә, әйтик, Маяковский кебек—юынып, чиста киемнәр киеп, түшәккә ятарга һәм тәтегә басарга. Ә менә үз-үзен үтерү өчен нужаланып киллер эзләүче бәндә Маяковский кебек эшли алмый, йә аның тәтегә басарга кыюлыгы җитми, йә якты дөнья белән җәмгыятьчелек һәм дин әһелләре тискәре караштa торган суицид ярдәмендә хушлашасы килми. Элегрәк андыйларны зиратларга да кертмәгәннәр, каядыр читтә җирләгәннәр.

Әгәр дә, кеше яралганда, беркемнең дә аннан туасы килү-килмәве турында сорап тормаганлыгын исәпкә алсак, кешене үз ихтыяры буенча дөньядан китүдән тыю аның хокукларын тупас бозу булып тора. Шуңа күрә дә дөньяда эвтаназияне законлаштыру мәсьәләсен гамәлгә кертү зур авырлык белән бара. Мисал өчен, Ливиядә, Гыйракта мондый сүз өчен асып куюлары да ихтимал. СССРда моның өчен «психушка»га озатканнар, ә постсовет чоры Россиясендә эвтаназия турындагы мәкаләне бер генә газета да бастырмый.

Кеше рәхәт мизгелдә туа, ә җәфа чигеп үлә. Чынлап та, әгәр үлем оргазм ләззәте дәрәҗәсенә кадәр җиткерелсә, бер атна эчендә Җирдә бер генә тере кеше дә калмас иде. Кешене табигатьнең әлеге тозагыннан бары эвтаназия генә коткара ала, әмма әлегә эвтаназия законлы рәвештә Голландиядә генә гамәлдә.

2001 елның 10 июнендә Тимоти Маквейга карата кулланылган үлем җәзасын эвтаназиянең иң яхшы формасы дип атарга була. Башта аны бернинди ирексезләүсез йоклатканнар, ә аннан соң инъекция ясаганнар, һәм ул, хәтта сискәнмичә дә, үлеп киткән. Аңа бар теләгәнен әйтергә мөмкинлек бирелгән, һәм, аның исемен мәңгеләштерү максатында, бөтен бу процедура видеотасмага төшереп алынган. Әгәр дә Россиядә мондый «татлы» үлем мөмкинлеге барлыкка килсә, күп рәсәйлеләр, шул исәптән мин дә, кайчандыр бөтен ил белән «Жигули»га язылган кебек, чиратка язылыр идек. Гәрчә, чиратта 10 ел көтеп тә мин машиналы була алмадым.

## Мәхәббәт, коммунизм һәм тәмәке

Беренче карашка бер-берсеннән шактый ерак торган әлеге төшенчәләрнең уртак яклары бар: мәктәптә аңыбызга сеңдерелгән чын мәхәббәт һәм якты коммунизм кешелекнең тормышка ашмастай хыяллары булып торалар. Хәзерге вакытта гомумтигезлек иллюзиясенә, ягъни «уравниловка»га нигезләнгән коммунизмның утопия икәнлеге исбат ителде инде. Ә бит чынлап та, намуслы кеше белән карак-угры, эш сөючән белән ялкау, акыллы белән ахмак, чибәр белән ямьсез кеше һ.б.лар үзара тиңдәш була алмый. Без аларны ничек кенә тигезләргә тырышсак та, алар һәрвакыт төрле булып калачак. Ә менә мәхәббәтнең буш хыял икәнен яшьләргә дәлилләп күрсәтү шактый кыен, чөнки кеше бу хактагы дөреслекне картайгач кына, яки озакка сузылган авырганы вакытында үз гомерен башыннан алып ахырына кадәр анализлап чыкканнан соң гына белә. Берсеннән-берсе акыллырак булып күренергә теләгән совет фәлсәфәчеләре һәм язучылары «мәхәббәт» төшенчәсенә билгеләмә бирергә атлыгып торганда, Көнбатышта һәм АКШта «Нәрсә ул мәхәббәт?» дигән сорауга «мәхәббәт

белән шөгыльләник» дигән уникаль гыйбарә белән җавап бирәләр. Совет чоры шагыйрьләре һәм җыр авторларының берничә буыны мәхәббәт темасы ярдәмендә ашарларына акча эшләп кенә калмыйча, үзләренең төп туйдыручыларын— төзүчеләрне, игенчеләрне, корыч коючыларны һәм тагын бик күпләрне онытып, әлеге иллюзия белән үз исемнәрен дә мәңгеләштерде. Шулай итеп, мәхәббәт безнең язылмаган кануннарыбыз рәтенә керде. Кискен хәлләр килеп туганда, кемгә дә булса кирәге чыкканда, һәрвакыт «Ә бәлкем бу мәхәббәттер» дигән сорау кабыргасы белән куелды, бездә хәтта шулай дип исемләнгән нәфис кинофильм да бар иде. Ул гына да түгел, халык судьялары, мәхәббәтне законнан өстен куеп, көчләүчене суд залыннан ук ирекка чыгарган очраклар да булды. Ә Көнбатышта хәтта присяжныйлар судының да моңа хокукы юк.

Бүгенге суверен Россиядә «мәхәббәт белән шөгыльләник» сүзтезмәсен кулланучылар юк, кешеләр бу—тылсымлы сүзне мыскыл итә дип саныйлар. Мәхәббәт иллюзиясе хәтта коммунизм иллюзиясеннән дә көчлерәк булып чыкты, чөнки без, совет халкы, алдап йә алданып яшәргә күнеккәнбез. Еш кына югары сыйныфларда укучы кызлар, ә кайчак яшьрәкләре дә, малайларның уйнап әйткән «яратам» дигән сүзләренә ышанып, вакыты җитмәс борын сафлыгын югалталар һәм соңыннан, үзләренең йөккә узуларын акларга тырышып, «хыянәтче»гә ләгънәт укыйлар.

Хәтта тәмәке төпчекләрен җыеп йөрүче бомж да, организмының никотинга ихтыяҗын канәгатьләндерү белән, тартылып бетмәгән хуш исле сигаретын читкә төкерә. Ә бит тәмәкесен кабызып җибәргәндә, ул, төтенне комсызланып суырып, шул сигаретны кабып йотарга әзер иде. Мәхәббәт белән шөгыльләнү, хуш исле тәмәке төтенен берничә мәртәбә суырып, төпчеген исә тартуны бөтенләйгә ташлагандай нәфрәт белән атып бәргән тәмәкеченең үз-үзен тотышына бик охшаш. Организмны чамасыз тәмәке тартудан һәм мәхәббәттән саклаучы ләззәтне чикләү механизмы бик нигезле эшли, һәм берникадәр вакыттан соң кешедә кабат «кайф тоту» теләге туа.

Асылда, мәхәббәт һәм тарту үтә картлыкка кадәр дәвам итә, ләкин яшькә пропорциональ рәвештә алар әкренләп практикадан теориягә күчә бара. Кайвакыт кызык өчен генә тәмәке пыскытучы яки кулына кабызылмаган сигарет тоткан картларны күзәтергә мөмкин. Теоретик мәхәббәт турында сөйләп тору кирәкмәс, аның хакында һәркем, вакыты җиткәч, һичшиксез, белер. Гомумән, ул сүнгән сигарет исе белән ләззәтләнүгә тиң.

**Редакциядән:**
***Быелның февралендә Локман ага Закирга 80 яшь тулды. Аны олуг юбилее белән тәбрик итәбез, сәламәтлек, уңышлар телибез.***

---

## Авторларыбыз игътибарына

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, җиңел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**



Мәхмүт
Әхмәтҗанов

# ТОРМЫШ МИЗГЕЛЛӘРЕ

*Бөек драматург Уильям Шекспир: «Дөнья—театр, ә кешеләр—аның актерлары»,—дигән. (Бәлки, бер «моңсу сүзләрне» искә төшерү дә артык булмастыр—И. Гёте: «Һәр каберда олы бер дөнья ята»... дип әйткән...) Маркснын фикере исә башкачарак: «Кешеләр—җәмгыятьтә яшәүче хайваннар» («люди есть общественные животные») дип әйтергә яраткан ул. Ходай Тәгаләгә килсәк, аның «хөкеме» шик калдырмаслык: «Мин сезгә җан өрдем, мин кушканча яшәсәгез, бәхетле булырсыз»,— дигән ул...*

*Югарыдагы әйтелгәннәргә таянып, түбәндәгеләрне өстисем килә: башы да ахыры да булмаган Мәңгелек алдында кеше гомере—бер мизгел генә ул. Ничек тә шул мизгелләрне үкенмәслек итеп яшисе иде...*

*Әйдә, кадерле укучым, шуларның кайберләренә «күз салыйк» әле.*

*Балачакны әйтеп торасы да юк, яшүсмер һәм егет чакта үлем, авыру кебек «вактөяк» турында уйлап та карамыйсың... Янәсе, таң ата да кич була: кеше дигән җан иясенең табигате әнә шулай оптимизмга корылган.*

*Шушы кечкенә кереештән соң, шактый озынга сузылган гомеремнең кайбер мизгелләрен күздән кичермәкче булам...*

*Тумышым белән мин—Көньяк Урал итәгеннән. Моннан 300 еллар элек ата-бабаларым, чукынырга риза булмыйча, күп сулы елгалар, күлләр дөньясына—Урал төбәгенә килеп чыккан. Искиткеч матур яклар—мәңге яшеллеккә күмелгән карагай, карагач, нарат, чыршы урманнары—тайга шуннан башлана. Иксез-чиксез болыннар, кырлар офыкларга кереп югалалар. Димәк, монда җир урыска да, башкортка да, башкаларга да җитәрлек.*

## Истә калган беренче мизгелләр

Бу хәл колхоз төзелгәнгә кадәр булгандыр: дәү әни бурлы бияне тарантаска җикте дә, икәүләп юлга чыктык. Миңа яшь ярым тирәсе. Көн искиткеч матур, кояшлы иде. Бара-бара «калкулыкка кунаклаган» бер урамлы авылга килеп кердек. Халык күренми. Мөгаен, эштәләрдер (ул чакта мондый «үзенчәлекләрне» мин белмим әле...). Дәү әни: бу—башкортлар яши торган Чибәркүл авылы, ди. Тагын алга таба барабыз. «Монысы Шәрәк авылы, анда да башкортлар көн итә»,—ди. Шулай итеп, табигать матурлыгына сокланып, күп сулы Әй елгасы (ул Златоуст шәһәре тирәсеннән башлана икән) буена урнашкан чагыштырмача зур башкорт авылы (гадәттә, башкорт авыллары әллә ни зур булмый) килеп кердек. Әмма тукталып тормадык. Дәү әни елга аша чыгу өчен кичү эзләп китте

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ (1927)—*галим, язучы-публицист; «Килер бер көн», «Яманны юлдаш итмә» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

(бу хакта соңыннан «ак белән караны аера башлагач» кына белдем). Тапкан, ахрысы, суга кереп киттек. Бераздан су тарантас өстенә чыкты, дәү әни мине кулына алды. Яр буена чыгу белән өйләр күренде. Безне ничек каршы алганнар, ничек кире әйләнеп кайтканбыз—алары хәтердә калмаган... Бу башкорт авылы Мөхәммәткә ни өчен баруыбыз сәбәпләрен үсә төшкәч кенә белдем: дәү әни анда яши торган кодасын—тегүче Мөхәммәтҗанны (чыгышы белән Бөгелмәдән) күрергә дип барган икән. Коданың «кыскача тарихы» болай: кыш кергәч башкортларга тун теккән. Картны ошатканнар, ахрысы... Безгә күчеп кил, йорт салып бирербез, халык ярлы түгел, күрше авылларга да туннар тегәрсең»,—дигәннәр. Булачак кода, күрәсең, безнең авылга да килгәләп йөргән.

...Миңа иң күп дигәндә дә, ике яшь ярым (энем Шакирҗан миңа 3 яшь тулган көннәрдә туды...). Җәйнең бик матур көне. Әткәй-әнкәй һәм мин, юлга чыктык. Соңыннан әйттеләр—без дәү әнинең туган авылы Елангыга (20 чакрымлык юл) кунакка барганбыз икән. Бер урында әткәй атны туктатты да, калкулыкка менеп китте. Әйләнеп килгәндә, кулында ике кечкенә кошчык бар иде. Янәсе, ул мине шатландыру өчен әлеге җан ияләрен күрсәтергә булган. Мөгаен, ул моңа кадәр дә әлеге урында кошлар бала чыгаруын белгәндер. Әткәй әлеге кошчыкларны ояларына илтеп куяр алдыннан болай диде: «Кошларны яратырга кирәк. Алар безнең дусларыбыз, бик күп зыянлы бөҗәкләрне ашыйлар...»

## Әнкәй кыйссалары, әткәй васыяте

Халык телендә «ата-ананы сайлап алып булмый» дигән әйтем бар. Бу яктан мин үземне бәхетле дип сануйм. Моңа бәлки кайберәүләр ышанып та җитмәс, әмма чынбарлыгы шул: без гаиләдә 4 ир, бер кыз бала үстек. Әткәй-әнкәй безгә кул күтәрү түгел, авыр сүз дә әйтмәде. Татар менталитетын күз алдында тотсак, моның кирәге дә булмагандыр. Чөнки ислам дине болай аңлата: «Ходай Тәгалә ата-анага балалар бүләк итә. Аларны яратыгыз».

Инде әнкәмә килгәндә, (исеме Рәбига, гарәпчә «дүртенче кыз бала» дигәнгә туры килә), ул гаҗәеп дәрәҗәдә сабыр, аз сүзле татар хатын-кыз иде. Төскәбиткә чибәр. Кара күзле, кара чәчле, Авыл советы депутатын да пәйгамбәр илчесе дип кабул итә. Әнисе Гайнелхаят Мөгаллимә 40 яшьтә дөнья белән хушлаша. Бердәнбер кызы өчен борчыла. Әнкәйгә үги ана белән яшәү җиңел булмагандыр. Шуңа күрә бик иртә—16 яшендә кияүгә чыга. Гаиләдә тату яшәгәннәр: «Халык безне Таһир белән Зөһрә дип йөртә иде»,—дигәне истә калган...

Бала шәхесен формалаштыруда гаиләне алыштырырлык бер «инструмент» та юк. Шуны истә тотып, бөек чех галиме Ян Каменский (1592—1670) «Аналар мәктәбе» дигән методик яктан камил дәреслек язган. Миннән торса, ул китапны бүген дә һәр яңа гаилә коручыга бушлай тапшырыр идем... Моңа әһәмият бирүче бар микән: һәр белгечләр буенча махсус уку йортлары бар. Ә иң мөһим урында—гаилә тәрбияләүгә еш кына «бармак аша карыйлар». Бүген яшь гаиләләрнең өчтән икесе таркала икән, бу яшьләрнең «гаилә азбукасын» бөтенләй белмәгәннән...

Бу момент та бик мөһим: тәрбия ул «болай эшлә дә, тегеләй ит» дип туктаусыз тәкрарлау түгел; иң беренче чиратта—өлкәннәрнең үрнәге, аларның үзара сөйләшүләре, теге яки бу мәсьәләгә мөнәсәбәте. Аларның һәммәсе дә диярлек сабыйлар тарафыннан «йотыла бара». Шуңа күрә халык та «атасына карап—улын сөй, анасына карап кызын коч» дигән бит инде...

...Иртән йокы тәмле була. Мәктәпкә барасы да бар. Белеп ятабыз—әнкәй тәгам әзерли һәм матур, моңлы тавыш белән «Сак-Сок» бәетен көйли (ул әлбәттә, моны аңлап эшли...).

Икенче бер очракта, шулай ук иртән, әнкәй Сөләйман пәйгамбәргә багышланган кыйссаны сөйләде. Кыскача эчтәлеге: Сөләйман пәйгамбәр чит илләрдә патшалык итеп байый һәм шуннан соң әтисен күрергә дип туган иленә кайта. Язмышы шулай булган микән, әтисенә сәламне ат өстендә килеш кенә бирә. Аллаһ Тәгалә «болай сәламләүне» зур гөнаһ итеп саный. Җәза бирә: башка

пәйгамбәрләрдән аермалы буларак, Сөләйман тәне череп үлә. Бу очракта да әнкәй безгә «акыл сатмады». Ә без—балалар—мондый нәтиҗә ясадык: әти бала өчен бөек зат икән!

Йосыф пәйгамбәр кыйссасы да йөрәкләргә үтте: туганнары көнләшеп, үлсен дип, Йосыфны коега ыргыталар. Әмма фәрештәләр аны саклап кала. Соңыннанрак, зур дәрәҗәләргә ирешкәч, Йосыф абыйлары белән очраша. Искиткеч киң күңеллелек күрсәтә—һәммәсенә дә яхшылыклар эшли.

Әнкәй, әлбәттә, күп китаплы гаиләдә үскән. Әмма акылны китаплар саны белән генә белгеләп-үлчәп булмый ич.

Әнкәй һәрвакыт Аллаһны телгә ала, «теге дөньяда аңа нинди, ничек кенә җаваплар бирербез икән», дип бик борчыла иде. Гайбәтне яратмый, сер тота белә. Шуңа күрә хатыннар «эчләрен бушатырга» дип, еш кына безгә керәләр. «Рәбигакаем, синдә ирләр холкы, сөйләгәннәребез беркая да чыкмый». Мөгаен, шулай булгандыр...

...Сугыш башланганда әткәйгә 41 яшь иде. Армияга аны август урталарында алдылар. Уфадан ерак түгел урында татар дивизиясе төзелә икән, сугыш башлану белән андый татар дивизияләре татарлар компактлы булып яшәгән урыннарда—4-5 җирдә кызу темплар белән төзелгән. Болар—сүз уңаенда гына... Аларның часте берәр ай ать-дваны үтте микән, фронтка китә. Мисал: әткәй 1941 елның 8 октябрендә Калинин шәһәре янында каты яралана һәм госпитальгә озатыла... Ә 1942 елның җәендә, госпитальдән чыккан сержант Рәхимҗан Әхмәтҗановны, Ржев юнәлешендәге фронтка җибәрәләр. Монда ул икенче мәртәбә каты яралана. 8 айлап госпитальдә дәвалангач, инвалид буларак, туган иленә кайтырга рөхсәт ителә. Бервакыт ул болай дигән иде: Ржев тирәсендә бер генә татарны да күрмәдем, аларны Калинин тирәсендә кырып бетермәделәр микән дип уйлыйм...

«Татар дивизияләре» турында сүз чыккач, Татарстанның Санкт-Петербургтагы вәкиленең Төньяк Башкаланың 300 еллыгы уңае белән «Татарстан» журналында чыккан мәкаләсенә тукталасы килә. Ленинградны салуда татар ташчылары бик зур көч куйганнар. Ул чакта Кавказ, Урта Азия Россиягә кушылмаган булалар, шуңа күрә ташчылар бары тик татарлар гына була. Уннарча мең татар ташчылары беренче мәһабәт биналарны төзиләр. Үзләре ачлыктан, төрлечә авырудан үлеп бетәләр. Бу хакта үз вакытында күренекле артистыбыз Габдулла Шамуков «Совет әдәбияты» (бүгенге «Казан утлары») журналында «Ленинград татар сөякләре өстендә тора» дигән тирән эчтәлекле мәкалә белән чыгыш ясады (шунын аркасында 2 ел эшсез йөрде).

1941 елда, Ленинградның язмышы кыл өстендә чакта, шулай ук аны татарлар саклады—Әхмәтшин мәкаләсенең бер «акценты» әнә шунда... Госпитальдән кайтып бер-ике көн узды микән, әткәйне райкомга чакырып алдылар. «Салават» исемендәге колхозга рәис итеп куярга уйлыйбыз. Ризалык бир»,—дигәннәр. Әткәй сугышка кадәр дә райондагы иң абруйлы рәисләрдән санала иде: халык белән эшли белә. Кешеләргә хөрмәт, ышаныч белән карый. Тыныч характерлы. Чыннан да, башкортлар әткәйне җылы кабул итәләр. Кулга-кул тотынышып эшлиләр...

Соңгы мәртәбә әткәй белән 1982 елның август башларында күрештем. Махсус рәвештә авылга шул теләк белән кайттым. Кем алай дип уйлаган—бу соңгы күрешүебез-очрашуыбыз булган икән... Матур кеше иде ул. Яшел-зәңгәр күзләре тыныч кына карый. Гомумән, тыныч холыклы кеше. Һаманда газеталар укый, радио-телевидение тапшыруларын калдырмаска тырыша. Бәхәскә керүне яратмый. Үз фикерен кешегә көчләп тагуны кире кага...

Минемчә, әткәй, шактый өлкән яшьтә булуына карамастан (икенче группа сугыш инвалиды да...), оптимист иде. Дәү әнисе Сылуның 106 яшьтә «бер минут эчендә» җан бирүе турында сөйли... Үзе бу хакта искә төшерергә яратмаса да, классташлары аның Земская школаның иң яхшы укучысы (безнең авыл Уфа губернасы, Златоуст өязенең волость үзәге булган) булуы хакында әйтәләр иде... Бервакыт, ничектер сүздән сүз чыгып, мин Пушкинның «Иван Сусанин»-ын искә төшердем. Ә ул тыныч кына итеп: «Без аны «Боже, царя храни» дип

яттан өйрәндек»,—диде, һәм бөтенләй көтмәгәндә, поэманы һичбер акцентсыз сөйләп чыкты. Гаҗәпләндем, исем китте.

Ә классташы Шәрәфетдин абзый менә нәрсәләр сөйләде: чыгарылыш имтиханында уезд земствосы әгъзасы алпавыт Кропачинский (аның исеме Көньяк Урал тимер юлының Кропачево станциясендә саклана...) катнаша һәм «татарчонок Рахимзяннын» «Боже, царя храни» поэмасын «тын да алмый укуына» сокланып, хәтта елап җибәрә һәм малайга 1 сум көмеш тәнкә бүләк итә...

Фиркасыз булса да (шуның аркасында «37 еллар мәхшәрендә» исән-имин кала), шактый еллар колхоз рәисе, «коммун булган» кеше бит әткәй. Шуңа күрә соңгы күрешүебез вакытында әйткәннәре мине сагайтты. Татар гадәте буенча, ул сөйләгәннәр уңаеннан сораулар бирмәдем, каршы сүз дә әйтмәдем.

Әткәй сүзне шуннан башлады: «син Аллаһка каршы сүз әйтмә»,—диде. Мин болай дидем: «Аллаһка тел тидерергә теләгем дә, вакытым да юк». Бу җавап кына аны канәгатьләндермәде, бугай. Өстәп сорау куйды: «Аллаһның сиңа начарлык эшләгәне булдымы, ни өчен дип уйлыйсың?». Минем җавап болайрак булды: «Бик нык кыенлыкларга очраган, үлем бугаздан алган чакларым булды. Әмма «беттем бугай» дип уйлаганда ниндидер көчләр «гомеремне саклап калдылар»,—дидем дә, шактый гына мисаллар китердем. Ә әткәй әйткәннәремне хуплады кебек.

«Бу кеше шулай эшләмәсә, исән калыр иде, диләр. Әмма белеп әйтмиләр. Язмыш, күрәчәк дигән нәрсә бар дөньяда. Мин моны фронтның алгы сызыгында күрдем-белдем. Дивизиябез атакага күтәрелде. Ике кешегә бер мылтык. Күктән бомбалар ява. Безнең самолетлар юк. Снарядлар шартлый, немец автоматлары безне турый гына. Мәхшәрнең дә мәхшәре. Югалтулар шулкадәр зур булган диләр, дивизиянең калдыкларын тылга—пополнениегә күчерделәр. Авылдан бер көнне 47 кеше киткән идек. Икебез—мин һәм Вәли генә исәнимин калдык. Яраландык, әлбәттә. Команданы тыңлап «алга!» дип йөгерәсең, күршең, чордашың үлә, ә син исән каласың»,—диде әткәй. Өстән: «Беркемнең дә кара җир куенына тиктомалдан кереп ятасы килми, әмма мин үлемнән курыкмыйм. Мәңге яшәүчеләр булмый»,—диде ул моңсу гына тавыш белән.

«Кешеләрне хөрмәт итәргә, беркемне дә «син болай да син тегеләй» дип үртәмәскә кирәк. Син кешеләрне хөрмәт итәсең икән, алар да үзеңә хөрмәт күрсәтерләр. Тыныч йоклыйсың килсә, нәфесеңне тый, дәүләт милкенә, кеше әйберенә кулыңны сузма. Миңа бик авыр, куркынычлы елларда колхозлар белән җитәкчелек итәргә туры килде. Мине утыртып куярга тырышкан көнчеләр булды, әмма үзем бер генә кешене дә суд алдына бастырмадым. Һәм үткәннәрне искә төшерәм дә, юлым дөрес булган дип шатланам, күңелем тыныч»,—диде ул шактый уйга калып...

## Без сиксән идек...

Колхозлар оешканчы авыл халкы начар яшәмәгән. Теләгән кадәр мал тоткан, бакча утырткан. Күпләрнең умартасы да булган. Нигә булмасын ди. Җир күп, тирә-якны урман каплаган. Әнә шул шартларда балалар үстерү дә мәшәкать сорамаган. Кыскасы, бер ел эчендә 80 бала дөньяга аваз салган! Ул чакта укырга 8 яшьтән алалар иде... Әмма райфо дигән оешма мәктәбебездә ике беренче класс ачарга рөхсәт итмәгән. Сәбәбе болай икән: районда 45 башкорт, 7 татар, 3 урыс авылы бар. Башкорт авыллары, гадәттә, кечкенә була. Димәк, балалар да аз дигән сүз. Ә классны барыбер ачарга кирәк. Башкортстан булгач, бигрәк тә башкорт классларын. Һәммәсенә дә акча җитми, янәсе.

Шулай итеп, ул елны безнең мәктәптә бер генә беренче класс ачылды. Безне, 50 кыз һәм малайларны сафка тезеп, бер апа мәктәп бинасына алып кереп китте. Бераз алга китеп булса да шуны әйтәсем килә: Әкълимә апа безне—бер кыз белән бер малайны, парта артына утыртып чыкты. Исем-фамилиябезне барлады. Апабыз, бик матур булу өстенә, бик ягымлы. Хәрефләр язарга өйрәнгәндә, авыр үзләштерүчеләрнең дәфтәрләренә теге яки бу хәрефне язып та күрсәтә иде... Ул заман өчен (балалар бакчасы булмаган вакытта) бик сирәк күренеш: мин әлифбаны әнкәйдән өйрәнгән идем. Әмма мине башка нәрсә борчый: сул

кул белән язам. Әнкәй Әкълимә ападан «улымны уң кул белән язарга өйрәт» дип үтенгән. Бу эш җиңел булмады булуын, әмма уң кул белән язарга өйрәндем. Әмма эшләрне сул кул белән башкаруымны дәвам иттердем.

## Хатыннарда корыч үзәк

Сугыш башланып ике атна үтте микән, мине колхоз идарәсенә чакырып алдылар. Рәис буларак, Хәниф абзыйның сүзе төгәл булды: «Монда үзара сөйләштек тә сине икенче бригада бригадиры ярдәмчесе итеп тәгаенләдек. Күреп-белеп торасың, авылда эшләрлек ир заты калмады. Бөтен ышаныч хатыннарда, сезнең кебек яшүсмерләрдә. Бригадир итеп 70 яшьлек Садыйк абзыйны куйдык. Укый-яза белми. Төп авырлык синә төшәр. Әмма укуыңны да өзмәссең. Әтиең сугыштан кайткач, йөзебез кызарырлык булмасын. Бүген үк эшкә тотын!»

Төп эшем шул булды: хатыннарны эшкә өндим. Кырда, болында эшләгән эшләрен кабул итәм. Шулар хакында һәр кич идарәгә барып хисап бирәм. Хатыннар, мәсәлән, урак ура, көлтә бәйли, печән чаба. Бер төрлеләре амбар тирәсендә эшли, ашлык җилгәрә. Нинди генә эш кушсаң да баш тартмыйлар.

1941 елда кар иртә ятты. Шактый икмәк, бигрәк тә солы, бодай кар астында торып калды. Әмма җае табылды. Хатыннар зур агач көрәкләр белән ашлыкны кардан арчыдылар һәм чалгы белән чаптылар. Малайлар исә әлеге чанага төяп, колхоз ындырына ташыды. Сугылган икмәк нык чи булгач, аны хуҗалык саен тараттылар. Шуны киптереп, колхоз амбарына тапшырдылар. Бераздан колхозның икмәк киптерү пункты да эшли башлады.

...1942 елның җәе. Апалар, чалгыларын күтәреп, җәяүләп печән чабарга баралар. Ара ерак түгел, 1-2 чакрым тирәсе булыр. Кечкенә таема атланып, хатыннарның төшке ашка туктаган вакытларына барып җитәм. Таган корып чәй кайнатырга куйганнар. «Дежур» торучыдан башкалары, җиләк, бөрлегән, кыргый чия, кымызлык, юа, балтырган кебек табигать күчтәнәчләрен җыялар. Бераздан җыелып табын коралар. Ипиләре (бәрәңге кәлҗемәсе) исем өчен генә. Кечкенә шешәдә—сөт. Шуны чәйгә салалар... Йөрәгем апа-җиңгиләрне кызганып сызлый: тәннәрендә—ит, йөзләрендә нур юк. Шактыена иренең үлемен хәбәр иткән «кара хат» килгән. Өй саен күпләренең кулында 4-5 бала һәм картлар... Вакытында һәрберсе иргә яратып чыккан, үзен бәхетле итеп санаган. Мондый хәл булыр дип кем уйлаган ди? Бу буын кешеләре «дошманны үз җирендә тар-мар итәчәкбез» дигән җырлар җырлап үсте. Шуңа күрә фашистларның бер-ике ай эчендә Мәскәүгә килеп җитүе, Ленинградның камалышта калуы, туктаусыз «похоронка»лар килү халыкны аптырашта калдырды.

...Төшке аштан соң хатыннар тагын эшкә тотындылар. Арадан берсе: «Хәл бетә, бетмәс иде дә, бәрәңгенең мае юк шул»,—ди.

Көтмәгәндә авылны тагын бер кара кайгы басты: күрмәгән, колак ишетмәгән «септик ангина» дигән авыру таралды. Бу—1943 елның җәе.

«Септик ангина» дигән авыру—бик хәтәр нәрсә икән. «Септик»—агулы дигәнне аңлата. Ангина исә тамакка бәйле. Авыруның төп сәбәбе—кышын кар астында яткан ашлыкларны ашау.

Авыручылар саны нык арткач, мәктәбебезнең бер бинасын «лазарет»ка әйләндерделәр... Шуларга бәйле бер вакыйга әле дә булса исемнән китми: «лазарет»тан бер малай тәрәзә аша бу якка чыкты, әмма озак тормады, янәдән кире кереп китте. Мөгаен, ул мескенкәй җанын кая куярга белмәгәндер!.. Тиздән тәрәзә аркылы үзәк өзгеч тавышлар ишетелә башлады. Малайның авыз-борыныннан ургып кан ага башлагач, иптәшләре нишләргә белми кычкырганнар икән. Моны аңларга була. Авыруның характерына килгәндә, ул болайрак икән: бер атна буе тамак шешә. Аннан соң муенынннан тамакка бара торган юан тамыр шартлый-ярыла. Кешедә уртача 6 литр кан (балаларда кимрәк) була. Тамыр кан юлы шартлагач, бөтен кан борын-авыз аша агып бетә дә йөрәк тибүдән туктый.

...Кар астында яткан ашлыкта агу хасил була икән. Бигрәк тә тарыда һәм арышның зур-зәңгәр бөртекләрендә... Бу авыруны сульфидин дигән дару

белән җиңәргә мөмкин икән (Академик Бурденко андый даруны уйлап та тапкан, диләр. Әмма ул авылларга килеп җитә алмады.). Кар астында яткан бодай башакларын без дә җыйдык, юып-киптереп, кул тегермәнендә тарттырып ашадык. Исән калуыбыз өчен күп сөт бирә торган зур корсаклы сыерыбызга рәхмәт әйтү бик тә урынлы булыр кебек...

«Сугыш еллары хатыннарына» яңадан кайтыйк әле...

Табигать кануннары катгый: аларның берсе дә исән түгел инде... Әмма һәрберсе күз алдымда «тере килеш басып торалар»: дөньяның бөтен матурлыгын туплаган Мәрзияттәй (ире Минислам җизни, 18 яшьлек улы Мөхәммәтсалих Сталинградны саклаганда корбан булдылар...) Салихәттәй, Нәгыймә, Фәриха, Сәвия, Рәхимә, Камәрия, Хәтимә, Тәгъзимә апалар, Фәрзәнә, Гакыйлә, Фәүзия, Мәликә, Җәмилә, Гыйльминур, Миңленур җиңгиләрне дә бик сагынам... Аларга бервакытта да каты бәрелмәдем, әмма ул чакта ниндидер гаебем булса, җаннары мине гафу итсен иде димен...

Дәүләт бервакытта да «тылда эшләүчеләрнең» кадерен белмәде. Сталин үлгәнче авыл халкы сугыш вакытындагыча начар яшәде. Хрущев властька килгәч кенә, авыл кешеләренә 5 сум күләмендә пенсия түли башладылар...

...Ачтан, ял күрмәүдән 1943 ел уртасына атлар үлеп бетте. Ат—бик акыллы җан иясе. Күзеннән яшь тама, көч-хәл белән булса да атларга тели... Үзебездәге атлар урынына кечкенә буйлы монгол атларын бирделәр. Янәсе алар аз ашый, күп эшли. Әмма алар да түзмәде, берсе дә исән калмады. Без аларны—10 мең километр җир үтеп килгән бахбайларны, бик кызгандык. Бу кырылыштан соң йөк ташулар һ. б. хатыннар җилкәсенә төште. «Ирләр дә сыгылып төшәрлек эшләрне апалар-җиңгиләр ничек үтәделәр икән?»—дип әле хәзер дә исләрем китә... Шулар тәэсирендәдер, 1943 елның җәендә район газетасында шигырьгә тартым булган бер язмамны басып чыгардылар. Аның түбәндәге юллары әле дә күңелдә сакланган:

*Язгы ташкын ера буаларны,*
*Авырлыктан атлар үләләр.*
*Хатыннарда, ахры, корыч үзәк,*
*Һәммәсенә алар түзәләр.*

## Сугыш еллары укытучылары

Бу күпләргә мәгълүм-таныш: сугышка кадәр авылда иң абруйлы кешеләр—укытучылар иде. Моның үзенә күрә традицияләре дә булган. Революциягә кадәр волость үзәге булган безнең авылда Земская школа ачканнар. Берара аның учительләре булып күренекле (булачак) шагыйрь Михаил Давыдович Львовның әти-әнисе—Дәүләтша һәм аның хатыны Гөлҗиһан Габитовлар эшләгән. Гөлҗиһан мөгаллимә көндез дәресләр бирү белән генә чикләнмәгән. Кичләрен үз фатирында кызларга урыс теле буенча дәресләр дә биргән. Алар арасында минем әнкәм дә булган...

Совет власте безнең авылны читләтеп үтмәгән. Районда беренче татар ТБУМыннан соң урта мәктәп безнең авылда ачылган.

Шул хәтердә сакланган: укытучыларның күпчелеге ирләр, хәтта башлангыч классларда да алар укыта иде. Тарих фәнен мәктәпнең директоры Мәгави Багдасаров, рус теле һәм әдәбиятын завуч Зыя Әминов, математиканы Гаффар Җамадетдинов, физиканы Кәрәмәт Галимов, химияне Хатим Гайнанов, татар теле һәм әдәбиятын Гомәр Бәйрәмгулов укыттылар.

Сугыш башлангач, күп тә үтми, аларның һәммәсен дә армиягә алдылар. Кызганычы шул: ике укытучы гына, каты яраланып, авылга кайттылар...

Сугыш елларында югары классларда рус теле һәм әдәбиятын Минск университетын тәмамлаган Георгий Севастьянович Хомутовский укытты. Аның тәэсирендә дип уйлыйм: күңелемдә университетта уку теләге туды һәм мин аны тормышка ашырдым. Немец телен эвакуация белән Мәскәүдән килгән Березина фамилияле апа укытты. Кайбер классташларым (мәсәлән, Рәүф, Гадил, Әкрам, Габделәвәл) «фашист теле безгә кирәкми» дип «баш күтәрмәкчеләр»

иде. Әмма классның күпчелеге апаны якын итте. Чөнки ул безне бөек немец язучылары белән таныштырды.

Хаклыкны раслау булыр: сугыш башлануга, абыйлар фронтка китүгә карап кына укулар туктап тормады. Беренче сентябрьдә барлык класс ишекләре дә ачык булды.

Сугыш еллары укытучыларының тормышы бик авыр булган дип әйтү—йомшак итеп әйтү. Укытучылар бәрәңге, яшелчә утыртмыйлар, мал-туар асрамый (дәүләт керткән традиция). Сельподан аена 10 кило он бирәләр үзләренә. Май, ит, сөт—проблема. Кием-салым белән дә шулай. Мәсәлән, Тәскирә Сарбаевна 4 ел буена бер сарафан киеп йөрде. Ул аны күз нуры кебек күргәндер, өенә-фатирына кайту белән дә киеп йөрде микән?..

Бүгенге педагоглар сугыш еллары укытучыларын авырлык белән генә күз алдына китерә алыр. Дәрес бирү белән генә чикләнмиләр, райком кушкан бөтен эшне үтиләр иде. Агитатор, пропагандист, заем кампаниясен үткәрү, фронтка хатлар язу, җылы оекбашлар, перчаткалар бәйләүне оештыручылар да—алар.

Сугыш искиткеч күп корбаннар таләп итте. Мисал өчен, үзебезнең туганнарны гына әйтсәк тә, 37 абый-җизниләрем чит җирләрдә ятып калдылар бит... Туганнан туган Касыйм абый Әхмәтҗанов, яшь лейтенант Брест крепостенда җирләнгән... Без яшәгән Ярминкә урамында 50 йорт бар. Сүз уңаенда гына: Мәскәүдә укып диссертация язганда, экспериментал база итеп Балтач, Кукмара районнары мәктәпләрен алдым. Шуларның берсе—Чепья урта мәктәбенең тарих укытучысы Гарифҗан Галиев укучыларга (алар шактый авыллардан килеп укыйлар икән) болай дигән: авылыгыздан ничә кеше сугышка киткән, күпмесе исән-имин кайткан, исем-фамилияләрен, туган елларын күрсәтегез. Укучыларның җаваплары белән танышкач, башымны кая куярга урын тапмый йөрдем. Чөнки сугышка китүчеләрнең 80 процентка якыны фронттан әйләнеп кайтмаган...

## Комбайнчы... студент булды

Авылыбызның бер ягына МТС урнашкан. Халык өчен аның шактый уңай яклары бар. Мәсәлән, минем кебек 30 яшүсмерне 1944 елның июнь башында бер айлык комбайнчылар курсына җыеп алдылар. Кем әйтмешли, көн-төн укыдык, хәлдән килгәнчә тырыштык. Имтиханнар да тапшырдык. Нәтиҗә болай булды: «Сталинец-6» комбайнына утырырга рөхсәт ителде.

Халыкта «җан биргәнгә—юнь бирә» дигән мәкаль бар. Аның мәгънәсенә тиз төшендем: үзем эшләячәк (мине Салават исемендәге колхозга—Әлкә исемле башкорт авылы икмәген урырга җибәрделәр...) Трактор, комбайннар өчен җаваплы кеше итеп Петр Кувайцев дигән механикны билгеләгәннәр.

Сорау туарга мөмкин: ни өчен мин бу үткәннәрне искә алам да шуның белән нәрсә әйтмәкче булам?

Әлбәттә, күпләр үзләренең балалык, яшьлек елларын сагынып искә төшерәдер. Һәм ул табигый күренеш. Шатланып шуны әйтә алам—тормыш юлларымда күбрәк әйбәт кешеләр белән очраштым. Минемчә, ул чакта нинди дә «милләтчелек» юк иде. Хәбир агайны, Сиражетдин бабайны бригадир Мәликә апайны сагынып искә алам. Бу урында бер кечкенә белешмә бирү урынлы булыр кебек: татарлардан аермалы буларак, башкортларны сугышка ярты елга соңрак алдылар. Алардан атлы дивизия төзү өчен шулай хәл иткәннәрдер. Башкорт кавалериясе (аның командиры Шәйморатов—башкортстанның Кырмыскалы районы татар егете) фронтта шактый батырлыклар күрсәтте. Әмма авиация, танк, артиллерия өстенлек иткән сугышта югалтулар зур була, әлбәттә. «Похоронка» алган башкорт хатыннары үзәкләре өзелгәнгә түзә алмыйча, кычкырып еладылар...

Әлкә кырларында икмәк уру октябрь урталарында гына тәмамланды. Кулымда Казан университетыннан килгән чакыру кәгазе булса да, паспортны миңа октябрь урталарында гына бирделәр. МТС директоры шуны раслаучы белешмә дә язып бирде. Әлеге «кәгазьләрне» университет ректоры К. П. Ситниковка күрсәткәч, гаризама: «Татар теле бүлегенең беренче курсына кабул итәргә» дип язып куйды. Бу минутларда үземне күк капусы ачылып, күкнең җиденче

катында итеп сиздем! Хәтердә шулай сакланган...

Бераз алга китеп булса да, шуны әйтим әле: һәр лекциягә бәйрәмгә барган кебек шатланып йөрдем. Үзем өчен туктаусыз «Америка ачтым». Монда сугыш вакытында Мәскәүдән, Ленинградтан килгән профессураның роле зур булгандыр... Аларның сөйләгәннәрен бөтен тәнем-җаным белән тыңлап, мөмкин кадәр язып бара идем...

Тагын бер үзенчәлекне искә аласым килә: татар бүлеге яңа гына ачылгач, аның төпле укыту программалары да булмаган. Һәм бу бик тә табигый хәл. Бүлек белән татар теле кафедрасы мөдире Рәбига Хәкимова җитәкчелек итә.

Сүз уңаенда тагын бер мөһим мәсьәләгә тукталыйк әле...

Сталин кушуы буенча, бер тәүлек эчендә—1944 елның 23 февралендә—нигездә, мөселманнарны: карачай, черкис, нугай, балкарларның (мөселман булмаган калмыкларны да), месхет төрекләрен мал вагоннарына төяп көнчыгышка озаталар. Ачлыктан, салкыннан, авырудан шуларның яртысы юлда үлә. Кырым татарларының язмышы да бик аянычлы була—аларны Урта Азиягә озаталар. Кайбер ышанычлы мәгълүматларга караганда, чират Казан татарларына да килеп җитәсе булган—өлгерә генә алмаганнар... Өстәвенә, татар егетләре фронтта арысландай сугышканнар—бу момент та искә алынгандыр, мөгаен.

1944 елның августында партия Үзәк Комитеты «Татарстан өлкә партия оешмасында идеологик эшләрнең торышы» дигән куркыныч карар-документ кабул итә, анда ачыктан-ачык «Татариядә милләтчелеккә каршы көрәш бик сүлпән алып барыла» дип күрсәтелә. Янәсе, язучылар, галимнәр арасында «ханнар заманын идеаллаштыручылар бар». Минемчә, Мәскәүнең 1938 елда Казанда кылынган мәхшәрлекне кабатларга (ул чакта Черек күл базында 218 иң затлы кешеләр—җитәкчеләр, язучылар, галимнәр атыла; бик күпләр ГУЛАГка озатыла) нияте булса да, эш, бәхеткә күрә, «ярты юлда» тукталып кала...

Һәм нәкъ әнә шул елда татар хатыны—күренекле галим, Мәскәүдә бөек урыс галимнәре җитәкчелегендә диссертация язган һәм уңышлы итеп яклаган Рәбига Абзаловна Хәкимова Казан дәүләт университетында татар бүлеген ачтыруга ирешә! Акыллы кеше, «Мәскәүләрнең якадан тоту» мөмкинлеген яхшы белгән хәлдә әлеге адымны ясый.

Бу бөек зат турында мәгълүматлар аз. Миңа, мәсәлән, шулар билгеле: ул 1902 елда Татарстанның Чистай районы, Яуширмәдә, Гаяз Исхакый туган авылда туган. Югары белем алгач, төрле җаваплы урыннарда эшләгән. Радиокомитетның баш мөхәррире дә булган...

Күңелдә аның образы шулай сакланган: уртача буйлы. Төскә-биткә чибәр. Горур. Үзенә дә, безгә дә үтә таләпчән. Хәтта кырыс, усал. Ул үз янына телчеләрне (үзе телче булгач) тупларга тырыша. Андыйларга иң элек И. Нуруллин, Ф. Фәсиев, А. Кәримов, Л. Гаделшин, Б. Хафизова, Х. Мөхәммәдиев кебекләрне кертә.

Мине иң элек шушы нәрсә гаҗәпләндерә: ничек ул—Рәбига Абзаловна мөселманнарның аяк астында гөрләп ут янган бервакытта—1944 елда татар теле бүлеген ачтыра белде икән?

Иң үкенечлесе шул: Рәбига Абзаловна докторлык диссертациясен язып тәмамлый да... Мәскәү галимнәре бу фәнни хезмәткә бик югары бәя бирәләр. Әмма хезмәтен яклап өлгерә алмый: озакка сузылган каты авыру аның гомерен өзә. Ул чакта аңа нибары 53 яшь була...

Рәбига Абзаловна оештырган татар бүлеге татар халкына талантлы «гуманитар элита» кешеләрен мулдан бирде. Алар белән халкыбыз горурлана. Әмма шулай да күңелнең бер китеге җанны үртәп тора: юбилейларда Рәбига Абзаловнаны искә алмыйлар. Зур гөнаһтыр бу!

## Мәҗит Рәфыйков, Гурий Тавлин белән соңгы күрешүләр

1986 елда Татарстан китап нәшриятында «Совет Татарстаны язучылары» дигән китап басылып чыга. Андагы мәгълүматларга ышансак, Мәҗит Рәфыйков

1950—1955 елларда Иркутск өлкәсендә, Тайшет-Братск рассасында фельдшер һәм санинструктор булып эшләгән икән. Әмма университет студенты Мәҗит Мәгъсүм улы нишләп Себер якларына барып чыккан—бу хакта ләм-мим. Гурий Тавлин исеме китапта бөтенләй юк. Димәк, аны ул чакта Язучылар берлегенә алмаганнар булып чыга. Шундый ук «кызык хәлләр» Аяз Гыйләҗевка да хас икән... Әлеге китапта аның хакында болай диелгән: «1948-50 елларда ул—В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенты, ә 1950 елның мартыннан башлап 1955 елның августына кадәр Казакъстанда яши һәм төзелештә ташчы, бетон коючы, бригадир һәм десятник профессияләрен үзләштерә». Аяз дуска артык тукталып торуның әлләни кирәге юктыр, чөнки әлеге китапны «обллит тураганы» ярылып ята: акны кара дип әйтү заманы иде ул чаклар. Шуны гына өсти алам: 1945 елда КДУның беренче курсында Аяз белән бер төркемдә укыдык, хәтта тулай торакта бергә яшәдек. Шуны әйтәсем килә: без, аның группадашлары, Аязда язучылык сәләте бар икәнен белдек, чөнки ул безгә кайбер хикәяләрен укып күрсәтә иде. Аязның бер җирдә дә басылмаган «Лира чыңлый» дигән хикәясе шундыйларның берсе иде. Кем белә бит, язмышы шулай булганмы, «иҗат кешесенә каты сугылмаслар» дип уйлау сәбәпме, Аяз лекцияләргә бик сирәк йөри иде. Беренче семестр имтиханнарына, гомумән, йөрмәде. Закон буенча, язга кадәр аны укудан да, тулай торактан да чыгармадылар. Әмма бер дә алга китеш сизелмәгәч, егеткә университет белән хушлашырга туры килде... Кызганыч һәм ни үкенеч, әмма чынбарлык шуннан гыйбарәт. Гулагтан кайтып, «Чаян»да эшләгәндә, мин Аяз белән күрештем. Ул мине бик ачык йөз белән каршы алды. Шундыйрак мөнәсәбәт озак елларга сузылды дисәм, һич тә арттыру булмас.

Мәҗит Рәфыйков белән «хәлләр» болайрак тора: чыннан да, белешмә-китапта әйтелгәнчә, ул сугыштан каты җәрәхәтләр алып туган авылына кайта һәм, озак та тормый, Башкорт дәүләт désинститутына укырга керә. Ул чакта бөтен илгә диярлек хас нәрсә—күп вузларда профессорлар, доцентлар юк дәрәҗәсендә иде. Бу хәл Мәҗитне һич тә канәгатьләндерми. Шул нәрсә аны Казан дәүләт университетына юл тотарга мәҗбүр итә.

Мәҗит Башкортстанның Күгәрчен районы Үзәгендә—зур татар авылында туа. Сугышка кадәр фельдшерлыкка укыган, техникум тәмамлаган яшь егет... Мәҗит белән сөйләшкәләгән чаклар булды. Әмма ул бервакытта да ачылып китми, каядыр ашыга кебек тоела иде. Моның уңай ягы шунда булды бугай: кулга алынгач, «Якын дусларың кемнәр иде?»—дигән сорауга җавап биргәндә, минем исемне әйтмәгән... Мәҗитнең бер «сәер» ягы шунда (моңа бигрәк тә кызлар әһәмият бирә) иде: күкрәген киеребрәк, башын арткарак чөеп йөри. «Шагыйрь булдым дигәч тә, алай ук масаерга кирәкмәс иде»,—дип хөкем чыгара иде кызлар... Ә чынлык шуннан гыйбарәт: фронтта умыртка сөяге зарарланган булган...

Соңгы тапкыр Мәҗит белән 1950 елның 9 мартында, университет китапханәсенең түбәнге катында сөйләштек. Кичке 8ләр чамасы кебек хәтердә калган. Кыска гына гәпләшүнең төп мәгънәсе шул: Мәҗит И. Гёте поэзиясенә багышланган диплом эшен тәмамлаган икән. Тиздән чиста кәгазьгә күчерәсе генә калган. Ә мин: «Такташ поэзиясенә багышланган диплом эшен тәмамладым»,—дидем... Мәҗит тулай торакка кайтып китте. Мин китапханә ябылганчы (уннар тирәсенә кадәр) «бил бөктем», гадәтем шулай иде... Мәҗит тулай торактагы бүлмәсен (бүгенге геология факультеты бинасы) ачып кергәч, караватында матрас, мендәр, одеал ише нәрсәләрнең булмавын, өстәл артында ниндидер ике ят кеше белән тулай торак комендатының утыруын күреп гаҗәпләнгән. Әмма аңа хискә бирелергә ирек бирмәгәннәр, «ике кеше»нең берсе Мәҗит Рәфыйковны кулга алу турындагы «кәгазь-ордер»ны күрсәткән дә, аны шундук алып чыгып киткәннәр. Хәтта бәдрәфкә чыгарга да рөхсәт бирмәгәннәр...

Мәҗиткә нинди гаеп тākканнардыр, бу хакта ул бервакытта да, беркемгә дә сөйләмәгән. Чөнки ГУЛАГтан чыкканда «булган-белгәннәрне сөйләмәскә» дигән язма кисәтү алган. Янәсе, «сүзеңдә тормасаң, яңадан безнең кулга килеп керерсең». Шуңа күрә Мәҗитнең ни өчен кулга алыну, зинданга ябылу сәбәпләре

хакында фараз итәсе генә кала. Беренчесе: Совет властеның кан дошманнары булган, чит илгә качып киткән Зинаида Гиппиус, Андрей Белый, Иван Бунин кебекләрнең әсәрләре турында, «тәнкыйть күзлеге аша» дип булса да, күп ишетәбез-беләбез, ә чын күңелдән социализм-коммунизмга бирелгән яклаучыларны телгә дә алырга ярамый» дип, семинарда бәхәс күтәрмәде микән Мәҗитебез? (Гурий Тавлин турында сөйләгәндә, бу мәсьәлә ачыла төшәр әле).

...Бергә укыган иптәшләре белән Мәҗит бер Казан кызының фатирында кунакта була. Бераз гына тамак чылатып та алганнар. Тулай торакка Ирек мәйданы аша кайтканнар. Опера-балет театрына күрше булган бер бинаның (ул чакта Юридик институт бинасы иде ул. Институтны Карагандага күчергәч, бинаны Авиаинститутка бирделәр...) өске өлешенә Сталин портреты урнаштырылды. Шуны күргәч, алны-артны уйламый гына Мәҗит «какой мерзкий-неприятный взгляд» дип ычкындырган. Ул чакта һәр төркемдә кимендә бер-ике МВД шымчысы булган (безнең 16 кешелек группабызда да ике ир заты шымчылык белән шөгыльләнгән. Алар бу хакта Сталинның шәхес культын ачып салгач кына әйттеләр. Безне шул эшкә алынырга мәҗбүр иттеләр, диделәр...).

Гурий Тавлинның «Афәт» романы 1996 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Курск дугасы һ. б. сугышлар герое—өлкән лейтенант, танкист Гурий Иванович Тавлин (1925 елда Зәй районының урта Баграж авылында туа). Әти-әнисе репрессияләнгәч, ятим үсә, мобилизацияләнгәч, туп-туры Казанга кайта һәм пединститутның татар бүлегенә укырга керә. Ләкин вузны тәмамлый алмый: 1950 елның башында, милләтчелектә гаепләнеп кулга алына. Гурий аганың ГУЛАГта күргән газапларын күзаллау өчен «Афәт» китабын тулысынча укып чыгарга кирәк...

Студент Тавлин бер семинар дәресендә доцент Җамал Вәзиева белән сүзгә керә... «Совет властен өнәми читкә киткәннәрнең әсәрләрен «тәнкыйтьләгән булып» искә алабыз, ә менә бөтен тәне-җанын яңа тормышка биргән Галимҗан Ибраһимовның әсәрләрен халыктан яшерәбез»,—ди. Укытучы аны нык ачулана, бу аның киләчәк язмышын хәл итә... Әлеге хакта мин күптән түгел Мәскәүнең I каналында күрсәтелгән 12 серияле «Ленин васыяте» дигән фильмны караганда уйландым. Фильм 20 ел ГУЛАГта, концлагерьларда утырган күренекле язучы Варлам Шаламов әсәрләренә нигезләнеп эшләнгән. Гурий Тавлин да Шаламов күргән мәхшәрләрне күргән-кичергән бит... Шуны гына өстисе кала: урта гасыр инквизитрлары да Сталин җәлладлары кадәр үк кыланмагандыр...

Фашизмны һәрберебез бөтен йөрәк-күңелләребез белән кире кагабыз. Ләкин шунсы хак: үзен милләтче-социалист дип атаган обер-фашист Адольф Гитлер партбилетларыннан баш тарткан социалистларны, коммунистларны төрмәгә утыртмый. Кыска вакыт эчендә эшсезлек бетерелә. Тормыш яхшыра. Әлбәттә, башка илләрне талау хисабына. СССРда шуларның киресе эшләнә: миллионнарча иң яхшы кешеләрне аталар, концлагерьларда черетәләр.

## Митькә дәдәй, таз Зәйнулла һәм башкалар

Митькә дәдәй (халык аны шулай дип атап йөртте) безнең авылга каян һәм ничек килеп чыккан—мин белми идем. Әткәй колхоз рәисе булганда, Митькә дәдәй берничә мәртәбә бездә булды, әткәй аны «бер дигән умартачы» дип мактый иде. Ул Белая Глина дип йөртелгән урман уртасындагы аланлыкта, махсус салынган өйдә гаиләсе белән яши. Умарталар да шунда икән...

Көтмәгәндә дип әйтү дөрес булыр кебек: бервакыт дәдәй юкка чыкты. Халык бик гаҗәпләнде. Әмма бер айдан авыл советына Уфадан хәбәр килгәч, күп нәрсәләр ачыкланды кебек: Митькә-Дмитрий Патоповны Югары Суд, 58 нче статья буенча («халык дошманы») үлем җәзасына хөкем иткән икән. Шул көнне үк атканнар да. Гаебе шул: ул ислам диненә тартылган. «Гаеп»нең үзенә килгәндә, ул шуннан гыйбарәт: алдан килешенү-сөйләшенү буенча, җәйге караңгы төн уртасында Митькә дәдәй Хафиз мөәзиннең өй ишеген шакыган. Утны яндырмыйча гына мөәзин бабай дәдәйне ислам өммәте кешесе иткән. Дмитрий урынына Динмөхәммәт дигән исем кушкан. Шулай фараз итәсе кала:

авыл куштаннары бу эшне күзәтеп торганнар. Дәдәйнең болдырдан җиргә төшүе булган, кулларын бәйләп милициягә илтеп тапшырганнар. Ә милиционер, таң атканын да көтми, «халык дошманын» район үзәгенә алып китә... Монда эш яңа дин кабул итүдә генә түгел, урман өскә авып торса да, мунчасы да булмаганнарның («акамай Каюм», «аю Хаҗи» кебекләр) дәдәйдән, аның 5 бала үстерүеннән үлеп көнләшкәннәр.

...«Таз» Зәйнулла (пеләш булганга шулай дип атаганнар) абзыйның язмышы да дәдәйнекеннән әйбәт булмаган. Халыкның «бәла аяк астында» дигәне хак икән: бөтенләй көтмәгәндә Малаяздагы (Вәкый абый туган авыл) бер танышы Зәйнулла абзыйларга килеп кергән. Йомышын-гозерен әйткән. «Буш кул белән» килмәгән икән, өстәлгә «шайтан суын» чыгарып куйган. Шуны күргәч хуҗабикә тиз генә табын әзерләргә тотынган. Тиздән күрше Хаммат та килеп кергән. Аны да табынга утыртканнар. «Шайтан суы» ирләрнең күңелен күтәргән. Хаммат, исә: «Зәйнулла абзый, тавышың матур, берәрне җырлап күрсәт әле»,— дип ялварган. Таз абзый канатланып киткән һәм җыру сузган:

*Николай патша—дурак,*
*Сигез сыер саудырган.*
*Иптәш Сталин—акыллы,*
*Бер кәҗәгә калдырган.*

Хаммат: «Оныта язганмын, идарәгә барырга кирәк»,—дигән дә тиз генә чыгып сызган... Малаяз кешесе, сый-хөрмәт өчен рәхмәтләр әйтеп, үз юлы белән китеп барган... Икенче көнне, таң атуга, милиционер Камаловның тарантасы Зәйнулла абзый капкасы төбенә килеп туктый. Зәйнулла абзыйның: «Тамак ялгап алыйм әле» дигән сүзләренә: «Әйдә, киттек, район үзәгенә барып җиткәч ашарсың»,—дип җавап биргән. Шул китүеннән Зәйнулла абзый авылга кайта алмаган. 58 нче статьяны кулланып, Зәйнулла абзыйны үлем җәзасына хөкем иткәннәр. Әмма колхоз идарәсе абзыйны яклап сүз әйтергә курыкмаган. «Зәйнулла Хәйруллин күп еллар буе ударник булды. Сәясәткә катнашмады. Начар җырны аңа кем өйрәтсә, шуны хөкем итү дөрес булыр иде» дигән язуны судка тапшырган. Шул нәрсә абзыйның гомерен саклап калган: үлем җәзасын 10 ел төрмә белән алыштырганнар.

...Гаиләсенең әйтүенә караганда, ул әлеге срокны көненә кадәр тутырган... Әмма дә ләкин станциядән авылга кайтканда (ярты юлны җәяү үткән) салкын тидереп, үпкәсе нык шешкән. Шулай да өенең бусагасыннан атлап керә алган. Һәм берничә сәгатьтән җан биргән... Шымчы Хаммат абзыйның да бәхете булмады, дип сөйли халык: үзе үпкә авыруыннан үлә, кызы Сажидәнең (класстащымның) борыны чери, малаен урманда яшен сугып үтерә.

## Чулак Рәхим абзый, Миңҗамал җиңги һәм башкалар

Чулак Рәхим абыйны сугышка алмадылар, чөнки уң кулы терсәгенә кадәр кабыргалары тирәсенә ябышкан—балачактан шулай калган. Уртача буйлы, хәрәкәтчән кеше. Апасы Шәрәфниса—безнең күрше—балалы ятим хатын. «Гыйззәт сугышка китеп үлгән булса, налог түләмәс, хөкүмәткә 400 литр сөт тапшырмас идем»,—дип зарлана иде ул. Әмма «җан биргәнгә—юнь бирә» дигәндәй, Рәхим абзый апасын ташламады...

Көньяк Урал тимер юлының Мәрсәлим станциясе авылыбызга 35 чакрым. Рәхим абзый һәр көнне шуннан тимер мичкәләргә тутырып ягулык алып кайта. Тракторчылар, комбайнчылар аның күзенә генә карап торалар...

Рәхим абзый җиде бала атасы... Беркөнне (бу—1944 елның язгы кояшлы көне) ул хатыны Зәйнәпкә болай ди: «Мәрсәлимдә юнь генә хакка бала-чага әйберләре саталар. Кайсы балага нәрсә кирәк, үзең сайлап алырсың, әйдә киттек,—ди... Моны берни белән дә аңлатып булмый: почта ташучы кечкенә самолет түбәнәя бара һәм Рәхим абзыйның атын, арбасын изеп ташлый да, җиргә

төшеп утыра. Шул тирәдә эшләүчеләр «бу ни хәл» дип, самолет утырган җиргә йөгерәләр. Ат та, ир белән хатын да изеп ташланган. Очучы эндәшми генә басып тора. Әлбәттә, безнекеләр аны милициягә тапшыралар. Берничә айдан суд була. Очучы болай ди: «Шаяртырга гына уйлаган идем, ниятем атны куркыту иде». 4 елга төрмәгә ябалар. Янәсе, очучы явыз ният белән эш итмәгән. Шулаен шулайдыр да, әмма ата-анасын югалткан 7 бала нишләргә тиеш? Суд бу хакта эндәшми, янадан суд артыннан йөрүче дә булмый. Бикеев Рәхим абзый балаларын язмыш кочагына ташламыйлар. Һәммәсен дә төрле шәһәрләрдәге балалар йортына урнаштыралар. Очучы исә төрмәдә озак утырмый, сугыш бетү уңаеннан кабул ителгән амнистиягә эләгеп, тиз генә ирекккә чыга...

...Бригадир булган чагым (1942-43). Һәр иртәдә апа-җиңгиләрне эшкә өндәп йөрим. Урамыбызның каршы ягында—Шәрифулла абзыйның бишпочмаклы матур йорты. Аларга беренче булып керермендер... Әмма аңа кадәр кечкенә бер «сәхифә»не искә төшерәсем килә...—Казан губернасында гомер-гомергә җиргә кытлык булган. Чөнки татар җирләренең иң яхшыларына урысларны китереп утырткannар. Колхоз төзелгәч, халыкның хәле тагын да мөшкелләнә төшкән. Казан татарлары—һөнәрле халык—көньяк Урал якларында тун тегкәннәр, итек басканнар. Әнә шуларның бер төркеме—Көньяк авылының (Саба районы) 20 гаиләсе безнең авылга күченеп килгәннәр. Шуларның берсе—күп һөнәрләр иясе Шәрифулла абзый Зиннәтуллин.

Сугыш башлангач МТС директоры Әмиров Шәрифулла абзыйны эшкә чакырган. Бронь белән тәэмин иткән...

Авылда ишекне бикләмиләр—барасың да керәсең. Мин дә шулай иттем. Минҗамал җиңгигә йомышымны әйтим дип авызымны ачкан идем, ул өлгерерәк булып чыкты: ачы тавыш белән Шәрифулла абзыйны ачулана башлады, теленә ни килде, шуны әйтте бугай: «Маеңа түзә алмыйсыңдыр, кеше фронтта кан түгә. Сиңа да чират җитәр әле»,—диде. Миңа бик уңайсыз булып китте. Шәрифулла абзый эндәшмәде, миннән оялды кебек. Шундый тәэсир кала: Минҗамал җиңгинең сүзләрен фәрештәләр тыңлап торган, ахрысы: Шәрифулла абзыйның бронь вакыты бетәр алдыннан гына директор Әмиров Уфага киңәшмәгә киткән. Бәлки, хәрби комиссариат моны махсус уй белән эшләмәгәндер—әйтү кыен. Кыскасы, комиссариат Шәрифулла абзыйга броньне озайтмаган, шундук Уфага озаткан. Нәкъ начар әкияттәге кебек: бу вакытта Уфада Курск дугасына җибәрү өчен «маршевый батальон» төзелеп ята икән. Шәрифулла абзыйны шул батальонга кушканнар... Кыска гына итеп әйтәм: 15-20 көн көтте микән, почтальон кыз Минҗамал җиңги кулына «похоронка» тапшырган...

Әткәм-әнкәм исән чагында, ел саен авылда булып, ялны шунда уткәрергә тырыша идем. Мәктәп музеенда булам, классташларым белән күрешәм. Авылым табигатен гизеп чыгам.

Миннур, Гайния әбиләргә кереп сөйләшеп утырам. Иксез-чиксез кайгыларга баш ими яшәүләренә сокланам, яшәү серләренә төшенергә тырышам. Миннур әби әткәй ягыннан безгә якын гына кардәш. Садыйк җизни белән ике егет үстерделәр. Егетләрнең икесе дә педвуз тәмамлады. Әмма мәктәптә озак эшли алмадылар—армия хезмәте. Офицерлыкка укыдылар. Сугышның башыннан ук фронтта булалар.

Бик тә үкенечле: өлкән лейтенант-танкист Мөнир абый Калинин шәһәре өчен барган бер сугышта—бу 1941 елның октябрь уртасында була—танкында яна... Майор Әхмәтнур абый 1943 елда, Кырым өчен барган төнге бәрелештә һәлак була...

Гайния әбинең ире—безнең туган—Гариф Шәрәфетдинов 4 ел герман сугышында катнаша. Шулай да исән-имин кала. Туган иленә кайта. Гражданнар сугышы башлана. Шактый авыл кешеләре мобилизациядән качып котылса да, «юаш Гариф» (аны шулай дип йөртәләр) андый юлга бармый.—Димәк, зур ялгыш ясый—гражданнар сугышыннан әйләнеп кайтмый... Гайниясе кулында 3 ир, 2 кыз бала кала. Зур авырлык белән булса да, аналары аларны аякка бастыра. Тора-бара һәммәсе дә башлы-күзле була. Гайния әби оныкларына карап куана!

...Таң атуына, кояш чыгуга шатланып яшәгән көннәрдә, бөтенләй көтмәгәндә,

район сабантуе барганда, сугыш башланды. Абыйлар да, җизниләр дә атна-ун көн эчендә фронтка киттеләр. Иң үкенечлесе шул: берсе дә туган илгә әйләнеп кайта алмадылар.

## Татарның киләчәге бармы? Булса— ул кемнәр кулында?

Әлеге сораулар һич тә риторик характерда түгел. Нык уйландыра, күңелләрне айкый торган сораулар алар. Тарих аренасына күпләр килеп киткән. Мәсәлән, Европа илләренең төп халыкларын күп кенә халык-милләтләр «эретмәсе» хасил иткән. Алар да—тарихның чагыштырмача яңа чоры. Ә аңа кадәр нәрсәләр булган? Америка галиме Р. Морган, дәүләт барлыкка килгәнче, кешелек җәмгыяте иң элеке матриархат чорын узган, кешелек дөньясы хатыннар кулында булган, ди һәм моны хатыннарның җәмгыятьтә тоткан урыны белән билгеләнгән, ди: аналар, балаларын иертеп, азык-төлек җыйган, ял итү өчен урын әзерләгән. Ирләр ау белән шөгыльләнсәләр дә, еш кына буш кул белән кайтканнар. Малтуарны кулга ияләштерү, иген игә башлау ирләрне алгы планга чыгарган. Бу— патриархат чоры...

Җәмгыятьләр, дәүләтләр барлыкка килү, формацияләргә күчү теорияләре бар. Әмма бу очракта аларга тукталмый гына үзебезнең язмышка якынрак килик: тарихта бик күп халыклар, илләр булган. Кайберәүләренең исемнәре әле дә сакланган. Мәсәлән, хазарлар, печенеглар, сәльҗүкләр, кельтлар, бриттлар һ. б. Бу мәсьәләләр галимнәр арасында әлләни гауга чыгармый. Ә менә «татар» исеме-теориясе сүз көрәштерүнең туктап та торганы юк. Бу «көрәшнең» башында беркем дә түгел, үзебезнең галимнәр тора.

«Болгарчылар» өчен җавап бирү—безнең бурыч түгел. Ләкин шундый тәэсир кала: янәсез, без үзебезне «болгар» дип атасак, урысларның безгә мөнәсәбәте һичшиксез уңай якка үзгәрәчәк. Йә, шулай да булсын ди, әмма тарихи процессларны кая куярга? Моны ачык итеп әйтергә кирәк: халкыбызның болгар чорын беркем дә кире кагарга җыенмый. Мәсәлән, Татарстан хөкүмәте карары белән, «История татар» дигән 7 томлык чыгып ята. Моның белән, нигездә, Татарстан фәннәр академиясенең Тарих институты фәнни хезмәткәрләре шөгыльләнә. Әлеге җидетомлыкның Икенче томы тулысы белән болгарларга, Идел Болагрстанына багышланган (960 битле, 60 басма табак). Бу том үз эченә 9 бүлекне ала...

Әйе, татар халкының милләт булып формалашуында болгарларның роле бик зур. Әмма бүгенге татар канында фин-угры, урыс-славян һ. б. өлеше дә бар. Россия президенты Путин әйтмешли, «бер каннан гына торган саф милләт булмый һәм була да алмый. Урыс милләте барлыкка килүдә татарлар өлеше зур»...

Бу минем фикер генә түгел: татарны, шул җөмләдән бүгенге татарны харап итүче төп нәрсә—үзара дуслык булмау. Дөресрәге, үзара ызгышу. Заманында миңа, СССР Педагогик фәннәр академиясе системасында укып, диссертация язарга туры килгән иде. Шул чакта ВАКта (Югары Аттестация Комиссиясе) эшләүче Уфа татары Марат Тайчинов белән танышырга туры килде. Бервакыт ул болай диде: «Казанда диссертация яклыйлар. Документлары бер ай эчендә ВАКка җибәрелә. Әмма Казанда якланган диссертация турында хәбәр бер атна эчендә килеп җитә. Милләттәшенең фәнни хезмәтен һәртөрле хурлап татар галиме, хәтта галимнәре яза. Башка бер яктан да андый хәбәрләр килми. Коллегаларым алдында оят. «Опять татары грызут друг друга»,—диләр алар...»

Җәйнең бик матур чагы. Уфага пароходта кайтырга булдым. Дүрт тәүлек буе безнең якларның (Идел, Кама, Агыйдел буйлары) никадәр матур икәненә сокланып бардым. Өске катта палубада баручы профессорлар М. Абдрахманов (КДУ проректоры. Заманында безнең группада философия буенча семинар дәресләре алып барган фронтовик галим, Н. Воробьев («Казанские татары» дигән күләмле фәнни китап авторы)—күршеләрем булып чыкты.

Бу темага сөйләшергә артык теләгем булмаса да, Николай Иванович, аны миңа «көчләп такты». Түбәндә сүз шул хакта барачак...

Николай Иванович сүзне болайрак башлады: «Сез—татарлар, безгә—урысларга, Казанны басып алган өчен үпкәлисез инде. Монда үзенә күрә әйтер сүз бар. Әмма тарихны да яхшы белергә кирәк. Моңа иманым камил: әгәр татарларның бер өлеше ныклап Мәскәү ягына аумаса, Явыз Иван гомердә дә Казанга поход оештырырга батырчылык итмәс иде. Гадәттә, Шаһгалине сүгәләр. Аны К. Маркс та тәнкыйтьләгән. Әмма Шаһгалиләр йөзәр, меңәр булган. Мәскәү ягына үзләре теләп күчүчеләрне, православиенең динен кабул итүләрен белмибезмени? 1551 елда Явыз Иван кышны үткәрү өчен Мәскәүгә кайтып киткәч, урысларның Зөядәге агач корылмасын татарлар бик җиңел генә җимерә алырлар иде. Әмма бу хакта уйлап караучы да булмый. «Мәскәү партиясе» Казанда үзен иркен итеп тота. Мичкәдәге дарыга су сибүче, чишмәләрне агулаучылар да, урыслар түгел, татарлар булган бит. Явыз Иван татар гаскәрләрен сугышка кертмәсә дә, алар шактый булган һәм үз сәгатьләренең сугуын гына көткәннәр».

Профессор «Казанны алуда егетлек күрсәткән» татарларга алпавыт грамотасы бирелүен күпсанлы мисаллар белән дәлилләде. Шуны әйтергә дә онытмады: «Себер, Әстерхан, Кырым ханлыклары гына түгел, зур көчкә ия булган Оттаман (Төркия) империясе дә Казанны яклап бер кәлимә сүз дә әйтмәде»,—диде ул. Шунысы характерлы: Н. И. Воробьев Явыз Иван кылган явызлыкларны, мәсәлән, ир затын суеп бетерүен, хатыннарны көчләү һ. б. вәхшилекләрне яклап-аклап чыкмады. «Хәзер без бер зур дәүләттә яшибез. Узганнар өчен җавап биреп булмый. Хәтта теләсәк тә. Туры юл бер генә: үзара дус булып яшәү»—дип тәмамлады сүзен мөхтәрәм галим.

## Татар халкының киләчәгенә ышанам

Бу хакта матбугатта да чыгыш ясыйлар, радио-телевидение дә читтә калмый: дәүләте булмаган халыкның киләчәге юк, диләр алар. Принципта, бәлки, шулайдыр да. Әмма күңел моның белән һич тә ризалашмый. Дөрес, тарихта империяләр күп булган. Һәммәсенең дә язмышы бер: таркалганнар. Көчләп корылган кораманың юкка чыгуы табигый. Әмма «без бетәбез» дип мескенгә салыну—дөрес булмас иде. Кайчандыр, моннан 5-6 йөз еллар элек, Англиянең Бирмингем шәһәре тирәсендә кельт кабиләләре яшәгән. Бүген шул милләтне аякка бастырырга йөрүчеләр бар. Хөкүмәт тә моңа каршы килми, бездәге кебек, ил таркала дип курыкмый. Скандинавия ярым утравында бик аз санлы саам-лопарьлар яши. Норвегия, Швеция, Финляндия җитәкчеләре әлеге халыкны саклап калу өчен бик күп эшлекле чаралар күрә. «Теге заманнарда» европалыларга каршылык күрсәткән кызыл тәнлеләрне күпләп кырганнар, резервуарларга куып кертkәннәр. Бүген Америкада иң яхшы тәэмин ителүче, иң абруйлы кешеләр—кызыл тәнле индеецлар. Безнең чукчалар, кырык яшькә җитәрҗитмәстән, аракы эчеп үләләр. Ә АКШ эскимослары бер дигән итеп яшәп ята, югары белем алалар... АКШның үзенә килгәндә, барлык кешеләрне «америкалы» дип атасалар да, Нью-Йоркта, мәсәлән, япон, кытай, испан һ. б. халыкларның бистәләре бар. Тәртип саклаучыларына кадәр үзләренеке.

Бу нindидер яңалык ачу түгел—милләт сакланcын-яшәсен өчен аның милли үзаңы югары булырга тиеш. Мисал итеп революциягә кадәрле татарларны алыйк. Ленин 1911 елда болай дип яза: «Һәр татар авылында мәктәп бар. Татар балаларының һәммәсе дә укый-яза белә». Әллә нинди көчләүләр, көчләп чукындыруларга карамастан, һәр татар—татар булып кала бирде. Алай гына түгел, аз гына мөмкинчелек килеп чыгу белән татар зыялылары киң хокукларга ия булган автономия төзү мәсьәләсен ачыктан-ачык көн тәртибенә куйганнар. Әлеге дә баягы, милли үзаңда «милли дәүләтебез булган» дигән нәрсә нык сакланган. Моны Сталин да яхшы белгән. Ул үзенең милли мәсьәләләргә багышлап язган бер хезмәтендә болай ди: «Россиядә 4 милләт кешеләрендә—урысларда, украиннарда, грузиннарда һәм татарларда үз дәүләтен булдыру теләге һәрвакыт яшәп килде». Бу чыннан да шулай.

Булган заманалар—сан ягыннан татарлар урыслардан әлләни ким булмаган. Хәзерге нисбәтне искә төшереп эч пошырасым килми. Әмма үзара дуслык булмау, башка халыклар эчендә «эреп бетүне» хуп күргәннәр саны ишәйде шул.

Кайбер статистик саннарга ышансак, болай килеп чыга: Владивостокта 19 мең, Сахалин, Камчаткада—унар мең, Якутия-Сазада, Бурятия, Хакассиядә 1-3 мең татар яши. Мәскәүдә ярты миллион чамасы диләр. Урта Азиядә шактый халкыбыз көн күрә дип беләбез. Әмма чагыштырмача якын киләчәктә әлеге татарларның «безләр» булып калуы бик шикле. Сәбәп ике дисәк, дөрес булыр кебек: югарыда әйтелгәннәрдә татар менталитеты, милли үзаң—юк дәрәҗәсендә... Шул ук вакытта әлеге процессны туктатырлык, хәтта акырынайтырлык көч тә күренеп тормый. Үзәк исә ачыктан-ачык-рәсми рәвештә илдә бер генә милләт булдыру сәясәтен алып бара. Бәлки, мин хаклы түгелдермен, әмма татарны халык-милләт итеп саклап калу өчен Татарстанда, Башкортстанда яшәүче татарларның милли үзаңны үстерү концепциясен булдырырга һәм аны тормышка ашыру юлларын табарга кирәк... Бу аксиома, милли үзаңы югары булган халыкның гына киләчәге бар. Бер классик мисал да китерик: безнең эрага кадәр үк Рим империясе яһүдләрнең Иудея-Израиль дәүләтен юкка чыгара. Шуннан соң яһүдиләр бөтен дөньяга тарала. Иврит теле онытыла. Һәм икенче бөтендөнья сугышыннан соң яһүдиләр, тарихи ватаннарына кайтып, мөстәкыйль дәүләт төзеделәр. Хәзер ул Якын Көнчыгыштагы иң көчле дәүләтләрнең берсе. Монда яһүд халкы зыялыларының, җитәкчеләренең роле әйтеп бетергесез зур. Бөек немец язучысы (милләте белән яһүд) Л. Файхетвангер үзенең бер әсәрендә мондый хәлне тасвирлый: Израиль яшәүдән туктагач, аның элекке җитәкчеләре (шул җөмләдән хәрбиләр дә), раввиннар яшерен җыен үткәреп бер мәсьәләне тикшерәләр: яңа шартларда халыкны ничек саклап калырга? Мәсьәләне һәряклап-җентекләп тикшергәч, тиешле карарлар кабул ителә. Язучы аның ике пунктын бәян итә: 1. И син, яһүд кешесе, кайда гына яшәсәң дә шуны бел—синең туган илең, Ватаның бар. Килер бервакыт һәм син үз илеңә әйләнеп кайтырсың. 2. И син, яһүд кешесе, кайда гына яшәсәң дә һәр яһүдне якын туганың кебек күр һәм һәрьяклап аңа ярдәм ит». Минемчә, әлеге ике тәгъбирне һәр яһүд әнкәсе баласына күкрәк сөте белән бергә сеңдергәндер кебек тоела. Тормышымда, фәнни эшчәнлегем вакытында шактый яһүд кешеләре белән аралаштым һәм һәрвакыт аларның үзара дус булып яшәүләренә кызыгып яшәдем. Их, безгә, бераз гына булса да, алардан үрнәк аласы иде!.. Безне бер нәрсә—югары милли үзаң гына тарих аренасында саклап калачак. Ә без моңа лаек: тарих анналары татарларны «бөек халык» дип саный...

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# Ф. ЯРУЛЛИН ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

***

Сез иҗат иткән шигърият ул тулы мәгънәсендә туган халкыбызның, аеруча яшьләрнең җан азыгы, рухи таянычы, оптимистик өмет һәм ышаныч чыганагы. Илебезгә, халкыбызга, тормышка мәхәббәт белән сугарылган прозаик һәм драматик әсәрләрегез дә талантлы әдәби әсәрләр генә түгел, көчле рух һәм сыгылмас ихтыяр җимеше булу белән кыйммәт.

Язмыштан узмыш юк, ди халкыбыз. Ә шулай да Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил кебек тарихи шәхесләребез язмыш белән даннлы көрәш үрнәге күрсәттеләр. Сез дә язмышның сикәлтәле, каршылыклы юлларын узып, әнә шул олпат әһелләребез сафына бастыгыз, алар биеклегенә күтәрелдегез, ихтирам казандыгыз.

**Минтимер ШӘЙМИЕВ.**
*Татарстан Республикасы Президенты. 2003.*

***

Фәнис Яруллин белән без, бер төркем язучылар, беренче мәртәбә аның туган йортында—Кызылъяр авылында танышкан илек. Өйрәнчек шигырьләре матбугатта күренә башлаган чакларында ук аның язучылар арасында танышлары, якын дуслары бар иде инде. Менә шул еллардан бирле без гаять үзенчәлекле бу тырыш егетнең һәр яңа әсәрен ифрат кызыксынып, юк, алай гына түгел, иҗатындагы һәр уңышына чын күңелдән куанып каршы алабыз. Чөнки ул үзенең яшәү рәвеше белән дә, игелекле әдәби иҗаты белән дә аерым игътибарга лаек ир-егет. Чөнки аның бөтен иҗат гомерен мин кайнар, еллар буена сузылган тоташ батырлык, фидакарьлек дип атар идем. Бик борынгыдан ишетелеп килә торган «Язмыштан узмыш юк» дигән өметсез бер гыйбарә бар. Фәнис Яруллин менә шул фикер белән бәхәскә керде...

**Гомәр БӘШИРОВ.**
*Татарстанның халык язучысы. 1988*

***

Фәнис Яруллин командировкаларга йөреп «тормыш өйрәнү»дән мәхрүм. Әмма ул кайберәүләргә караганда тормышка якын. Күңеле белән якын ул. Үзе дә тормышның бер күзәнәге булып, аның шатлыкларын тоеп, кайгылары белән сызланып яши. Бала чактан сеңеп калган, илһам чыганагы булган авыл тормышына органик бәйле ул. Иҗаты көннән-көн ачыла бару перспективасын мин шунда күрәм...

Шунысына сөенәм—Фәнис турында ташлама ясамыйча сөйләп була. Иҗаты шул дәрәҗәдә. Үзенең дә холкы әйбәт—ихлас күңелдән, күзгә туры карап кимчелекләре турында да сөйләшеп була. Ул аларны искә ала, җиңә бара.

**Шәүкәт ГАЛИЕВ.**
*Татарстанның халык шагыйре. 1968.*

***

Фәнис Яруллин—төрле жанрларда уңышлы иҗат итә торган нык каләмле, киң колачлы язучы... Бөтен язганнарын җентекләп беләм дип әйтә алмыйм, әмма шигъри әсәрләрен эзлекле күзәтеп барам. Зур шагыйрь ул! Тормышчан шагыйрь, кешеләр өчен кирәк шагыйрь.

Шигырьләренең тәрбияви әһәмияте турында уйлаганда, әдәбият галиме, күп кенә дәреслекләр авторы Азат Әхмәдуллинның бер үзара сөйләшкәндә әйткән сүзләре искә төшә. «Теге яки бу темага үрнәк әсәрләрне Ф. Яруллиннан теләсә күпме табып була, ә менә кайбер шагыйрьләрнеке, хәтта бик үзенчәлекле талант булсалар да, һич кенә дә дәреслек таләпләренә туры килми». Агымдагы дәреслек-әсбапларга иллюстратив материал булып керү-кермәү—әдәби әсәрне бәяләүдә иң төп критерий түгелдер дә, бәлки. Шулай да, күп нәрсәне аңлатучы күренеш. Дәреслекләрдә, гадәттә, классик әсәрләр басыла.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН.**
*Татарстанның халык шагыйре. 1999.*

***

Хөрмәтле Фәнис дустыбыз!

Берүзенә бөркет һәм былбыл сыйфатларын берләштергән кешеләр күп түгел. Сез—шундый аз санлы асыл затларның берсе. Язмышның авыр сынаулары да рухыгызны сындыра алмады. Без, нефтьчеләр, сезнең кебек якташыбыз булу белән горурланабыз... Синең иҗатың һәм яшәү рәвешең меңләгән кешегә якты рух биреп тора. Язмышның безне очраштыруына рәхмәтлемен.

**Ринат ГАЛИЕВ.**
*«Татнефть» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры. 1998, 1999.*

***

Юк, кайчандыр матбугатта шаулаган «Островскийча, Корчагинча батырлык, кыен язмышны җиңгән совет кешесе ныклыгы» өчен түгел, ә бәлки халкындагы бөек рухның янә бер сыналуы, татар көченең дәвамы, сәләт-байлыгының мул, түкәнмәс булуының яңа мисалы итеп, үзенеке итеп яраталар аны. Изге хис бу, нәкъ менә пәйгамбәрләргә, күп газаплар күреп тә тугры юлыннан тайпылмаган әүлияләргә мәхәббәтнең бүгенгедә дә чагылышы ул...

Газаплар аша пакьләнү, чистарыну, күңел матурлыгына ирешү безнең халыкта Язмыш, Язмыш каләме, Тәкъдир кебек борынгы тәгъбирләр белән бергә үрелгән...

**Рәдиф ГАТАШ.**
*Шагыйрь. 2008.*

***

Мин аның Татарстан китап нәшриятында быел дөнья күргән «Җан авазы» дигән шигырьләр китабын укыдым, һава җитмәде миңа. Үткәнем бушанды, киләчәгем тыгызланды. Бүлмәмдәге һәр нәрсә, телгә килеп, миннән мөстәкыйльлек һәм шигърият таләп итте. Ә монда мәхәббәте янып чыккан публицистика—барысы да хәрәкәттә һәм һөҗүмдә, шигырьчелек һәм байронистикага урын калмаган, һәм көтмәгәндә мондый публицистик шигърият—югары ялкыннан яралган лирикадыр ул дигән фикергә киләсең.

**Айдар ХӘЛИМ.**
*Язучы. 1994.*

***

Фәнис Яруллин чын мәгънәсендә сизгер шагыйрь. Аның шигырьләрендә гап-гади, көндәлек, без инде тәмам күнегеп беткән көнкүреш кинәт яктырып, нурланып, нәфисләнеп китә. Фәнис шигырьләрен укыгач, үз тормышын, эшен, яшәвен кызыксыз дип йөргән кеше дә тормышыннан кызык, эшеннән тәм, яшәвеннән ләззәт таба башлый. Чөнки бик күп кызыклы якларын күрә генә белмәгән икән.

Фәнис Яруллин лирикасы—нык, таза, киң күңелле лирика. Аның герое кыенлыклар алдында югалып, җебеп, вакланып калмый. Тормыш аны нинди генә зур сынаулар аша уздырса да, ул үзендә (...) көч таба. Көләч лирика, йөрәккә якын лирика, җанга көч өсти торган лирика.

**Гәрәй РӘХИМ.**
*Шагыйрь. 1975.*

***

Фәнис Яруллин шигъри образлар ярдәмендә гүзәл рәсемнәр иҗат итә. Ләкин алар гади рәсемнәр генә түгел. Канатсыз баласын үз канатлары белән каплап җылыту өчен зәмһәрир бураннар эчендә калган карлыгач сулышын тоясың ул рәсемнәрдә, болынга рәшә булып эленгән җылы сөт исен сизәсең, горур замандашларыбызның «Алтыннан кече түгел мин, ипидән олы түгел; үлемнән көчле түгел мин, тик язмыш колы түгел» дигән мәгърур сүзләрен ишетәсең.

**Фаил ШӘФИГУЛЛИН.**
*Язучы. 1978.*



*Фәнис Яруллин. 1998 ел.*



*Өлкәннәр Фәнис Яруллинның хәлен белергә килгәннәр. Сулдан уңга—шагыйрь Мәхмүт Хөсәен, режиссер Сәет Булатов, Фәнис Яруллин, артист Габдулла Шамуков. 1962 ел.*



*Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе алган көн.*
*Фәнис Яруллин әдәбият-сәнгать әһелләре белән. 1995 ел.*



*Татарстанның халык шагыйре исеме алгач. Минтимер Шәймиев һәм Фәнис Яруллин. 2001 ел.*



*Фәнис Яруллинның хатыны Нурсия ханым Хәсәнова-Яруллина. 1998 ел.*



*Фәнис Яруллин «Татнефть» генераль директоры Ринат Галиев белән. 1995 ел.*

Рифат
Сверигин

# ФАТИХ ХӨСНИ ФЕНОМЕНЫ

Фатих Хөсни һәм ... феномен—килеп чыгышлары ягыннан карасаң, бу ике төшенчә яисә күренеш—икесе ике җирлектән, хәтта бер-берсеннән бик еракта торучы җирлекләрдән. Фатих Хөсни—гомере буена халкыбызның күркәм сыйфатларына, гадәтләренә дан җырлаган, бигрәк тә аның гади һәм тыйнак кешеләренә, татар авылына сокланып бик күп матур иҗат әсәрләр иткән, танылган әдип. Үз-үзен татар кешесе дип санаучы һәркем өчен бу иҗат бик кадерле һәм якын булып санала, аның китаплары күпләребезнең киштәләрендә тора. Дөресрәге, алар шунда кунарга гына кайталар, чөнки бу китаплар гел әйләнештә, гел укылып, хәтта кат-кат укылып кулдан-кулга йөреп торалар.



Күңелебез түренә оялаган Фатих Хөсни исеме һәм дөнья сүзлегеннән килеп кергән, татар кешесе колагына бераз ятрак булса да, тирән мәгънәле «феномен» сүзе арасында бик тыгыз бәйләнеш бар. «Феномен» төшенчәсе колагыбызга бик тә ятышлы «могҗиза» сүзенә якын тора, шулай да алар бер-берсенә тәңгәл үк килеп тә бетмиләр: беренчесен аерым өлкәләрдә, шул исәптән әдәбият-сәнгатьтә куллану уңайрак тоелса, икенчесе—»могҗиза» дигәне гаять киң кулланышта йөри, хәтта әкиятләр-риваятьләр аша әле дөньяга күзләре яңа гына ачылып килүче балачагаларга тикле килеп җитә.

Шуларның барын да истә тотып, без бу урында «Фатих Хөснинең иҗат могҗизасы» дип үк авыз ачарга җөрьәт итмибез, әмма «феномен» дигәне ошбу әдипкә бик тә туры килә дип саныйбыз.

«Фатих Хөсни иҗатын өйрәнәм, тикшерәм, аңлатып бирәм» дип каләм кыштырдатучылар очраштыргалап торсалар да, бу зур әдәби кыйтга яисә материк бүгенге көндә ачылмаган килеш кала бирә. Әдипнең тәҗрибәләрен, ачышларын, сабакларын өйрәнмәү, белмәү, санга сукмауның ачы нәтиҗәләре еллар үткән саен үзен ачыграк сиздерә бара. Бу хәл бүгенге көндә яшь язучыларның иҗади рухи байлыкларга салкын, битараф мөнәсәбәтендә дә, тел күренешләренә, аның нечкәлекләренә, күп һәм күчерелмә мәгънәле образлыгын аңлап житкермәүдә дә, мин-минлекне иң алгы планга куеп, төрле стиль «шаккатаризм»нары белән шөгыльләнүдә дә ачык күренә.

Бүген мәхәббәт турында әсәр язмаган каләмчене очрату кыен. Тема бик отышлы һәм укучы игътибарын тәгаен җәлеп итәчәк дип санала. Бу турыда

ничек язсаң да, укучы күңеленә барыл җитеп була дип уйлыйлар. Ә Фатих Хөсни кешелекнең, шул исәптән әдәбият-сәнгатьнең шушы мәңгелек темасын изге өлкә, гүзәллек, яхшылык чыганагы итеп күрсәтә һәм тасвирлый алды. Ничәмә-ничә буыннар аның «Йөзек кашы» әсәрен укып үстеләр, үз-үзләрен шундагы Вәсилә, Айдар кебек бер халәттә тойдылар, яхшыны яманнан аердылар, хыянәт һәм сафлык, яхшылык һәм явызлыкның нәрсә икәнлеге хакында уйландылар. Тора-бара нәни генә бу повестьның исеме әдәбиятыбызның гүзәл символына әверелде.

Фатих Хөсни бер карашка бик тә гади, гадәти булып тоелган тормыш күренешләреннән дә ямь-ләззәт табып яши белә иде. Әлбәттә, мондый халәт, тормышны, кешеләрне ярату сәләте, иң беренче нәүбәттә, мәхәббәт дигән серле дөнья образлары аша гәүдәләндерелде.

Фатих Хөсни бөтен иҗат гомере буена мәхәббәт җырчысы булып калды. Геройларының да кемлеге, кешелек сыйфатлары еш кына мәхәббәт аша ачылды. Мәхәббәт драматизмы әдипнең кайбер әсәрләрендә үтә кискенләштереп бирелде («Йөзек кашы», «Авыл өстендә йолдызлар», «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» һ. б.) Мондый әсәрләрдә хәлиткеч мизгелләрдә, узгынчы хисләргә бирелеп, кирәкмәгән адымнар ясап, үз бәхетләрен үз куллары белән җимерүчеләр дә очрап куя. Кыскасы, автор тормышны бөтен катлаулылыгында, ничек бар, шулай сурәтләү тарафдары иде. Әмма бу хәл һич тә үз карашларыннан чигенү яисә ваз кичү дигәнне аңлатмый, мәхәббәтне дә ул кешеләрне, бу очракта үзенең геройларының яшәешләрен сафландырып торучы көч дип саный.

Аның әсәрләрендә мәхәббәт тормыш тантанасы, яшәү шатлыгының бер өлеше буларак гәүдәләнә. Табигатьнең уянуы, яз матурлыгы хисләрнең бөреләнүе белән үзара үрелә. Мәхәббәтнең мәңгелеге иксез-чиксез тормыш тантанасына мәдхия булып ишетелә. Язучы әдәбиятыбызны мөлаем һәм күркәм хатын-кызлар образлары белән баетты. Йөрәк җылысы белән сугарылган, тиз арада укучыларның да күңел түрләренә кереп урнашырдай мондый гүзәл фигуралар бик күп: «Йөзек кашы» әсәрендәге Вәсилә, «Җәй башы»ндагы Мөнирә, тагын Тәзкирә («Авыл өстендә йолдызлар»), Зәйтүнә («Җәяүле кеше сукмагы»), Нажия, Гайния («Утызынчы ел»), Гыйльмениса (шул исемдәге повестьтагы) кебекләр Фатих Хөсни әсәрләренә матур лирик ямь өстәделәр.

Хатын-кыз образларында авторның поэтик сурәтләр, хисси төсмерләр белән эш итә белүе аеруча ачык күренде, героиняларның күңел дөньяларын сурәтләүгә аеруча әһәмият бирелде. Шушы урында язучы тудырган ике генә образга мөрәҗәгать итеп китик. «Җәяүле кеше сукмагы» романындагы яшь кыз Зәйтүнәнең күңелендә хисләрнең ташыган чагы. Биредә Сәфәргалигә кияүгә чыгып, бергәләп гомер кичерү турында эчке ләззәтләнү дә, әйләнә-тирәдә аның язмышына кагылышлы ниндидер нәрсә әзерләнүен уйлап шомлану да, туып-үскән өендә үзен ничектер артык кашык итеп тоя башлавы да—бөтенесе катлаулы рәвештә бергә аралаша. Зәйтүнәнең киләчәге шомлы һәм караңгы. Аны үзе яратмаган, теләмәгән кешегә кияүгә бирәләр. Әмма әлегә билгесез һәм драматик вакыйгалар алдында яшь кыз күңеленең очынып җилкенүе генә күрсәтелә. Героиняның бәхетле төше дә әнә шул булачак вакыйгаларга контраст булып тоела.

Ф. Хөсни ярым тоннар, катлаулы лирик, психологик бизәкләр ярдәмендә күңелнең иң нечкә тибрәнүләрен дә тасвирлый белә. Зәйтүнә образында нәкъ әнә шундый катлаулы хисләр гаммасы сурәтләнә. Язучы хис-кичерешләрнең әле яңа туып кына килүенә, әлегә тиешенчә ачыкланып җитмәвенә дә ишарә итә. Бу типтагы геройларның сурәтләнешенә фольклор элементлары, лирик бизәкләр килеп керүе дә бик табигый. Зәйтүнә менә ничек тасвирлана: «болында төшеп калган каз каурые»; «терекөмеш тамчысы кебек тәгәрәп эшләп йөри»; «нечкә бил»; «агач ботагына килеп кунган кош

кебек күренә иде»; «Тын урман күле кебек тыйнак табигатьле кыз».

Ф. Хөсни әсәрләрендә кияүгә бирү, туй йолалары күренешләре искиткеч төгәллек һәм этнографик бизәкләр белән сурәтләнә. Язучы мондый картиналарны бик төгәл һәм тәэсирле тасвирлый.

Мәгълүм ки, «феномен» дигән сүз кабатланмастай, үзенә бер хасиятле, ягъни уникаль күренешне күз алдында тота. Бәлки бу урында бәхәскә керергә торучылар да табылыр. Чыннан да, яшьлекләре, мәхәббәтләре, хыяллары патриархаль гадәтләр тарафыннан җәберләнгән, кимсетелгән кешеләр—татар хатын-кызлары образлары М. Гафури, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал иҗатларында да чагылды. Әмма Ф. Хөсни аларның берсен дә кабатлау юлына басмый. Ул үзе яраткан, әйтергә кирәк, үзе мөкиббән киткән татар кызы, татар сылуы образын каләме кәгазьгә төшерерлек нинди бизәкләр таба алса, шуларның барысын да кушып, күңел җылысын бик тә мулдан салып, үзенчә тасвирлауга ирешә. Аның Зәйтүнәсе теге татар кызларының ачы язмышларын уртаклашырга теләми—яңа социаль шартларда, яңа чынбарлыкта тураеп, аягына торып басарга үзендә көч таба. Барыннан да бигрәк, ул хисләренең байлыгы, күңеленең сафлыгы белән хәтердә кала.

«Гыйльмениса» повестеның үзәгенә дә татар хатын-кызының язмышы куелган иде. Гыйльмениса—озын, катлаулы гомер кичергән, олы хисле, тормышның иң кыен сынаулары аша намуслы үтә белгән, нык ихтыярлы кеше. Тормышта да еш булганынча, әдипнең геройлары шактый авыр хәлләрдә калгалыйлар. Андый хәлләр, андый сынаулар нечкә күңелле, саф рухлы, тирәннән уйлап кичерә, хис итүче кешеләр өчен бермә-бер авыр. Ф. Хөсни геройларының бик күбесе—әнә шундый эмоциональ типтагы, күңелләре тиз яраланучан кешеләр. Аларның рухи драматизмы да шуннан килә торгандыр. «Гыйльмениса» повестенда әнә шундый кыенлыклар эчендә хатын-кыз тора. Бу әсәрдә дә тигез мәхәббәт идеаллаштырыла, һәм ул тантана итә, һәртөрле социаль һәм башка төрле чикләүләрдән өстен чыга.

Язучының милли характер иҗат итү юнәлешендәге эзләнүләре аеруча кызыклы иде. Бу—билгеле бер типтагы характер сыйфатларын үзенә җыйган геройда, дөресрәге, аның образ-моделендә күренде. Әйе, бу әдипнең уйлап чыгарылган геройлары төрле исемнәр астында бер әсәреннән икенчесенә күчкәләп тә йөрде. Әмма бу хәл һич тә авторның вариантлары яисә фантазиясе чикләнгәнлеге хакында түгел, ә иҗади карашларының эзлекле һәм үзе принципиаль дип санаган төп юнәлешендә үстерелеше турында сөйли икән. Бу эзләнүләрен ул кешелеклелек һәм гражданлык сыйфатларын үзенә туплаган колоритлы халыкчан герой проблемасы белән дә бәйли алды. «Гармунчы», «Йөзек кашы», «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», «Авыл өстендә йолдызлар», «Минем тәрәзәләрем», «Язмыш шуклыгы» әсәрләренең һәркайсында Ф. Хөснинең геройлары төрле социаль шартларда куелып сурәтләнсәләр дә, нигездә үзләренең төп характер сыйфатларына тугры калалар.

Фатих Хөсни иҗатына гына хас бу типлар өчен жанр чикләре киртә була алмый, ул гына да түгел, язучы жанр һәм стиль чараларын нигездә бер максатка—әнә шул милли геройны тулырак һәм үтемлерәк тасвирлау максатына җигә. Әлбәттә, ул үз-үзен кабатламый—һәр очракта диярлек образны иҗат итүнең янадан-яңа ысулларын таба.

Безнең алдыбызда—авылда туып, шунда күзләре ачылып, бик яшьтән кешеләр белән аралашып, эшләргә өйрәнеп, эшкә ияләнеп үскән кеше. Һәртөрле каршылыклар, кыенлыклар белән ул бик яшьтән очраша, әмма ул аларны җиңә белә, һичкайчан коелып төшми, теләсә нинди шартларда да, аптырап калмый, үз максатларына барышлый читкә тайпылмый, теләгәненә ирешергә тырыша. Ул—һәрвакыт хәрәкәттә, тормыш ташкынының уртасында. Шук һәм җор табигате, уен-көлке яратуы, киң күңеллелеге, башкаларга үпкә-ачу саклый белмәве аңарга карата гел ихтирам уята.

«Гармунчы», «Йөзек кашы» повестьларында барлыкка килгән, дөньяга «романтика болыты аша карый торган» мондыйларның хәрәкәт сферасы сонрак социаль-гражданлык янгырашлы «Жәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» романнарында, «Авыл өстендә йолдызлар», «Гыйльмениса» повестьларында тагын да киңәя төште. Хәзер бу әсәрләр идея-проблематикасы буенча тәмамланган бербөтен, бер цикл, авторның әдәби-ижтимагый карашларының билгеле бер төзек системасын тәшкил итә. Аларның барысын бергә җыеп, янәшә куеп карасаң, гади татар крестьяннарыннан булган язучы сайлаган мәгълүм типның төрле ижтимагый-социаль чорлар аша үтеп үзгәрүен күз алдына китерергә мөмкин. Ул «Йөзек кашы» һәм «Жәяүле кеше сукмагы» әсәрләрендә революциягә кадәрге татар авылы шартларында күрсәтелсә, «Утызынчы ел» романында колхозлашу елларында үсеп килүче яшь буын, «Жәй башы» һәм «Авыл өстендә йолдызлар»да сугыштан соңгы еллар авылынын яшьләре вәкиле итеп бирелә. Бу әсәрләрнең барысында да яшьлек, мәхәббәт, бәхет кебек мәңгелек темалар геройлар яшәеше, эволюциясе белән бик тыгыз үрелеп бара.

Әдәбиятыбызда геройларның билгеле бер тотрыклы рухи сыйфатларын бу кадәрле җырлаган, эзлекле данлаган башка берәр язучыны табу кыен эш булыр иде. Инде әдипнең житлеккән чорында иҗат ителгән күләмле ике романы да шушы фикерне раслап тора. «Жәяүле кеше сукмагы» романы Ф. Хәсни иҗатында аеруча зур адым, татар әдәбиятының олы казанышы дип бик хаклы рәвештә үз вакытында билгеләп үтелде. Әсәр композицион төзеклеге, сюжетының җыйнаклыгы белән дә бик күпләрне сокландырды. Әдип сайлаган композицион алым да уңышлы иде. Әсәр дәвамында герой төрле урыннарга күчеп йөри, бик күп кешеләр белән очраша, шул очрашулар тезмәсе аша укучыга төрле тормыш хәлләре, чуар социаль катламнар һәм аларның кызыклы, характерлы вәкилләре күрсәтелә. Ә геройның үзендә барган эчке көрәш, эчке каршылыкларның муллыгы Сәфәргали образын тормышчан итте.

Фатих Хәсни әсәрләренең характерлы якларын бик күп күрсәтеп булыр иде. Әмма бу мәкаләбездә без әлеге иҗатка тулы анализ ясау, хәтта әдәби күзәтү ясап чыгу максатын да куймадык. Без әдип иҗатының иң кыйммәтле һәм әдипнең үзен бөекләр дәрәҗәсенә күтәрелергә ярдәм иткән кайбер сыйфатларга яисә факторларга гына тукталып китәргә уйлыйбыз.

Иҗатын бәяләүчеләр хаклы рәвештә, аның олылыгын иң беренче нәүбәттә милләт җанлы булуында, милли характерда, милли рухта язылган әсәрләрдә күрделәр. Әмма бу урында әдипнең үзенчәлекле иҗатына кагылышлы тагын бер бик әһәмиятле факторны онытырга ярамый торгандыр. Чөнки Фатих Хәсни аерым бер милләт кысаларына гына сыйган яисә чикләнгән әдип түгел иде. Ул бервакытта да үзенең гомумкешелек яисә аерым халыклар тудырган мәдәни байлыкларга сокланып яшәвен яшермәде. Менә шуңа күрә дә аның иҗатына дөнья һәм Россия халыклары тормышындагы вакыйгалар-сюжетлар, геройлар, образ- характерлар, сурәтләр чит-ят түгел иде. («Рубенс», «Кеше күтәрелә», «Күләгә» һ.б. лар.) Әдип үзен бөек илнең—Советлар Союзының мәгърур улы дип санады. Шуңа күрә дә ул олы идеяләрне, шул исәптән, ватанпәрвәрлекне дә яклап чыкты. Гади кешеләрне тормышчан табигыйлекләрендә сурәтләү, андыйларның романтик рухларына соклану мотивлары әдипнең Ватан сугышы чорында язылган хикәяләренә дә үтеп керде. Аеруча кыен шартларда да кешенең үз характер сыйфатларын саклап кала белү сәләте, гуманистлыгы, патриотлыгы, мәхәббәтенә, намусына тугрылык саклавы сугыш чорында әдипнең төп темаларыннан иде. «Даһи Сталин гына илебезне җиңүгә алып килде» дип рәсми пропаганда сафсата такрарлаган елларда да әдипнең: «җиңүнең чыганагы—миллионнарча гадиләрнең фидакарьлеге, үз-үзләрен аямыйча утка керүләрендә иде» дип раслап торуын әдипнең гражданлык кыюлыгы димичә, ни дисен?

Җиңү шатлыгы миллионлаган язмышларның ачы фаҗигасе белән аралашты. Совет халкының рухи ныклыгы, какшамас бердәмлеге күнел яралары, югалтулар, йөрәк яргыч фаҗигаләр фонында тагын да калкурак гәүдәләнде. Сугыш беткәч иҗат ителгән әсәрләрдән «Кеше язмышы» хикәясе (М. Шолохов) «Торналар оча», «Солдат турында баллада» (режиссерлары М. Калатозов һәм Г.Чукрай) кебек кинофильмнар тирән психологизм белән сугарылып, сугыш чорындагы кеше характерының иң катлаулы яклары зурайткыч пыяла аша күрсәткәндәй ачык тасвирланды. Әлбәттә, мондый әсәрләр сугыш беткәнгә 10-12 ел узгач, заманалар үзгәреп киткәч кенә дөнья күрә алдылар. Әмма мондый психологизмның байтак күренешләре татар әдәбиятында, аерым алганда Ф. Хөсни һәм Ә. Еники иҗатларында инде сугыш вакытында ук, яисә ул тәмамлануга бер-ике ел үтүгә, чагылган иде инде.

Ф. Хөсни иҗатында яшәү шатлыгы, тормыш язы, мәхәббәт темалары аеруча бер көч белән үлемгә, сугыш дәһшәтенә контраст рәвешендә янгырадылар, кешеләрнең шул чордагы нечкәргән тойгылары, кичерешләре янадан-яна бизәкләргә баедылар. Яз темасы сугыш чоры хикәяләрендә тагын да тирәнрәк мәгънәгә ия булды.

«Буранлы кыш дулап узып китте...—дип башлана «Карлыгач» (1945) исемле хикәя.—Тәрәзә төбендә апрель гөрелдәп тора, ана күнегеп беттек инде, хәзер майны көтәбез». Тоташтан лирик нурларга коендырылган кечкенә хикәянең һәр юлыннан шатлык, олы мәгънә, озак көтелгән Җиңү язы килеп җитүенә сөенеч бөркелеп тора. Карлыгач сурәте яз, шатлык, җиңү хәбәрчесе буларак гәүдәләнә. Традицион сурәт яңа лирик, романтик бизәкләр кушып җанландырыла. Сугыш еллары хикәяләрендә гади кешеләрнең язмышлары ил-ватан язмышы белән бәйләнештә бирелә, геройларның үзләренә әнә шул яшәү белән үлем арасында барган каты бәрелешнең шомы, шәүләсе төшеп тора, аларның һәр эш-хәрәкәтләре, уй-кичерешләре Ватан сугышы янәшәсендә яңа лирик-эмоциональ төсмер ала.

Гомумән, Ф. Хөснинең язучылык адымнарын ил язмышы, ил үсеше, ил тарихының төрле, катлаулы, драматик һәм фаҗигале этаплары янәшәлегендә карап, күзәтеп һәм өйрәнеп була. Моның шулай икәнлеген—ил сулышы һәм яшәешенең татар җирлегендә ничек тулы чагылганлыгын—беренче әсәре мисалында да раслап булыр иде. Мәсәлән, «Минем тәрәзәләрем», «Бертуган Таһировлар», «Утызынчы ел» һ. б.

Фатих Хөсни феноменының бик әһәмиятле ягы—ул әдәби осталыкка мөнәсәбәт. Бу турыда әдипнең үз әсәрләре сөйләп тора. Әмма язучының теоретик карашларын да онытмыйк—ул үзе югары әдәби техникага ирешүнең ысулларын, серләрен һәрьяклап ачарга, пропагандаларга кирәк дип санады. Әдәбият-сәнгать өлкәсендә нечкә зәвыклылык, эстетик гүзәллекне сиземләү зарурилыгын, психологик нюанслар, телнең метафоралылыгы аның күчерелмә мәгънәлелегенең табигате—боларның һәркайсының гаҗәеп бер рәвешкә кереп, гармонияле формада үзара ярашырга тиешле икәнлеген әдип үзенең теоретик мәкаләләренең тупланмалары рәвешендәге җыентыкларында язып, яктыртып, даими әйтә килде: «Уйланулар», «Ни әйтергә, ничек әйтергә», «Карурманга керәм». Шулай ук аның теоретик мәкаләләре Татарстан һәм Бөтенсоюз матбугатында төрле дискуссияләргә, әдәби бәхәсләргә сәбәпче дә булдылар.

Психологик нюанслар дип сүз әйткәч, монысын аз гына аңлатып та китик. Гадәттә, әдәби әсәр белән танышканда, укучы моны үзе дә сизмичә, герой һәм аның кичерешләре белән үзен һәм үз халәтен янәшә куеп, чагыштырып утыручан була—ягъни, икенче төрле әйткәндә, кеше әсәрдә үзен күрергә тырыша. Әгәр дә геройның хисләре, тормышны аңлавы, уй-фикерләре, күнеле, кичерешләре белән укучы арасында нинди дә булса якынлык яисә охшашлык бар икән, андый әсәрләр һәм шундагы геройлар, персонажлар укучыга да якын, һәм хәтта үрнәк булып әверелергә мөмкин. Ф. Хөсни әнә шул психологик үзенчәлекне искә ала, әдәби геройны укучыларының төп массасына

якынлаштыра белә, иң гади, тормыш-көнкүрештә һәркем очратырлык кешеләрдән әдәби образ ясап, аларның рухи дөньяларын ачып керә. Автор куллана торган күп төрле сәнгатьчә чаралар да герой белән укучы арасында якынлык, авваздашлык булдыруга хезмәт итә. Шундый чаралардан берсе— мәсәлән, көнкүреш детальләрен, вакыйгалар яки ситуацияләрне нәкъ тормыштагыча итеп күз алдына бастыру.

Мәгълүм ки, әдәби персонажларга, геройларга авторның билгеле бер карашы, мөнәсәбәте була. Алар аша идея-тенденцияләр төрле рәвештә, төрле формаларда чагылдырыла. Кайбер язучыларның әсәрләрендә авторның персонажларга мөнәсәбәте бигүк күзгә ташланып тормый (мәсәлән, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, И. Гази, Ә. Еники әсәрләрендә). Авторлар каядыр читтә, вакыйгаларга битараф хәлдә генә карап торалар кебек. Мондый алым әсәрнең идеясен ачуда геройларга төшкән йөкләмәне бик нык арттыра. Язучы расларга теләгән төп фикер яисә идея геройларның үз эшләреннән-хәрәкәтләреннән яки вакыйгалар агышыннан килеп чыгарга тиеш була. Ә менә Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хәсни әсәрләрендәге геройларга авторларның җылы яки салкын карашлары, симпатия, антипатияләре яшерелмичә, ачык булып, әллә каян сизелеп тора. Бу хәл бигрәк тә Ф. Хәсни стиленә хас: ул һәрвакыт вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен белдерергә ашыга, яраткан геройларына бәхет һәм уңышлар тели, кешелек сыйфатларын югалтучыларны күреп ачына, нәфрәтләнә. Мондый урыннарда риторик эндәшләр, сораулар, укучының үзенә турыдан-туры мөрәҗәгать итү, лирик чигенешләр—болар барысы да әсәрнең эчке пафосын, психологик палитрасын көчәйтә.

Һәр әдәби әсәр, күп төрле мәгълүм функцияләр башкару белән бергә, кешеләрдә гүзәллек тойгысын да тәрбияли. «Укучы китаптан нинди дә булса яңа эстетик ләззәт таба алдымы? Китап аңарга моңарчы бер җирдә дә, һәм бер китаптан да ала алмаган яңа шатлык, чак кына булса да, яңа бер куаныч китердеме?» *(Ф. Хәсни, Уйланулар. К., 1961, 184 бит).*

Иҗат процессының катлаулылыгы һәм үтә үзенчәлекле булуы турындагы фикерләре белән уртаклашып, ул иҗади эштә тагын шәхси канәгатьләнү һәм рәхәтлек хисе дә булырга тиеш, бу рухи шатлык языла торган әсәрне җылытачак, укучы һәм тамашачыны сөендерәчәк, дип саный.

Ф. Хәсни әдәби тәнкыйтьнең чире—әдәби әсәрнең үзенчәлекле эстетик ягын игътибарга алмыйча, темасы һәм идеясе буенча гына анализлауның—аянычлы нәтиҗәләргә китерүе турында гел әйтә килде: «...язучының кайда аксавын тәнкыйтьчедән бүтән тагын кем әйтсен? Ләкин тәнкыйтьче моны «чалып ташлыйм мин сине» дип дәррәү куркытып түгел, ә тегенең аксамыйча баруы өчен җаны-тәне белән кайгырып, әсәрнең әдәби сферасына язучының үзеннән дә болайрак тирәнгә үтеп, теле һәм рухы ягыннан тоеп, иң әһәмиятлесе—белеп, профессиональ осталык белән төзәтергә тиеш» (шунда ук).

Әдипнең үзенең эстетик дөньясы гүзәл һәм катлаулы. Дөресен әйткәндә, аның серләрен бер мәкаләдә генә ачарга мөмкин дә түгел. Бу—лиризм белән тулган шигъри һәм романтик дөнья. Аның прозасы да гадәти түгел, ә шигъри проза. Әдипнең замандашы Сибгат Хәким «бәлки проза, гомумән, шулай булырга тиештер,—дип язды.—Кайчагында проза белән поэзия икесе бергә шундый нык үрелә, аларны аеру читен, син жанр турында бөтенләй онытасың. «Йөзек кашы», «Җәяүле кеше сукмагы», «Авыл өстендә йолдызлар»... Минем колакка алар җыр булып та, лирик шигырь яки романтик поэма булып та ишетеләләр». *(С. Хәким. Прозаикмы, шагыйрьме? Соц. Татарстан, 1968, 3 февраль.)*

Ф. Хәсни иҗатындагы телнең метафорик байлыгы, лирик детальләрнең муллыгы, сүзнең тирән мәгънәлелеге, чыннан да, поэзиянең иң матур үрнәкләрен хәтерләтә. Аның романтикасының нигезендә яшәү шатлыгы, мөнәсәбәтләр гармониясе һәм, барыннан да бигрәк, кешеләрне олылау, ана

соклану мотивлары ята.

Табигать күренешләре күп очракларда гаҗәеп матур сурәтләр, акварель картинасындагыдай чиста, саф, ачык буяуларны хәтерләткән төсләр аша бирелә. Бу мөнәсәбәттә әдипне шагыйрь дип кенә түгел, рәссам дип атарга да мөмкин. Менә бер генә үрнәк:

«Тузан әле кузгалып өлгермәгән, бакча киртәләрендә аксыл чык ялтырый. Яңа Сала авылы өстендә ак мамык төсле томан аунап калды, тирә-якта тынлык, һава шундый чиста, атка бер сызгырып җибәрсәң, скрипка кылына чиерткән кебек, әллә кайларга чаклы яңгырап китә».

Әдипнең деталь белән эш итү осталыгы махсус һәм җентекләп өйрәнүне сорый. Аны бу юнәлештә мәшһүр Чехов традицияләрен дәвам иттерүче дип тә санап булыр иде. Әмма милли җирлектә ул Чеховның яңа якларын да үстерде. Характерларның, вакыйгаларның җанлы, тормышчан ышандыру көченә ирешүдә, яисә тормыш дөреслеге иллюзиясе тудыруда зур уңышлар казанды.

Әдипнең хикәягә, новеллага бөтен иҗат гомере дәвамында тугры калуы— үзе генә дә Фатих Хөсни феноменының бер билгесе булып саналырга хаклы. Укучыга нииндидер бер интимрәк дип әйтикме, якын дуска эндәшкәндәй мөрәҗәгать итеп, әңгәмәгә чакыру, аерым бер тормышчан деталь тирәсендә сүз уйнату барышында хикәянең тиешле тоны билгеле. Кайбер очракларда деталь кинәт яктырып, балкып, күренеп кенә ала. А. П. Чехов эзеннән барып, әдип күп сыйдырышлы детальләрне дә эшкә җигә. Болардан тыш әсәрләрдә һәртөрле көнкүреш, лирик, юмористик, пейзаж, портрет детальләренә дә урын бирелә. Әдипнең иҗат серләренең ачкычларын шушы тарафлардан эзләргә кирәк.

Язучының әдәби форма өлкәсендәге эзләнүләре дә нәтиҗәсез калмады. Остазның казанышлары белән бәйләнгән традицияләр бүген яңа шартларда уңышлы дәвам иттерелә. Минем өчен, әдәби сүзнең тирән мәгънәлелегенә омтылу, аның метафорик, күчерелмә, ә кайсыбер очракларда кинаяле яңгырашлы вариантларыннан файдалану, әдәби деталь мөмкинлекләренә актив мөрәҗәгать итү үрнәкләрен без хәзерге прозаикларыбыз иҗатларында да очратабыз. Мәсәлән, Мәгъсүм Хуҗин, Миргазиян Юныс, Айдар Хәлим, Рабит Батулла, Камил Кәримов һ. б. лар.

«Фатих Хөсни феномены» турында сүз йөрткәндә иҗатның үтә дә үзенчәлекле, билгеле бер романтик шартлылыкка нигезләнгән дөнья икәнлеген дә искә алырга кирәк була торгандыр. Күпме генә эзләнсәм дә, милли әдәбиятыбызда бу әдипкә якын торучы, дөньяга карашлары яисә иҗаты белән аны хәтерләткән бүтән иҗатчыны таба алмадым. Инде әдәби процесстагы урынына килгәндә, бәлки аның урынын рус әдәбиятындагы Юрий Олеша, Исаак Бабель, Александр Грин, Андрей Платонов урыннары белән чагыштырырга яисә янәшә куярга мөмкиндер... Алар кебек үк Ф. Хөсни дә әдәбиятта үз мәйданын һәм иҗат йөзен озак еллар буена искиткеч бер эзлеклелек белән яулаган әдип. Шуңа күрә бу иҗади байлыкны өйрәнү, барлау аеруча төгәллек, зәвык һәм саклык сорый.

Тәлгат
Галиуллин

# РУХ БӨЕКЛЕГЕ

Шагыйрь, прозаик, рәссам якташым Г.Сәгыйров турында язу нияте күнелемдә күптәннән яшәсә дә, каләмгә алынырга сәбәбе чыкмый торды. Ләкин теләк булганда форсат табыла, диләр. Баксаң, ул житлеккән чорына, житмешенә якынлашып килә икән. Шуны да истә тотып булса кирәк, Татарстан китап нәшрияты 2006 елда чордашымның барлык язганнарын диярлек, хәтта иң жете рәсемнәрен дә туплап, "Йөрәк сере" исемле тулы мәжмугасын бастырып чыгарды. Җыентык язучының ижат юнәлеше, эзләнүләр киеренкелеге, шәхси үзенчәлекләре, үсеш авырлыклары турында житди сөйләшергә мөмкинлек бирә.

...2007 елның июнь азагында Нурлат районының Яңа Әлмәт урта мәктәбен 50 ел элек тәмамлаучыларның очрашуы булды. Тантананы оештыручы шул уку йортында белем алган, хәзер Мәскәү метросын төзүчеләрнең берсе, эшкуар Азат Вәлиев иде. Мәктәпкә, укытучыларына, сабакташларына кыйммәтле һәм истәлекле бүләкләр алып кайту өстенә, гармунда үзе уйнап, үзе жырлаган, сикереп чыгып биюгә дә оста булган Габбас абый улы үзенең һәм шәриктәшләренең күнелен күргән мәлдә, мин шыпырт кына мәктәп китапханәсенә юл тоттым. "Акыл мәгарәсенә" аяк баскан язучы халкының нияте гади инде аның: китапханәгездә ничә китап бар, гәзит-журналлар вакытында килеп житәме, яшьләр классикларыбызны укыйлармы? Шул ук вакытта ул күзләре белән шүрлектән үз әсәрләрен эзли. "Сәет Сакманов" исемле роман-трилогиямне мәктәпкә бүләк иткәч, хужа ханым, мина артык тыныч тоелган тавыш белән: "Безнең мәктәптә" күптән түгел шагыйрь Гакыйль Сәгыйров булып китте, бик матур очрашу үткәрдек, залыбыз шыгрым тулы иде, килгән кешеләрне кочкә-кочкә сыйдырды", дип сискәндереп куймасынмы! Әйтерсең лә, Гакыйль абыйсы күрше авылдан, "Тойота"сында жилдереп кенә килеп киткән. Аяклары йөри, куллары әйбер тота алмаган, гомерен урын өстендә, инвалид арбасында уздырган кеше турында шулай әйтү иң әүвәл сәер тоелса, сонрак, "вәт без нинди, язмышка баш биреп, жебеп тормыйбыз әле", дип татар шигърияте өчен горурлык хисе дә уятты. Күз алдына китерәсез булыр: очрашуга килү өчен Гакыйльгә кемгәдер ялынасы, якыннарының вакытын аласы, шактый озын юлны үтәсе була бит. Әмма аны авырлыклар куркытмаган—килгән, очрашкан, күпме кешенең жанында киләчәккә өмет, яшәүгә мәхәббәт, тормышны ярату рухы тәрбияләп, ижатка дәрт кабызган! Мондый фидакарьлеккә мөкиббән китмичә, сокланмыйча мөмкинме соң?!

Мина нәкъ ун ел элек Г. Сәгыйров белән очрашырга да насыйп булган иде. Карлы-буранлы февраль аенда, ул чордагы премьер-министр урынбасары Илгиз Кәлимуллин Гакыйльнең 60 яше уңаеннан бер төркем язучыны Мәләкәскә (шәһәргә көчләп кушылган Димитровград исемен әйтергә тел әйләнми) алып барган иде. Ерак сәфәргә чыгучылар арасында Г. Ахунов, Р. Фәйзуллин, Р. Мөхәммәдиев кебек каләм осталары булуы хәтердә. Дөрес, татар язучылары, журналистлары вакытлы матбугатта күренә башлауга, Г. Сәгыйровны болай да игътибарсыз калдырмадылар. Үткән гасырның алтмышынчы елларында, хәзер "Чаян" журналының баш мөхәррире Р. Зәкиев "Социалистик Татарстан" газетасында шагыйрьнең шәхесе һәм ижаты белән таныштырган мәкаләсен бастырган иде. 1968 елда А. Расих, Г. Зәйнашева, Роберт Әхмәтжанов һәм Р. Зәкиевләрдән торган төркем Г. Сәгыйров шул чорда яшәгән Фәйзулла (Самара өлкәсе) авылына барып чыгалар. Очрашудан алган тәэсирләре, хисләре белән А. Расих "Ижат уңышлары телибез сина, Гакыйль" исемле мәкаләсендә (хәзерге "Казан утлары", 1969, 1- сан) уртаклаша.

Безнең төркемне дә Г. Сәгыйров ифрат җылы каршылады, барыбызны да танып, исемнәребезне әйтеп, мескенләнмичә, кызгану, ташлама таләп итмичә, уйнап-көлеп сөйләште, арбасы белән сәхнәгә күтәргәч тә, ул үзен иркен тотты. Татарстан хөкүмәтенә, Язучылар берлегенә кайгыртулары өчен рәхмәтен әйтергә дә онытмады. Аның елмаюга әзер йөзе, соры күзләренең көлемсерәү катыш сынаулы карашлары әле һаман хәтердә, күңелдә.

Аерым язмаларда, әдәби җыеннарда исеме телгә алынгаласа да, ул—бүтән чордашлары, каләмдәшләре белән чагыштырганда әдәби тәнкыйть игътибарыннан читтәрәк кала килгән шагыйрь. 2006 елда чыккан "Йөрәк сере" җыентыгындагы яшәү көче бөркеп торган лирик аһәңле, акыллы шигырьләр, романтик рухлы рәсемнәр, тезмә һәм чәчмә юмористик парчалар дөньясында яшәгәндә исә, аларның ничәмә дистә еллар урын өстендә яткан кеше тарафыннан иҗат ителгәнлекләре башыңа да килми! Үзе турында язганда да, язмышына рәнҗеми, үпкәләми шагыйрь. Гап-гади мантыйк буенча да Гакыйль авыруларыннан иза чигүе, ялгызлыктан интегүе турында язарга, табигатьнең үзенә карата күрсәткән мәрхәмәтсезлегеннән, язмыш җәбереннән зарланырга тиеш иде шикелле. Дөрес, "Көрәшергә житми көч-куәтем", "Чынаягым төште, чәлпәрәмә...", "Ник нуры караңгы кояшның..." кебек сагышлы шигырьләрендә аның җан әрнүе үзеннән бәйсез рәвештә диярлек тышка бәреп чыга. Әмма әнә шундый шигырьләрендә дә ул тормыштан яктылык, матурлык, киләчәккә өмет, шәфкать нуры эзли, дошманнарны яхшы якка үзгәртү ("Дошманнарым күп булмасын өчен Әйләндерә барам дусларга"), чәлпәрәмә килгән чынаякны гамәлгә яраклы итү ("ябыштырып куйсак икән бергә!") турында хыяллана. Әйе, бер кеше дә язмышын үзе сайлап алмый. Аллаһ үз колларын туктаусыз сынар, иң яратканнарына кайгы-хәсрәтне күбрәк җибәрер, диләр бит... Авырлыклар басымына чыдар хәле калмаганда, шагыйрь юмор, ироник караш кабырчыгына яшеренә ("Ә язмыш елмаеп көтте, хәйләле күзен кысып"—"Тунлы Мәхәббәт"; "Әтәч өенә йөгергән тиешле сабак алгач"—"Өтек әтәч").

Бәлки ялгышамдыр, әмма көчле рухлы Ф. Яруллин, Г. Сәгыйров кебек чыдам холыклы каһарман шәхесләребез үз дөньяларына бикләнеп, үз борчуларына артык игътибар бирсәләр, татар халкы вакланыр, милләтебез тарихи горурлыгын югалтыр иде кебек. "Ходай үзе биргәч, миңа шундый йөрәк, Дога дип тә җырлар язам, ярый, димәк?!—ди Г. Сәгыйров "Сөю-сөелү турында..." исемле шигырендә. Сүзләрдән "энже" коя белү сәләтен ул югарыдан бирелгән илаһ дип саный, ритмик буыннарны тәсбихка тезә алмаганнарын да рәнҗетми: "Яза белмәгәннәр өчен күкләр яза".

*Кайтарып булмый ла үткәнне,*
*Онытсин—бел, егет, әйткәнне...*
*Ничек мин юк итим*
*Күңелем түрендә*
*Хисләрдән коелган һәйкәлне?..*

Шагыйрьнең бөтен иҗаты үз-үзенә "хисләрдән коелган һәйкәл", дияр идем мин. Тормышны чиксез ярату, аның һәр мизгелен Аллаһ бүләге дип кабул итү әнә шундый хисләр муллыгын тудыра.

Кеше, шагыйрь фикеренчә—табигатьнең таҗы, иң югары казанышы.

*Шөкер әле мин бер чәчәк түгел,*
*Шөкер әле мин бер бөҗәк түгел.*
*Шөкер әле мин бер кош-корт түгел,*
*Шөкер әле мин бер ерткыч түгел.*
*Шөкер әле күкләр тарафыннан*
*Кеше итеп җирдә яратылган.*
("Шөкер әле мин...")

Лирик зат үзенең Кеше булып тууына, Кеше булып яшәвенә сөенеп бетә алмый. Раббыбыз сине кеше итеп яраткан икән, бу бөек исемне кош-кортлар, бөҗәкләр,

ерткычлар дәрәҗәсенә төшермичә, башка җан ияләренә үрнәк булып яши белергә дә тиешсен! Камил инсан турында уйлануларын, фаразларын шагыйрь башка шигырьләрендә дә дәвам иттерә. Мәкаль-әйтемнәрдән, чичән шагыйрь Акмуллалардан ингән хикмәти төгәллеккә омтылып, юлның беренче сүз-тезмәләрен кабатлау—зиһенгә сеңдерү аша төп фикерен төгәл һәм ачык әйтеп бирүгә ирешә:

*Бай булырсың малың белән,*
*Юмарт булсаң җаның белән,*
*Юмарт булсаң малың белән,*
*Бай булырсың җаның белән.*
("Бай булырсың...")

Бу шигырь мисалында Гакыйльнең бөтен иҗатына хас бер үзенчәлекне искәртеп китү мөһим. Һәр шагыйрьнең табигатенә, рухына якын, хисләр ташкынын сыйдырырдай, кайта-кайта үстерә килгән алымнары була; алар Г. Сәгыйровта да бар. Шуларның берсе, еш очраганы—шигырьләрнең мәгънәви җегәрен ачуга буйсынганы—юл башындагы сүзләрне кабатлау, эчке кафия, ягъни анафора ысулы. ("Шөкер әле—шөкер әле", "Бай булырсың—бай булырсың"). «Хәйран калам мин үземә үзем...." шигырендә һәр куплет башында кабатлана килгән "Хәйран калам", "Әй мин, җүләр", "Рәхмәт сиңа" тезмәләре шигырьгә үзенә бер нәзакатьлек, ритмик төзеклек рухы бөркиләр. "Ике чибәр" ("Берсе, берсе), "Бу дөнья бит минсез торган кайчандыр..." ("Бу дөнья бит, бу дөнья бит..."), "Сагыш тулы коңгырт күзләрендә..." ("Сагыш тулы, сагыш тулы") кебек шигырьләрдә анафора алымы шигъри кичереш агышына юнәлеш биреп, фикер-хисне бер җепкә тезеп бара.

Г. Сәгыйров эзләнүләренең янә бер үзенчәлеге (анысы, бәлки, аның рәссамлыгыннан килә торгандыр) бер карауда әһәмиятсез күренгән детальдә мәгънәви борылыш, тирән эчтәлек эзләү. "Куллар" шигыре—шуның ачык мисалы. Кешенең кулы кылган яхшылыкларына яисә тискәре гамәлләренә карап хуҗаларының кем икәнлекләрен, хәтта рухи йөзләрен билгеләүдә ачкыч була ала икән:

*Бар арада көчле куллар, таза куллар,*
*Башсызлыкка бирелеп китеп азган куллар;*
*Озын куллар, кыска куллар, оста куллар,*
*Иптәшенә яшерен яла язган куллар.*
("Куллар").

"Кара айгыр" шигырендә шагыйрь үзәк образ-детальнең мәгънәви офыгын киңәйтү аша гомумиләштерелгән нәтиҗәгә килә: "Һаман әле кешеләрнең тыныч сулыш алган көне юк". Миһербанлылык, ярдәмчеллек, кимсетелгәннәр турында онытмау кебек әдәбиятның үзәк юнәлешен Г. Сәгыйров үзенчә үстерә, яңа шартларда дәвам иттерә, яшәүне бары тик ләззәт алу, башкалардан өстенлеккә ирешү дип уйлауны кабул итми. Акчага, «сары шайтанга» табынган кеше дөньяга аклык, яктылык өстәми һәм башкалар өчен кызыклы шәхес булудан туктый. Шагыйрь үз китабын чыгарышу гозере белән "Бер бай әфәндегә" килә. Тик Сембер бае "балык сыман шома" булып чыга, башкалар белән киңәшү, өенә кайтып уйлап карау вәгъдәсеннән ерак китми. "Китап! Китап диеп", ялынып, түбәнсенеп, соранып йөргән зат үзенең олы халык баласы булуын, аткан уктай сүзенең абруен исенә төшереп, тәүбәгә килә һәм үз биеклегендә кала ала:

*Гомеремдә булмас хәлгә җитеп,*
*Бирештемме җиңәр көчем бетеп?*
*"Китап" диеп сиңа килгән идем,*
*Горур җаным аша үтеп...*
("Тәүбә").

Камил инсан үз халкын, аның яшәү рәвешен ярата белергә, төп байлыгыбыз—

телебезне—киләчәк буынга калдырырга тиеш, ди шагыйрь. Шул дөньяви вазифаларын үти алмаганнардан усал итеп көлү дә аңа килешә. Хис, кичереш үсешенә караганда шагыйрь акыл җебенең эзлекле хәрәкәтенә, рационалистик фикергә, хикмәтле сүзгә өстенлек бирә, йөрәк ярсуын, җан әрнүен афористик юлларга чыгара.

*Яшь буыннар*
*тарта алга—хәрәкәткә,*
*Карт буыннар*
*тарта ялга—караватка.*
("Яшь буыннар").
*"Эссе" дип зарландык кичә,*
*Бүген—салкын,—зарланабыз.*
*Кемгә генә ничек кенә*
*Ярап бетсен бер Аллабыз?..*
*("Эссе дип...")*

Татар шигъриятендә Кол Гали, Кандалый, Тукай, Такташ кебек бөекләребез иҗатыннан юл алган реалистик алымнарның берсе—илһам чыганагын исемгә чыгару. "Әлфиягә", "Гөлфиягә", "Рафиләдән" кебек татар хатын-кызларының күркәм исемнәре белән аталган шигырьләрендә Г. Сәгыйров та бөеклекне, галилекне күктән эзләми, чын матурлыкны якын-тирәдән таба, һәркайсы үз гүзәллеге, үз язмышы белән кадерле, күңелдә уелып калырдай образлар тудыруга ирешә.

*Исеңдәдер әле үсмер еллар,*
*Онытыла белми үткәннәр.*
*Без утырткан нәни ак каеннар*
*Күптән безне узып киткәннәр.*
("Рафиләдән...").

Заманында аңа матур чәчәк бәйләме бүләк итеп, күңелендә өермәле, ялкынлы хисләр дулкыны, онытылмас хисләр уяткан Кызны шагыйрь нәкъ халык җырларындагыча, гомуми бизәкләр ярдәмендә, йөзен гөлләргә, ал таңнарга тиңләп, романтик биеклеккә күтәреп сурәтли:

*Күзләреңә сихри төннәр*
*серлелеге тулган кереп;*
*Алсу йөзең роза гөлләр*
*чәчәк аткан ал таң кебек—...*
("Әлфиягә")

Әмма тышкы чибәрлек һәм ярата белү генә үзеннән-үзе кешене бәхетле итә алмый икән әле. Яшәеше ал да гөл булырга тиешле Гөлфия үзе дә сизмичә, "иренә кол" булып яши, иң авыр вакытта да "ачы яшьләрен" коюдан, елап-сыктап юанудан уза алмый. Кайгы-хәсрәтне, бала мәшәкатен яратмаган иренең балалар үстерү турындагы "хыял-өметенә" киртә куюы аркасында ул ялгызлыкка дучар ителгән.

Кимсетелгән, рәнҗетелгән, тормышы кайсы ягы беләндер китек язмышлы кешеләргә игътибар Г. Сәгыйров иҗатының буеннан-буена сузыла. Битарафлык—аның җан дошманы. Ятим балалар, ярдәмгә мохтаҗ өлкәннәр, гомумән тибәрелгән бәхетсез кешеләр турында ул кайта-кайта, чын гуманист буларак яза.

*Картлар йорты,*
*Чиксез кайгы-хәсрәт тулы*
*Монда эләккән һәрбер җанның*
*Соңгы юлы.*
("Картлар йорты").

Кешенең олы мәңгелектә бер тапкыр бирелә торган гомерен өзүне ул иң зур җинаять дип саный. Шагыйрь Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарны олылап, зурлап искә алса, Чечен сугышы кебек кешене үтерүгә корылган мәгънәсез афәтне каһәрли ("Чечня—18.04.02", "Мәргән кыз", "Сугыштан соң бөтенебез өчен..."). "Этләр сугышы" шигырендә ул явыз кешеләрнең канына сеңгән рәхимсезлекнең психологик нигезләре, "серләре" турында уйлана:

*Мәрхәмәтсез, һич аяусыз микән*
*Кешеләрнең җаны шулкадәр?*
*Ялгышамдыр, бәлки...*
*Талаш... этләр...*
*Акылыннан шашкан адәмнәр...*
("Этләр сугышы").

"Янымa килә бер песи..." исемле сигез юлдан торган парчада ялгызлыктан иза чиккән лирик герой янына песи килеп "мыр да мыр" итеп сырпалана, иркәләнә. Шул күзәтүдән икесенә дә кагылышлы нәтиҗә ясала:

*Минем җаным кебек ул да*
*Назлануга мохтаҗдыр.*

Г. Сәгыйровның иҗат алымы сюжетлы шигырьләрдә, реалистик өслүбтә тулырак ачыла. Дөрес, артык "тормышчан" әсәрләрендә ул материал "каршылыгын" җинә, аны кичереш дулкынына буйсындыра алмый интегә. "Ике чибәр", "Тәбә", "Каршы алган", "Картаймаган" кебек шигырьләрендә, "Әткәй гармуны", "Ул еллар" исемле ярым автобиографик поэмаларында вакыйга колы булу үзен сиздерә. "Дәва юк шул..." дуртьюллылыгында артык акыллы күренергә тырышу исә коры дидактика ярларына алып чыга:

*...Дәва юк шул картлыктан,*
*Килми ул дәва юктан*
*Ул килә—кайчан үзең*
*Аңа ирек бирәсең.*

Әдәби осталык җәһәтеннән чыгып бәяләгәндә, Г.Сәгыйров иҗатына заманчалык, символлар, шигъри кодлар, фәлсәфи тирәнлек, аң төпкеленә "төшү" җитешми, анда барысы да ачык, аңлаешлы дип дәгъва белдереп булыр иде. Әмма аның гаҗәеп сабыр, фидакарь, тормыш ваклыкларыннан өстен, мәрхәмәтле, кешеләргә, табигатькә, җиһанга игелекле лирик каһарманы белән таныша-аралаша торгач, кайбер чатаклыклар турында онытасың.

*—Вакыт нигә гомерләрне*
*утлы мизгелләргә бүлдең?*
*Берсе—шатлык,*
*Берсе—яшәү,*
*Берсе—үлем...*
*Бәлки, менә бу мизгелдә*
*берәү мохтаҗ җылы сүзгә?*
("Тик бер мизгел...")

Шагыйрь "Һәр шигырем уйларымның чыны—Тормыш көзгесенең кыйпылчыгы" дип язса да, ул чынбарлыкны гади күчерә, җирдән "шуышып бара" дигән нәтиҗә ясарга ярамый. "Уйларымның чыны" вакыт һәм ара, яшәү белән үлем, мәңгелек белән мизгел, ялган белән дөреслек кебек катлаулы күренешләргә мөнәсәбәтне дә үзенә сыйдыра.

Табигать ямен, аның кабатланмас бизәкләрен сурәтләгәндә шагыйрь ак төскә

өстенлек бирә. Сафлык, чисталык, рухи матурлык символы булган ак төс күнелләргә нур бөрки. "Кырлар кышны...", "Ак чишмә", "Көзге этюд" шигырьләрендә ак төсне сынландырганда нечкә зәвыклы рәссамның «зиһен уены» сизелә. Беренче шигырьдә кышның талгын матурлыгын сурәтләүдә халык җырларына хас 7-7 үлчәве иң кулае булса, "Ак чишмә"дә җир астыннан көмеш тәнкәләрен сирпеп, биеп килеп чыккан суны сурәтләгәндә йөгерек ритмның алга чыгуы, шигырь юлларын чишмә чыңына яраклаштырып бүлгәләү аклана.

*Тау эче*
*Караңгы,*
*Ул шунда*
*Яралды...*
*Иректә-иркендә*
*Тотынды җырларга*
("Ак чишмә").

Ә мәхәббәт, шагыйрь уенча, пакьлек, гүзәллек, якын кешеңә тугрылык кебек төшенчәләрне эченә ала: "Сафлык кына бирә ала сөю шатлыгының чын ямен" ("Сафлык кына..."). Лирик геройның күңеле бик нәзберек, ул, җан тибрәлешләренә игътибарлы, мәхәббәтнең иң олы илаһи хис икәнлегенә ышанычы мәңгелек аның.

*Күпме еллар агым хәрәкәттә*
*мәңге тынмас Идел төсле без,*
*Мәхәббәттә мең ел яшәсәк тә*
*сүнмәс безнең сөю хисебез.*
*("Бер мизгелгә карт бер карчык булып...")*

"Син эгоист", "Кайвакыт син—тиран: Тик синең үтәлсен теләгең!", Син "тәмуг ялкыны", дип зарлангандай, "мәхәббәтне" әрләгәндәй булса да, шагыйрь бу көчле тартылуны йөрәкнең иң "күркәм тойгысы" дип олылый. Сөеклесен югалткан, татлы хыяллары чәлпәрәмә килгән мизгелләрне искә алу исә аның өчен авыр, газаплы, әрнүле чак:

*Әй, язмыш, нигә син мине*
*бер ялкынсыз яндырасың?*
*Бу җанымны ник һәр көнне*
*Кара кисәү калдырасың?*
("Әй, язмыш...").

Әйе, нинди генә нык ихтыярлы, көчле булмасын, адәм баласы таштан ясалмаган. Башкалар бәхете өчен сөенеп утырганда, аңа үз язмышы, сөю-сөелү бәхетен татып өлгермәве капылт исенә төшә дә, бәхет җылысын боз салкыны кысрыклый:

*Сөю-сөелү дигәннең*
*Назларын алыйм каян?*
*Төннәрендә туңа тәнем,*
*Ялгызлыктан җылый җан.*
("Сөю-сөелү дигәннең...").

Г. Сәгыйров "язарына илһамны" авылы Фәйзулла болыннарыннан, җиләкле аланнарыннан, кендек каны тамган ундырышлы җирдән алса, фәлсәфи тирәнлекне дини-мифологик катламнан эзли. "Мәхәббәт шаукымы", "Нух көймәсе" шигырьләре—шул юнәлешнең ачык үрнәкләре.

Табигый сәләте, фикерләү үзенчәлекләре, хисси дөньясының чакыруы белән шигырьгә тартылып торса да, Г. Сәгыйров чәчмә жанрда да көчен сынап карый. Ул прозасында үзе күргән-белгән, башыннан узган хәлләрне тасвирлауга, документаль

башлангычка, төгәл, кыска җөмләләргә өстенлек бирә. Төрле эчтәлекле язмаларын автор "парчалар" дип атаган. Кечкенә бер вакыйганы, хикмәтне, зиһен уенын, ишек ярыгыннан "күзәтүләрне" эченә алган чәчмә әсәрләре арасында, "Ай тозы", "Кара икмәк", "Бәхетле җан", "Нәрсә килеп чыкты?" кебек әхлакый-тәрбияви максатка буйсынган уңышлылары янында, телдән сөйләнелә торган тәмсез мәзәкләр дәрәҗәсендә генә калган "Танып калган", "Үткен нәрсә", "Бичура" кебекләрнең дә җыентыкта урын алуы аңлашылып бетми.

Бер хастаханәдән икенчесенә күчеп йөрүен, табибларның, шәфкать туташларының үзенә, башка чирлеләргә мөнәсәбәтен, күршесендә яткан авырулар язмышын үзәккә алган "Елавык көннәр хатирәсе" исемле автобиографик язмалар күңелдә уелып кала. Автор чорыбызга бәяне чирлеләр белән аралашу, аларның үз язмышлары турындагы бәяннары аша бирә, рухи халәтебез турында уйлана, нәтиҗә ясый. Бу язмаларында хикәяче психологик анализ алымнарын иркенләп эшкә җигә.

Г. Сәгыйров кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр, әдәп-әхлак кагыйдәләре турында уйлана, аерым алганда, "матурлык" төшенчәсен төрлечә аңлау мәсьәләсенә туктала. Берәүнең өенә килен төшерүен ишеткәч, кешеләр "уңганмы", "акыллымы" дип сорамыйлар, ә "матурмы" дигән сорауны бирәләр икән. Бу халәтне автор үзенчә аңлата. "Матурмы?" дип төпченүнең төп сәбәбе шундадыр: матур кешедән начарлык көтелми, ни өчендер ул уңган да, чибәр дә, ягымлы да, мәрхәмәтле дә булырга тиеш кебек тоела. Чөнки матурлык дөньядагы бөтен яхшылыкны, гүзәллекне үзенә сыйдырган шикелле... «Кешенең эчке матурлыгы тиз генә ачылмый, күңел гүзәллеге, рухи байлыгы соңрак кына беленә".

Авторның янә бер күзәтүе үзенчәлекле. Янәшә ятып дәваланучы Андрей үзенең олы мәхәббәте, өйләнешкәч фатирлы булуларын, балалар үстерүләре, әмма хатыны акчалырак эшкә күчкәч, көйле тормышларының пыран-заран килүен сөйли. Хатынының хыянәте аркасында килеп туган фаҗига турында бик кинәясе килмәсә дә, авыр йөкне инде озак тотып булмагандай, күршесе йөрәк өзгәләнүен үзендә генә калдыра да алмый. Әлеге ирнең бу халәтен автор болай тасвирлый: "Вак-төяк эшләрен алдан тәмамлап, иң кыенына керешергә җөрьәт итә алмыйча аптыраган кеше шикелле, Андрей да банкыдан су салып эчте, миндәрен рәтләп салды".

Хастаханәдән чыккач та кайберәүләрне "олы хәсрәтләр кочак җәеп" каршы ала бит әле. "Яшәү барышында очраган төрле кыенлыкларны, башка төшкән кайгы-хәсрәтләрне җиңү, алардан өстен чыгарга омтылу күп көч таләп итә... Барысын да үзең өзелеп, әрнеп, бәгырең аша, йөрәгең аша үткәрергә кирәктер".

Г. Сәгыйров шигъри эзләнүләрендә реалистик өслүбкә өстенлек бирсә, рәсемнәрендә ул—югарыга, яктылыкка ашкынган, табигатьтә яшәү чыганагы, илаһи матурлык эзләгән романтик. Язучылар төркеме Мәләкәскә сәяхәт кылган көнне Г. Сәгыйровның авызына карандаш кабып, тушька манып ясаган рәсемнәренең тулы күргәзмәсе оештырылган иде. Без аларны могҗиза, гаҗәеп бер тамаша кебек карап йөрдек. Сурәтләрдә—табигать һәм кеше яшәешенең төрле мизгелләре, бер караудa күзгә чалынмый торган төсмер, нюанслар... Аларда рәссам Г. Сәгыйровның сиземләү сәләте, күзәтүчәнлеге таң калдырды.

...Гакыйль Сәгыйров иҗатының киң катлау укучыга артык таныш булмавының мәгълүм сәбәпләре бар. Бердән, ул шигърияткә житез аргамакта килеп кермәде, сонарып басыла башлады. Икенчедән, шагыйрь башкаладагы җанлы әдәби процесста катнашудан мәхрүм, аның шигырьләре-җырлары сәхнәләрдән яңгырап, аларга сүз әйтелә торса, өслүбе чарланыр, җирсү хисләрен, шигъри гайрәтен чагылдыру юлларын төрләндерер иде. Каһарманыбыз Ф. Яруллинныкы кебек янында Нурсия ханымдай олы җанлы ярдәмчесе, кинәшчесе, сөеклесе булса, хисләре кайнап тору өстенә, китаплары да ешрак нәшер ителер иде. Мәгәр, ничек кенә булмасын, татар халкының чыдамлыгына, үҗәтлегенә, талантына үрнәк-мисал булып, милләте, туган теле, киләчәк мәнфәгатьләре турында җан атып яшәүче ерактагы якын кардәшебез—Гакыйль Сәгыйров дигән сынмас-сыгылмас рухлы, батыр шагыйребез бар!

# ИЛЧЕ

Ерак офыклар артында, саф биеклекләргә омтылган таулар арасында күнелне тын гына дәшкән, тинсез рухи байлыклар вәгъдә иткән Мәгараләр... Уйлап баксаң, кеше үз гомеренең аерым мизгелләрендә балачакка-яшьлеккә кайтара алучы тылсымлы дару вәгъдә иткән Мәгараләрен уй-хыялларында үзе генә белгән изге юл-сукмаклар буйлап эзләп китә түгелме?! Һәм шушы хыялый эзләнүләрдән, якты алгысулардан аерым бер мәлдә шигърият тә туадыр, мөгаен.




XX йөзнең сиксәненче елларында әдәбиятка, шигъриятькә килгән, үз буынының иң тынгысыз, сәләтле, уйчан шагыйрьләренең берсе (буындашларын әйдәп баручы шагыйрь, язучы дип тә әйтәләр аны) Ркаил Зәйдулланың нәүбәттәге шигъри китабы бер сүз белән—серле рәвештә «Мәгарә» * дип атала... Китапны укыганда аңлыйсың: юкка түгел икән бу. Чөнки, ошбу серле Мәгарә темасы шигъри мәҗмуганың биш бүлеген дә мәгънәви, фәлсәфи, метафорик тоташтырып тора. Дүрт бүлекнең дә тәүге өлешендә без Мәгарәгә юл тоткан шигъри «мин»нең үзенчәлекле шигъри мажараларын укып үтәбез. Бишенче бүлектә ул, ниһаять, Мәгарәсенә килеп житә һәм аннан үзенең бәхетле, кадерле балачагына кире кайтаручы тылсымлы даруны алып чыга... Игътибар итсәң: кайсыдыр яктан бу шигъри каһарманның символик мажаралары Пауло Коэльоның мәшһүр «Алхимик» романын хәтерләтеп куя...

Шундый сорау туа: ни өчен танылган шагыйрь Ркаил Зәйдулла төрле елларда иҗат ителгән шигырьләрен гомеренең чиста чишмәбашын сагынган ностальгия астында берләштерергә булды икән? Шагыйрь байтак гомер кичереп, тормыш юлы узып, төрле эшгамәлләр кылып Мәгарәгә барып житә—«Үз жаныма төбәлдем бу кичтә, Жаным гүя алтын мәгарә...»—һәм күнелендә янә үткәннәргә әйләнеп кайта... Бәлки, шагыйрь безгә монда гомеренең зур бер арасы, циклы тәмамлануын белдерергә телидер?! Бәлки, ул узылган еллар биеклегеннән үткәннәргә бер караш ташларга омтыладыр, үзе өчен мөһим булган Шигъри Нәтиҗә дә ясарга алгысыйдыр?!

Уйласаң, Мәгарәдә вәгъдә ителгән тылсымлы даруны эзләп табарга ашкыну—гомеренең иң гүзәл чакларын янә кичерергә, янә кабатларга алгысыну—ул кешенең иң кадерле хатирәләре белән, гомеренең иң чиста чаклары белән бергә калырга теләведер. Чөнки, күңел биеклегеннән карасаң, балачак ул—Сафлык Иле, берсеннән-берсе матуррак Хыяллар Галәме, кыскасы, тормышның иң керсезгөнаһсыз, иң матур чагы... Менә ни өчен кеше олыгайган саен, тормыш кырыслыклары һәм катлаулылыклары белән күбрәк очрашкан саен күнелендә аңа ешрак бага.

Яшәеш лабиринтларында үз Мәгарәсен эзләп киткән Ркаил Зәйдулланың шигъри «мин»е дә еллар артында күмелеп калган балачагына, аның иң истәлекле көннәренә еш әйләнеп кайта.

«Мәгарә» китабының беренче бүлеге, гомумән, нәкъ менә шул балачак,

---

Ркаил Зәйдулла. «Мәгарә». Татарстан китап нәшрияты, 2005.

яшүсмерчак дөньясы белән, гомернең чишмәбашын олы Сагыну белән бәйләнгән дә инде. («Өмет», «Хәлвә», «Әби», «Типте тупны шаян малай...», «Авыл малае», «Рәхмәт» һ.б. шигырьләр)... Бу шигырьләрдән олыларның мәшәкатьле тормышында сирәк очраган ниндидер үтә бер табигыйлек, сафлык, жылылык бөркелеп тора төсле!.. Аларда балачак гомернең иң мөкатдәс чагы булып күз алдына баса! Бу якты дөньяда әти-әни дә бар, әби-бабай да исән-сау, офыклардан офыкларга кадәр жиһан түгәрәк, ул шатлык-бәхет өчен генә яратылган булып тоела...

«Төнге рәсем» шигырендә шагыйрь еракта—еллар артында калган кадерле балачагын искә төшереп сагына:

*Хуш исле печән өстендә*
*Малай йокыга талган.*
*Янәшәсеннән баралар*
*Абыйсы да әтисе...*
*Ә дөнья...*
*Дөнья шундый—*
*Дөньяда чәчәк исе.*
*Мәңге онытылмас бу төн.*
*Сахра, йолдызлар, ирек.*
*Нарасый бара арбада,*
*Әнисен төштә күреп.*

Гажәеп гүзәл дә һәм гади дә сурәт ул: чәчәк исен сулап атлап баручы әтисе белән абыйсы, һәм әнисен төшендә күреп арбада татлы йокыга талган саф күңелле малай!.. «Тукта, мизгел!» диясе килә эчкерсез рәвештә. Балачакның асылын әнә шундый гади дә, серле-якты да минутлар тәшкил итә бит!..

Әмма, дөньяга килгән кеше, гомер буе сафлык илендә, ак хыяллар дөньясында кала алмыйдыр ахры?!. Вакыт алга тәгәрәгән саен, фанилык аның күңелендә үзенең тамырларын жибәрергә ашыга. Еллар узгач, кеше телиме-теләмиме, олыларның үзенчәлекле дөньясына атларга мәжбүр.

*Атлар булып томырылды күккә*
*Балачакның ап-ак хыяллары.*

—ди шагыйрь дә уйчан төстә «Булмый елап» шигырендә.

Сорау гына кала: кайчан башланды икән соң шагыйрьнең гүзәл балачак—ак хыяллар дөньясы белән саубуллашуы, фанилык белән күпмедер килешүе? Уйласаң, анласаң—тормыш кырыслыгы белән беренче очрашулардан, жанны авырттыргыч тәүге югалтулардан түгелме икән?! Шагыйрь үз ижатында балачагының һәм яшьлегенең сагышлы көннәренә дә вакыт-вакыт әйләнеп кайта... («Карт этне алып чыгалар... « һ. б. шигырьләр)

Әйе, яшәгән саен кеше тормышында табулар белән бергә югалтулар да үз урынын ала. Китапның икенче бүлегендә, мәсәлән, исән-сау каләмдәшләренә багышлаулар белән бергә инде бакыйлыкка күчкән, татар тормышында якты эз калдырып киткән күренекле каләмдәшләре истәлегенә (Фаил Шәфигуллинга, Мөхәммәт Мәһдиевкә һ. б...) багышланган шигырьләр дә бар. Шушы шигырьләрдә чор-заманның үз табышлары һәм югалтулары да чагылып үтә. Сүз дә юк: XX гасыр ахырында кыргый капитализм чоры килү, жәмгыятьтәге кайсы куанычлы, кайсы начар үзгәрешләр, рухи тамырлардан да күпмедер ераклашу нечкә күңелле шагыйрьләр яшәешенә дә үз тәэсирен ясамый калмады. Бәлки, кыйблалары итеп рухи тормышны алганнарга үзара теләктәшлек, иптәшлек тә житеп бетмәгәндер?!. Замана зилзиләләре бөтереп алып киткән, югалган талантлы чордашына кагылышлы рәвештә, мәсәлән, шагыйрь түбәндәгечә әйтә:

*Синең белән беркем хушлашмады,*
*син үзең дә кирәк тапмадың.*
*Чабып үтте бары баш очыннан*
*ярсу ахырзаман атлары.*

*Монда әле беркем уянмаган,*
*офыкларның күзе эренле.*
*Күк йөзеннән күргаш шәүлә үзды.*
*Беркем искәрмәде.*
*... эреде.*

(«Эдуард Мостафин рухына»)

Әйе, фажигаләр кичергәннән соң әле генә төзек булган дөньяң жимерелеп киткәндәй тоелып китә, яшәешнең гүзәл гаме югалгандай хис ителә... Әмма, ни генә булмасын, кеше бәхетле чакны, дөньяның гармониялe, төзек булган чагын—Сафлык Илен югалтырга

теләми! Шуңа күрә дә бит инде ул Мәгарәгә юнәлеп, тормышның изге янарышы белән бәйле тылсымлы даруны эзләп табарга ашкына!..

Чыннан да, шагыйрьгә, бәлки, ачыргалану кирәкмидер дә?!... Шагыйрь Ркаил Зәйдулла да аерым мизгелдә олылар дөньясында балачак—саф хыяллар иленең—бер Илчесе булып күз алдына килеп баса түгелме?! Әйе, нәкъ менә Илче! (Аның милли тарих катламнарын күтәргән «Ил» китабын да искә төшерик). Дусты, фикердәше Ләбиб Леронга багышланган шигырендә ихлас рәвештә менә нәрсә ди бит ул:

*Без сабыйлар иленнән бит, дустым!*
*Иртә киткән ишләр өчен дә*
*Йончу атлар төсле аунык әле*
*Җиләк үскән карлар өстендә.*

*Бусагадан үтә алмый бүтән*
*Үчле кол да, явыз түрә дә...*
*Алда томан, юанабыз һәр төн*
*Узганнарга кылып күрәзә.*

(«Без сабыйлар иленнән бит, дустым!»)

Әйе, яшәешнең беренчел пакълеген саклаган, тормышның чын асылы булган, балачак белән бәйле сафлык иленә үчле һәм явыз җанлы кешеләр үтеп керә алмас иде... (Мәгълүм: явызлык җәзасыз калмый.) Күрәсең, ошбу сафлык иле кеше йөрәгенең, кеше җанының иң мәгънәле, иң гамьле төшендәдер...

Шуңа да түгелме икән, нинди генә дәвердә яшәсә дә, җәмгыятьтә нинди генә ялганнарга дучар булса да кеше Хакыйкатьнең барлыгын тоя һәм аңа алгысуын дәвам итә. Гомумән, олы Хакыйкатьне эзләү кеше яшәешенең иң якты алгысуларын тәшкил итмиме?!...

Кеше үзенең тынгысыз йөрәге, саф күңеле белән чиксез тормыш куйган сорауларга үзенчә җавап эзләргә омтыла... Аның дөньяга килүенең дә олы бер мәгънәсе шушындадыр, бәлки?! Әмма, бу юл җиңел түгел.

*Мәңгелек яр яулык болгый ярда,*
*Китә микән, кайта микән бәндә?*
*Без белербез моны барлык өмет*
*Шигырь юлы кебек өзелгәндә.*

(«Чапты атлар...» Зиннур Хөснияргa)

Кайчак шулай да тоелырга мөмкин: нәкъ менә үз буындашларына багышланган шигырьләрдә шагыйрь үзе өчен мөһим булган борчу-уйланулары белән уртаклашырга ашыга.

Газинур Моратка багышланган шигырендә шагыйрь үзе тормыш итеп яткан чынбарлыкны борынгы бабалары яшәгән бөек Дала чынбарлыгы рәвешендә күз алдына китереп бастыра... Һәм, гомумән, Татар тарихының үткәненә, аның шанлы чагына, драматик чорларына игътибар итү Р. Зәйдуллага хас. Әйтерсен лә, ул үзенең яшәешен, омтылыш-кичерешләрен, кылган эш-гамәлләрен ерак бабаларының милли гамьгә төренгән, табигать белән гармониягә ия булган, күпмедер кырыс, күпмедер моңлы яшәеш чынбарлыгы белән үлчәргә тели.

*Бер офыктан бер офыкка таба*
*Чабып йөрим. Авам. Биртеләм...*
*Кысылам да янә киңәям мин*
*Үзем генә белгән серемнән.*

(«Зы•лап тора һава бу далада...»)

Лирик каһарман—«ялгыз җайдак» тормыш даласында нишли соң? Ул яшәеш кануннарына үзенчә буйсынып, карашы белән ымсындырган офыкларга төбәлеп, җәясен тарта... Ә садакта уклар кими бара... Соңыннан ул аткан укларны (бу очракта: ихлас эшләнгән эш-гамәлләр нәтиҗәсен?!) эзләп киң Далада йөри. Ә аның урынына ни таба?

*Сибелделәр черек көннәр кебек.*
*Әрәм, дидем. Алар асылда*
*Офыкларга кереп югалганнар*
*Газәлләрнең кабыргасында.*

(«Зынлап тора һава бу далада...»)

Символик юллар... Шигырь дәвамында шагыйрьнең ни әйтергә теләгәне аңлашыла: якты офыкларга барганда безгә сынган җәя, бушаган садак белән «ат сагынган ялгыз җайдак» булып калмыйсы иде!.. Милләттәшләрен, замандашларын ул тормышның борынгыдан килгән табигый, изге чакыруына әзер булып калырга чакыра:

*Ә далада тагын ук сызгыра.*
*Исән әле, исән чуралык.*

*Күздән җуела,*
*Дастан атларының*
*Калын ялларына чорналып.*
(«Зыңлап тора һава бу далада...»)

Шигъри фикерләүләрнең кайсыдыр мизгелендә шагыйрь уйланып сорап та куя:

*Бу дөньяны ни коткарыр икән?*
*Матурлыктыр, бәлки? Мәхәббәт, наз?*
(«Чапты атлар...»)

Чыннан да, бу дөньяны ни коткарыр? Бәлки, инсан үзедер? Чөнки, кеше үзе үзгәрми торып дөнья яхшыра алмый бит!

Шагыйрь, үзенең бер мәкаләсендә җәмгыятьнең бүгенге халәте турында уйланып түбәндәгечә язган иде:

«Без хәтта Намус дигән сүзне кулланырга кыенсына башладык. Әдәп-инсаф, низам, итагать кебек төшенчәләр тормышта ирешәсе уңышларга киртә сыман күзаллана хәзер. (...) Котылу юлы кайда? Тамырлардамы?» *(«Казан утлары», 2006, №10)*

Тамырлар... Чыннан да, бүгенге катлаулы дәвердә мәңгелек рухи йола (традиция) белән бәйле тамырлар безне коткарып калырга тиештер. Ә бу тамырлар үзләре ничек, нидә табыла? Бәлки алар—Табигать-Ана белән изге бәйләнештә; Исламның мәңгелек кыйммәтләренә тугры калуда, аларны санлауда, хөрмәт итүдә; Туган якка, Милләткә булган изге хисләрдә! Мәхәббәт дигән илаһи халәттә...

Яшәешнең саф асылы, бәхетле мизгелләр белән бәйле туган җир, сөю-мәхәббәт темалары... Алар «Мәгарә»нең өченче бүлеген тәшкил итә. Чыннан да, нәкъ менә туган якка булган мәхәббәт, хатын-кызга булган саф сөю—сәламәт, гүзәл тормышның нигезендә ята. Шунадыр да бу изге темалар кайвакыт шагыйрь иҗатында гүзәл мантыйкка буйсынып сихри рәвештә бергә кавышалар да:

*Туган якның төннәре дә якты!*
*Бу—син яккан учак балкышы.*
*Еллар аша шул төннәргә төшә,*
*Мине эзлидер күк ялгышып.*
(«Еллар аша»)

Күренгәнчә, шагыйрь монда да якты офыклар, сафлык иле эзләп үткәннәргә таба юнәлә... Туган якның еллар аша күңелләрне назлаган яктысы исә милли нурлар белән өртелгән... Китапның дүртенче бүлеге, асылда, нәкъ менә кешенең җан-бәгыре өчен мөһим булган тагын бер изге темага—милли тамырларны барлау темасына—багышланган. Монда да шагыйрь үзенең эзләнүчән, тынгысыз җанына тугры кала: төрле-төрле җилләр искән яшәеш кинлекләрендә газиз халкына лаеклы урын барларга ашкына.

*Без адаштык бугай карурманда,*
*Урманның да насыйп безгә карасы.*
*Кайсы кошның авазына иярик соң,*
*Татар иле?!—*
*Идел-Урал арасы.*
(«Карурман»)

Кеше һәм халык үзе дә, гомер буе җиһанда үзенә лаеклы, мәгънәле, бәхетле урын эзләп табарга омтыла. Әйе, инсан өчен дә, халыкның үзе өчен дә иң мөһиме—рухи кыйбланы югалтмаудыр, ана хыянәт итмәүдер?! Ә бу җинелмә сон? Бигрәк тә рухсызлык көйчәйгәндә, тормыш далаларында ялган маяклар күзгә еш чалынганда... Ләкин, шунысы хак: Чынлык, барыбер, өскә чыга: Ялган, шиксез, җинелә! Шуңамы, Хакыйкатькә омтылу Зәйдулла шигырьләрендә ялганны, рухсызлыкны, дәһрилекне кисеп югарыга омтылган гүзәл сөнге булып гәүдәләнеш ала.

*Ә без? Ә без? Без—имансыз түгел,*
*Ул—күз яшьтә, аккан каннарда...*
*Алар җирдә ятмый!—Сөңге булып*
*Кабат калкып чыга манара.*
(«Бисмилла»)

—дип язган иде шагыйрь җәмгыятьтәге торгынлык елларыннан соң зур үзгәрешләр башланып киткән чорда татар өчен, аның киләчәк яшәеше өчен гаҗәеп мөһим булган Ислам кыйммәтләрен искәртеп. Бу—ерак бабаларыбыз сайлаган изге кыйбланың дөреслеген тану, аның бәхетле, якты тормышка китерәчәк чын мәгънәсендә хакыйкый маяк икәнен икърарлау иде.

Гомеренең саф чишмә башыннан

чыгып киткән һәр кеше дә аңа гына билгеләнгән гомер юлын узып, бакыйлык дингезенә үзенчә якынлаша... «Мәгарә» китабының соңгы—бишенче бүлегендә—фәлсәфи фикерләр тыгызлыгы арта, Яшәү һәм Үлем белән бәйләнешле уйланулар тагын да куера төшә. Шигырьларнең исемнәре дә «бакыйлыкка күчү» турында искә төшереп тора: «Зиярәт», «Зират каравылчысы турында», «Соңгы юл» һ.б...

*Далада ут уйчан-уйчан...*
*Авып кала, төбен уйсаң—*
*Без шул кылган түгелме?*
*Бәгырьләргә басып утә,*
*Әллә үкенүне көтә,*
*Кисә көннәр гомерне.*

(«Югыйсә». Наис Гамбәргә)

—ди шагыйрь тормышның изге, бакый әйләнешенә кагылышлы рәвештә.

Шагыйрьнең бишенче бүлеккә кергән, соңгы еллардагы фәлсәфи уйлануларын аеруча киң чагылдырган кыска шигырьләр бәйләме «Өзелгән дисбе» дип атала. Өзелгән һәм янә җыелган дисбе... Игътибар итсәң, шагыйрь бу китабында шигырьләреннән, шигъри уйлануларыннан шактый мәгънәле һәм гамьле дисбе җыя алган. Ошбу шигъри дисбене тарткан чакта аның тылсымлы Мәгарәсенә—яшәешнең саф асылына—үз юлын эзләгән шагыйрьгә еш очрыйбыз без.

Кеше, әгәр Алла теләсә, төрле үзгәрешләр кичереп, төрле сукмакюллар аша узып, иртәме-соңмы эзләгән Мәгарәсен табар, ягъни, үзенең Мәңгелек Сафлык иленә әйләнеп кайтыр—Хакыйкатькә ирешер... Бу вакыт, бәлки, аның күңеле керсез Балачак Иленә янә кагылыр—аның белән тоташыр, изге бәйләнешкә керер?!.

*Ябышып калам—ызан сизелми:*
*үкенеч белән өмет арасы—*
*Офыкка кадәр пакуслар буйлап*
*сабый йөгерә...*
*сабый...*
*нарасый...*

(«Өмет»)

...Өзелгән дисбене (өзелгән мәгънәләрне...) өр-яңадан ялгарга ашкыну (күңелдә, җанда...) дигәннән исә... Безнең өчен, чыннан да, пакъ күңелле, сәламәт рухлы әбибабаларыбыздан калган, төймәләре бердәм булган мөселман дисбесе кадерле. Анда олы мәгънә, көндәлек рухи яңарыш, рухи-илаһи бердәмлек, иман бар. Анда Җәнабе Хакны бакый олылау бар. Анда Аллаһы Тәгаләнең бөеклеген, кодрәтен, пакълеген, җиңелмәслеген, гаделлеген, шәфкатен аңлау бар. Анда Галәмнәрнең Раббысыннан, кешеләрнең хак Хуҗасыннан килгән Китапка—Коръәнгә ахыргача изге ышану бар.

*Бит Аллаһуга итагать итү һәм Аңа гына гыйбадәт кылу—иң туры юл.*

(«Коръән тәфсире», Гимран сүрәсе, 200 аять, 51)

**Илшат ВӘЛИУЛЛА**

Аяз Гыйләҗев

# ГОМЕРНЕҢ БЕР ЕЛЫ

КӨНДӘЛЕК СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

**12 гыйнвар, Иске Әлмәт.**

Ике көн рәттән ягымлы кыш кояшының кыйгач нурларына кинәнеп басу-кырларда йөреп килдем. Мәктәп, зират янынннан уздым. Бүген Сарман-Әлмәт юлына чыгып "Әүлияләр зираты" янына ук барып җитмәкче идем. Рәис, Фәрхенур, Таһирлардан җентекләп сорасам да "Әүлияләр зираты" хакында өзеп сөйли алмадылар... Бик борынгыда әрвахлар йокыга талган җирнең шушы изге почмагы тора-бара онытылган. Таш юл салган чакта каберләрне санга сукмаганнар, юл Әүлияләр зиратының бер өлеше өстеннән дә узган... Соңгы елларда зират үзенең барлыгын, үзендә әүлияләр күмелгәнен сиздерә башлаган. Утын төяп кайтып килүче машина тип-тигез җирдә ауган... Йөк өстенә утырып кайтучы хатын тип-тигез урында тәгәрәп киткән. Атлар тезләнгән, арба тәгәрмәчләре нәкъ шушы урында таралган. Тагын бик күп, һич көтелмәгән бәла-казалар "Әүлияләр зираты" өстендә була башлагач, адәмнәр искәргәннәр, борынгыны исләренә төшергәннәр. Зират өстендә теләсә ничек таралып яткан ташларны җыештырып, ташлардан койма кебек нәрсә ясаганнар. Ташлар теләсә кайда тәртипсез аунап ятканнар, язулары ышкылып, ашалып, юылып беткән икән. Тора-бара адәмнәр үткәннәр хакында ныграк уйлый башлаганнар һәм "Әүлияләр зираты"н тимер койма белән урап куярга керешкәннәр. Бу эш әлегә тәмамланмаган, койманың бер өлешен генә койганнар икән. Бу хәбәр мине чиктән тыш дулкынландырды. Казан-Чаллыяр юлында, Казаннан барганда уң якта, агач-куаклар арасында да, Иске Кирмән тирәләрендә шикелле, "Әүлияләр каберлеге" саклана түгелме? "Борынгы Болгар каберләре" дигән иде аны кемдер. Мондагы зират та шул заманнардан калган истәлекме? Борынгы бабаларыбыз—болгарларны халык "әүлияләр" дип сагынып искә аламы?..

**13 гыйнвар, иртәнчәк**

Табигать колы шул мин, и дөнья! Кичә төшкә кадәр иләс-миләс селкенеп йөрдем, ятып аунадым, урам белән серләшеп, Әлмәт йортларына рәттән сәлам биреп, эт-көчекләренә юл сабып үттем. Кичкә таба гына күңел урынына утырды, ләкин күкрәктәге моң очып чыга алмады, эш үргемәде. "Бесы"ны укыйм. Кызыксынып укысам да әле тозны төбенә сала алмыйм. Табышмакмы?..

Бүген... ходаның кодрәте киң!—вак яңгыр сибәли, ыжгырып берсе өстенә берсе менеп өелгән ак кикрикләр шиңә, басыла. Дуамал һава үзгәрешләренә дә күңел әзер икән: мин бүген тыныч, мин сабыр. Иртәнге концертны тыңладым. "Икмәк булса җыр да була!" дигән калынкаш бабайның ахмаклыгын сыздыралар. "Әллә каян солдатта булганы күренеп тора!" дип сокланалар. Күзен чыгарганнар, кашын җимергәннәр, аягын сындырганнар, солдатта булганы дүрт яктан да күренеп тора, дип җырлыйсы урынга, һаман кылана, чынбарлыкка күз ачып карамый кайберәүләр.

*Дәвамы. Башы узган санда.*

***

—Алмагачына чыпчыклар кунган, ботакларның эресен-вагын сырып алганнар. Чыпчыксыз бер ботак та калмаган. Кинәт ишетәм:үзара сөйләшәләр, гадәтләренчә мактанышалар: "Мин утырган ботактагы алма шундый дәү иде!" дип мактана берәвесе. Икенчесе тәтелди:"Ә мин кунган ботактагысы кып-кызыл иде!" өченчесе канатларын җилпи-җилпи чыркылдый:"Ә мин утырган ботактагы алма... Мин кунган ботактагы алма дәү дә, кызыл да, авыр да иде... Шап итеп җиргә төште. Аны нәни кызчык Зифа алып ашады."



*Рәис һәм Фәрхенур.*

—Яңгыр атапява ул,—ди Рәис.—Йә шифалы була, йә шифасыз. Шифалы яңгырдан соң игеннәр күтәрелеп китә, үләннәр калкына.

Көчеңә күрә кыймылдыйсың инде, умырып эшләмәсәң дә.

—Суыкта чыпчыклар йоннарын кабарталар, шулай җылыналармы?.

—Чыпчыклар туры сызык белән диярлек оча. Песнәк исә купшы борылышлар ясый, очуын бизи, матурайта. Килә-килә дә дугадай эз сызып борыла. Песнәк—үтә купшы кош.

—Төбен этләр сарыга манган чаттагы юан багана йокымсыраган, көн авыр, узыша-узыша яңгыр белән кар алмашлап ява. Кыеклардан чырылдап тонык су ага. Менә сиңа Раштуа суыклары!

**16 гыйнвар 1993 ел, Иске Әлмәт**

Күк тоташ томаланган, җир белән күк арасында әле кара, әле ак буран—көн вә төн, бурый-бурый дымлы кар ява, баскан саен аяк батып китә. Җылы, җылы, җылы. Гыйнвар җылысы черек, гәүдәне камыр итә, мускуллар йомшара, күкрәк читлеге җеби, тәндә көч калмый. Шушы өч көнгә биш-алты бит язылды микән? Рух көчәеп, эчке тоткынлыктан ычкынып яза гына башлыйсың, казыган коең тиз саега, өч-дүрт чиләк чумырып алуга төбе күренә башлый, суы болгана,болгана. Ә бүген, иртәгә алтмыш биш яшь тула дип торганда болганчык су ярамый инде; су көмештәй саф, ширбәттәй татлы, мәк чәчәге сыман йомшак булырга тиеш. Югыйсә, күрче, бүген радиода "Күтәрмен мин, иркәм күтәрмен, ялгызлыкның барын кичәрмен" дигән җыр колагыма "явызлыкның башын кисәрмен!" булып ишетелә. Колак та кай ара хуҗасына буйсынмый, ул тыштан әлләниләр яңгырап-дөбердәп торса да үзенекен итә:эчке авазларны гына оештыра, күкрәк читлегенә сыймыйча тышка ыргылган дулкыннар ымын гына баш миенә җиткерә... Инде мондагы тормышымның көйлелеге! Хуҗаларым кече күңелле, һәр адымымны сагалап, олылап, күңелемне күрергә дип торалар, ни ашасаң шул бар, иртән яңа сауган җылы сөт, кичкә кырын тагын сөт. Телең йотарлык хуш исле катык. Үзләре ашатып симерткән тана ите... Фәрхенур миңа ярарга тырышып көннәр буе газ плитәсе янынннан китми. Урыным йомшак, бүлмәләр иркен. Шунысы бар:бу өч-дүрт көн өй тавыгына әйләнеп куначадарак гомер кичәм. Яңгырлы карда, карлы яңгырда әллә кайларга барып буталасым да килми...

**19 гыйнвар, Иске Әлмәт авылы**

Менә, алтмыш биш яшь тә тулды. Монда бу хакта беркемгә дә белдермәм дигән идем Фәнҗия белән Таһир иртән үк котладылар, матур гына күлмәк бүләк иттеләр. Көндезге уннарда Ильяс килеп керде. Бергәләп Таһир Җиһаншиннарга киттек. Анда мәйләп, тыныч кына гәпләшеп утыра идек, Түбән Камадан Рәшит Вәлиевич Абдулхәкимов килеп төште. Кара ипи, алма, лимоннар алып килгән, бер "Виски" дә кыстырган. Хуҗам Рәис Мөхлиевне уртага утыртып бераз салырга,

"ураза"ны бозарга туры килде...

Алтмыш биш, алтмыш биш. Әз дә түгел, Г. Бәширов, Риза Ишморатлар янында күп тә түгел. Шулай да тән әгъзаларында өзмәс үзгәреш барганын сизәм: күз начарлана, колак ишетми, кайчандыр балык сөяге кадалып интектергән тамак төбе дә кинәт-кинәт сызлаштырып ала, димәк, ул да эзсез үтмәгән. Тәнемнең кайсы почмагыннан картлык төртеп чыгар да соңгы, караңгы юлга өндәр икән дип уйлаштырам. Юк, үлемнән курыкмыйм, Нәкыяне генә жәллим. Ул картлык ялгызлыгын бер дә күз алдына китерми, коты чыгып шуннан куркып яши. Балалар, оныклар белән генә бизәлгән картлык ялгызлыктан коткара алмый дип саный ул. Алда ни көткәнен кем анык кына белгән?.. Ходай ни язгандыр, калган гомеремне Нәкыя белән тату, матур итеп үткәрәсе иде. Соңгы елларда эш белән нык изаланды, ял иткәне юк, һич көтмәгәндә кинәт олыгаеп китте. Соң дәрәҗәдә борчылучан, тынгысыз җан шул.

Хәзерге авылга карыйм да, шәһәр, үз тормышыбыз белән чагыштырам. Элеккеге авыл хатын-кызларга мәшәкать арты мәшәкать өстәп, аларны кол хәлендә яшәтсә дә хәзер тормыш күзгә күренеп үзгәргән, аруланган. Авылга су кергән, электр энергиясе бар, ниһаять, иске әлмәтлеләр газлы да булганнар. Газ өйне җылыта, кухняда өзлексез янып тора. Хуҗаларым икесе дә шактый мул пенсия алалар, Рәис Ватан сугышы инвалиды, икенче группа. Мал асрыйлар, мал ризыклары табу да азмы-күпме җайга салынган. Бәлки бөтен йортларда, барлык хуҗалыкларда алай ук түгелдер, минем хуҗаларның тормышы көйләнгән, түгәрәк тормыш. Бүгенге тормыш шартларын без белгән тарихтагы авыл тормышы белән янәшә куеп чагыштырырлык түгел! Иң мөһиме: авыл халкы шәһәрнекеләргә караганда күп мәртәбәләр тыныч яши ала. Нәкыя кибетнең берсеннән икенчесенә чаба, һәр җирдә чиратлар, халык, ызгыш-талаш, тегесе юк, бусы кайтып җитмәгән. Барасың, син алырга теләгән нәрсәләр беткән, кайчан буласы да мәгълум түгел. Кибетләргә һәр сәяхәтеңнән гасабиланып, борчылып, йөрәгеңне урталай телеп, әчтән сүгенеп, тыштан зарланып кайтасың. Һәр таң нервларны ашый, һәр көн саулыкны урлый, һәр кич сине хәлсез, өнсез, көчсез хәйван хәлендә калдыра. Авылда хәзер мал асрамаган кеше юк, быел Рәис балалары һәммәсе сугым суйган, бүтән елларны итне ата йортыннан да алып китә торган булганнар, быел һәр каюсының үз сугымы, ит запасы бар. Дөрес, Рәис белән Фәрхенурның балалары хәлле кешеләр, кызлары уңган, сакчыл һәм йорт тота белерлек кызлар.

Авылның тышкы кыяфәте дә нык үзгәргән. Бигештә абзар-кура өсләренә киң-киң такта сарайлар утыртып куеп, печәнлекләрне, салам лапасларын киң-киң җәеп аңа "Аэродром" дигән исем бирсәләр, монда да шундый типтагы корылмаларны "Камаз" дип атап йөртәләр. Яңа өйләрне киң, иркен итеп, кубесенчә кирпечтән салганнар, йорт тирәсенә иркен верандалар чыгарганнар, авыл урамы буйлап очтан-очка барасың, тоташ коймалар, һәммәсе буялган, капкалар бизәкле: татар яраткан кояш сурәте күпчелек, сирәк кенә чәчкәләр, үлән яфраклары күренеп кала. Этләр явызланмый, өрми диярлек, үткән-сүткән адәмнәргә ырлап ташланмый, димәк—тамаклары тук...

**20 гыйнвар, Иске Әлмәт**

Кичә урта мәктәптә очрашу булды. Укытучылар (сөйкемле генә яшь төркем!) өлкән класс укучылары, аксакаллар, китап сөючеләр килгән иде. Авыл мулласы башлап җибәрде, корьән укыды. Җырлар, биюләр булды, сораулар яуды.

Минем китапларны тезеп куйганнар. Арада шактый таушалган, тузганнары да бар. Терлекче, гади бер ханым чыгыш ясады:"Ирем белән икебез дә сез язганнарны бик яратып укыйбыз, гыйбрәт алабыз", диде. Хәзрәтнең әтисен утызынчы елларда юк иткәннәр, чибәр генә ир, ә хатыны—Казан кызы икән—затлы чибәр хатын. Укытучы. "Балалар арта!" дип куана директор. Бу хәбәргә мин дә куандым. Мәчетле, иманлы татар авылында да татар үрчемәсә, без кая барабыз?!

**21 гыйнвар, Иске Әлмәт**

Көн озынлыгы—8 сәгать! Шөкер Тәңремә, кояш миңа ярдәмгә ашыга, иртәнге концерт мәлләрендә мин тәрәзәнең салкын, җансыз пыяласына терәлеп көннән-

көн яктыра барган ягымлы офыкка текәләм. Күземнең начар күрүен, укып-язып хәлдән таюын бик яхшы аңлаган чиксез кодрәтле кояш мине кызгана, яз ясарга кабалана, иртәнге шәфәкъ ал чәчәкләр булып уйный, күзне камаштыра, көннәрдә кояш моңарчы яктылыкны каплап торган лапас өстендәге салам кибәне өстенә үк менеп үрмәли. Кояш нурлары һәр таңда өмет төяп килгән кебек. Ә җан яраткан җырчылар бүгенге тургай-сандугачларны алыштыралар. Җанга күпме дәрт, күңелгә кайнарлык өстәүләрен белә микән җырчылар? Татар күген иңләгән моңнарны тотып ала белгән композиторлар аңлыйлармы?.. Бүген аларның исеме дә кояш белән бергә уяна да нур булып татар илендә тарала... «Әй, Идел-йорт, Идел йорт! Әй, Идел-йорт, Имин йорт!" Без татар дөньясының гимны өчен текст эзләп изаланабыз, нинди сүзләр генә тәкъдим итмәде үз байлыгын барлый алмаган татар балалары! "Идегәй"дә ята безнең гимн тексты, "Идегәй"дә! Дөрес, минем күңелем тәкъдим иткән шигъри юлларга көй язылган, ләкин ул юаш. Басынкы көй янәшәсендә татарның гаярь җайдаклары, аргамакларының тояк астыннан чәчрәп чыккан очкыннар, сыгылып, сыпылып калган кылганнар дулкыны, урман авызларында яңгыраган болгар-татарларның ур-ра тавышлары, киндер тукмаганда моңланган кызларның күкрәк аһәңнәре дә, монгол, урыс кылычларыннан киселгән башларның соңгы хушлашуы авазлары да ишетелергә, татарның мең еллык иңрәүләре, тантанасы да яңгырарга тиеш анда.

**22 гыйнвар, 1993 ел, Иске Әлмәт**

Ике көнне кышка бирдек! Гыйнвар рәхәтләнә! Купшы агачлар бизәнер нәрсәләр тапты—агачлар чигеш төсле, җир-күк ак томанда тавышсыз гына чыңлый. Салкын һава, сыкылы дөнья мине иңнәремнән тотып күтәрә, әкияти дөньяның сихри манзарасына уралып, телсез калган хәлдә әүвәл баштан тыгыз кар көшелләре каплаган тыкрыктан урамга менәм, тыкрык башында йөнтәс курчак хәтле генә эт каршылый, суыктан иреннәре ябышып катканмы, өрми... Авылны чыгып шундый ук бай бизәлгән урманга таба барам. Юлны кисеп сикергәләгән кыска койрыкларның эзләренә елмаеп баш иям, төнлә-төнлә аларның шушы киң тынлыкта бер-берсен куышып уйнаганнарын күз алдыма китерәм. Рәхәт, рәхәт! Гаҗәеп тын, мондый рәхәт, тирән тынлыкны татырмын дип күз алдыма да китермәгән идем. Еракта, еракта самолет мырлый, ул да бу биек, тын гөмбәз астына адашып, ялгышып кына килеп кергән кош төсле. Серле ак диварлар арасына, текә ак кирмәннәргә пар-пар чаңгы эзләре сузылган, минем дә шул юллардан, яшьләр эзеннән ак әкият арасына кереп югаласым, сихри гүзәллек чоңгылында онытылып басып торасым килә. Дөнья гүзәл, гүзәл... Кычыткан куралары да көмеш зәр булып үрелгән, юл читендәге һәр таучык Мисыр пирамидалары кебек серле, бай... И дөнья, әле синең шундый сихерле белә торган көннәрең дә бар икән! Артыма борылып карыйм, Иске Әлмәт авылы өстенә. Өстән караганда йортлар йөзтүбән ятканнардыр кебек тоела, йөз түбән ятканнар да өсләренә тау-тау кар япканнар, төсле төшләр күрә-күрә йоклыйлар... Умарталык тирәсенә таба тирәнтирән бәллүр эзләр —чана эзләре ашыккан. Чана эзләре офыкларны бер-берсенә ялгаганнар кебек, бүгенге әкияти сәгатьләрендә эзләр дә гади түгелдер, чананы чаптар атлар, канатлы аргамаклар тартып үткәндер кебек. Ирексездән шул ялтыравык эзләргә төшәм дә ак, куе томан кәфенгә төренеп, әзгә генә булса да бу ыгы-зыгылы дөньядан китеп, сихри урманга кереп барам. Баш очымнан каргаларны, кара җилпәзәләр очып үтә, "мондый көндә нигә алар агармаган соң?" дип гаҗәпләнеп калам. Шулчак кинәт урман авызы җанлана, шыбырдап сыкы сәйләннәр коела, тынлык томалаган колагыма абалап өргән явыз эт тавышлары кереп тула. Умарталыкта явыз этләр бар, бәйдә торалар, вакыт-вакыт аларны ычкындыралар, андый чакта алар кемгә барып ябышырга белмиләр, дигән иде Рәис. Этләрдән болай да куркам, үзем генә кинәнеп барган әкияти юлларда, көмеш җәймәгә төрелгән ялгызлыгыма этләрнең ниндиен дә, юашын да, явызын да кертәсем килми, мине чакырып ишарәләп торган урманга тагын бер карап баш орам да чана юлының бөтенлеген, төгәллеген, тигезлеген бозмаска тырышып кире борылам. Рәхмәт явыз этләргә, алар күземә күренмәделәр, тавышлары еракта гына яңгырады. Тындылар, бәсәргән агачларны, ак наратларга бүген

тәмам гашыйк булган ак каеннарны кызгандылар бугай. Этләр дә матурлыкның кадерен белми дип кем әйтә ала?

**23 гыйнвар, Иске Әлмәт.**

Ах, җилнең бүген төн ката мине кысып кочкан җылы ятакка үтеп керәсе килде! Мең бармаклы җитез кулы белән ул төн буе стеналарны капшады, сыйпады, сызгырып ялварды. Стена һәм төнге җил хакында том-том әсәрләр язылган, адәм җаннарына тынычлык түгел, борчулар китергән бу табигать омтылышы бүген мине тынгысызламады. Җил тавышына уяндыммы, бишләрдә калкындым да мендәремне тәрәзәгә табарак тартып тыңлап яттым, җилдән качасым килмәде бүген, киресенчә, кул биреп көрешәсем, аңлашасым килде. Ә җил аның саен көчәйде, чак кына тынып хәл алды да тагын тәрәзәгә ташланды, стеналарны ялап чыкты, тишек табалмагач ак карны дулкынландырып-тузгытып ындыр аша әллә кайларга йөгерде.

Бүген "Петр Скороходов" бүлеген яздым. Кызыклы шәхес иде! Сергей Сергеевич Козлов-Куманский аша миңа Пастернак, Мандельштамм килеп керде, Скороходов Есининның моңлы, ак каенлы дөньясына өндәде, Ростислав Иванович Илечко миңа көнбатыш дөньясы хакында гыйбрәтләр аша белем бирде. Әле Мерзленков Александр бар. Бөек, якты шәхес! Аның татарларга мөнәсәбәте нәкъ Худяковча иде. Ул власть иялеренең—Сталинның, Ленинның кемлеген ачу өчен урыс тарихының түрендә киерелеп утырган Петр патша мисалына мөрәҗәгать итте. Аның табынган, яраткан әдибе Мережковский иде. Мин монда килгәч Мережковский сайланмаларының ике томын ермачлап чыктым. Икенче томдагы "Антихрист"—"Петр һәм Алексей" романы Гариф Ахуновча әйтсәк—"таң калдырды". Без Петр 1 гә Пушкин ясаган иконага ышанып йөргән бер катлы бәндәләр икән!.. Власть бозмый кешеләрне. Властька явыз: кансыз бәндәләр генә килә ала, дигән хакыйкатьне миңа шул елларда ук Мерзленков сөйләп, кат-кат аңлаткан икән. Мин—әзерлексез, системалы төпле белемсез авыл гыйбады—тиешле көннәрендә аңлап бетермәгәнмен. Ләкин мин Александр Васильевич Мерзленковка мең бурычлы. Мең!

Ниндидер бер дәрәҗәдә мин югарыда исемнәре саналган олпат ирләрнең шәкерте. Үзләренә лаек хатирәләр яза алырмынмы? Мәсьәлә шунда. Тагын яһүдләр турында бер бүлек булырмы... Наум Песин, шапшак, түше ашка баткан, серле күзле Рафаэль Шапиро... "Мост Ватерлоо" фильмын караганнан соң Вивьен Ли хакында тирән лекция укыган, җәя кебек бөкерәйгән, урак кебек бөгелгән тынмас җан Берсеневич карт. Яп-яшь булса да хәйләгә оста, култык таякларына таянып, атлар-атламас йөрүче Луи... Мең анекдот белгән одессалы Мирошниченко... Фамилиясе украин булса да үзе яһүд иде. Бер кулының бармаклары юк, көрәшче, украин егетен күтәреп алып чөйгән иде... Французча көрәшкән егет.

Аннан: татарлар. Алардан соң "лагерь сугышлары"... Казанга кайту...

**25 гыйнвар, Иске Әлмәт.**

...Кыш. Кар. Буран. Иртән Рәис ишегалдын себерә. Сорадым:"Җил карны кырдан урлап ташып куйганмы әллә? Яшь кар яуганмы?" Рәис көлә:"Кыр кары каты бөртекле ком шикелле була, ә бу ефәк кар, йомшак. Әле җир белән катыланып өлгермәгән", дип куана.

—Эт кешенең куркак икәнен әллә каян сизеп тора, чөнки адәм баласының куркаклыгы баш түбәсеннән сөрем булып күтәрелә,—диде Фәрхенур.

Гыйнварның соңгы атнасына кердек, көн иртә уяна, иртә яктыра. Хәзер ашыгып-ашыгып яз ясалыр, аны кире куып җибәрер хәлең юк...

Китапханәдән Әхсән Баянның "Язмыштан узмыш" китабын бүләк иттеләр. Алтмыш еллыгына чыккан бу җыентыгын күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде. Дүрт повестен тезеп салган. Баксаң, үз тормышын вә язмышын Әнис Бадыйгинга ышанып тапшырган икән егет. Гомеренең һәр фасылында шул кеше аның тулы хокуклы вә вәкаләтле илчесе булып татар укучысы каршысына чыгып баскан икән. Һәр язучы-әдип үзенең геройларын үзе теләгәнчә милләтенә тапшырырга хокуклы ич...

Ф. Достоевский, М. Е. Салтыков-Щедрин, Д. Мережковский, Григорий Кановичның "Козленок за два гроша" әсәрләре белән Иске Әлмәт гомеремнең уртасына килеп керде. Ремарк, Хемингуэй әсәрләрен, Кановичның романнарын кат-кат укып чыгып, ничәмә-ничә кат ләззәт алам, уй-фикерләренең тирәнлегенә, хисләренең байлыгына, тел осталыгына гашыйк булып, туймыйча сокланып, укыган саен образларының яңа, бөек якларын ачып, китап белән аралашуның, туганлашуның бәхетен татысам да кабат-кабат Канович әсәренә әйләнеп кайтам. Эссе көндә, челләдә печән өстендә тау асты чишмәсеннән эчкәндәй туеп булмый Канович әсәрләреннән. Достоевскийның "Бесы" романының мең чуар күзәнәкләренә әле кереп бетә алганым юк, дөньяның рухи хәрәкәтенә зур йогынты ясаган әсәрнең бөтен серле төпкелләренә кереп җитә алмыйм һаман, җиңелерәк җил капкаларны ача барам, ә алда зур, биек, нык урыс капкасы, әлегә ул бикле, ачкычны таба алганым да юк дияргә ярый, әсәрнең бөеклегенә бүтәннәр, белгечләр фикере аша гына ышанырга мәҗбүрмен. Тарихны, роман язылган дәверне, бөек адәми зат Достоевскийның җанын кыйнаган мәсьәләләрне белер-белмәс кенә баргангамы, әсәрне бер бөтен итеп кабул итмәдем әлегә. Чор да, кешеләре дә, аларның бергә ялганган гамәлләре дә мине көймәгә утыртып, бу ярлардан аерып яңа дөньяга алып керә алганнары юк...

***

Райком-горком хуҗалары бер чакта да ачылып бетми торган затлар иде. Җүләрләр җүләрлекләрен, акыллылар акыллылыкларын ачып бетермәс дәрәҗәдә хәйләгә өйрәтелгән, хәйлә белән кочаклашып яшәргә күнеккәннәр иде. Коммунистик режимга бары тик стандарт фикер йөртә алучы таш курчаклар гына зарур иде. Әле кичә Рәис сөйләп тора. "Сирәк кенә мине дә райком бюросына ияртеп баралар иде, малчылыкта эшли идем бит... Байтак колхозлардан җитәкчеләр килгән була, берәм-берәм аларны чакырып алалар да пешекләп чыгаралар... Безнең үтә хәйләкәр рәисебез бар иде...Күпне күргән, сансыз-исәпсез бюроларда мунча кергән адәм... Шуның бер сүзе хәтердә, кан калтырап бюро көтеп утырган бәндәләргә киңәш бирә иде:"карышмагыз! Ни әйтсәләр дә "үтибез, үтибез без аны!" дип тәкърарлап тик торыгыз, шул чагында бөтен хаталарыгызга хөкем кичектерелер!" Совет хакимияте ничә еллар дәвамында әнә шундый буш-бугаз попугайларга күз тотып, шуларның буш куык вәгъдәләренә ышанып яшәде. Горком-райком секретарьлары... Күпләрне күрдек, ләкин алар арасыннан берәү дә мине үз тормыш бакчасына чакырып кертмәде, икәүдән-икәү калган мизгелләрдә дә аларның күңеле йомык, теле бикле иде...

Элегерәк, ватандашлар, милләттәшләр белән киң аралашуга сүрән генә булса да өмет яшәгәндә, мин коммунистлар партиясендә югары урыннар биләгән иптәшләрдән ачылу, мине әсәрләндерерлек серләр, без белә алмаган караңгы катламнар легендаларын ишетермен дип көтә идем. Еллар үтеп бара, коммунистик хакимият серләре яңа вакыйгалар юшкыны астында калып югала торалар, ә кулларында хакимиятне тоткан таныш-белешләр ачылырга ашыкмыйлар. "Дуслар" дип атарга базмыйм аларны, ата коммунистлардан дусларым булмады. Мәгәр, арада мине үз иткән иптәшләрем дә бар иде. Алар әсәрләремне укып, чыгышларыма, сүзләремә игътибар юнәлтеп яшәделәр. Дөньялар болганды, югарыдагы иптәшләрнең эш, дәрәҗә урыннары үзгәрде, мәгәр Казанга килгәч берсе дә мине юксынмады, телефоннан шалтыратып, "әйдә, очрашыйк әле бер, эчләр бушаганчы гәпләшик!" димәде. Мин, карт җүләр,әле соңгы вакытларда гына шуны ачыкладым... Ничектер, Набоков хакында сүз чыкты да, газета-журналлар актарырга яраткан, бай көтепханә туплаган азмы-күпме якынрак танышым: "Набоковны яратасыңмы?"—дип сорады. Набоковны ныклап укырга вакыт тимәгәнен әйткәч, "Лолита"ны да укымадыңмы? Дип сорады. "Юк", дигәч, Чамасыз нык гаҗәпләнде, битарафлыгыма шаккатты. "Язучы башың белән...матурлыкны һәр тарафтан эзли торган кеше... ничек читтә калдың икән?"—диде әрләп һәм битәрләп... Мондагы авыл китапханәсе шактый бай, Набоковның 4 томлыгы бар, "Лолита" аерым китап булып киштәдә ята. Алып кайттым да кызыксынып, җентекләп укып чыктым... Акылыма уй килде: менә район җитәкчесе, әйтик шул ук

бәндә, райондагы ыгы-зыгылардан, көнчеләрдән, шикаятьчеләрдән, хатыныннан, бала-чагалардан, ун меңләгән кеше күзеннән, колагыннан вә теленнән ычкынып Казанга килеп элгәшә. "Лолита"ны укыган ир! Хәзерге дөньяда фахишәләрнең көннән-көн яшәрә баруын, Мәскәү калаларында җиде-сигез яшьлек кызыйларның иң кыйбат бәядә йөрүен белгән ир! Хәзер шул нәниләрне кочакка алу егетлек санала, аның чиксез ләззәте хакында том-том китаплар, галимнәрнең эзләнүләре языла, кинолар төшерелә. Унике яшьлек татлы ... хәйләкәр, чибәр, ... дигәндә чиксез гайрәтле ир кулына төшә... О хикмәт, ул кыз да түгел икән инде. Алай гынамы сиңа, лолитаның сыйныфташлары арасында кыз дигән мәгънә дә калмаган...Ятак, хөрешү күренешләре шактый тәэсирле язылган бу китапны кемсәләр дәреслек урынына күрми мени? Сынап карамаганмы ул аны? Хәзер шәһәр-авылларда Лолиталар әз мени? Хуҗалар, район күләмендәге ханнар, губернаторлар бәйдән ычкынып Казан шәһәре киңлекләренә килеп керәләр икән... сәламәтләр, туклар, яшьләр, кесә тулы акча, алтын-көмеш... Җүләр, җүләр мин! Мине юксынып киләме алар шәһәргә?.. Акыл эзлиме? Мөхәммәт Мәһдиевнең яңа әсәрен анализларга ычкынамы алар бәй-муенчактан? "Лолита"лар белән очраша алар, "Лолита"ларны үпкән-кочкан татар айгырлары, заман аргамаклары, дөнья чаптарлары белән күрешеп-кавышып, сер уртаклашырга ашкына...

**28 гыйнвар, Иске Әлмәт, иртәнчәк.**

Авылда туып, гомернең иң сизгер көннәрен шунда уткәреп, кышның кодрәтле рәссам, буйсынмас хикмәт иясе икәнен белмәгәнмен икән. Өченче көн, ягъни 26 сында җир өстенә ак томаннар явы төшеп туктаган иде. Нигә синең төньяк котыпларың, боз диңгезен яргалап калкынган торос-тауларың—Әлмәт басу-кырларында бүген барысы да бар иде. О-о, ул өченче көн, өченче көн! Өйдә чакта ук рухи җиңеллек, рәхәт тугарылу тоеп машинкам белән нык кына серләштем... Инде өй кысасын ертып урамга, урман ягасына, иркенлеккә чыгып китkәч, андагы тамашаны, җанны сыйпый торган тыныч манзараны... сөйләп бирергә тел җитмәс!.. Мондый чакта җырлап җибәрергә генә кирәк, җанны аңлатырлык бүтән әмәл юк...

Өске урамнан иплән кенә Түбән очка төшеп барам. Ишегалдында җан ияләре күренеп-күренеп кала, тавышлар килә, кеше шәүләләре төсмерләнә. Озаклап тукталып тормыйм, мондый сихри матурлыкка гади кешеләрне катыштырасы килми, мондый көн арасында бары тик бөек шәхесләр, әкияти язмыш ияләре генә сыя торгандыр дип, нинди дер могҗизалар эзләргә теләп, туры атларга тырышып барам. Матурлык бүген исерттә, кайгыларны оныттыра. Мережковскийда укып уздым: "Глаз дает человеку более совершенное знание природы, чем ухо". Леонардо де Винчи сүзләре. Татарның "Йөз тапкыр ишеткәнче бер күрүең артыграк" дигәнеме бу?

Барам, барам, мәктәпне үтәм. Уңда зират, аннан ары Сарманга юл үргә менеп китә. Шундый тын, җир шарының ипле генә әйләнгәне ишетелә. Тоташ кар, зират тирәләрендә нәни көмеш таучыклар тезелгән. Төнге буран, төнге кар җәймәләре әтрафлы танымаслык итеп үзгәрткән. Мин кырга, кыр миңа ятсынып карашып торабыз. Озын чокырга сыенган сырынтылар яңа, аучы түгелләрнең дә йөрәген җилкетә торган ашыгыч куян эзләре дә яңа, күпер култыксасына кунаклаган кар калачлары да яңа...Мин Әүлияләр зиратына таба менеп барам. Инде ничәнче кат мин бу серле сәяхәтемне башладым?

Беркавым атлагач та нигә тыелып тукталам мин? Күпер аша чыгуга күкрәгемә сак кына ага башлаган авыр сагыш тыгызланып тынымны бүләме?.. БУ—бөек атама, тыңдәшсез олы исем—Әүлияләр зираты тирә-ягыма, шул серле каберләрне мәңгегә сүзсез кочагына алган үргә мөнәсәбәтем һәркөн үзгәргән саен үземнең дә үзгәрә баруымны тоям. И дөнья! Без бичара татарларның җан алгысыган мөлләрдә барып баш ора торган урыннары бармыни?.. Иң изге җиребез Яңа Бистәдәге татар зираты ташландык бер чүплек башы ләбаса... Зират—җан югарылыгының билгесе, милләт югарылыгының бәясен билгеләүче нокта да ул. Мин кинәт шушы кырда бер үзем калам, мине чолгаган ак дөнья югала, күз алдымда Әүлияләр зираты да көмештән коелган кышкы юл гына кала.

Әнә генә ул зират, Әүлияләр сагында әлерәк кенә, күздән генә баскан баганалар... Нигә чабып кына үтә алмыйм мин шушы юлдан? Нигә зиратка якынайган саен адымнарым читенләшә дә атлар-атламас калам... Сизенәм, минем Әүлияләргә эндәшер хәлем юк, сүзләрем, арадашлык җепләрем өзелгән. Әүлияләрнең Бөек рухына багышлап дога укыр идем, белмим... Менә кайчан кирәк ул тиңдәшсез Олы сүзләр! Җаннарны уртаклый торган, Әүлияләрне һәм мине бергә Күккә күтәрә торган догаларны мин белмим. Нинди кызганыч вә мескен минем хәлем! Мин озак кына дөнья тынлыгына күз яше аша текәлеп карап торам. Ни көтәм мин, Бөек бер Могъҗизамы?.. Мине шушы төбәккә тартып тоткан, ычкындырмаган көч әле сыекланган канымда калгандыр ләбаса! Күңелгә килгән якты уйлар нигә сүзләргә, хөрмәткә, сокланууга әверелеп телгә килмиләр икән?.. Минем күз алдымнан бүгенге кыр кебек ап-ак сакаллы бабаларымның шәүләләре тезелешеп үтә. Йөз яшь аларга, ике йөз, ...мең яшь! Минем күз алдымнан илемне-җиремне саклаган батыр атлылар чабып уза...Мин белмәгән, мин белмәсәм дә тарихта булган, барлыгын сеңдереп калдырган яугирлар ат тояклары белән йокымсыраган татар илен уятырга теләп чабышалар... Кемнәрнең изге сөякләре шушы үрдә ятып һаман-һаман тынгы табалмый икән? Нинди җаннар?..

Татарстанның—Татар иленең чынкый картасы әле төзелмәгән, дога көтеп, җылы хөрмәт көтеп яткан җаннарның кайдалыгын без әле билгеләмәдек. Татарстанны моңарчы таларга җайлы булган урыннарын күрсәтеп кенә бүтәннәргә тәкъдим иттек. Ханнарыбызның каберләре юк, Идел йортны саклаган гаскәр башлыкларыннан берәүне дә юньләп белмибез, акыл ияләре, Ил агаларыбыз кадерсезләнеп күмелгән чокыр-чакырларда таралып яталар. Менә ул чиксез кадерле җиребезнең берсе—Әүлияләр зираты. Мин шушы Изге почмак хакына әллә ниләр эшләргә әзер, әрвахларның җаны җылынырлык итеп, изге китап аятьләре белән нығытып, сагыну хисләре белән бизәп гаҗәеп бер таш куясы иде монда!.. Юк шул, без хәтерсез вә хәерсез халык шул. Ә кызыл авызлар шапырынган булалар, и мактаналар, Сара Садыйковага да һәйкәл торгызмакчылар, Баки Урманчега да, хәзер Нәкый агага һәйкәл кирәк дип үзара, корып-коргаксыган камышлар сыман шаулашалар... И раббым! Бөегебез Салих Сәйдәшкә дә һәйкәл куя алмавыбызны, моңарчы җыелган маяның да әрәм-шәрәм юкка чыгуын белмисезме сез әллә, замана бичаралары? Татар кулыннан андый эш килми ул, без ярлы халык, мескен-бичара гавәм, нигездә матурлыкның кадерен белмәгән авыл гыйбатлары. Казанның ямаулы, җылымса канлы мокытлары корырмы ул һәйкәлләрне?.. Бирмәде Ходай муллыкны, һәр адымы мең чакырым булган Әүлияләр зиратына ак мәрмәрдән зур бер таш куяр идем!.. Сарман зиратыннан әрвахларның сөякләрен җыеп та тормаганнар, әлләнинди биналар корып, тарихыбызга, үткәннәргә лач итеп төкергәннәр, мәсхәрәләгәннәр... Аңлыйм, хәзер генә боларны аңлау дәрәҗәсенә ирештем: минем кадерле әбием Гыйлембаянның сөякләре дә шунда уалып ята бит... Җаны йә карлыгач булып июнь кичләрендә, җылы, тымызык һавада шушы тирә күген кисеп очадыр... Йә сандугач булып шушы як агач ботакларына кунып зарый-зарый җылыйдыр. Монда күмелеп, һәркөн лаплоп яңгыраган аяк тавышларын ишетеп, ләхетләрендә борылып-борылып интегүче әрвахлар! Сездән гафу сорап, бәхиллегегезне өметләнеп бу олы татар зиратының аулаграк почмагын табып Мәрмәр таш куясы иде лә! Әүлияләр янына бүген дә барып җитә алмадым. Күкрәгемә моң, сагыш, әче күз яшьләре төяп, бөтен бер дәвернең явызлыкларын аягыма тагып, ава-түнә, әкрен генә Рәисләргә кайттым...

Егерме җиденче гыйнварда көн аша буран котырды...Капкадан үземне түгел, борынымны гына күрсәттем...

**29 гыйнвар, Иске Әлмәт**

Беркөн килеп, килешенеп киткәннәр иде. Кичә күрше Рангазар авылына, мәктәпкә очрашуга бардым. Яп-яшь укытучылар, укучылар күтә иде. Унынчы класста биш егет, барлыгы 40 бала. Ә авылда 150 йорт. Мәчет.

“Рангазарда дин гомергә көчле булды”, диләр хуҗаларым. Монда типтәрмазар дигән бүленеш юк. Әле читтән кайтып урнашкан качаклар да юк. “Күрше

авылга...таҗиклар кайтты",—диде мәктәп директоры Мәҗит. Иске Әлмәттә укыту, мәктәп традицияләре юк, гомер-гомергә дүрт класс булган. Рангазарда бүтәнчәрәк, мәктәпне тәмамлаган яшьләрнең күбесе ВУЗларга китә, укымышлы кешеләр шактый. Коридор стенасында герой-пионерларның рәсемнәре, пионер оешмасына багышланган плакатлар. "Пионер оешмасын алыштырырлык нәрсә юк ич әле!"—диде директор. Егетләр дә, кызлар да биеделәр. Таза, сәламәт егетләр, үтә сылу кызлар. Биргән сорауларында да мәгънә бар. "Йөртә безне язмышлар"ны укыганнар. "Язмышка ышанасызмы, намаз укыйсызмы, ураза тотасызмы?" дип сорадылар. Ахырга таба мондый сорау да булды: "Сез...иң зур язучыларның берсе. Нигә сез мәктәп программаларында юк? Булган очракта да обзорный урыннарда гына..." Минем бу хакта ныклап уйлаганым юк та иде. Быел Бигештә, Алмазларда "Мәгариф" журналының былтыргы саннарын актарып, күзгә чалынган программаларны карагач мин мәктәпләрдә әле берни дә үзгәрмәгән дигән фикергә килдем. Шул ук Г. Гобәй, Г. Әпсәләмов, Ш. Рәкыйповлар кызыл почмактан көлеп карап торалар. Иконалар... Коммунистик әхлак белән агуланган тар маңгайлы программистлар әле һаман шул ленинизм идеяләрен тормышка ашырып яталар. Стандарт калыпка рәхәтләнеп сыя торган язучыларның иҗатын тырышып-тырышып мәктәпләргә тәкъдим итәләр. Кичә, берара шукланып, болай дияргә дә җыендым: "Программа төзүчеләр шул тиклем түбәндә калганнар ки, алар утырган эт биеклеге таулар түбәсенә генә үрмәләп менә алалар. Шуннан торып дөнья фәлсәфәсен, дөньяны, әдәбият кануннарын аңлаталар. Ә өстә Аяз Гыйләҗевләр барын, Гаяз Исхакый кебек гигантлар иҗаты әлегәчә сер булып сакланганын алар белми дә, белә дә алмый..." Тыелдым, дәшмәдем, сорауны уен-көлке белән үткәреп җибәрдем. Рангазар укытучылары арасында дөньяны аңларлык дәрәҗәгә күтәрелгән укытучылар да бар икән дигән фикер белән кайттым. Арык кына чәй өстәле әзерләгәннәр, табын тирәсендә сүзсез диярлек утырдылар. Нигә икән? Аңламадым.

Гигант "КамАЗ" белән барып алдылар, чак-чак ябышып мендем, бик биектән сикереп диярлек төштем. Әле дә аякларым сызлап, гүләп тора.

Кичә-бүген "Бригада" бүлеген яздым. Әле эшнең очы-кырые күренми. Тагын атна торсам эшне шактый алга илтер идем дип уйлыйм... Көннәр җылак, инде генә суыта дип торсаң, шалт, Мөхәммәтҗан! Мәскәүдә җебеп ага да безгә килеп җитә. Аптыраш.

Бүген Мансур улымның туган көне. Аңа утыз ике яшь... Әз түгел, валлаһи!

**1 февраль, Иске Әлмәт авылы**

Иртән радиода Мидхәт Миншин. Акыллы гына егет ләбаса! Татарстанны яклап ару гына сүзләр дә әйтә ала. Юк-букны лыкылдаган хәсрәт-депутатларга кадала да белә! Нигә без татарлар шундый икән, уң кулы белән эшләгәнен сул кул белән изеп ташлыйбыз!.. Бүген Мидхәт очына-очына бер татар гаиләсен мактый. Бер авылда (авылын ишетмәдем!) берәүләрнең җиде улы бар икән! Өлкәне дуңгыз бага, икенчесе фермада силос ташый, өченчесе тагын кемдер. Җиденче малай әле мәктәптә. Укый. Мидхәт төче тавыш белән сорый тегеңәрдән: "Укып бетергәч абыйларың кебек авылда каласыңдыр инде? "Малай яклана-яклана:" Калам! Әйе! Авылда!" ди... Бичара татар гаиләсе. Бичара татарлар тезелешеп сыер койрыгын борырга, дуңгызның маңкасын сөртергә калалар. Һәм шуны дөньяның алдын-артын белүче дип саналган Мидхәт Миншин мактап ята! Хурлык, оят, икмәктер... Шуннан соң ук радиодан берәү сөйли. Украинада туган, милләте поляк. Идел аша күпер сугучы коллективны җитәкләгән, Әгерҗедә тимер юл развязкасын ул башкарган. Хәзер Зөя елгасы аша күпер сугуны тәмамлаган да... Сорочье Горыда Чулман аша күпер сугарга керешкән. "Шушы күперне дә тәмамлый алсам..."дип хыялын да яшереп тормый. Әлләкем... Францевич... Хи-хи-хи! Чулман аша күпер сугарга керешәләр икән, бусы искиткеч шәп нәрсә! Күпер сугылып, су астында калган болыннарны әз-мәз дамбалар төзеп халыкка кайтара алсалар... Күпер башына: "Бу күперне фәлән пан, мөхтәрәм поляк җитәкләгән мәшһүр коллектив сукты", дип язып куячаклар. Кремль янындагы онкология диспансерына әлерәк кенә Мойше Зельманович Сигалга багыш-

лап истәлек тактасы куйдылар. Диспансерга Сигал исемен бирү хәл ителгән... Курашов ис. Институт... Сигал дигән больница... Мин бу мөгтәбәр затларның данын киметергә җыенмыйм. Ләкин нигә алай? Әхмәтҗанов Фоат дигән иптәш тә эшләде вә эшли ул онкология больницасында. Ул да өч меңнән артык операция ясаган һәм әйтүләренә караганда уңышлы ясаган. Фәнни хезмәтләре дә, шәкертләре дә бар... Ник Сигалны тәүге адымыннан башлап телдән төшермибез дә, нигә Әхмәтҗанов дигән татарны түргә уздырмыйбыз?! Нигә без җиде баласын да пычрак арасына керткән татарны мактап бөтәннәрне дә шул түбәнлектән чыкмаска котыртабыз? Менә ай буе авылда яшим, урамнарда җәяүле кешеләрне күрмим диярлек, бүген, туксан өчтә колхозчы машинага утырган. Иске Әлмәттә унбиш трактор бар. Арлы-бирле узып бульдозерлар йөри. «К-700» тракторы гөрс-мөрс үтеп тора. Дәү-дәү "КамАЗ"лар, "быел гына 3 "КамАЗ" алдык" ди председатель Нәҗип. Димәк, алдагы елларда да шулай булачак, адәмиләр машиналарга менеп утырачак. Фермаларда, кырларда бик аз кеше кирәк булачак. Урыс шәһәргә күченеп беткән, нәни-нәни урыс учаклары сүнгән. Нигә татарны югарыга өндәмибез без? Ник әзерләмибез? Торам-торам да хатынның колагын борам дигәндәй, теге җиде малайның һич югы бер-икесе укып, колхозга экономист, инженер булып кайтса?.. Акыл, белем, тапкырлык гаиләдән килә ләбаса! Бу ап-ачык нәрсә. "Оясында ни күрсә—очканында шул булыр", ди татар. Татарның ничә гасырлык зыялылары асылда мулла балалары булганнар. Татар укымышлылары нык, укымышлы гаиләләрдә туганнар. Әгәр без татарны һаман арзанлы араннарда авызлыклап тотабыз икән, алдагы көндә татар иле, татар җире, татар акылы белән идарә итәрлек кадрларны каян алырбыз?! Казанда җиде РОНОның җидесендә дә мөдир булып урыс агайнесе утыра дип зарлану ансат ул... Ә куярлык татарың бармы соң? Җиде буыннан бирле тоташ сыер койрыгын борган адәмнәрнең балалары каян килеп эчке милли хисләргә байый алсыннар?..

**2 февраль, Иске Әлмәт.**

Асылда кеше һәр таңда яңа кеше булып көнгә керә. Гомернең бер көне дә үзгәрешсез узмый. Кемнедер очратасың, уйларыңны уртаклашасың, йә син байыйсың, йә—югалтасың, димәк—үзгәрәсең. Дөнья хәлләре алмашына, үзгәрә, алар да сиңа тәэсир итми калмый. Бүген февраль бәяләрен күтәрделәр... мин өйдән чыгып киткәндә генә доллар 420 сумнар торса, бүген ул 580 сум... Болай барса 1000 сумга менеп җитәчәк тә болай да соңгы сулышында тилмереп яткан Рәчәй икътисадына аклы-каралы кәфен кигертәчәк. Шундый һәм шуңа охшаган меңнәрчә вакыйгалар адәм җанына тәэсир итми каламы?... Үзгәрәсең, алмашынасың. Син һәр иртәдә бер көн олырак булып туасың... Бәяләр, көнкүреш мөмкинлекләре тарая. Кичә Бунич белән Отто Лацис ил икътисады, яшәү-эш шартлары турында ике яклап сафсата сатып, ил язмышын, безнең башларны бутап утырдылар. Черномырдин да телевизорда күренеп китте. Өзеп кенә бер сүз дә әйтә алмыйлар. Сай суда чупырдашкан сабыйлар кебек шаулыйлар үзләре, күмәк авазлардан юньле бер мәгънә алырмын димә. Александр Васильевич Мерзленков сүзләре кабат-кабат искә төшә: "Россиядә ил башына менеп утырырлык затлар туа да, үсә дә алмый" дигән иде... Ленинны сызып ташларбыз, тәгълиматен чүплеккә чыгарып чөярбез. Сталинның гәүдәсен әллә нишләтә алмасак та исемен кат-кат капларбыз да... тормыш туры юлын табар дип ышанып килдем. Тормышның туры да, кыек та юлы юк икән. Тормыш, төп асылында, бер урында таптану вә берберенне изү-таптаудан гыйбарәт икән. Нигә? Таптану да хәрәкәт бит! Кемдер әзмәз кыймылдаганда да "алга барабыз, хәрәкәтләнәбез", дип үзе дә юанадыр, тирәяклап үзен камаган матдәләрне дә ышандыра аладыр. Йөз миллионлаган адәм бөртекләре арасында шушы боткадан аерылып чыгарлык көчле, гайрәтле берәү булмасын инде! Академик Бунич та, йорт хуҗасы Рәис тә нәкъ бер сүзне сөйлиләр: "Очына барып чыга торган түгел әле бу!.."

Кошлар усалланды, ди Рәис.—Юаш чыпчыкларга тиң азынды, язын авыр юлдан арып килгән сыерчыкларга тынгы бирмиләр. Оя тибеп утыра гына башлый бичара сыерчык, Югары оч чыпчыклары болыт булып очып киләләр дә оясыннан буранлатып куып чыгаралар тегене... Инде ничәмә ел сыерчыклар бала чыгара алмый...

Кара син, сыерчыкларга һөҗүм бөтен фронт буенча башланган икән. Займищеда мин элек өч оя куя торган идем, өч улымнан сыерчыкларга яз бүләге. Өч ояда мәж киләләр иде тырыш кошлар! Тора-бара оям бергә калды. Анысында да хәзер бүтән хуҗалар... Сыерчык очып килә, сайрап мең рәхмәтен безгә җиткерә, туган иленә кайтуына чиксез куана... Инде бала чыгарыр көннәрем җитә дигәндә генә кара канатлары белән ал таңнарны кисеп керәшәләр оча башлый. Әүвәл пычак канатларының очы белән ояга эз сала-сала кошның котын алалар. Аннары тәмам акылдан шашып оя тишегенә ядрә сыман атылып кереп, якты өметләренә куәт биреп күкәйләре өстендә утырган бичара ананы куып ук чыгаралар... Тәки кертмиләр! Бәбиләре шакып-шакып әнкәләренә эндәшсәләр дә җавап юк, керәшәләр җылы җан иярен тышка чыгарып ыргыталар... Явызлар! Үз балалары чыккач керәшәләр бу тирәгә тагын яу булып төшәләр, буш ояга кереп-чыгып балаларына явыз үгет бирәләр: "Менә... аларны оялар ясап, хөрмәтләп көтеп торалар!.. Бәйрәм ясап каршылыйлар... Ә без?.. Оя тибеп күпме көч түгәбез... Газап белән типкән ояларыбызны малайлар җимерә, тыелмас яңгыр сулары юа!.. Бик кинәнмәсеннәр әле сыерчыклар!"



*Аяз һәм Нәкыя Гыйләҗевләр, аларның өч улы һәм Нәкыянең әнисе Нәүбәһәр (алдагы рәттә, сулда).*

Саесканнар артты. Каргалар ишәйде. Хәзер тургай тавышы берән-сәрән генә ишетелә. Сандугачлар тынды!..

Кошлар усалланмый нишләсен? Алар мең еллардан бирле кеше белән янәшә яшиләр, адәм балаларының гореф-гадәтләрен күзәтәләр, адәмнәрне ялгыз калдырмыйлар...Ни өйрәнә алар адәмнәрнең гыйбрәтләрен күреп? Ни акыл ала? Күрегез дә торыгыз, ун-унбиш елдан соң чыпчык өерләре явызланып бала-чаганың күзен чокып чыгарачак, песиләргә отрядларына берләшеп кешеләрнең колагын чәйнәргә тотыначак...

Кошлар, кошкайлар, рәхәтләнеп күзәтегез мине! Карлы юлларның матурлыгына куанып бетә алмыйча сукмак-юллардан йөргәндә миңа ияреп янәшәмдә очыгыз. Песнәк-чыпчыклар! Карга-саесканнар!.. Күңелемдә инә очы хәтле дә явызлык юк... Әүлияләр мәңгегә йокыга талган изге төбәктә күңелемә гел ак уйлар гына иңә!..

*Дәвамы киләсе саннарда*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ШӘТХ*** *г.* – Экстаз халәтенә ирешкән һәм үз-үзенә контролен җуйган суфи авызыннан чыккан сүз, фикер, хикмәт. Бу термин шушы экстаз халәтенә карата да кулланылган. Күплек саны шәкеле-*шәтахәт* яки *шәтхийәт*. Шәтх, әлбәттә, иррациональ һәм суфилар аның мәгънәсен шушындый ук хәлне кичергән кеше генә аңлый һәм аңа бәя бирә ала дип санаганнар.

Әл-Хәллаҗның: "Мин – Алламын!" ("әнә-лХакк") дигән сүзен шәтхийәтнең аеруча ачык бер тарихи мисалы дип әйтергә була. әл-Бистаминың: "Мин ничек данлыклымын! О, мин ничек бөекмен!" дигән сүзләре дә күбәүләргә мәгълүм. Әш-Шиблинең күпсанлы шәтхләреннән берсе түбәндәгечә яңгырый: "Сезнең заманагыз бетә, ә минем заманамның ахыры да, башы да юк!" Әбү Сәгыйтьнең сүзләре тагын да кыюрак: "Минем сәләмә киемем эчендә Аллаһтан башка берәү дә юк!"

Шәтхийәт турында төрле карашлар була. Суфилар һәм аларга уңай караучы дин әһелләре шәтхләрне аңлатудан һәм тәнкыйтьләүдән баш тартырга, йә бу эшне аерым "сайланмыш затларга (хәвассларга) тапшырырга кирәк дигән фикердә торалар. Суфи экстаз халәтендә Аллаһның рупорына әйләнә, шуңа күрә бу сүзләре өчен суфи җаваплы түгел дигән караш та киң таралган була. Шулай да, мәсәлән, әл-Газәли шәтхләрне тәнкыйть итеп, алар халыкны көндәлек хезмәттән аерып, фетнәгә этәрәләр дип саный. Кайберәүләр (мәс., әл-Җүнәйд) мондый экстаз халәтендә әйтелгән сүзләргә каршы чыгалар, хакыйкатькә ирешкәннәрнең илаһи серләрне ачуы мәгънәсез һәм хәтәр бер эш дигән фикердә торалар.

Шәтхийәт шигъри әсәрләрдә бик еш очраган. Әл-Хәллаҗ, Ибн әл-Фәрид, Ибн Гарәби, Руми диваннарында шәтхләр аеруча күп.

XIV гасырларда эш практикаларында шәтх куллануны үзмаксат итеп алган суфиларны *шәтихун* дип атаганнар.

***ШӘФӘГАТЬ*** *г.* – Яклау, канат астына алу, аралау, химая, ярдәм Исламда: Кыямәт көнендә яклау табу. Бу көнне өч төркем кешеләр шәфәгать кыла алачак: пәйгамбәрләр, галимнәр һәм Аллаһ юлында шәһид киткәннәр. Шәфәгать өч баскычтан тора: 1)Кыямәт көнендә Пәйгамбәр Аллаһтан адәмнәрнең җирдә кылган эшләре өчен хисап тоту вакытын һәм аның авырлыгын киметүне сорый ала. 2)Кайбер бәхетле кешеләр кылган кылыклары өчен сорау алусыз гына оҗмахка кертелергә мөмкин. Хәдистә бу баскычның да Пәйгамбәр карамагында булуы әйтелә. 3)Тәмугка лаек булган кайбер кешеләргә карата. Мондый шәфәгать тә Пәйгамбәр соравы буенча яки Аллаһ Үзе сайлаган кешеләрнең үтенече буенча кылына. 4)Инде тәмугка кертелгән гөнаһкярларга карата. Алар өчен Пәйгамбәр, фәрештәләр һәм кайбер мөселманнар ялварып сорарга мөмкин. Гомерләренә бер генә тапкыр "*Лә иләһә иллә-л-Лаh*" дип әйткән гөнаһкярлар тәмуггтан чыгарылачак. 5)Оҗмахка кертелгән аерым кешеләрнең дәрәҗәсен күтәрүне сорап шәфәгать кылу.

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

***ШӘФКАТЬ*** *г.* — Мәрхәмәт, рәхим, аяу. Гади сөйләмдә еш кына *"шәфәгать"* рәвешендә әйтелә, ягъни башка мәгънәдәге сүз белән керешә.

***ШӘХЕС КУЛЬТЫ*** — Иң куркынычлы социаль авыруларның берсе — эреле-ваклы шәхесләргә табынуның гавәми (массакүләм) төс алуы. Ленин, Сталин, Брежнев кебек "даһилар"га табыну күпләгән халыкларны тимер богауларда тотты һәм әле дә тота. Бик күбәүләр үзләре кебек үк шәхесләр алдында кимсенеп, аларны башкалардан өстен куралар, алар ниндидер аерым сыйфатларга ия дип уйлыйлар. Җентекләбрәк караганда исә мондый табынуның төбендә карьерачылык, комсызлык, эгоизм, ә кайчакта рухи авыру кебек әхлаксыз яки патологик сыйфатлар ята.

Ислам Аллаһыдан башка кемгә булса да табынуны кире кага. Шәхес культы гади бер гөнаһ кына түгел, бәлки Аллаһыга шәрик катнаштыру булып исәпләнә. Изге Коръәннең иң бөек кагыйдәләреннән берсе — Аллаһыга гына табыну, теләсә кайсы кеше алдында табынудан ваз кичү.

Хәлбуки, Будда үзе исән вакытта алла роленә дәгъва кылмаган. Әмма үзе үлгәч, тарафдарлары аны алла кебек итеп зурлый башлаганнар.

Исламда да Пәйгамбәрне аллалаштыру куркынычы булган. Чын Ислам диненчә, Мөхәммәд башкалар кебек үк гап-гади кеше. Ул Аллаһының колы һәм Аның илчесе. Коръән-каримдә болай диелә: "Әйт: "Мин сезнең кебек бер инсанмын, миңа Аллаһыдан вәхий булды, сезнең Илаһыгыз — барча вөҗүдкә бер генә Аллаһы дип. Әгәр берәү Раббысына яхшы хәлдә юлыкмакны теләсә, ул кеше яхшы эшләрне эшләсен, изге гамәлләрне кылсын, әмма Раббысына тиешле булган гыйбадәтенә һичкемне шәрик-тиңдәш кылмасын" ("Тау тишеге" сүрәсе: 110). Рәсүлебез бу васыятьне һәрвакыт һәм һәрнәрсәдә саклаган, тыйнак кеше булып калган, үзен кешеләрдән өстен итәргә тырышучыларга моны рөхсәт итмәгән.

"Азатлык" радиосы бу терминны *шәхес шөһрәте* дип әйтә торган иде.

***ШӘХСӘЙ-ВӘХСӘЙ ЙОЛАСЫ*** — Мөхәррәмнең унысында шигыйлар урамда Хөсәенне искә алып елау-сыктау оештыралар. Нәмаешта катнашучыларның кайберләре үзләрен-үзләре җәрәхәтләп, Хөсәен гаскәренең өммәвиләр белән сугышын искә төшерәләр һәм гадәттә *"Шаһ Хөсәен, ваһ Хөсәен!"* дигән сүзләрне кабатлыйлар. Шушы сүзләргә карап, гашурә *шәхсәй-вәхсәй* дип тә атала. Сөнниләрдә мондый йола юк.

***ШӘҺӘРЛЕК*** — **1**.Борынгы шәһәр булган урын һәм андагы хәрабәләр. **2.**Шәһәр кешесе. *//Шәһәрлекләр сала кызыны яратмаслар.* Ф.Халиди.

***ШӘҺИД, ШӘҺИДӘ*** — Хак эш өчен сугышта һәлак булган; дин өчен үтерелгән. Русча *мученик* сүзенә туры килә. Ләкин бала тапкан вакытта үлгән аналар да "иман хакына" һәлак булучылар исәбенә кертелә. *//Шәһид китү. Шәһид кылу.* (Берәү тарафыннан) *шәһид ителү. Хакый- кый (чын) шәһид*-Аллаһ юлында милләт һәм мәмләкәт мәнфәгате өчен җанын фида иткән кеше. *Хөкми шәһид* — суда баткан, бала тапканда үлгән, ваба авыруыннан үлгән, хаксызга үтерелгән һ.б. мөэмин яки мөэминә.

***ШИГЫЙЛАР*** *г.* — Ислам динендә шигыйчылык тарафдарлары (*шига, шыйга*-гарәпчә "төркем", "фирка" дигән сүз; *шыйга Гали*-Гали төркеме, Гали фиркасы яки партиясе). Пәйгамбәрнең вафатыннан соң аның сәхабәләреннән бер төркем (Пәйгамбәрнең агасы әл-Габбас һәм аның гаиләсе, Әбү Зәр, әл-Микдад әл-Кинди, Сәлман әл-Фариси, Гаммәр ибн Ясир, Әбү Әйүб әл-Әнсари, Билял әл-Хәбәши, Халид ибн Сәгыйд һәм Зөбәер) Гали ибн Әбүталибны Пәйгамбәрнең варисы һәм хәлифә итеп тануны яклап чыкканнар. Бу вакытта бәхәс һәм каршылыклар асылда дини мәсьәләләргә кагылмаган, фәкать варис турындагы мәсьәлә генә кузгатылган. Тора-бара шигыйлар хәрәкәте көчәйгән һәм Хәлифәтнең көнчыгыш төбәкләрендә (Гыйракта һәм Иранда) киң таралыш алган. Безнең якларга килгәндә, аз санда гына шигыйлар Башкортстанда да бар ("Башкортостан" энциклопедиясе).

Төптә "шигый" термины "сөнни" терминына таңгал: беренчесе — "Ибраһим тарафдарын", икенчесе исә "беренче пәйгамбәрләр тарафдарын" белдерә.

Төркиядә шигыйларны *"галәвиләр"*, ягъни Галигә иярүчеләр дип атыйлар.
Кара: Шигыйчылык.

***ШИГЫЙЧЫЛЫК*** — Мөхәммәд Пәйгамбәрнең кияве дүртенче хәлифә Гали бине Әбү Талиб һәм аның балаларына тарафдарлык. Бу мәзһәбнең нигезен Гали хәлифәнең замандашы *Габдулла бин Сәба* салган дип исәпләнелә. Юнәлешләре: *кайсанилар, зәйдиләр, имамилар, исмәгыйлиләр*. Аннары *хариҗилар* аерылып чыга (VII гасыр ахыры).

Шигыйчылык Гыйракта, Иранда, Йәмәндә, Пакистанда, Әфганстанда һәм Һиндстанда таралган, беркадәр Әзәрбайҗанда һәм Таҗикстанда сакланган. 1501 елда Исмәгыйль шаһ шигыйчылыкны Иранның рәсми мәзһәбе дип игълан итә һәм шигыйчылыкны пропагандалау өчен Төркиягә бик күп миссионерларын җибәрә. Шул рәвешле, XVI гасырга шигыйчылык Иранда һәм кайбер кенәзлекләрдә дәүләт диненә әйләнә. Шуңа күрә күбәүләр шигыйчылыкны ирани чыгышлы дип саныйлар, ләкин чынлыкта ул гарәпләр дөньясында туган.

Шигыйлар гасырлар буена хакимиятне Гали варисларына кайтару өчен көрәшәләр һәм вакыт-вакыт төрле илләрдә моңа ирешәләр дә (мәс., Тәбәристанда, Йәмәндә, Мисырда галәвиләр дәүләте төзиләр).

Аллаһуның берлеген һәм Мөхәммәднең аның рәсүле икәнлеген игълан итә торган иң мөһим гыйбарәдә *"Лә иләһә илләл-Лаһ, Мөхәммәд расүлүл-Лаһ"* — Аллаһудан башка илаһ юк, ә Мөхәммәд аның рәсүле" дию урынына алар ахырда Мөхәммәдтән соң "һәм Гали-Аллаһуның якыны" сүзләрен өстиләр яки хәтта Мөхәммәд Пәйгамбәр исемен бөтенләй төшереп калдыралар.

Шигый азанында да аермалар бар. Шигыйларда азанның бишенче һәм алтынчы формулалары арасына бер җөмлә ("Иң күркәм эшкә килегез!") өстәлгән була. Аннары аларда азанны теләсә кайсы мөселман әйтә ала.

Шунысы кызык, шигыйлар үзләрен сөнниләрдән дә "сөннирәк" дип саныйлар, чөнки алар Пәйгамбәр сөннәсенең изге хәлифәләр чорында үзгәртелгән яки гамәлдән чыгарылган элементларын саклап калдык дип раслыйлар. Алар үзләрен "мәзхәб әл-хасса", ягъни "сайланмышлар мәзхәбе", "өстеннәр мәзхәбе" әгъзалары дип исәплиләр.

Җыйнап кына әйткәндә, шигыйчылык тәгълиматы 5 догматны таный, болар: *таухид* (Аллаһның берлеге), *гадел*, *нәбүват* (пәйгамбәрлек), *имамат* (имамнар җитәкчелеге) һәм *кыямәт* (үлгәннән соң терелү).

Шигыйлар, Мәккәдән тыш, Гали каберенә (Гыйрактагы Нәҗәф шәһәрендә) һәм имам Хөсәен каберенә (Гыйрактагы Кәрбала шәһәрендә) хаҗ кылырга баралар.

Исламда гомум кабул ителгән бәйрәм һәм мөбәрак көннәргә өстәп, шигыйлар түбәндәге көннәрне дә билгеләп үтәләр:

1) Имам Хөсәен һәм аның тарафдарларының газаплануы көне — Сәфәрнең 20 нче көне.

2) Фатыйманың вафат булу көне — җөмадел-әүвәл аеның 13 нче көне.

3) Галинең туган көне — рәҗәп аеның 13 нче көне.

4) Гали үлем ярасы алган көн-рамазан аеның 19 нчы көне.

5) Гадир әл-Хумм көне — зөлхиҗҗәнең 18 нче көнендә бәйрәм ителә. Шигыйлар дөрес хәдис дип тапкан бер ривайәт буенча, бу көнне, Хушлашу хаҗыннан кайтып килешли, Мәккә белән Мәдинә арасында урнашкан Гадир әл Хумм дигән су буенда Мөхәммәд пәйгамбәр күпләгән халык алдында Гали ибн Әбүталибны үзенең варисы итеп билгели. Ләкин сөнни галимнәр бу хәдисне мәүду, ягъни ышанычсыз дип саныйлар.

Гашурә исә, имам Хөсәен һәм аның тарафдарларының үлеменә багышланган матәм көннәре буларак, шигыйларда мөхәррәм аеның 1 сеннән 10 сына кадәр дәвам итә. Ә сөнниләрдә гашурә мөхәррәмнең 10 нчы көнендә билгеләп үтелә.

Шигыйларда бу бәйрәмнәрнең күбесе 963 елда хәлифә Мүгиз әл-Дауд (хакимияте 945-967 еллар) тарафыннан рәсми рәвештә кертелә.

Һиҗрәт кичәсе шигыйларда бәйрәм ителми.

Шигыйларның сөннәсе сөнниләрнекеннән аерыла. Шигыйлар сөннәсендә "Әхбар", ягъни "Хәбәрләр" (ривайәтләр) тупланган. Анда, сөнниләр тарафыннан танылган хәдисләрдән тыш, Гали нәселеннән булган имамнарның сүзләренә дә зур урын бирелә.

Шигыйлар Галигә каршы сәхабәләрдән килгән хәдисләрне тапшыручыларны кире кагалар. Гомумән, алар Гали хәлифәне Мөхәммәд Пәйгамбәр варислыгына өстен хокукка ия булган дип саныйлар. Шигыйлар мәһди турындагы һәм Гали хәлифәнең уникe варисы турындагы тәгълиматны тоталар.

Шига һәм ваһһабилар тәһарәт алганда аякларын юмыйлар, димәк, аларның тәһарәтләре камил булмый.

Шигыйларда язмаларда рәсем төшерү дә гөнаһ саналмый.

Шигыйлар Коръәннең бүгенге мәтенен шик астына куялар, иң ахыргы "Фәләкъ" һәм "Нәс" сүрәләрен, харижилар исә "Йосыф" сүрәсен дә инкяр итәләр. Алар Галинең хәлифәлеккә хокукы күрсәтелгән "Ике нур" дигән сүрә һәм башка сүрәләрдәге кайбер аятьләр Госман мәтененә кертелми калдырылган дип раслыйлар. ("Ике нур" дигәндә алар Мөхәммәд белән Галине күздә тоталар.) Алар фикеренчә, Коръәннең төп нөсхәсе *"Яшерен имам"* кулында саклана, ул кайткач кешеләр чын Иманны беләчәкләр имеш.

Гакыйдәдә булган аерымлыкларга да карамастан, бүгенге көндә сөнниләр белән шигыйларның диннәре төрле дип әйтергә урын юк,—бусы принципиаль нәрсә.

"Краткая история Ислама" китабында (М., 2002) шигыйчылыктагы сөнниләр күзлегеннән караганда уңай һәм тискәре ("плюс" һәм "минус") моментларның кыска гына исемлеге китерелә. Уңай моментлар түбәндәгеләр: үзәкләштерелгән идарә (имамнар, факиһлар, Ага-ханнар һ.б.), иҗтиһад капкасының ачык булуы (яңа дини кануннар һәм принциплар кертү һәм аларны дәлилләү мөмкинлеге), организацион бердәмлек, пассионарлыкның гаять югары булуы.

Тагын кара: ***ГАБДУЛЛА БИН СӘБА.***

***ШИГЪРА*** *г.*—Сириус йолдызы. "Нәҗем" (53) сүрәсенең 49 нчы аятендә шул йолдыз турында сүз бара: "Дәхи Ул—Аллаһ Шигъра йолдызының Раббысыдыр". Мәҗүсиләр көньяк күгенең иң якты йолдызы Сириусны аллалаштырганнар.

***ШИМАЛЬ*** *г.*—**1**.Сул кул як. **2**.Төньяк. *Сул як* һәм *төн ягы* мәгънәләренең бер үк сүз белән бирелүе борынгы гарәпләрдә алгы (төп) як булып кояш чыгышы, көнчыгыш, шәрык саналганлыгы турында сөйли дип әйтә алабыз // *Шималь гарби*—төньяк-көнбатыш. *Шималь шәркый*—төньяк-көнчыгыш. *"Шималь ягы"*—1918 елның башында Петроградта чыгып алган татарча гәзит, аны милләтчеләр нәшер иткән.

***ШИМБӘ*** *ф.*—Атнаның җомгадан соңгы көне. Татарлар *аны "җомга иртәсе көне"* дип тә йөрткәннәр. Иске китапларда *шинбә, шәнбә.* "Шимбә" сүзе көрдчә "көн" дигән мәгънәдә (фарсылардагы—"рузе", гарәпләрдәге—"йаум"). Р.Әхмәтьянов шимбә сүзенең асыл мәгънәсе—"җиде көнлек атна ахыры" икәнен һәм аның нигезе мөселманнарда, христианнарда һәм йәһүдләрдә таралган булуын искәртә.

Ж.Г.Зәйнуллин бу сүзнең татарча укылышы *шәмбе* дип күрсәтә ("Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба"). XX гасыр башларында Казанда дәүләт мәктәпләрендә укучы яшьләр оештырган әдәби түгәрәк "Шинбә" дип аталган.

Шимбә—еврейләрдә буш, ягъни эшсез көн (*шабат / шабаш*). Ногмани тәфсирендә Муса пәйгамбәрнең йәһүдләргә җомга көнне олугларга кушуына да карамастан, аларның шимбә көнне зурлау өчен тартышуы турында әйтелә. "Шуның өчен Аллаһу Тәгалә йәһүдләргә шимбә көнне бик зарарлы кыла, дөнья кәсебен аларга хәрам кыла" ("Умарта кортлары" сүрәсе, 16:124).

Чыганакларда шимбә көнне *сабәт / сәбәт* (суббота) дип атау очрый.

Татарда "Им көне—шимбә көн" дигән борынгы сүз бар.

***ШИРЕК*** *г.*—Күп аллага табынучылык, мәҗүсилек. Аллаһтан башка тәңреләргә, шулай ук төрле нәрсәләргә һәм кешеләргә табыну Исламда иң авыр гөнаһ (*кәбирә*) һәм көферлек дип карала. Ширек категориясенең гомум кабул ителгән билгеләмәсе булуга да карамастан, бу мәсьәлә электән үк төрле бәхәсләргә урын калдырган. Мәс., сөнниләр шигыйларны күп аллага табынуда гаепләгәннәр. Әл-Газали матди табыш алу максаты белән Аллаһка табыну да ширек була дип санаган. Хәнбәлиләр ширек мәсьәләсенә көндәлек тормышта да зур урын биргәннәр, үткән замандагы яки хәзерге абруйлы руханиларны артык мактау, зиратларга барып сәҗдә кылу, кешеләрне аягүрә

торып каршы алуны да гаепләп чыкканнар. Хәзерге вакытта ваһһабилар кабул иткән ширек теориясен хәнбәлиләр эшләгән. Бу теория буенча ширекнең 5 төре бар: 1)*Ширек әл-гыйлем* — барлык пәйгамбәрләрне, киләчәкне алдан күрүче әүлияларны, астрологларны "яшерен гыйлем"гә ия дип санау; 2)*Ширек әт-тәсарруф* — Кыямәт көнендә Мөхәммәдкә биреләчәк арадашчылык хокукына кемнең дә булса ия булуын тану; 3)*Ширек әл-гыйбадәт* — Аллаһтан башка кемгә яки нәрсәгә булса да (беренче нәүбәттә каберләргә, ташларга) табыну; 4)*Ширек әл-гадәт* — хорафатларга һәм "яман" гореф-гадәтләргә ышану (начар һәм яхшы көннәр булуына, галәмәтләргә ышану, хаҗәте булмаганда бөти-томырлар тагып йөрү); 5)*Ширек фи-л-әдәб* — Мөхәммәд, Гали исемнәре һәм мөселман өммәтендәге башка абруйлы исемнәр белән ант итү.

Аллаһуга ширек кату, ширек катнаштыру, ширек кылу (ширкәт кату варианты да очрый).

***ШИРКӘТ*** *г.* — Җәмгыять, компания, кооперация; бергәләп эш итү. Ширкәтнең дүрт төре бар: 1) тулы ширкәт — монда катнашучылар бертигез өлеш кертәләр һәм аларның мөмкинлекләре дә бертигез була, ягъни алар бер үк эш белән шөгыльләнүче иректле мөселманнар; 2) тулы булмаган ширкәт, монда үзара килешү генә кирәк, ә бертигез өлеш кертү таләп ителми; 3) максатлы ширкәт, монда уртак капитал булмаска да мөмкин, ләкин уртак эш бар һәм аны кредитка алып барырга ярый; 4) ширкәт-кооперация, монда уртак эш өчен төрле һөнәр әһелләре берләшә. Дөрес, кайбер мәзһәбләрдә ширкәтнең соңгы ике төрен танымыйлар, чөнки аларда уртак мал юк. // *Ширкәт кагыйдәсе* — иптәшлек кагыйдәсе.

***ШКОЛА*** *р.* — XIX гасырның икенче яртысында Халык Мәгарифе Министрлыгы һәм земстволар ачкан башлангыч мәктәпләр, изге Гурий борадәрлеге мәктәпләре, рус-татар уку йортлары (училищелар), чиркәү мәхәллә мәктәпләре "школа" дип аталган. Гомумән, татар халкы "школа" дигәндә әлеге рус-татар училищеларын күздә тоткан. Рәсми документларда һәм халык телендә татар уку йортларын "мәктәп" һәм "мәдрәсәләр" дип йөрткәннәр.

***ШОНКАР*** — Төркиләр изге дип санаган һәм кулга ияләштереп сунарда файдаланган кош, бөркет, лачын. Ауга өйрәтелгән яшь бөркетне һәм лачынны күп кенә төрки халыклар *валабан/балабан* яки *әтәлге* дип атаганнар, ләкин татарда: "Әтәлге шонкар булмас" дигән мәкаль дә бар. Лачынның бер төре *тырантай* да ау кошы итеп кулланылган. Үзбәкләр очарга өйрәнүче яшь лачынны *"очырма"* ("учирма") дигәннәр. Татар әкиятләрендә *Сонгур хан*-кошлар патшасы. Электә Казанда шонкарчылар (Соколовая) урамы да булуы билгеле.

Борынгы чыганакларга караганда, шонкар белән ауда йөрү татар ханнары арасында да таралган була. Хикәятләрдә *"кош чөймәгә ау аулай"* гыйбарәсе очрый. Лачын җибәреп аулауны *лачын салу* дигәннәр. Ау кошларына нисбәтле терминология дә эшләнгән булган. Мәс., *"тугры"* ("тур", "тургач") — ау кошын (лачын, бөркет) кундырып йөртә торган агач; *"томага"* — сунар шонкарының башына кидерелә торган күн башлык яки *"тумак"* — ау кошларының калфагы. Хан яки кенәзләр ауга чыкканда бөркетләрне карый торган кешене *"кошчы"* һәм *"кош бәге"* дип атаганнар.

***ШӨКЕР*** *г.* — **1.** Күргән яхшылыкка каршы рәхмәт һәм шатлык белдерү. // *Шөкерана, шөкран(а)* — шөкерләр (гарәпчә *шөкер* сүзенә ирани *-ана* кушымчасы ялганып ясалган). **2.** Ризалык, канәгатьлек күрсәтү.

Шөкранның өч төре бар дип караганнар: 1)гәүдә белән белдерелгән шөкер — *габидләр шөкере*; 2)тел белән шөкер итү-*галимнәр шөкере*; 3) кальбтән чыккан шөкер — *гарифлар шөкере*.

// *Шөкер Бари* — Аллага шөкер. *Шөкран нигъмәт* — ризыкка шөкер итү. *Аллаһка шөкранә кылу. Раббыма мең шөкранәмен!*

*"Шөкер"* сүзе "Псалтирь"ның (Казан, 1914) керәшеннәр өчен татарчага тәрҗемәсендә дә актив кулланылган.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Радик Фәизов

### Забастовка

Совет хакимияте чорында эшчеләр барысына да түзеп яшәделәр, бернинди ачыктан-ачык ризасызлык белдерүләр, эш ташлаулар, забастовкалар булмады дигән фикер яши. Дөрес түгел бу! Мин үзем 1957—1965 елларда Уралның тоташтан диярлек эшчеләр шәһәре булган Магнитогорскида тордым. Төзү трестының тимер юлында, паровозда эшләдем. Безнең шәһәргә Кемерово шахтерлары күтәргән зур чуалышлар турында хәбәр килеп иреште. Анда эшчеләр ашханәләрендә хезмәт күрсәтү, ризыкларның сыйфаты бик түбән булган. Төрле түрәләр һәм чиновниклар эшчеләрнең ихтыяжларына төкереп караган. Менә көннәрдән бер көнне атаклы пролетариат баш күтәрә. Ашханәләрне, идарә биналарын ватып- җимереп ташлыйлар, ул хәрабәләрне куәтле бульдозерларга утырып җир белән тигезлиләр. Котлары алынган шахта идарәсе түрәләре алдына катгый таләпләр куялар. Ачулары тәмам кабарган баш күтәрүчеләрне гаскәр чакыртып кына тынычландыра алганнар. Әмма эшчеләр куйган барлык таләпләр дә үтәлгән. Ә төп гаепне идарәче түрәләр һәм чиновниклар өстенә китереп салганнар. Алар тиешле җәзаларын алган.

Безнең Магнитогорскида да булды андый эш ташлаулар. Хәтта бер генә дә түгел, ике тапкыр! Һәм аларның икесенә дә мин үзем шаһит булдым.

Тимер юлда поездларны тартып йөргән локомотивлар өчен генә түгел, вагоннар өчен да аерым деполар бар. Биредә аларны рәтлиләр-төзәтәләр, күп йөреп тузган тәгәрмәчләрен алмаштырып куялар. Беркөн безнең паровоз бригадасын шунда җибәрделәр. Монда инде смена буена хәрәкәттә буласың, түгәрәк эчендәге тиендәй әйләнәсең. Төзәтәсе вагоннарны аралап депога кертергә, ә инде төзәтелгәннәрен станция юлларына чыгарып куярга кирәк. Ярый, без смена башында депо капкасы янына килеп туктадык, ә анда гомер булмаганны, бернинди хәрәкәт-фәлән сизелми, хәтта безне каршы алучы да юк. Берничә тапкыр гудок биргәч кенә олы капкадагы кечкенә ишек ачылды, аннан безгә таныш слесарь Василий дәдәй чыкты.

—Без эш ташладык бүген, егетләр. Бүген бездә—забастовка! Әгәренки без куйган таләпләрне үтәмиләр икән, эшкә башламыйбыз да,—диде ул мыегын бик тәвәккәл төстә кабартып һәм әйтте.—Ә сез кире кайтып китегез. Бүген монда сезгә эш булмас,—диде һәм кире депога кереп тә китте.

Без исә үз колакларыбызга үзебез ышанмыйча тордык. Нәрсә диде соң әле бу дәдәй, «забастовка» диде түгелме?! Соң, забастовка бит инде ул аларда—капиталистик илләрдә генә була. Мин үзебезнең машинист Саша белән вагоннар ялгаучы Иванга карадым. Алар да бик аптыраштa торалар иде.

—Әйдәмәкәй без дә депога керәбез! Ничек була икән ул баш күтәрү? Шуны күрербез,—дидем мин үзем эчтән куркып кына.

—Әйдә. Ул-бу була калса, безгә нәрсә, чыгабыз да таябыз,—диде Иван да. Һәм без тәвәккәлләдек. Паровоз будкасында Саша гына калды.

Кешеләр генә үтеп йөри торган тар ишектән керсәк, андагы хәлләр! Депо тулы халык, тик берсе дә эшләми. Кешеләрнең йөзендә ачу, тәвәккәллек, күбесе тәмәке тартә. Нindидер авыр, шомлы халәт. Эшчеләр, дулкынланудан,

күрәсең, бер урында гына басып тора алмыйлар, йөренәләр. Түрдәрәк, сәхнә кебек биек урында, депо түрәләре. Ул арада шәһәр комитетыннан, тресттан яхшы киемле күркәм адәмнәр килеп төште. Күрәбез, алар да бик дулкынлана, араларында култык асларына папкалар кыстырган елгыр адәмнәр йөренә... Әйе, эшләр зурга киткән биредә.

Менә шәһәрнең төзелеш тресты башлыгы Анкудинов үзе сәхнә алдына чыкты. Мәһабәт гәүдәле, кырыс йөзле бу түрәне бөтен шәһәрдә бик яхшы беләләр, ихтирам итәләр. Ул кулын күтәреп игътибар сорады, бик җай гына сүз башлады:

—Иптәшләр, тынычланыйк әле. Бу сезнең сәяси чыгышка әйләнә күрмәсен. Без, әлбәттә, хәлне бик җентекләп тикшерербез. Ә хәзергә әйбәт кенә эш урыннарына таралышыйк,—диде.

Әмма ләкин депо халкы аяк терәп каршы төште:

—Юк, таралышмыйбыз!

—Мондый шартларда эшләп булмый.

—Хәзер без куясы таләпләр үтәлмәсә, беркем дә эшкә башламаячак!

—Алайса, берегез генә сөйләсен,—диде җитәкче.

Шунда эшчеләр арасыннан Андрей дәдәй алга чыгып басты. Ап-ак зур башлы, олпат гәүдәле, нәкъ борынгы эшчеләр кебек итеп киң күн алъяпкыч япкан тимерче Андрей дәдәйне барысы да белә, хөрмәт итә иде. Аны Анкудинов үзе дә белә булып чыкты.

—Рәхим итегез, Андрей дәдәй, курыкмыйча сөйләгез!—диде ул ихтирам белән.

—Син, Леонид Георгиевич, кайчандыр үзең дә гади эшче булган кеше. Син безне аңлыйсың, эшләрнең ничек барганын да бик беләсең. Соң бит, Борчак патша заманында да эшче болай яшәмәде. Син аның монысын да беләсең... Безнең нормировщик Чувашин чыксын әле!—диде өлкән эшче.

Сәхнә алдына олы яшьтәге, бөтен йөзен диярлек каплаган зур күзлек кигән, алга йөгенгән тәбәнәк гәүдәле, ябык кына бер адәм чыгып басты.

—Әйтеп бир әле шуны, Чувашин!—диде аңа Андрей дәдәй.—Әле быелның башыннан гына да безнең расценкаларны ничә тапкыр кистең син? Менә мин, алтынчы разрядлы тимерче, күпме генә эш хакы алам хәзер? Айлык ике йөз сум акчага мин ишле гаиләм белән ничек көн итәргә тиеш? Шуны әйтеп бир син. Дөресен генә әйт!—дип боерды тимерче.

Чувашин тагын да йөгенә төште. Бик курыккан, каушаган төстә әле үзеннән җавап көткән эшчеләргә, әле түрәләргә карап алды. Тегеләрнең берсе «сөйләргә мөмкин!» дигәндәй баш каккач кына сүзгә керește. Анда да төпле сүз әйтә алмады.

—Без... нәрсә? Гаеп бездә түгел. Расценкалар алар безгә өстән төшә. Алтынчы разрядка ике йөз сум аз инде ул анысы. Без дә берни эшли алмыйбыз...—дип сөйләнде.

—Ә сез нинди таләпләр куясыз, Андрей дәдәй?—диде Анкудинов.

—Без халык белән болай киңәштек. Булмастайдан кубып сорамыйбыз. Әмма үзебез куйганнан бер карыш та чигенмибез дә. Алтынчы разрядка—өч йөз илле, дүртенчегә—ике йөз илле. Безгә әлегә шул да җитеп тора. Тамак туйса, азрак өс-башка алырга булса, шул ярар. Күрәсез, безнең таләпләр икътисади, бер кәлимә сәяси сүз әйтмибез!—диде Андрей дәдәй нык итеп. Бөтен халык гөрләтеп кул чапты.

Түрәләр сәхнә артына кереп киттеләр. Озак кына киңәштеләр алар анда. Әмма эшче халык сабыр гына көтеп торды, тәмәкесен тартты. Бернинди тәртип бозу, сүгенүләр, кычкырулар булмады. Бераздан шул ук Анкудинов чыкты.

—Сез куйган шартлар тулысынча үтәлә. Иптәшләр, киләсе айда ук үзегез билгеләгән күләмдә хезмәт хакы алачаксыз!—диде башлык күнелле итеп.—Ә хәзер, рәхим итеп, барыбыз да эшкә башлыйк. Карагыз, бу инде бернинди

эш ташлау-фәлән булмасын. Эш турында кинәшмә генә булды бу. Үзегез дә бик шапылдап йөрмәгез. Шулай дип килешик!—диде ул. Түрәләр алар ничек сөйләшергә кирәк икәнен беләләр иде шул.

Ләкин әле тагын бер таләп ишетелде:

—Нормировщик Чувашинны эшеннән азат итегез. Ул инде болай да күптән пенсиядә. Утырмасын безнең муенга атланып!

—Монысы да үтәлер!

Һәм ни диярсез?! Деподагы эшче халкы куйган барлык таләпләр үтәлде. Вагон төзәтүчеләр үзләре билгеләгән хезмәт хакын тулысынча алдылар. Чувашин да инде депода бүтән күренмәде. Әмма, трест управляющие сылап кына куйганча, эш турында гади генә кинәшмә булмады бу. Ә чын забастовка, эш ташлау булды. Әгәр шунда эшчеләр куйган таләпләр үтәлмәсә, түрәләр тупаслык күрсәтсә, эшләр кая киткән булыр иде тагын?

Нәкъ шундый ук икенче забастовканы мин калибровка заводында күрдем. Бу заводта күп төрле әйберләр: ак калай, кадак, төрле юанлыктагы тимер арканнар, тагын бик күп әйберләр ясыйлар. Продукциянең зур күпчелеге, аеруча ак калай, тугандаш социалистик илләргә чыгарыла. Без шунда төялгән вагоннарны алып чыгарга дип бу завод цехларына еш керәбез. Иң яхшы калай төргәкләренә Һиндстан, Куба, Корея, Вьетнам кебек илләрнең мөһерләре сугылган була. Кайбер калайлары бозык, кәкрәйгән- бөгелгән төргәкләр үзебезгә кала... Менә шушы завод та өч көн буе эшләмәде. Хезмәт хакын күтәрүне таләп иттеләр. Әмма биредә эшләр бездәгечә наять кенә төгәлләнмәде. Зур бәхәсләр, каршылыклар килеп чыкты. Ахырда хезмәт хакын күтәрделәр күтәрүен, тик унлап эшчене төрле срокка төрмәгә яптылар. Үзара сөйләшүне бозып заводта эш башламакчы булган адәмнәрне, ягъни штрейкбрехерларны тотып кыйнаган өчен. Усал ниятле хулиганлык ясаганнар дигән булып.

Ул елларда хезмәт хакыннан, гомумән тормыштан ризасызлык белдерү, түрә -коммунистларны, хакимиятнең үзен дә тиргәү, алар тарафына бик тозлы сүзләр юллау бар халык, шул исәптән тимер юлчылар арасында да бик киң таралган бер күренеш иде. Бездә машинист Евгений Назаров аеруча каргана, үзебезнең башлыкларны бер дә яратмый, хакимиятне туктаусыз сүгә иде. Ул, богылдай гәүдәле олпат адәм, кайчандыр үзе депо начальнигы булган, күп эчкәне өчен эшеннән алганнар. Евгений Петровичның тамак бик зур, бер утырып ашаганда бөтене белән ипи, килосы белән колбаса кирәк, һәм ул хезмәт хакын арттыру мәсьәләсен бик ансат һәм үзенчәлекле генә хәл итеп куя.

—Нигә безгә акчаны болай бик аз түлиләр?!—дип кычкыра ул үзенең куәтле тавышы белән.—Әгәр дә инде акчалары житми икән, бассыннар шул акчаны ике тапкыр күп итеп. Безнең илдә кәгазь беткәнмени? Түләсеннәр безгә ике тапкыр артык итеп. Шуна да башы житми микәнни ул югарыда утырган дуңгызларның? Аналарын!..—дип, дәү йодрыгын югары күтәрә, каядыр яный ул.

Бездәге социалистик системаның кризиска кереп бару гамәлләре булган бу. Һәм безнең ил житәкчеләренең, Мәскәү Кремлендә жыелып утырып йөдәп беткән картларның шушы кризисны ерып чыгарга гакыллары житмәде. Эчтәлеге нинди әйбәт системаны жимереп төшерделәр.

## Юлбашчы башы

Бу хәл дә Магнитогорск шәһәрендә булды.

Биредәге бөтен дөньяга билгеле металлургия комбинаты Урал суының сул як ярына, ягъни Азия кыйтгасына урнашкан. Ә шәһәр үзе уң як ярда, ягъни Европада. Димәк, шәһәрдән комбинатка эшкә барган адәм көн саен Европадан Азиягә һәм киресенчә үтеп йөри.

Әллә ничә чакрымнарга таралып, күккә кара төтен болытлары күтәреп утырган бу комбинат янында күпсанлы идарә бинаалары, кунакханә, ә алар каршында иркен мәйдан бар. Ул завод идарәсе мәйданы дип атала. Менә шул мәйдан уртасында, бирегә килгән бар халыкны, чит ил кунакларын да каршылап, бөек юлбашчыбыз Сталин һәйкәле торды. Кап-кара чуеннан коелган, биниһая зур, мәгърур һәйкәл иде ул. Бер катлы йорт хәтле аслыкта юлбашчының кимендә ун метр биеклегендәге сыны тора, ул кулын гадәтенчә күкрәгенә куеп, киң адым белән алга атлый янәсе. Йөзендә кырыслык, тәвәккәллек. Бу мәңге тутыкмый торган чуеннан коелган юлбашчы шушында мәңге басып та торыр кебек иде.

Әмма мәңгелек нәрсәләр юк, заманалар үзгәрә шул. Хакимияткә Н.С.Хрущев килде һәм... барыбызга да Алланың үзедәй булып күренгән юлбашчыбызның хисапсыз һәйкәлләре астына да су үтеп керде. Халыклар атасының асылда кем икәне ачылды һәм ул һәйкәлләрне урыннарыннан, биек аслыкларыннан алып ташлый башладылар. Әлләни озакка сузмый гына нәүбәт безнең комбинат каршысындагы мәгърур сынга да килеп житте.

Эш болай була. Төнлә белән завод идарәсе мәйданына куәтле автокраннар килә. Алар берни абайламый басып торган сынның муенына төрле яктан иплән кенә тимер арканнар ташлыйлар һәм... ул арканнарны төрлесе-төрле якка тарткалый башлыйлар. Тырыша торгач, сын да хәрәкәткә килә, яхшы ук салып алган агайдай бераз вакытлар як-якка чайкалып тора да... гөрселдәп, тирә-якларны тетрәтеп авып төшә. Чуен гәүдәсе таркала, кул-аяклары тарала, ә башы каядыр тәгәрәп китә. Бу төндә кызу эш бара. Һәйкәл ватыкларын үзбушаткыч машиналарга төяп шактый еракта тимер юл станциясенә ташыйлар, ачык платформаларга төйиләр. Юлбашчы һәйкәлен төяргә берничә платформа кирәк була.

Һәм... менә шулай килеп чыга бит ул! Бу ватыклар төялгән платформаларны комбинатка кертү безнең паровоз бригадасына йөкләнде. Анда ул ватыкларны мартен мичләренә салып эретәселәр, шуннан корыч коясылар иде. Без паровозга шул платформаларны тактык та, тимер юлның поездлар бик сирәк йөри торган аулак бер тармагы буйлап сак кына комбинатка таба киттек. Вагоннар ялгаучы Иван паровозның алгы мәйданчыгында бара, күптән йөрелмәгән юлда саклык кирәк, ул-бу хәл булса, ул безгә сигнал бирәчәк иде.

Юл буена үскән куе чытырманлыклар арасыннан бара торгач, Иван безне туктатты. Машинаны тормозга куйдык, будкадан төшеп, Иван янына килдек.

—Ни бар?

—Егетләр, карагыз әле сез бу юлбашчы Сталинның башына. Берни булмаган бит аңа, бик матур бит ул,—диде Иван.

Без машинист Александр белән платформага бактык. Анда йөзе белән өскә карап Сталинның биниһая зур башы ята, ул ватылмаган-кителмәгән, дөрестән дә матур күренә, купшы мыеклары астыннан аталарча елмая иде.

—Әйдә, юлбашчыбызның башын шушында төшереп калдырабыз. Мартенда эреп юк булмасын ул. Аны без юл буена утыртып куярбыз, бүтәннәргә дә әйтербез. Үткән-сүткәндә карап йөрерләр. Тик түрәләргә генә әйтмәбез. Белми торсыннар әле,—диде Иван. Хакимияткә ачуы кабарган эшче халкы ул елларда әле Сталинны элеккечә хөрмәт итә, аның бөеклегенә шик тотмый иде.

—Әйдә, төшерәбез дә куябыз!—дидек без дә.

Платформаларда йөкчеләр кулланган агач күсәкләр бар иде. Баш яткан платформаның янын ачтык, бик иплән кенә башны төшерергә керештек. Астына күсәкләр тыгып каерабыз, төшми генә бит баш, урыныннан да кузгалмый. Шул кадәр авыр, әллә гәүдә ватыкларыннан аерылып каласы килми инде шунда. Ярты сәгатьтән артык маташтык, тирләп-пешеп чыктык, күсәкләребез сынып бетте. Ә баш урыныннан бер карыш та кузгалмады, һаман да мыек астыннан көлемсерәп ятуында булды. Әйтерсең, ул бездән көлә, безне үчекли иде.

—Гафу ит, атакай. Булмады бездән, сине саклап калырга куәтебез житмәде. Үзен дә инде бик кире адәм икәнсен,—диде Иван һәм юлбашчының мыегын сыйпап алды.

Шулай итеп, булмады! Төшереп калдыра алмадык без башны. Ул бүтән калдыклар белән бергә мартен мичләренен жәһәннәм ялкыннарына кереп китте...

## Тере ... Ленинны күрдек!

Өлкәннәр яхшы хәтерли, илдә Советлар хакимлеге вакытында Бөек Октябрь бәйрәме көнне, ягъни 7 ноябрьдә хезмәт ияләренен демонстрацияләре була иде. СССР дигән бөек илнең барлык шәһәрләре һәм авылларында. Хезмәт ияләре һәм мәктәп укучылары колонналары кызыл әләмнәр һәм төрле лозунглар күтәреп килә, ә шунда бер урында күтәрелеп торган трибунадагы житәкчеләр колонналар өстенә «Яшәсен безнең барлык жинүләрне оештыручы Коммунистлар партиясе!», «Яшәсен эшче һәм крәстияннәр бердәмлеге!», «Ленинчыл Үзәк Комитетка дан!» кебек шигарьләр ташлыйлар. Колонналар аларга «ура!» кычкырып жавап бирә.

Без яшәгән Магнитогорскида, халкы тоташтан диярлек эшчеләрдән торган шәһәрдә мондый демонстрацияләр аеруча куәтле үтәләр иде. Ул көнне барлык эшче халкы шәһәрнең сулъяк яр дип аталган өлешенә, завод идарәсе каршындагы иркен мәйданга жыела. Сталинның мәһабәт сынын алып ташлагач, анда Ленинның урта буйлы гына һәйкәлен куйдылар. Һәм ул Сталиннан бушаган биек аслык өстендә тагын да нәни күренеп, кулын күтәреп торган бер малайга охшап калды.

Алтмышынчы елларда, шундый бәйрәмнәрнен берсендә кызыклы да һәм шактый күнелсез дә бер хәл килеп туды. Иртән мәйданга жыйналдык, рәтләргә тезелдек, колонналар жай гына, әмма тоташ һәм кодрәтле агым булып мәйдан уртасындагы биек трибунага таба кузгалып киттеләр. Көчле музыка, трибунадагы житәкчеләрнең шигарьләре, шау-шу. Менә кинәт музыка да, шау-шу да киселде, тынлык урнашты, һәм без, колонналардагылар, ни күрәбез?! Трибунага ... Владимир Ильич Ленин үзе килеп чыкты! Әйе, тере Ленин, гадәтенчә кара костюмнан, ак күлмәк якасы, кызыл борчаклы галстугы да ачык күренеп тора. Башындагы ямьшәеп беткән кепкасы да нәкъ үзенеке. Менә ул ошбу кепканы башыннан йолкып алды, кулында йомарлап югары күтәрде һәм пеләшен ялтыратып, үзенең кинолардан безгә бик тә таныш булган бераз сакау тавышы белән кычкырып жибәрде:

—Товарищи!

Һәм шунда ... мәхшәр китте. Демонстрантлар, үз күзләренә үзләре ышанмыйча, бер мәлгә тукталып калдылар. Безнең алда юлбашчыбыз Ленин, бөек Ленин үзе тора... Икенче мәлдә үк колонналар таркалды, кешеләр трибунага таба ыргылдылар, һәркемнең тере Ленинны мөмкин кадәр якыннан күрәсе килә иде. Гайрәтле ташкын килеп орынудан трибуна чайкалып куйды, кемнәрдер егылып ташкын астында таптала башладылар, яман кычкырулар, сүгенүләр китте. Трибунадагылар тәртип сакларга чакырып акыра, милиция кешеләре бүртенә-бүртенә сыбызгы сызгырта, ләкин беркем беркемне тынламый.

Шунда ике яшь кенә сак хезмәткәренең башына акыллы уй килмәсә, эшләр белмим кая барып житәр иде. Алар юлбашчыбыз Ленин булып бизәнгән хәсрәт артистны икесе ике яктан жилтерәтеп тотып алдылар, йөгертеп кенә трибунадан алып төштеләр, шунда торган жинел машинаның ачык ишегенә атып бәрделәр һәм машина кычкырта-кычкырта китеп тә барды.

Мәйдан ярты сәгать буена тынычлана алмады, халык сафка басмады. Хезмәт иясе халкы нигәдер бик үпкәләгән, ярсыган, яман сүгенә, каргана иде.

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Г

**ГЫЙМАДОВ** Әхмәт Зыятдин улы (1915, Казан - октябрь 1943), язучы. 1930 елларда матбугатта басылган беренче очерклары һәм хикәяләре производство тематикасына багышланган. Аерым шигырьләре «Безнең тавыш» (1938), «Бәхетле яшьләр» (1939), «Үсәбез» (1941) күмәк җыентыкларына кертелгән. Бөек Ватан сугышында һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ГЫЙМАЗЕТДИНОВ** Марсель Гыйльфан улы (11.12.1943, Бондюг р-ны Бәзәкә а. - 19.4.1993, шунда ук), шагыйрь. Алабуга педагогия ин-тын тәмамлый (1966). Хезмәт эшчәнлеге Менделеев р-ны б-н бәйле: мәктәп укытучысы, Г.Тукай исем. к-з рәисе (1986-90), 1990 нан халык депутатларының район советы башкарма к-ты рәисе урынбасары, 1991 дән «Татарстан» с-зы рәисе. «Яшәү мәгънәсе» (1990), «Яздардан алалмыйм күземне» (1992), «Син мине белмисең» (1994) исемле шигъри җыентыклар авторы. Шигырьләрендә яңгыраган төп тема - туган як табигате, хезмәт кешенең тормыш-яшәү рәвеше. Шигырьләренә ягымлы лирик интонация, музыкальлелек хас. Г.нең күп кенә шигырьләре З.Хәйретдинев, М.Иванов, Ф.Хатыйпов, В.Усманов, И.Закиров кебек композиторлар тарафыннан көйгә салынып популяр җырларга әверелделәр.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙМАТДИНОВА** Нәбирә Минеәхмәт кызы (20.10.1956, Аксубай р-ны Карасу а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1995). ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007) Казан ун-тын тәмамлагач (1981), ВЛКСМның Татарстан өлкә к-ты каршындагы әдәби берләшмәгә җитәкчелек итә. 1989 дан «Идел» ж-лы редакциясендә бүлек мөхәррире, 2006 дан баш мөхәррир. «Су хикәясе» исемле беренче әсәре 1981 елда басыла. Г. «Сихерче» (1993), «Ут кубәләге» (1990), «Кыргый» (1996), «Ак торна каргышы» (1997), «Икебезгә дә авыр» (2000), «Парлы ялгыз» (2004), «Бер тамчы ярату (2006) повесть җыентыклары авторы. Г.ның әсәрләре үзенә генә хас үзенчәлекле мистикфантастик манерада язылган. Алар укучының игътибарын табигатьнең серле, танылмаган көчләренә җәлеп итәләр. Г.ның геройлары - катлаулы язмышлы, нык характерлы, үз фикерләрен кыю яклый белүче гадел кешеләр. Үзенең әсәрләре б-н Г. әдәбиятта көчле рухлы, ирекле, бәхет, мәхәббәт юлында каршылыкларны җиңәргә сәләтле заман герое тудырды. А.ның прозасы яшьләр арасында аеруча популяр.

Әд.: Ихсанова Л. Нәбирә Гыйматдинова: Безнең сафта // Казан утлары. 1982. N12; Фәттах Н. Яшь язучының бер хикәясе // «Казан утлары». 1983. N10.

**ГЫЙНИЯТУЛЛИНА** Асия Кәшшафетдин кызы ( 17.5.1919, Чиләбе ш.), библиограф. Мәскәү библиотека ин-тын тәмамлый (1945). 1936-38, 1950-56 елларда Казан унтының Фәнни китапханәсендә эшли, 1942-45 тә Беренче май р-ны халык мәгариф бүлеге мөдире, 1948-50 дә «Белем» җәмгыятенең Татарстан респ-ка оешмасында, 1963-67 дә «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» г-таларының берләштерелгән редакциясендә эшли. 1948 дә «Совет әдәбияты» ж-лы һәм «Красная Татария» г-тасы битләрендә басыла башлаган мәкаләләре милли әдәбият, мәдәният һәм сәнгать проблемаларына, милли әдәбиятларның үзара багланышларына, татар язучылары иҗатларына карый. Рус һәм татар телләрендә чыккан «Совет Татарстаны язучылары» (1957, 2 нче басма 1970), «Татар совет язучылары» (1958) биобиблиогр. сүзлекләрне төзүче.

**ГЫЙСМӘТУЛЛИНА** Хәнифә (19 йөз ахыры, Томск ш. — 20 йөз башы), язучы. Әтисе мәдрәсәсендә белем ала. Сембер губ.-сының Сенгелеев өязе Ст.Тимошкино авылында Акчуриннар фабрикасы каршындагы кызлар мәктәбендә, Зөя авылының хатын-кызлар мәктәбендә укыта. Уку-укыту, гаилә, татар хатынының җәмгыятьтәге урыны темаларын чагылдырган «Гакыйдәтеләһле хак» («Хак бәндәләренең ышанулары», 1895), «Тәргыйб» («Кызыксыну», 1898), «Мәгъдәнел-мәсаил» («Мәсьәләләр чыганагы», 1900) исемле публицистик китаплар авторы. «Тәргыйб» әсәрендә хатын-кызларны матбугат битләрендә үз хокукларын яклап, актив чыгыш ясарга чакыра. «Тәгъзия» (СПб., 1897) исемле җыентыкка кергән лирик шигырьләрендә иренең дөнья куюына карата авыр кичерешләре чагыла. Г. - әсәрләре матбугатта басылган беренче хатын-кыз язучылардан берсе.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Бурнашева З. Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан. К., 1971; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.

*М.В.Гайнетдинов.*

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 саныннан басылып килә.*

**ГЫЙСМЕТДИНОВ** Дамир Минсагыйр улы (25.1.1949, Чувашстан АССРның Батыр р-ны Татар Тимәше а.), язучы, җәмәгать эшлеклесе, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1975-86 «Чаян» ж-лы редакциясендә эшли. 1975-86 да КПССның Татарстан өлкә к-тында инструктор, соңрак халыкара мәсьәләләр буенча консультант. 1990-94 тә «Ватан» иҗтимагый җәмгыяте президенты. 2002 дән Бөтендөнья татар конгрессы рәисенең халыкара мәсьәләләр буенча киңәшчесе, чит илләрдә яшәүче татарларның иҗтимагый оешмалары белән эшләү бүлеге җитәкчесе. «Өметсез шайтан» (1990) дигән сатирик хикәяләр, шигырьләре, хикәяләре һәм публицистик мәкаләләре тупланган «Әйтсәм әйтим» (1999) җыентыклары, популяр җыр текстлары авторы. 1986 дан «Маяк» һәм «Азатлык» радиостанцияләрендә татар телендә тапшырулар алып бара.

**ГЫЙСЪЯНЧЫЛЫК** (гарәп. фетнә кубару, баш күтәрү, буйсынмау) - урта гасыр мөселман әдәбиятларында һәм 20 йөз башы татар әдәбиятының 1910-30 нчы елларында шактый үсеш алган романтик юнәлеш. Ул шәхеснең чикләнмәгән (абсолют) ирекҗә хокуклылыгын яклау, аның акылын, хис-тойгыларын дини-патриархаль гореф-гадәтләр басымыннан азат итү, феодаль-буржуаз җәмгыятьнең социаль һәм рухи изүенә ризасызлык белдерү б-н сыйфатлана. Мөселман Яңарыш әдәбиятының Мәгарри, Хәйям, Хафиз, Нәсими кебек шагыйрьләре горур һәм ирекле шәхескә мәдхия уку, аны пантеистларча илаһилаштыру, һәрнәрсәгә шик-шөбһә (скепсис) белдерү, дингә һәм голәмәләргә каршы кискен фикерләр әйтү, феодаль-патриархаль әхлакны кискен тәнкыйтьләү һәм гаепләү б-н танылдылар. Бу шагыйрьләрнең дөньяга карашлары өчен дуализм хас иде: берьяктан, алар ихлас Алланың барлыгына һәм берлегенә ышандылар; икенче яктан, кешене дә галәмнең үзәге дип югары күтәрделәр. 20 йөз башы татар әдәбиятында, ягъни шәхес азатлыгына һәм милли тәрәккыят мәсьәләләренә игътибар арткан бер чорда, урта гасыр мөселман дөньясындагы Г. традицияләренең йогынтысы аерата тирән һәм киң колачлы булды.

20 йөз башы татар Г. романтизмының күренекле вәкиле — шагыйрь С.Рәмиев. Аның иҗаты — кешене пантеистларча илаһилаштыру, Аллага карата да тәнкыйди сүзләр әйтү (богоборчество), буржуаз җәмгыять б-н бәйле өметләрдән гайрәт чигү, социаль һәм рухи изүгә ярсып каршы чыгу, шәхеснең хөр фикер йөртүгә хокуклылыгын яклауның ачык мисалы ("Таң вакыты", "Мин", "Син", "Алданган", "Дөньяга", "Мәҗид сүзе" һ.б.). "Таң вакыты" шигырендә яфраклары б-н бөтен дөньяны каплаган зур агач кәүсәсе мисалында ул урта гасырлардагыча торгынлык хәлендә яшәвен дәвам итүче 20 йөз башы татар тормышын символлаштыра. Җирдә һәм галәмдә кешенең акылы һәм ихтыяры иҗтиһад кылырга хокуклы икәнлеген раслап, барысын да язмышка сылтап, изге гамәлләрне бары тик Алладан көтеп ятучы, ислам диненең асылын аңламаучы замандашларын кискен тәнкыйть итә. "Таң ату"ны -Яңарышны күзаллаган гыйсъянчы шагыйрь шәхеснең рухи үсешенә, милли прогресска аяк чалган наданлыкка каршы чыга ("Бетмә надан / Туг янадан / Мәгърифәтле анадан! / Бул кеше, үзең тырыш, өмид итмә, / Хата ул өмид Алладан!").

Г. мотивлары Г.Тукай ("Өмид"), Г.Ибраһимов ("Кәтүчеләр"), М.Гафури ("Юктырсың ла, Алла!"), Ш.Бабич ("Газазил") кебек шагыйрьләр һәм прозаиклар иҗатында да очрый.

1905-1907 еллардагы Беренче рус революциясе җиңелгәч тә, сәяси, социаль, милли идеаллары тормышка ашмаган гыйсъянчы язучылар бик тә авыр күңел төшенкелегенә бирелделәр. Бу чор әсәрләренең төп мотивы - нәфрәт һәм рәнҗү белдерү. Мәс., 1909 елда язылган "Дөньяга" шигырендә С.Рәмиев: "Җир-суын да яндырыр һәм / Күкләрен ватар идем!..." - дип яза. Әмма шулай да 1917 елга кадәрге гыйсъянчы язучылар илаһияттән йөз чөермәделәр, чын күңелдән Алланың барлыгын һәм бердәнберлеген тану фәлсәфәсенә турылыклы булып калдылар. Алар иҗатындагы Г. мотивлары типологик яктан Европа һәм рус әдәбиятларындагы "давыл һәм һөҗүм" ("буря и натиск"), байрончылык, ницшечелек, иблисчелек ише фәлсәфи-эстетик агымнар белән охшаш иде.

1920-30 еллардагы Г. әдәбиятындагы төп мотив марксистик-ленинчыл идеология рухында илдә рәсми дәүләти атеизм урнаштыру, ислам дине, мөселман мәдәнияте б-н бәйле рухи кыйммәтләрне юкка чыгару, Аллаһы Тәгалә һәм аның пәйгамбәре Мөхәммәдкә карата ачулы гаепләүләр яудыру, Ленин белән Сталин кебек юлбашчыларга мәдхия уку иде.

Сугышчан атеизм, партиялелек, сыйнфыйлыкны алга сөргән большевистик идеология руханиларга каршы аяусыз сугыш ачты, динне хорафат дип тамгалап, "галәмнең шаһы", җир йөзендәге бердәнбер Алла дип, бары тик социализм төзүгә юнәлтелгән хезмәтне генә таныды.

Октябрьдән соңгы чор татар язучылары арасында гыйсъянчыл традицияләрнең дәвамчысы буларак һ.Такташ аерылып тора. "Гыйсъян" (1923) шигырендә ул: "Гыйсъян итеп сезгә каршы, / Сорыкортлар, мин менә / Куркыныч утлар ягып, / Чыктым янар тау өстенә. / Аллагызны, / Дөньягызны / Утка ташлыйм, яндырам, / Җирдә тик эшне илаһ дип калдырам", дип язды. Аның атаклы романтик эчтәлекле "Җир уллары трагедиясе", "Нәләт", "Эшлиләр", "Гыйсъян", "Пасха чаңнары", "Октябрь төне", "Син дошманым минем" кебек шигырьләре дә партиялелек, сыйнфыйлык күзлегеннән диннән катгый баш тарту б-н сугарылган. Г. мотивлары шулай ук М.Гафури, Г.Камал,

С.Сүнчәләй, Ф.Сәйфи-Казанлы, К.Әмири, Ә.Фәйзи, М.Максуд, М.Җәлил һ.б. язучылар әсәрләрендә дә үзләрен нык сиздертәләр.

1920 нче еллардагы Г. шигъриятенең бер тармагы авангард агымнар - имажинизм б-н футуризм булды. Алар шигъри формаларга революцион үзгәрешләр кертеп, экспрессия б-н сугарылган механика, техника стиленә мөрәҗәгать иттеләр, үткән дәверләрдәге мәдәни мирасны, әдәби традицияләрне, көйле шигырьне кире кактылар; "чүкечле аллалар"ның үткәнне җимерү көченә, пролетариатның "канлы гыйсъяны" на, Ницшечә көч һәм агрессия культына дан җырладылар (Г.Кутуй "Октябрьдә", К.Нәҗми "Таш шәһәр трагедиясе").

Гыйсъянчы шагыйрьләр татар поэзиясен хисси-экспрессив башлангыч, күтәренке-романтик һәм бәхәс стиле б-н баеттылар, аерым жанрлар һәм иркәле шигырь өлкәсендә кайбер ачышлар ясадылар, сәнгатьчә фикерләүгә, авангардизмга тартым эзләнүләр алып килделәр.

Әдәб.: Халит Г. Поэзия дерзания. К., 1980; Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. К., 1926; Садретдинов Ш. Сәгыйть Рәмиев иҗаты. К.,1973; Әдәбият белеме сүзлеге. К.,1990.

*Р.К.Ганиева.*

**ГЫЙФФӘТ ТУТАШ** (псевд. чын фам. һәм исеме Бурнашева Заһидә Хөсәен кызы) (19.10.1895, Рязань губ. Әҗе а. — 5.11.1977, Казан), шагыйрә, җәмәгать эшлеклесе. Укырга-язарга туган авылында өйрәнә. Беренче лирик шигырьләре «Ил» һәм «Сүз» газеталарында 1914–15 елларда дөнья күрә. Аны язудан тыйган патриархаль гаилә тәртипләренә каршы чыгып, 1915 елда туган йортын ташлап китә һәм «Вакыт» газетасында татар милләтенә «үзенең хаксызга җәберләнгән вә уку юлында бу кадәр җәһәннәм газаплары күргән бер кызын химайәгә милләтне чакырам» дип мөрәҗәгать итә. «Әнигә хат» (1916) шигырендә өйдән чыгып китүен искечә яшәргә теләмәве б–н аңлата. Шул ук елда якташлары ярдәме б–н Мәскәүгә барып урнаша, әдәби иҗат б–н шөгыльләнә, дәресләр бирә. 1917–33 елларда Үзбәкстанда яши һәм эшли. 1918 нең августыннан 1919 ның маена кадәр өяз мәгариф бүлеге җитәкчесе урынбасары була (Кәттә–Курган ш.), «Михнәттәшләр тавышы» (Сәмәрканд ш.) газетасында язышa, соңыннан мөхәррире була. 1920–21 елларда РКП(б) ҮКның Төркстан бюросында хатын–кызлар б–н эшләү бүлегенә җитәкчелек итә, берүк вакытта Үзбәкстан хатын–кызлар мәгарифе ин–тында директор була. 1920 ның маенда Төркстан хатын–кызларының 1 нче съезды делегаты, июль–августында Мәскәүдә узган 1 нче халыкара коммунист хатын–кызлар конференциясе делегаты. 1921–23 елларда РКП(б) ҮКның хатын–кызлар бүлеге инструкторы (Мәскәү). Аннары яңадан Үзбәкстанга китә: Урта Азия коммунистик ун–тының бүлек мөдире, Урта Азия ефәк сәнәгате техникумы директоры, Үзбәк дәүләт нәшриятында матур әдәбият секторы мөхәррире, Урта Азия рев–ция тарихын фәнни–тикшеренү ин–тутында фәнни хезмәткәр. 1933–52 елларда Кыргызстанда эшли: сов.–парт. мәктәбендә укыту бүлеге мөдире, Кыргыз ССРның матбугат эшләре буенча Баш идарә җитәкчесе (1941–45 елларда Кыргызстанның әдәбият һәм матбугат эшләре буенча Баш идарә мөдире), Бөтенсоюз юридик ин–туты Фрунзе филиалында укыту бүлеге мөдире. 1952 дә Буага кайта; шәһәр советы башкарма комитеты әгъзасы, партиянең Буа район комитетында пропагандист, урта мәктәптә укытучы булып эшли.

Г.Т. — укучылар һәм әдәби тәнкыйтьчеләр арасында зур кызыксыну тудырган «Гыйффәт Туташ шигырьләре» (М., 1915–17) исеме б–н дөнья күргән өч шигырь җыентыклар авторы. Анда басылган «Зөһрә йолдызы» исемле поэма–әкияте 1919 да «Заһидә Гыйффәт» исеме астында аерым басыла. Шигырьләренең төп мотивы — аның замандашы, татар хатын–кызының катлаулы язмышы. Г.Т.ның лирик героинясы гаделлеккә омтыла, үз көченә ышана («Эзлим», 1913; «Өмидкә», 1914; «Сәбат», 1915). Аның бай рухи дөньясын ачарга табигать күренешләре ярдәм итә («Көз», 1913). Алар аркылы Г.Т. дөньяга карата үзенең мөнәсәбәтен белдерә («Тарсыну», 1915). Г.Т. — «Татар хатын–кызлары хәрәкәте тарихыннан» (1971) исемле китап авторы.

Әсәр.: Айсылу. Хәнәфи. Зөһрә йолдыз: (Хикәяләр). К., 1919.

Әдәб.: Гайнуллин М. Гаҗәеп язмыш // Азат хатын. 1985. № 10; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын–кыз язучылары әсәрләре. К., 1988; Рәми З. «Ирләр шагыйрь булса, бездә шагыйрә бар» // «Мәдәни җомга». 1995. 27 окт.

*А.М.Ахунов.*

**ГЫЙФФӘТ УГАН** (псевд., чын фам. һәм исеме Кадыйрова Сания Хәбирҗан кызы) (1899, Чистай ш. — 12.4.1957, Анкара ш.), шагыйрә. «Буби» мәдрәсәсендә укый. 12 яшьтә яза башлый, шигырьләрен «Тормыш», «Сибирия» газеталарында, «Яңа милли юл» ж-лында бастыра. 1917 дә илдән куып китә, мөһаҗирлектә гомер сөрә (Кытай, Финляндия, Төркия). Татар балаларын укыта, татар вакытлы матбугатында язышa. «Сания Гыйффәт шигырьләре» (Уфа, 1918) шигырьләр җыентыгы, «Тормыш көзгесе» (Хельсинки, 1937) драмасы, басылмый калган «Хан бүләге», «Яңа көй» пьесалары, фин татарлары өчен «Уку китабы» (Хельсинки, 1938) уку әсбабы, Г.Тукай, Г.Исхакыйга багышланган әдәби-публицистик мәкаләләр авторы.

*Х.Й.Миннегулов.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес Гарипова

## АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

### Аты авыллары

Казан арты үзенең борынгы авыллары, матур табигате, эшчән халкы белән дан тота. Бу төбәктәге Урта-Аты, Югары-Аты, Түбән-Аты, Утар-Аты һәм Субаш-Аты дигән авыллар Казансу кушылдыгы Аты суы ярына урнашкан. Бу авыллар барысы да Арча районы җирләрендә.

Мәгълүм булганча, Урта-Аты, Югары-Аты авыллары Казан ханлыгы чорында ук булган. Урта-Аты авылының хәзерге зиратында алты борынгы кабер ташы табылган. Аның берсе XV гасыр ахырына, калган бишесе XV йөзнең беренче яртысына мөнәсәбәтле. Урта-Аты һәм Югары-Аты авылының көньяк очындагы иске зиратта XVI гасырның беренче яртысына карый торган кабер ташлары билгеләнгән. Әлеге авыллдагы кабер ташлары археологлар тарафыннан да теркәлә. Д. А. Корсаков төзегән тарихи чыганакта Кече Атыда 111 ясак түли торган, Яна Атыда—19, Урта-Атыда—67, Түбән-Атыда 108 йомышлы татар яшәве күрсәтелә. 1766—1861 нче елларда үткәрелгән Генераль ызанлау документларыннан күренгәнчә, Урта-Аты авылында чукынмаган йомышлы татарлар, Түбән-Атыда чукынган йомышлы татарлар яшәгән. Ике авыл да Аты суы ярына утырган. А. Артемьев хезмәтендә әйтелгәнчә, Аты суы янындагы Түбән-Аты авылында 62 хуҗалыкта 398 ир-ат һәм 429 хатын-кыз гомер кичергән, мәчет булган. Кече-Аты (Субаш-Аты) авылындагы 82 йортта 267 ир-ат һәм 276 хатын-кыз исәпләнгән, авылда мәчет эшләгән. Утар-Атының 100 хуҗалыгында 449 ир-ат һәм 429 хатын-кыз яшәгән. Н.Н. Вечеслав мәгълүматларына караганда, Түбән Аты авылындагы 107 хуҗалыкта 337 ир-ат һәм 294 хатын-кыз яшәгән. Халык Түбән Аты авылы җәмгыятенә кергән. Авылда бер агач мәчет булган, җил тегермәне эшләгән. Аты суы ярына утырган Урта Аты авылы халкы Урта Аты җәмгыятенә кергән. Андагы 80 хуҗалыкта 239 ир-ат һәм 212 хатын-кыз яшәгән. Авылда бер мәчет һәм җил тегермәне булган. Шул ук чыганакта Утар-Аты авылы турында да сүз бара. Андагы 151 хуҗалыкта 491 ир-ат һәм 468 хатын-кыз исәпләнгән. Авылда бер агач мәчет булган, тимерче алачыгы, әйбер мана торган кярханә эшләгән. Утар-Аты авылы җәмгыятенә керә торган Мөхәммәт пүчинкәсендә бер хуҗалык билгеләнгән. Бу чыганакта Яна Аты (Югары-Аты) авылы телгә алына. Андагы 147 хуҗалыкта 466 ир-ат һәм 433 хатын-кыз яши. Авылда бер агач мәчет, 4 су һәм җил тегермәне булган. Атының 102 йортында 322 ир-ат һәм 314 хатын-кыз яшәгән. Авылда бер агач мәчет булган. И. А. Износков хезмәтендә әйтелгәнчә, Түбән Аты авылы Аты суы ярына, Себер элемтә юлының сул ягына утырган. Авылдагы 86 хуҗалыкта ислам дине тотучы 404 ир-ат һәм 367 хатын-кыз яши. Тормыш-көнкүрешләре уртача була. Авыл халкы тегермәнчелек һәм умартачылык белән шөгыльләнә. Урта-Аты шулай ук Аты буенда һәм Себер элемтә юлының сул ягына урнашкан. Авылда 72 хуҗалык булып, аларда ислам дине тотучы 257 ир-ат һәм 179 хатын-кыз яши. Авыл халкы Урта-Аты авылы җәмгыятенә керә. Тормыш-көнкүрешләре уртача булган.

Кече Аты яисә Субаш-Аты авыллары турында И. А. Износков мондый мәгълүмат бирә. Бу авыл Аты суы буена һәм Себер элемтә юлының уң ягына урнашкан. Авылдагы 112 хуҗалыкта ислам динендәге 366 ир-ат һәм 356 хатын-кыз көн күрә, алар Кече Аты авыл җәмгыятенә керәләр. Тормыш-көнкүрешләре уртача, кәсепләре: иген игү, киндер туку һәм умартачылык.

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Яңа Аты яисә Югары-Аты авылы Аты суы ярына, Себер элемтә юлының сул ягына утырган. Авылда 146 хуҗалык булып, аларда ислам дине тотучы 502 ир-ат һәм 507 хатын-кыз яши, халык кәсепләре: иген игү, киндер туку, умартачылык. 1898 елгы китапта Урта-Аты, Түбән-Аты, Яңа-Аты һәм Кече-Аты авылларында татарлар яши дип билгеләп үтелә. Н. К. Берстель хезмәтендә Түбән-Атыда—677, Урта-Атыда—561, Кече-Атыда (Субаш-Аты)—788, Яңа-Атыда (Югары-Аты)—877 татар кешесе яшәве күрсәтелә.

Нажия Борһанова мәгълүматларына күрә, Югары-Аты, Урта-Аты, Түбән-Аты, Яңа Аты халкы күршедәге Наласа кешеләре белән июнь ахырында—июль башларында Наласа җыены, Субаш Аты авылы кешеләре Иске Кырлай, Чиканас халкы белән май ахырларында Урман җыены яисә икенче төрле—Урман җигү, Утар-Аты авылы халкы июнь башында Утар җыены исемле бәйрәмнәр үткәргәннәр.

Атыларының һәрберсендә Иске Йорт, Кирәмәт урыннары, Чирмеш зиратлары бар.

Авыллар яныннан агып уза торган Аты суы элек бик тирән булган. Хәзер ул бөтенләй бетү алдында.

Түбән Аты басуыннан Аты суына Шайтан, Кәҗә, Сөләйман, Чүп, Чүк, Сәйфи, Мулла Нәмәт, Киек, Мазар, Кала тавы, Кече елга һәм башка су-инешләр кушыла. Күлләрнең күренеклеләреннән Ат күле, Төмәнәй, Бака исемен алганнарын атарга була. Чишмә-кизләүләр дә шактый. Исәннәреннән Улаклы чишмә, Иске йорт, Сибгат чишмәләрен әйтергә мөмкин. Басуда Шайтан тавы, Бүре тавы, Кәҗә тавы, Аю тавы дип йөртелгән таулар, Кылачы, Шәләңгер басулары бар. Авылның якын-тирәсендә урман юк. Авылга якын гына күптәнге алма бакчасы урнашкан. Авыл кешеләре аннан мул итеп җиләк-җимеш җыялар. Аты суы аша сузылган күперләрнең дә исеме бар. Аларны халык Аскы күпер, Өске күпер һәм Кайферле күпере дип йөртә. Аскы һәм Өске күперләрнең ни өчен алай аталуы үзеннән-үзе аңлашылып тора. Ә менә Кайферле сүзенең нинди мәгънә белдерүен әйтү кыен. Авыл халкы да бу атаманың мәгънәсен кистереп кенә әйтә алмый.

Авыл урамнарының исемнәре: Урта урам, Атау урамы, Кое урамы, Карлыганлык, Арьяк, Яшьләр урамы, Килмешәкләр урамы (читтән күчеп килгән кешеләр яши), Бак-баклар тыкрыгы, Мәкиләр тыкрыгы һ. б.

Авылда элек мәчет булган, ләкин ул бүгенге көнгә кадәр сакланмаган. Янасы салынып бетү алдында. Авылда унберьеллык мәктәп, мәдәният йорты һәм балалар бакчасы, элемтә үзәге, кибет, китапханә эшли.

Гыйбадәт кылырга теләүчеләргә мәчет ачылган.

Авыл халкының кушаматын да әйтик: тавык дип йөртәләр аларны.

Түбән-Аты авылында сәүдәгәр Вәли Гыйззәтуллин туган.

В. Гыйззәтуллин утары Казан шәһәренең Шиһабетдин Мәрҗани урамында (йорт № 16/1) урнашкан.

Элекке Кабанның сул як яры һәм Беренче Аркылы урамнар чатындагы ике катлы ярымташ йорт XIX гасырның беренче яртысында (архитектор Н. Хәмитов билгеләмәсе) төзелгән. В. Гыйззәтуллин Кабан күле буенда ике катлы кирпеч флигель төзеткән.

Вәли Гыйззәтуллин 1837 елның 26 апрелендә Казан өязенең Түбән-Аты авылында (Татарстанның хәзерге Арча районына керә) туган. 1878 елда ул Казан сәүдәгәрлегенә кабул ителгән. Печән базары мәйданында һәм Рыбнорядская урамында кибетләр тоткан. Ул үзенең керемнәренең зур өлешен дини чараларга сарыф иткән, хәйриячелек белән шөгыльләнгән; аерым алганда, Мәрҗани мәчетенә матди ярдәм күрсәткән. Вәли бай шәһәр Думасының гласные булып сайланган, ятимнәр хөкеменең (судының) әгъзасы булган. Мәхәллә халкы арасында «Вәли Аты» исеме чыккан сәүдәгәр җәдитчелеккә каршы көрәшкән. XX йөз башында ул алдынгы татар руханиларының, укымышлыларының һәм сәүдәгәрләренең мәгърифәт өлкәсендә алып барган реформаларына кискен каршы чыккан. Ф. Әмирхан 1908 елда аны «Печән базары хөкемдарларының берсе» дип атаган. В. Гыйззәтуллин 1916 елның 17 августында вафат булган.

Югары-Аты һәм Урта-Аты авыллары тирә-юнендә Сафа пәрәләгән, Каенлык,

Кызыл Яр, Хәмеки, Ур, Солтан, Үзәк, Зирекле, Усаклы, Әмин, Кече ындыр, Нәртем һәм башка елга-инешләр, Әпәр, Каравай чишмә-кизләүләре, Гали, Каенлык тау, Югары тау башы һәм башка топонимнар теркәлде.

Утар-Аты авылы янында куе урманнар да, тирән сулы елгалар да юк. Ул кин болыннарга һәм кырларга бай, ерганаклар күп, таулар да бар. Авыл артык зур түгел, анда яшьләр һәм яшь гаиләләр дә шактый. Авылда урта мәктәп, шифаханә, элемтә үзәге, ике катлы зур мәдәният йорты бар. Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга. Авылның нәкъ уртасында мәчет балкып утыра.

Авылда биш урам бар. Аларның һәрберсен халык үз күңеленә якын исемнәр белән атап йөртә: Арйак урам, Өске урам, Аскы урам, Атау урамы, Килмешәк урамы һ. б.

Болыннарда һәм авыл эчендә дә кечкенә-кечкенә инешләр ага. Авыл башында зират урнашкан. Аны әйбәтләп койма белән әйләндереп алганнар, һәр елны яз көне авыл халкы өмә оештырып, зиратны тазарта, тәртипкә китерә. Мәетләрне күмә торган әсбаплар да хасиятләп тотыла.

Өлкәннәр балалары гаиләсендә хөрмәт күреп яшиләр. Караучысыз калган картларга күршеләре, әйләнә-тирәдәге миһербанлы кешеләр ярдәм итә.

Халык бер-берсенә төрле-төрле кушамат тага, әмма үзара тату яшиләр. Кушаматларның кызыклылары да юк түгел: пьюм, мокай, нәнүк, мишәр, мотрак, жапый, кәжә, әтәч, мөфти, чапай, бумазый, чәнгәр һ. б.

Авылда йортлар матур, халыкның тормышы таза. Тәрәзәләр тулы гөлләр үсә.

Утар-Аты авылында актриса Таждарова (Ахмадуллина) Нәгыймә Ахмадулловна (1888—1947) туган. Ул 1915 елда «Сәйяр» труппасында эшли башлый. Татар театрына нигез салучыларның берсе. Гражданнар сугышы елларында фронттагы театр бригадаларында катнаша. 1922—1926 елларда—Уфада Татар-Башкорт театрында (хәзерге Башкорт академия театры) эшли. 1926 елның көзеннән Татар академия театрында уйнаган. 1931нчы елдан ТАССР ның халык, 1940 нчы елдан РСФСР ның атказанган артисты.

***

Атамасына «Аты» сүзе катнашкан топонимнар Кама аръягында да очрый. Зәй кушылдыгы Аты суы ярында Олы Аты һәм Кече Аты авыллары утырган.

Олы Аты һәм Кече Аты авыллары янында бура, имәнкискә һәм болгар чорларына мөнәсәбәтле авыл хәрабәләре, керамика кыйпылчыклары табылган.

1870 елда Олы Атыда 140 йорт булып, аларда 399 ир-ат һәм 449 хатын-кыз яшәгән. Авылда су тегермәне эшләгән. Халык умартачылык, балта эше белән шөгыльләнгән. Кече Атыда (1870 ел) 73 йорт исәпләнгән, аларда 180 ир-ат, 160 хатын-кыз көн иткән. Халыкта умартачылык кәсебе булган. Авылның икенче исеме—Оскино, ягъни Үчкә.

«Аты» атамасы ни аңлата?

Бу турыда төрле фикерләр бар. Гомәр Саттаров аны мари телендә «кечкенә урман, урманчык, агачлык» мәгънәсендә кулланылган «ото» сүзе белән бәйләп карый. Ул түбәндәгеләрне яза: «Татарстан топонимиясендә мари субстраты булган аты (ото) географик номенклатура термины роща—«кечкенә урман, урманчык, агачлык» төшенчәсен белдерә дип караганда, Субаш Аты ойконимы «Су (елга) башындагы агачлык», Югары-Аты—«Югары агачлык», Түбән-Аты—«Түбән агачлык», Олы-Аты—«Олы (зур) агачлык», Кече-Аты—«Кече агачлык, урманчык» дигән мәгънә бирә булып чыга».

«Аты» сүзе ул рус елъязмаларында еш кулланыла торган «чулматы-челматы» этнонимының «аты» өлешен тәшкил итәргә мөмкин. Казан император университеты профессоры С. М. Шпилевский Чулман атамасын болгарларның челматы (татарча чулматы) дип аталган бер кабилә-кавемнәре белән бәйләп карый. Чул + ы(м) + ан суы янында яши торган чулыматылар, ягъни Чулман (Чулыман) суы тирәсен үзләштергән аты кавем-кабиләләре.

Борынгы төркиләргә һәм гомумән борынгы халыкларга елгалар, тирә-юньдә

юнәлеш билгеләү (ориентлашу) өчен хезмәт иткәннәр, су юлы итеп файдаланылганнар.

Себер елгалары арасында Чулман кебек чул (чул—«елга» + ым) терминыннан ясалган атамалар шактый.

Составында аты компоненты булган атамалар байтак очрый.

«Аты» компоненты торак пункт Шонгаты атамасында да очрый. Хәзерге вакытта ул Апас районында Үләмә суының уң ягына урнашкан Шонгаты авылының көньяк-көнбатыш өлешеннән ярты чакрым ераклыктагы шәһәр хәрабәсе. Бу шәһәрлекне С. М. Шпилевский ныклап тикшерә. Хәзерге Шонгаты авылы янында соңгы болгар чорына мөнәсәбәтле зират билгеләнгән. Шонгаты авылы Казан ханлыгы чорыннан ук мәгълүм. Апас районының Шонгаты, Тәтеш районының Алабирде авылында Шонгаты инешләре ага. Алар Олы Үләмә суының уң кушылдыклары. Апас районының Кече Күккүз авылында Шонгаты чишмәсе һәм күле бар. Шушы ук ояга тагын Татар Урматы һәм Рус Урматы авыллары керә. Алар Казансу кушылдыгы Урмат суы буена урнашканнар. Урмат атамасының беренче өлеше XIV йөз болгар чоры кабер ташы язмаларында очрый торган орым-урым этнонимы белән бәйләнешле. Икенче өлеше исә урыс елъязмаларында искә алынган «челматы» этнонимындагы «аты» компонентына мөнәсәбәтле. Бу авыллар янында борынгы, гомум һәм соңгы болгар чорларына мөнәсәбәтле авыл хәрабәләре һәм зират билгеләнгән. Урмат авылы Казан ханлыгы чорында да булган. «Урмат» атамасы Казан өязенең теркәү кенәгәләрендә һ. б. тарихи чыганакларда еш очрый. Татарларда Урмат исемле җыен бәйрәме дә үткәрелгән. 1966 елда Бәрәнге авылыннан Х. Ярми тапкан шәҗәрәдә Урмат шәхес буларак та теркәлгән.

Шушы ук рәткә рус елъязмаларында еш кабатланган Балыматы шәһәре дә керә. XIV йөзгә мөнәсәбәтле Болгар шәһәрлегеннән табылган икенче стильдәге кабер ташы язмасында Балымар кушаматын укып була. Һарун Йосыпов фикеренә караганда, Балымар—кабилә этнонимы. С. Мельников язганча, Балымар авылы иске документларда Балымәт дип атала. Борынгы болгар чорларының Балымар шәһәрлеге Иделнең сул ягында, Спас районында урнашкан. Нугай юлы өстендәге Балымар авылы Казан ханлыгы чорларында искә алына.

Шонгаты һәм Аты топонимнары Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә очрый. Атенинка—Ука елгасы бассейнындагы Мокша суы кушылдыгы. Элекке Самара губернасы, Ставрополь өязендә Сок елгасына коя торган Шонгаты суы билгеләнгән.

Марсель Әхмәтҗанов фикеренә күрә, аты компоненты Нугай Урдасы татарларының юрматы этнонимында урын алган аты берәмлегенә нисбәтән барлыкка килгән. Бик мөмкин. Чөнки бу галим төпле фикерле, татар чыганакларын (кулъязмадагыларын да) әйбәт белүе белән аерылып тора.

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

Рәйсә
ЮСУПОВА

# ТЭТЧЕР МАҖАРАЛАРЫ

Ә тагын ике көннән башлыкның хәбәре иреште: чыннан да студент кызлар вагонында бер кыз бала юл буе көчеге белән уйнап барган. Алар Ижевскида гына төшкәннәр.

Шул ук көнне мин «Казан-Ижевск» поездына утырдым.

### Җирсү

Инде менә... төн уртасында, Ижевск каласында, вокзалга якын гына биш катлы йортның кысан аш бүлмәсендә Әлфиянең өзек-өзек сөйләгәннәрен тыңлап утырам.



—...Кичә кичен ул юкка чыкты. Качты... Ияләшә бугай дип уйлый гына башлаган идем... Башта, ике тәүлек буе берни дә ашамаган иде. Менә кичә җамаягын да ялмап куйды. Аннары күзен ярым йомып көнозын кымшанмыйча ятты. "Ияләшә" дип уйларлык иде шул.

Кичен урамга алып чыккач кына әллә нишләде: иснәнде дә иснәнде. Борын яфраклары киңәйде, колаклары үрә катты. Шул чакта якынлашып килүче поезд тәгәрмәчләренең тыкылдавы ишетелде. Маэмайны әсәрләндергән бу тавыштан котылырга теләп, мин аны керү ягына тарткалый башладым.

Өйгә кергәндә тынычланган кебек иде инде ул. Керү белән кухняга, өстәл астына шуышты, башын тагы тәпиләре өстенә салды. Ә күзе һаман "аю"да булды.

..."Нинди хөкем чыгарсаң да—мин риза" дигәндәй, Әлфия тынып калды. Ә бераздан, нидер исенә төшеп, тәрәзәгә борылды. Мин дә шул тарафка карадым һәм... иманеп киттем: анда, тәрәзә төбендә—минем "Мехлы аю"ым!

...Менә ни өчен Тэтчерым үзенә урынны кухняда (җитмәсә, өстәл астында!) сайлаган икән, йә Хода!.. Әйе, әйе, "Аю" аңа туган өйне искәртеп торучы бердәнбер юаныч булган.

Теге чакта... Ярый әле ул көнне мин бу кадерле сувенирны биреп җибәрергә риза булганмын. И язмыш!..

...Бүлмә эченнән ишетелгән ыңгырашу авазы уйларымнан бүлде. Ыңгырашуга "ән-ни!" дигән өн дә өстәлеп, сискәндереп җибәрде.

—Айгөл саташа,—диде Әлфия.—Гел шулай саташып йоклый.

"Бар, тынычландыр кызыңны" диюемне аңлатып, мин Әлфиянең кулына кагылып алдым. Әмма ул кузгалырга ашыкмады, ишеккә текәлгән көе урынында калды. Мин дә шул якка борылдым һәм... һәм анда, кухня бусагасында, ап-ак озын күлмәкле кыз бала кочагында... Тэтчерымны күреп тынсыз калдым.

*Дәвамы. Башы журналның 1 санында.*

...Күкләрнең җиденче катыннан мине җиргә төшерергә Әлфиянең бер җөмләсе җитте; аның "Куеп тор әле, Айгөл, шул Марусяңны" диюе булды—мираж юкка чыкты. Инде ул урында... бала кочагында... маэмаем кебек үк күксел-соры төстәге песи иде.

Бәхет бүләк иткән әлеге күренешнең мираж гына булып, шул ук мизгелдә юкка чыгуыннанмы, әллә шушы хәтле нык алданып җирсенүдәнме—тамагыма төер утырды.

Үземне көчкә кулга алып, мин, ниһаять, телгә килдем:

—Песиегез... Марусягыз була торып Тэтчерны урлау—нигә кирәк иде?!..

—Без аны урламадык. Маэмайны безгә дәү әнием биреп җибәрде.

—Ничек инде ул—"биреп җибәрде"? Маэмай аныкы түгел бит.

Кызының сүзләренә Әлфия ачыклык кертте:

—Айгөл дөрес әйтә, Тэтчерны апкитергә кайнанам кушты. "Эт монда комачау гына, үзегез белән апкитсәгез, апагызны авыр бер мәшәкатьтән коткарачаксыз", диде. Маруся атлы песиебез барлыгын әйткәч, "юлда адаштырырсыз, җә берәрсенә биреп җибәрерсез; аны мин Казанда адаштырып-адаштырып карадым инде—барыбер кайтты, ә Ижаудан кайта алмаячак", диде... Сезгә комачау икәнен белгәч, Марусяга уйнарга иптәш булыр диеп апкиткән иек...

...Әлфиянең сөйләгәннәре, ниһаять, аңыма барып җитте, әмма күңел кабул итә алмады. "Ник?", "Ни өчен?" дип сөрән салудан көчкә тыелып, хәтер-хатирәләремдә актарына башладым. Тик... чигәмне бөрөзлексез "юлда адаштырырсыз", "адаштырырсыз..." дигән өн кысып, гаҗиз калдыра.

..."И апа! Апа!.. Тэтчерның сиңа ни зыяны тиде соң?" дип пышылдавымнан айнып киткәндәй булдым, һәм уйларым да Петровски бистәсе тирәсендә әйләнә башлады.

Бистә белән бергә апам һәм Тэтчерга кагылышы булган вакыйга-хәлләрне дә күз алдыма китердем.

...Әйе, ул чакта әле көчеккә ике генә ай иде. Мин өч көнлек командировкага китәргә юллама алдым. Ирем Мәскәүдә эш тармагы буенча киңәшмәдә булганлыктан, Тэтчерны күршеләрдә түгел, Петровскида апада калдыруны кулайрак күрдем.

Апа кире бормады, "Сумкага салып аны да үзең белән апкитәсең барые" дип, шуклана-шуклана алып калды. Ә мин кайткач... "һушны алган бияләй хәтле генә бу нәмә" турында кабат-кабат сөйләде.

...Бер көнне апа Казанга, мотоциклы белән машинага бәрелеп, больницада савыгып килүче төпчек улы янына барырга чыккан. Сәфәре дә уң булырга охшап тора икән: урман сукмагыннан олы юлга аяк басуга ук "Матюшино" автобусы күренгән...

—...Автобус шәһәргә якынлашып килгәндә генә,—дип дәвам итте апам,—бер хатын чырылдап җибәрде: "күсе", "күсе!" диеп акыра-бакыра башлады. Шул минутта теге "күсе" минем дә аягыма бәрелде. Утыргычымның астына карасам—исем китте—Тэтчер борыны белән балтырыма төртә: "Мин әле бу, биредә бернинди дә күсе юк, курыкма", диюе инде үзенчә.

Теге хатынны тынычландыру өчен мин маэмайны өскә күтәрдем. Көлү тавышларыннан автобус шартлый дип торам...

Тэтчерыңны әйтәм, нинди хәйләкәр бит, ә?! Сумкама тәм-том ризыклары тутыруымны күргәч, бу күчтәнәчләр белән сезгә барырга җыенам дип белеп, кайтырга уйлаган бит тәки... Форточкадан чыгып, агач-куаклар артына кача-поса тукталышка килүе әле бер хәл, ә минә беркемгә дә күренмичә, сиздермичә генә автобуска керә алуы, шундук утыргычлар астына яшеренүе... Бусы инде—могҗиза!..

Маэмайның галәмәтләре турында сөйләшә-сөйләшә, көлешә-көлешә "Павлюхин" тукталышына килеп җитүебез дә сизелми калды. Төшеп кенә өлгердек, РКБга баручы автобус килеп туктады.

Кырмыска оясыдай мыж килеп кайнашкан халык арасыннан Тэтчерны бер читкәрәк апкиттем дә: "Мин килгәнче шушында гына утыр",—дидем. Көчек автобуста китеп баруымны томырылып карап калды.

Больницадан соң тагы тукталышка килсәм... күзем шар булды—тәки көтеп утыра бит! Адәм ышанмаслык хәл: ике айлык нәмә... дүрт-биш сәгать буена мин калдырган урыныннан кымшанмаган да! Сөйкемле дип җәлләгәннәрдер

инде, алды тулы сый: күмәч сыныклары, колбаса-сыр кисәкләре, морожный стаканы, көнбагыш өеме...

Калдырып киткәндә бөтенләйгә хушлашкан идем—апкитмәгәннәр шул...

"...Бөтенләйгә хушлашкан идем—апкитмәгәннәр шул".

И Раббым, ризасызлык төсмерләре салынып әйтелгән бу җөмлә—апаның Тэтчерны өнәмәве хакында мине кисәтергә, һичьюгы искәртергә тиеш иде ләбаса!

Әле моңа өстәп, үзенең бер килүендә... тәгәрәгән каләмемне алу өчен Тэтчер йоклап яткан кәнәфине кучерүемне күреп, "Ал-ла, бигрәк кадерле инде, креслосыние белән күтәрмәсәң—олактырасы нәмәне; "эт тормышы" диләр тагы, миңа эләксен иде әле шушындый эт тормышы" кебек гыйбрәтле сүзләр белән безнең тарафка төксе караш ташлавы да—минем "күзне ачмаган".

Хәер, сиземләгән булсам да... әһәмият биреп бетермәгәнмендер. Чөнки соңгы айларда апа белән Тэтчер арасындагы мөнәсәбәт күз алданырлык, акыл томаланырлык дәрәҗәдә дустанә иде бит. Мәзмайның туганымны ихлас яратуы, аның килүенә чиксез шатлануы минем үземне дә сөендерә иде. Әйе, әйе, апа килгән саен аның каршысына утырып Тэтчерның өй хәлләрен сөйләве, ә туганымның: "шулаймыни?", "и-и, шулай булдымыни?", "алай икән!" дип, мәзмай сөйләгәннәрне җөпләп тыңлавы—үзе бер тамаша, үзе бер бәйрәм иде. Һәм мондый минутлар, ошбу күренеш—тормышыбызның матур бер бизәгенә әйләнгән иде.

Гадәттә мондый диалог ун-егерме минутлар дәвам итә; ә кайчакта, Тэтчер китеп барган җиреннән борылып килеп янәдән "сүз башлаганда", озаккарак та сузыла. Бу очракта апа: "әле сөйләп бетермәдеңмени?", "оныткансыңмыни?", "әйтәсе сүзләрең калганмыни?" диеп соклана-соклана тыңлый, һәм... һәм артыннан: и сылудыр ла үзе, ә күзләре... тач кеше күзләре инде, дип кала.

Гаҗәп, безгә килгән бүтән кунаклар белән Тэтчер мондый озын "аңгәмәләр" кормый. Без сөйләшкәндә исә ара-тирә "сүз" кыстыргалап, тыңлап кына утыра. Ә апага... фәкать апага гына—бөтенләй аерым мөнәсәбәт!

Нигә алай? Сәбәбе нидә? Моның җавабын кем белә?!..

Кайвакыт апа үзе белән мәзмайны да прогулкага чакыра. "Шәһәр кибетләрендә йөрербез дигән идем, апаңның вакыты юк әнә; сиңа да бер прогулка булыр—киттек, Тэтчер",—ди.

...Бу "прогулка"ларның Тэтчерны адаштыру өчен махсус оештырылуын кем уйлаган инде ул чакта?!

—...О-о, тагын ностальгия!..

Айгөлнең бу сүзләре мине сискәндереп, айнытып җибәрде. Һәм мин сеңлемнең өстәл астына ишарәләүче кул хәрәкәтен шәйләдем.

—Нишләтәсең инде аны—сагына бит.—Әлфия дә өстәл астындагы песиләренә ымлады.—Марусяны әйтәм, Тэтчер яткан урынны килә дә иснн, килә дә исни... Яраткан идек тә, качты шул Тэтчер, качты...

—Нишләп качырдыгыз соң?

—"Лампочкам янды, синең запасың юкмы?" дип, кичен күршем кереп чыкты. Ишекне ачып-ябу да җиткән бит әнә... Әйтәм бит: поезд килүен тоеп нык борчылган иде ул.

—Эзләп карадыңмы соң?

—Бүген көне буе вокзал тирәсен айкадым.

—Соң?..

—Дежур милиционер бәләкәй генә бер этнең төне буе вагоннар янында бөтерелүен күргән. Куып-куып та китмәгән көчек.

...Димәк ...димәк, мәзмаем үзенең поездын—әйе, әйе, тәгәрмәчләренә хәтле туган илкәенең җилен сеңдергән поездны эзләгән...

## Төнге очрашу

Әлфиянең ай-ваена карамыйча, үземнең арыган булуымны да иска-исәпкә алмыйча, шул ук төндә кайтасы иттем.

Мин вокзалга килеп җиткәндә "Ижевск-Казан" поездына утырту башланган иде инде. Утырасы вагонымны карый-карый атлаганда кемдер җиңелчә генә иңбашыма кагылып: "Нихәл, якташ!"—дип эндәште. Борылдым һәм... дөньядагы иң кадерле кешемне күргәндәй, кычкырып җибәрдем:

—Ярабби, мыеклы машинист!..

Якташым көлеп җибәрде һәм:

—Якыннарым миңа "Федя" дип эндәшә. Кемгәдер—Федор, кемнәрдер өчен бик күптәннән Федор Андреевич инде мин,—дип, танышырга кулын сузды.

—Федя!.. Федор!.. Федор Андреевич!..—Әнә шулай такылдый-такылдый, мин ике куллап аның беләгенә ябыштым.—Сез... сез минем өчен бу караңгы төндә күкләрнең җиденче катыннан иңгән кояш кебек,—дидем... һәм тукталып калдым. Ходаем, ул минем болай дулкынлануымны дөрес аңлармы?!

Дөнья күргән кеше аңламыймы соң! Йөзендәге елмаюын да киметмичә,Федор әфәнде минем бу шигемне юкка чыгарды.

—Мазмаен юллап Ижевскига ук килеп җиткән ханым алдында чал башым үзеннән-үзе иелә.—Ул, чыннан да, әз генә чүгә төшеп, башын иде.—Ә хәзер эзләү-эзләнү нәтиҗәләре турында кыскача гына сөйләгез инде?!..

Түкми-чәчми генә сөйләп чыктым да йөзенә текәлдем.

—Бөтен өметем сездә инде, Федор Андреевич. Сезнең менә хәзер очравыгыз да юкка түгел бит ул. Тэтчерымны сез... нәкъ менә сез табарсыз кебек тоела. Урлаган кешеләреннән ул кичәге төндә качкан. Дежур милиционер аның биредә, вагоннар тирәсендә йөрүен күргән. Димәк, ул Казан поездын, үзе килгән вагонны, ягъни сезнең составны эзләгән.

—Кичәге төндә биредә бүтән бригада иде. Карагыз әле... Нишләп әле сез мазмайны нәкъ менә поезд белән кайтырга тиеш дип уйлыйсыз? Аның автобуска, яки очраклы бер машинага утырып китү ихтималын нигә исәпкә алмыйсыз? Бәлки әле җәяүләп кайтыр; бәлки инде юлдадыр ул, ә?!

—Гафу итегез, минем болай уйлавымның үзенә күрә логик нигезе бар. Быел без җәй буе Васильево янындагы бакчабызга йөрдек. Бакчага поезд белән барабыз иде—поездда кайтабыз да. Машинада барсак, билгеле инде, машинабызда кайттык. Әле тормыш тәҗрибәсе булмаган, алты айлык Тэтчер өчен гадәткә әйләнгән бер кагыйдә кебегрәк инде бу! Ижевскига поездда килгәч...

—Аңладым... Шулай да, мазмайның миңа очрау ихтималы бик аз; юк дәрәҗәдә дисәм—дөресрәк булыр. Көнчыгыштан—көнбатышка, яки киресенчә, көнбатыштан көнчыгышка йөрүче бик күп поездлар Казан белән Ижевск калалары аша уза. Тагын... бездән Ижевскига килүче, яки бу шәһәр аша үтүче Казан поездлары бар. Димәк. Ижевск аша тәүлегенә дистәләгән состав, йөзләрчә-меңнәрчә вагоннар үтеп тора. Күбрәк түгелме соң бу—үзегез әйтмешли, бала яшендәге көчек өчен?! Чынбарлык, хөрмәтле ханым, менә шундый... Йә, ничек ярдәм итә алам инде мин сезгә?

—Аласыз, Федор Андреевич, аласыз! Сез Казан машинистларының барысын да беләсез бит. Машинистларга да, үзегезнең проводницаларыгызга да минем үтенечемне җиткерсәгез, мазмайны күрүләре турында алар, һичшиксез, сезгә хәбәр итәрләр. Ә сез—миңа!.. Менә монда адресым белән телефоным язылган!

Мин шушы сүзләр белән якташыма визиткамны суздым.

—О-о, сездәге оптимизм!—башын чайкый-чайкый, Федор әфәнде сәгатенә күз ташлап алды.—Вокзал башлыклары әмеренә инде менә сезнең гозер дә өстәлде. Бу эшкә ныклап тотынмыйча булмас, ахры. Ә хәзер кузгалырга вакыт. Сез дә безнең поездда кайтасыздыр бит?! Хәерле юл телим!

Күңелемдә өмет кузы калдырып, ул паровозына ашыкты.

...Ә көн үзәгендә мин янә аның көр тавышын ишеттем.

—Хәзер үк Юдино бистәсенә барыгыз!?—Машинистым адрес атады.—Мәрьямне сорарсыз. Бу хатын алдагы составның купе вагонында эшләде. Федор Андреевич җибәрде диярсез.

Мин дулкынлануымнан ык-мык килгән арада телефонымда кыска-кыска гудоклар гына ишетелә иде инде.

## Икенче вагон

...Хуҗабикә сүзен:

– Алар поезд кузгалыр вакытта гына килеп җиттеләр,—дип башлады.—Әни кешенең кызына текәлгән күзләре бик тә борчулы иде. Шунда, аларның аяк астында, ананы юатырга теләгәндәй, нидер әйтеп маташучы көчек тә күземә чалынды... И ул көчек! Ул булмаса, мине эштән очырачаклар иде бит...

—Мәрьям ханым купеда ни булганлыгын сөйли башлады. Аның сүзләре бәгыремне көйдерә; Тэтчерым урланганнан бирле юньләп йокы күрмәгән, ялны

белмәгән күзәнәкләрем сулкылдый. Һәм мин ул төндәге вакыйгалар эчендә мәзмаемның бөтен хәл-халәтен күз алдына китердем.

...Бу урыны җайлы иде Тэтчерның. Куаклык әйбәт бер куыш кебек икән: тегә, үзен куып интектерүче милициядән дә яшерде бит менә; күзәтү, йоклап алу өчен дә уңайлы: чирәм-үләне дә йомшак, җылы да әле, җитмәсә. Аны монда алып килгән поезд күренгәнче шушында йоклаячак ул; менә бусы, паровозы "пошкыра" башлаганы гына китсен дә... рәхәт бер йокыга талыр.

Ә-һә, кузгала бугай инде, проводница да әнә бер аягы белән вагон баскычына басты. Басты... һәм нигәдер тукталып калды.

Мәзмай проводница борылган тарафка күз салды. Вокзал ягыннан йөгерүче ике хатын-кызны ул да күреп алды. Менә инде аларның сүзләре дә аермачык ишетелә башлады. Чү, болар бит туган телдә, әйе, әйе, аның (ягъни Тэтчерның) апасы, абыйсы сөйләшә торган газиз телдә сөйләшәләр ләбаса!

—И кызым,—ди бит әнә өлкәне,—безнең Ижау ул Казанның бер районы кебек кенә. Ничекләр яшәп китәрсең, ничекләр укырсың икән инде син ул Казан калаларында?! Әтиең дә кайтып җитмәде ичмаса. Үзебезнең машинада илтеп, урнаштырып кайтасы иде дә бит, самолетлар очмаган шул: җир тетрәгән Ташкентта. Бер кире килсә килә бит ул—билетлары да шушы икенче, купелы вагонга гына калган, хәерсез. Юлдашларың җүнле кешеләр булса ярый ла. Күкрәкләреңне дә капламаган бу кофтаны кигәнсең, җитмәсә. Ялгыз кыз баланы аерым купеда кемнәр яклар, йә Ходам?!

Ананың бу монологын артык тыңлый алмыйча, ике-өч сикерүдә алар каршысында пәйда булган Тэтчер: "Үзем, үзем яклыйм кызыңны, борчылма?!"—диюен сизми дә калды.

Аның бу "сүзләрен" хуплагандай, кузгалуны аңлатып паровоз кычкыртты.

Кызның чемоданнарына ышыкланып, мәзмай да вагонга үтте. Купеда берәү дә юк иде. Тәрәзә янында, "сандыклы сәке" астында, аяк киеме сыярлык кына урын бар. Көчек шунда шуышты.

—Синең урының шушысы!—Кыз бала артыннан ук кереп җиткән проводница Тэтчер яшеренгән "сәке"гә ымлады.—Ят та йокла, үскәнем. Юлдашларың бүтән купеда, иптәшләре янында. Алар кайтканчы йоклаган бул, яме?!

Вагон хуҗасының әмер кебегрәк әйтелгән бу сүзләре сагайта калды. Ананың бөтен борчу-хәсрәт дулкынын үзенә алган мәзмай бу минутта үз поездында, үз вагонында кайтырга ниятләве турында бөтенләй оныткан иде инде. Бөтен барлыгы белән ул шуны гына белде: бу кызны якларга кирәк! Әмма кемнән, нәрсәдән якларга кирәклеген әлегә сизенми, тоемламый иде ул.

...Вагонның талгын гына тирбәнүе йокыны китерә башлады. Бөркү булса да кыз җәймәсен башыннан ук ябынды: йокларга җыенуы инде бу!..

Күрше купедагы берәүнең гырлаганын тыңлап ята торгач, мәзмай да үзенең күз кабаклары авыраюын тойды. Селкенеп аласы, йокыны куасы иде дә бит, кызны уятудан куркып, кымшанырга кыймады.

Шулай да кыймылдарга, бу кысан почмакта оеый башлаган аякларны язарга кирәк иде.

Тэтчер купеның өстәле астына шуышты, һәм аякларын сузып җибәрде. Тәпиләре шундук җылы җәймәгә орынды. Кызны уятырга, "җәймәң идәнгә төшкән" дип кисәтергә кирәк иде. Кофтасыннан тартса... әйе, әйе, кыз уянып беткәнче почмагына шуышырга өлгерә бит әле ул.

Мәзмай "сәке-ятак"ка үрелде, әмма нәкъ шул мәлдә ишектә ят тавышлар ишетелде.

...Купеда пәйда булган өч әзмәвернең дә күзләре кулларын дугалап чалкан йоклап ятучы кызга текәлде. Аларның бу карашыннан көчекнең йоннары тырпайды; һәм ул бөтен барлыгы белән караңгы почмагына сеңде. Тумыштан килгән үзен-үзе саклау инстинкты иде инде бу.

Ниһаять, әлеге адәмнәр бер-берсенә ниләрдер әйтеп, көлешеп алдылар. Ят телдәге сүзләрне аңламаса да, гәпнең кызга кагылышы барлыгын тойды мәзмай. Һәм бу тою-сизенү дулкыны аны почмагыннан кубарып, алгарак этәрде. Хәзер тегеләрнең бөтен хәрәкәтен күзәтә ала иде инде ул.

Менә берсе каршы як "сәке-сандык"ны ачып, шешәләр чыгарды. Икенчесе дипломат-портфеленнән шоколад алды. Мәзмайның авыз суларын китереп, купега казылык исе таралды.

һәр сүзенә каты басым ясап:

—Крр-асавица,—дип башлады өлкәнрәк күренгәне Тэтчер да аңлаган телдә,—тор әле, тор; синдәй кызлар юлда йоклап, гомерләрен заяга үткәрергә тиеш түгелләр; тем более Сергоның туган көне—табыныбызны матурлаш!

Маэмай күңеленнән генә кызга: "Торма!"—дип ялварды. Тик кыз бала торды һәм әзмәвер күрсәткән урынга шуышты.

Аны үзләре белән таныштыра-таныштыра, касәләрне сыеклык белән тутырдылар. Араларында яшьрәк күренгән Серго дигәне кыз янына утырды.

—Туган көн хөрмәтенә!—дия-дия, өлкәне кызга да касә сузды.

—Мин... мин... кичерегез инде, мин эчмим бит,—диде кыз бала тотлыга-тотлыга.

—Бу—француз коньягы—дөньяда иң затлы эчемлек. Моңардан баш тарту—бик зур гөнаһ санала,—дип кыстады әзмәвер.

Кыз янә башын чайкады.

—Ә безнең кавемдә хәмер эчү—гөнаһ! Мин—мөселман кызы,—диде ул, ниһаять, кыюлана төшеп.

Шешәдәшләр күз карашлары белән генә аңлашып алдылар.

—О-о, әбиең әнә ничек яхшы тәрбияләгән үзеңне! Сезнең халыкның традицияләрен без бик хөрмәт итәбез. Булмаса, болай эшлик: син Сергога исәнлек-саулык теләп, сок кына эчәрсең—бәйрәм бозылмасын инде...

Янә "сәке-сандык" ачылды. Өстәлгә әфлисуннар тәгәрәде, сок каплары куелды.

Купеда эссе-тынчу иде. Юлдашларының кузгалуыннан файдаланып, кыз да урыныннан торды; кечкенә сумкасыннан кульъяулыгы алып,сөртенгәндәй итенде.

Кызның һәр хәрәкәтен күз угында тоткан Серго тәрәзәне ачты. Купе урман исе белән тулды. Өстәлнең икенче ягына килеп баскан кыз исә тәрәзәдән башын тыгып чәчәк исләре аңкыган һава сулаудан тыелып кала алмады. Ә бу мәлдә тегеләр хәмер белән мөлдерәмә касәгә сок тамызу белән мәшгуль иде.

—Утырышабыз!—диде катгый тавыш.—Касәләребезне тын алмыйча гына бушатабыз да, крр-асавицабыз йокларга ятар, ә без бәйрәмне бүтән купеда, дуслар янында дәвам итәрбез. Йәле, эчеп җибәр әле, матур-кай, согыңны!

Маэмай борыны белән кызның аягына орынды: "Эчмә, эчә күрмә!"—дип әйтүе иде бу.

Агайлар шуклана, дип уйлады кыз. Әмма үзенең касәгә үрелгән кулы, ток тоткандай, туктальп калды.

—Җә, җә, әллә виноград согын да эчмәс идеңме?!

Аяк өсте баскан әзмәвер касәне алып кызның иреннәренә тигезде. Туташ башын чөеп җибәрде. Бик уңайлы поза иде бу: теге адәм, "тәмлеме сок?" дия-дия, аның авызына хәмер койды.

Кинәт кенә хәле китеп күз кабаклары авырайган кыз баланың башы Сергоның иңбашына ишелде.

—Ну, без киттек,—диде теге агай Сергога.

Ә икенчесе ыржаеп:

—Безгә калым тиешлеген онытма!—дип өстәде.

—Бөтенесе дә әйбәт, искиткеч әйбәт булыр,—дип сөйләнә-сөйләнә, Серго кызны ятагына салды. Үзе аннан күзен алмыйча гына чишенә башлады.

Менә ул чишенеп бетеп кызга таба иелде. Хәзер Тэтчерга аның аяклары гына күренә иде. Маэмай тагы бераз шуышты һәм... һәм кызның кофта сәдәпләрен ычкындырып маташучы йонлы кулларны күреп алды. Менә ул куллар бер сәдәпне ычкындырды, икенчесен йолкып ыргытты, ә чираттагысын... кофтасы-ние белән бергә умырып атты.

Йоклап яткан кызның ялангач тәненә әлеге куллар орынган бер мәлдә, маэмай ятакка сикерде һәм, "тиясе булма!" дигәнне аңлатып, "һау-һау"лап алды. Ерткычка әверелгән адәм аны шундук тибеп очырды.

Тэтчер бу юлы әзмәвернең җилкәсенә үк сикерде һәм колагына тешләрен батырды. Кыргый тавышлар чыгарып, әзмәвер үкереп җибәрде.

Үкерә-үкерә, улый-улый Серго маэмайны тәрәзәдән томырды.

Тәрәзә аша очкан мизгелдә Тэтчер купе уртасында, проводница кочагында үзе әле генә намусын саклап калган кызның яшьле күзләрен күреп алды; ачык ишек янына җыелган кешеләрне дә шәйләргә өлгерде ул.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## *Хуҗиәхмәт Мәхмүтовка 75 яшь*

Фольклорчы галим, әдәбият белгече һәм журналист Мәхмүтов Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы (Хуҗи Мәхмүтов) 1933 елның 15 февралендә Мамадыш районының Түбән Ушмы авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Туган авылында җидееллык, Мамадышта—урта белем алгач, ике ел авыл мәктәбендә физика һәм математика укыта. 1953 елда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегенә укырга керә, аны кызыл диплом белән тәмамлагач, җиде елга якын Буа районында чыга торган «Яна юл» (сонрак «Байрак») газетасында әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркәтип, бүлек мөдире булып эшли.



1966 елдан бирле Х. Мәхмүтов Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли. Биредә ул аспиранттан алып баш фәнни хезмәткәргә кадәр үсү юлы үтә, «Татар халык табышмаклары» дигән темага кандидатлык һәм халкыбызның афористик иҗаты буенча докторлык диссертацияләре яклый. «Кечкенә дә төш кенә», «Афористические жанры татарского фольклора», «Язылмаган кануннар» кебек китапларында галим бу төр әсәрләрнең мәгънәви тирәнлеген һәм шигъри камиллеген бик тулы итеп яктырта. Х. Мәхмүтов 30га якын китап, 800 ләп мәкаләләр авторы.

Х. Мәхмүтов борынгы фольклорыбыз мәсьәләләрен өйрәнүгә күп көч куя. VIII—XVII йөзләрнең төрки язма һәйкәлләрендә теркәлеп калган афористик гыйбарәләрне җыеп, бүгенге татар мәкальләре белән чагыштырып чыгып, алар арасындагы бәйләнешләрне ачыклый. XI йөз галиме Мәхмүд Кашгари сүзлегендәге шигъри парчаларның бер өлешен хәзерге татар теленә күчереп, матбугатта бастыра.

Х. Мәхмүтовның каләменә фәнни дә, үтемле-кызыклы да итеп язу сыйфаты хас. Аның «Ел тәүлеге—12 ай», «Канатлы сүз—хикмәтле сүз» кебек китапларындагы бүлекләр мавыктыргыч әдәби парчалар кебек укылалар, шуның белән белгечләрнең генә түгел, киң катлау укучыларның да игътибарын җәлеп итәләр. Әдәби телебезнең матурлыгы, сурәтлелеге мәсьәләләрен галим һәрвакыт күз уңында тота. Утыз елдан артык инде ул—радиодагы популяр «Тел күрке сүз» тапшыруларының даими авторларыннан берсе.

«Мәгариф» нәшрияте «Энҗе чәчтем—энҗе җыям» дигән гомуми исем астында мәктәпләр һәм гимназияләр өчен татар халык иҗаты буенча уку ярдәмлеге итеп чыгарган тугыз китапның дүртесе Х. Мәхмүтов тарафыннан әзерләнгән.

Халыкара Төрки академия академигы, профессор, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы Мәхмүтов бүгенге көндә үзенең олуг бәйрәмен билгеләп үтә. Редакция коллективы юбилярны ихлас котлый, исәнлек-саулык тели.

# КҮҢЕЛЕНДӘ КҮПМЕ ҖЫЛЫЛЫК БАР...

Бу Кеше каршында минем шактый уңайсыз хәлдә калганым бар, һәм шул уңайсызлану тойгысы әле дә җанны тырнап тора. Минем хакка, авыр ачыла торган «калын ишек»ләрнең берсен ачып керергә, ә керер алдыннан, хуҗаның «бушавын» көтеп, кабул итү булмасендә озак кына йөренергә туры килде аңа. Артык сиздермәскә тырышып кына, уң кулы учын әледән-әле йөрәк турысына куеп ала. Аның, йөрәге борчып, күптән түгел генә хастаханәдә ятып чыкканын, аулак авылда яшәп белми калган идем шул, шунлыктан аңа—ул чагында Татарстан Язучылар берлегенең рәис урынбасары булган дустыбыз Шаһинур Мостафинга—бер мәсьәләдә булышлык сорап килүем вакытсызрак килеп чыкты. Инде менә, шул вакыйга искә төшкән саен, Шаһинурны бик якын иткән, бик күп әдәби сәфәрләрендә бергә йөргән, «гадәт-холкы белән кыр казы» булган мәрхүм Илдар Юзеевнын, мондашы Фасил Әхмәткә багышлап язган бер шигыреннән:



*Фатир сораганда төштек инде*
*Түрәләрнең ишек төбенә,—*

дигән юллары хәтердә янара. Дөрес анысы, минем гозер фатир сораудан бик-бик кечкенә, аны хәл итәчәк түрә дә фатир бүлүчедән шактый бәләкәй иде. Шулай да беләсе иде: биш-алты ел рәис урынбасары, аннан алдарак байтак вакыт Әдәбият фондының Татарстан бүлеге җитәкчесе булып эшләгән чакларында үзенекен түгел, каләмдәшләре йомышларын үтәп, мондый ишек төпләренә ничә кат төшәргә, шуларның ничәсендә әрнеп кире борылырга туры килде икән аңа? Урынбасар—урынбасар инде: вазифасы зур, мөмкинлеге бәләкәй, аны санлаучы аз. Әле ярдәм алганнардан рәхмәт кенә дә ишетеп тормады, дип беләм. Бериш каләмдәшләреннән: «Син ник фәлән-фәләннәргә булышып йөрисең, мине тыңла, миңа гына ярдәм ит»,—кебек сөер кинәшләр ишетеп тә җаны кыйналды аның. Аксакал әдип Туфан Миңнуллин бер әсәрендә шаяртып кына да бик хак язганча, бүтәннәрнең бер рәхмәтенә сигез тапкыр рәхмәт әйтеп җавап бирә торган Шаһинур бит ул! Мамадыш төбәгендә, сугыш яралысы Әхмәтсафа белән Герой-ана Гөлзәйнәпнең ишле гаиләсендә баш бала булып үскән, алты энесенең һәм дүрт сеңлесенең һәркайсы өчен тигез кайгыртып яшәгән дустыбыз кеше араларга, каләмдәшләренең берсен үз итеп, икенчесенә кырын карарга өйрәнмәгән иде шул. Аның мондый холкы Кукмара район газетасы редакциясендәге әдәби берләшмә эшендә дә ачык күренде. Заманында шушы берләшмәдә каләм чарлаган, иҗат канатларын ныгыткан унлап кеше бүген татар әдәбиятының төрле жанрларын үстерешә, алар төрле-төрле әдәби бүләк ияләре. Туган төбәге булган Мамадыш районының сәләтле каләм ияләренә дә, иҗатларында гел канатландырып, матбугатта чыгуларына булышып, әдәбиятта үз урыннарын табарга ярдәм итте ул. Халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре буенча республика фәнни-методик үзәге баш мөхәррире, соңрак бик дәрәҗәле «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире булып эшләгән елларында исә Шаһинур Мостафинның каләмдәшләре иҗатына шифалы йогынтысы тагын да киңәйде.

Без Шаһинур белән беркадәр сабакташлар булдык—Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген бергәләп читтән торып укып тәмамладык (укытучыбыз Ибраһимов Сәгъдәт абый бездәйләрне «укудан читтә торып университет тәмамлаучылар» дип шаярта иде). Болай укучыларның үзара мөнәсәбәтендә бер бик зур җитешсезлек була—алар бер-берсе хакында бик аз беләләр. Әйтик, алты ел бергә укып, күбебез Рафаил Газизовның шагыйрьлегеннән бихәбәр идек. Җәен кырык көнлек, кышын ун көнлек бергә җыелу вакытлары баш күтәрми укуга, зачет-имтиханнарга, элекке «койрык»ларны бетерүгә җитми дә кала, кая анда якыннан танышып чын студентларча иҗади кайнашу. Шулай да безгә көндезге бүлектән өченче курста гына кушылган, һәрвакыт уйчан, аз сүзле Шаһинурның шигырьләр язуын укытучыбыз Флера Сафиуллинадан ишетеп белгән идек. Ә шул елларда ук күңелендә йөрткән, җанына тынгы бирмәгән уй-гамьнәрен бераз соңрак—сугыш каһарманнарына багышланган матур-матур документаль әсәрләрен укый башлагач—аңладык. Безнең төркемгә кушылу алдыннан гына аның әтисе төзәлмәс сугыш яраларыннан мәңгелеккә китеп барган, шуңа күрә баш бала Шаһинур, ишле гаиләне туендыруда әнисенә булышу өчен, эшкә урнашырга һәм көндезге укудан аерылырга тиеш булган. Алай гына да түгел, сугышның бар мәхшәрен күреп белгән, үләмме-каламмы дип госпитальдән-госпитальгә күчерелгән арада авылына ике тапкыр батырларча һәлак булу хәбәре килгән, фронттан башы каты җәрәхәтләнеп, ике күзе дә сукыраеп кайткан Кызыл Йолдыз орденлы Әхмәтсафа улына яшьтән язгалый башлаган темасын ташламаска, үзе кебекләрнең, әнисе Гөлзәйнәп кебек тыл каһарманнарының фаҗигале язмышын һәм батырлыгын әсәрләре аша сөйләргә дә сөйләргә васыять итеп калдырган. Һәм Шаһинур Мостафин, меңләгән-меңләгән фронтташлары исеменнән әтисе кушып калдырган юлдан барып, ялгыз бер язучының кулыннан килүенә ышану да кыен булырлык, иҗат уңышы белән бөтен дусларын сөендерерлек эшләр башкарды. Болай да аз һәм бик хәләл эш хакы, чираттагы яллары исәбенә хәрби архивларда һәм сугыш булган урыннарда эзләнеп, 26 милләттәш һәм якташыбызның Александр Матросов (чынлыкта Шакирҗан Мөхәммәтҗанов, аның ничек Матросовка әверелүен Ш. Мостафин тәфсилләп язды) батырлыгын кабатлавын ачыклау, төрле сәбәп аркасында хаксыз рәнҗетелгән фидакарьләребезнең пакь исемен кире кайтару, күп кенә сугыш һәм тыл каһарманнарының исемнәрен мәңгеләштерү һәм барчасы хакында сокланып та, гаҗәпләнеп тә укырлык әсәрләр язу—боларны гына әйтү, мөгаен, язучы Шаһинур Әхмәтсафа улы Мостафин башкарган зур һәм изге эшләр турында берни дә әйтмәүгә тиңдер. Бер Ходаебыз ярдәм итсә иде—алдына куйган максаты тагын да олырак бит әле. 2004 елда Татарстан китап нәшриятында яңа гына басылып чыккан «Хәтер яктысы» исемле күпъеллык иҗат җимешен кулына алгач, уе белән әллә кайларда йөреп, беркавем тын торды ул. Күңеленнән бәлки «уйланылган җиде китапның беренчесе генә бит әле бу» дигән уй узгандыр. Ләкин Шаһинурның шушы җыентыгы гына да мәгълүмат байлыгы, эзтабар әдипнең төпле фикерләве һәм киң карашы, элгәрләребез гамәлләренә бетмәс-төкәнмәс ихтирамы белән хәйран калдыра. Узган дәһшәтле сугышка, андагы җиңүгә, исән һәм шәһит каһарманнарына, җиңү хакына дип һәммә авырлыкны кичә алган тыл эшчәннәренә мөнәсәбәт үтә чуарланган бу заманда милләттәшләребез фидакарьлеген хәтерләребез яктысында яктырту, шулар аша «хакыбыз уртак ватанда яхшы ук» дип бар җиһанга сөйләү аерата кирәк.

Бүтәннәр мәшәкатен бүлешкәндә генә түгел, шәхси авырлык кичергәндә дә тыйнак Шаһинур дустыбыз киң күңелле һәм сабыр булып кала белә. Мондый чакта әнисенең (ул, шөкер, туган төбәгендә исән-сау яшәп ята) «гел безнеке генә әйбәт була алмас, сабыр итәргә кирәк» дигән сүзләрен исенә төшерә. Әле менә бишенче сыйныфта укыган елларыннан бирле дус булып һәм аннары пар күгәрченнәрдәй гомер кичергән, бергә-бергә балалар үстергән, оныклар баккан Дамирәсен һич көтмәгәндә җир куенына салдылар, мәрхүмәгә илле тугыз яшь туласы көндә кырыгын үткәрделәр. Авыр кайгылы чагында да дустыбыз үз-үзе булып калды. «Юл һәлакәтендә гаепле шоферга җәза бирмәүләрен сорадым, олы яшьтә инде, ялгышкан, Алла сакласын, андый ялгыш һәркемдә кабатланырга мөмкин»—диде ул.

Шаһинур Мостафинның зур әдәби хезмәте һәм җәмәгать эшчәнлеге, хаклы рәвештә, иҗат оешмаларының төрле бүлекләренә, халкыбыз ихтирамына лаек булды. Аны «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме белән тәбрикләү тантанасы күбебезнең исендә. Шул хактагы танықламаны ана, барлык каләмдәшләре алдында, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев үзе тапшырды. Бүләкләнүченең исеме ишетелүгә зал үтә көчле алкышларга күмелгәч, Минтимер Шәрип улы:

—Рәхмәт үзегезгә! Каләмдәшегез Шаһинур Мостафинны бик яратасыз икән,—диде.

Бу көннәрдә сагышлы алтмыш яшьлеген билгеләп үтүче эзтабар язучы, шагыйрь һәм публицист—Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, «Бәллүр каләм» иясе, Россия Федерациясенең М. Ломоносов исемендәге премиясе лауреаты Шаһинур Мостафин дустыбыз үзе дә каләмдәшләрен, кешеләрне бик ярата бит ул. Шулай булмаса, бер шигырендә түбәндәгечә язар идемени:

*Әле Җирдә күпме изге җаннар*
*Рухи салкынлыктан өшиләр...*
*Күңелемдә күпме Җылылык бар—*
*Барысын Сезгә бирәм, Кешеләр!*

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ.**

---

## *Укучы сүзе*

***

Хөрмәтле баш мөхәррир!

Бераз үзем турында.

Миңа хәзер 83 яшь. Башкортстанда татар авылында туып-үстем. Урта мәктәпне тәмамлагач, 18 яшьтә армиягә алынып, фронтка җибәрделәр. Тормыш юлының азагында туган җирдән еракта—Петербургта торабыз. Туган авылда кардәшебез бар. Хат алышабыз.

Мин сезнең журналыгызны инде утыз елдан артык алам. Барлык мәкаләләрне кызыксынып укыйм. Бу хатны сезгә 9нчы санда басылган «Урамга чыгып кычкырыйммы?» дигән мәкаләне укыгач язарга булдым. Башкортстандагы татарларны башкортлаштыру сәясәте турында ул.

Р. Нурисламов язганнарны укыгач, мин дә шаккаттым! Бик тә ачуым килде. Мин һәм минем мондагы татар милләтеннән булган дусларым мәкалә авторының фикерләрен уртаклашабыз. Башкортстанда яшәгән милләттәшләрне һичшиксез якларга кирәк.

Автор «Монда Татарстан хөкүмәтенә дә үпкә сүзләре әйтергә була...» дип тә яза.

Бу мәкалә турында Татарстанның башлыклары беләме?

Казанда «Бөтендөнья татар Конгрессы» сымак, Россиядә яшәгән татарларны саклаучы җәмгыять оешмасы да бардыр бит? Башкортстандагы татарларның язмышы турында «Казан утлары»ның алдагы саннарында һәм бу мәкаләдә язылганнар буенча нинди чаралар күрелгәнен язсагыз бик яхшы булыр иде.

Бер уңайдан, «Казан утлары»ның күптәнге укучысы буларак, минем теләк: журналда Россиянең башка өлкәләрендә яшәүче милләттәшләребез турында күбрәк языгыз. Безнең шәһәрдә «Татарская община» барлыгын да онытмагыз.

Сезгә һәм бөтен редакциягә яңа уңышлар теләп,

**Үзбәк ШӘРИПОВ.**

*Санкт-Петербург.*



СССРның халык артистлары белән очрашу.
Беренче рәттә (уңнан сулга): СССРның халык артистлары Габдулла Шамуков, Фуат Халитов, Шәүкәт Биктимеров һәм «Татарстан яшьләре» газетасы хезмәткәрләре: хатлар бүлеге мөдире Рина Зарипова, редактор Ислам Әхмәтҗанов. Икенче рәттә (сулдан уңга): газетаның рәссамы Светлана Привина, әдәби хезмәткәрләр Рашат Низамиев, Барлас Камалов, Рәфикъ Юныс, Нәбирә Гыйматдинова, Илдус Сафин, Рәшит Әхмәтҗанов, Харрас Әюпов, Госман Гомәр, машинистка Фирдәүсә Салаватова.
1983 ел.



Илдус Ахунҗанов (1930—1990). Әдәбият тәнкыйтьчесе.



Язучыларның Аккош күлендәге элеккеге дача йортларының берсе. Анда озак еллар татар әдәбияты классиклары Гомәр Бәширов һәм Мөхәммәт Мәһдиевләр яшәде. Тарихи йорт берничә ел элек сүтелде. Хәзер зур пулат-сарайда яңа хуҗалар яши.



Композитор Фасил Әхмәтов (1935—98). 80 нче еллар рәсеме.



Шагыйрь Хәсән Туфан һәм рәссам Рәшит Имашов. Үткән гасырның 70 нче еллар ахыры.



Замандашлар. Сулдан уңга: Фатыйх Хөсни, Әхмәт Исхак, Мостай Кәрим. 1960 ел.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ БЕЛДЕРҮЕ

Татарстан язучылары узган ел азагында «Россия Федерациясенен кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль Закон кабул ителү уңаеннан, Россиядәге милли әдәбиятлар, мәгариф, төрле халыклар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү эшенең киләчәк язмышы өчен тирән борчылуларын белдереп, Россия Федерациясе Президенты В. Путинга, Россия хөкүмәте Рәисе В. Зубковка, Россия Федерация Советының Федераль Җыены Рәисе С. Мироновка һәм Россия Дәүләт Думасы Рәисе Б. Грызловка мөрәҗәгать итәләр.

Дәүләт Думасы һәм Федерация Советы тарафыннан кабул ителеп Россия Президенты кул куйган әлеге закон Россиядәге милли мәктәпләрдә туган тел һәм әдәбиятны укытуны, туган халык тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүне нигездә юкка чыгаруга корылган.

Федераль Закон мона кадәр Россиядәге милли мәктәпләрдә әлеге фәннәрне укыту һәм өйрәнүдә милли-төбәк компонентын юкка чыгара, икенче төрле әйткәндә, ул Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешен чикли.

Әлеге законны тормышка ашыру милли мәктәпләрнең ябылуына, гамәлдә мәгариф системасының кире «житлеккән социализм» чорына кайтуына тиң. Бу исә халыкара закончылык актларын, милли республикалар законнарын, Россия Федерациясенең үз Конституциясен тупас бозу.

Нәтиҗәдә меңъеллык тарихы булган татар әдәбиятына алга таба үсүеннән туктау куркынычы яный.

Татарстан язучылары Россиядәге милли мәгарифләргә, әдәбиятларга һәм мәдәниятләргә янаган бу куркынычлы хәлләрне булдырмас өчен әлеге законның милли мәгарифкә кагылышлы өлешен гамәлдән чыгарырга тәкъдим итәләр.

Фәкать шулай иткәндә генә Россиядәге милли республикаларда, шул исәптән Татарстанда да туган тел һәм әдәбиятны укыту, туган тарихыбызны һәм мәдәниятебезне өйрәнүдәге киртәләр юкка чыгарылачак. Үз милли мәдәниятен хөрмәт иткән һәм яклаган кеше генә уртак Ватанны да чын күңелдән ярата ала.

Без Россия җитәкчелеге Татарстан язучылары сүзен ишетер, тиешле нәтиҗәләр ясар һәм күпмилләтле Россиядә һәр милләтнең туган теле һәм әдәбияты, тарихы һәм мәдәнияте үсешен, Россия Федерациясе халыкларының конституцион хокукларын тәэмин итәрлек гамәлләр кылыр дип өметләнәбез.

**Татарстан язучылары.**
*Январь, 2008 ел.*

---

### КАЗАН ӨЧЕН ТАРИХИ ДОКУМЕНТ

Яңа ел көннәре алдыннан Казан шәһәр Думасы XXVI сессиясе утырышында Казан шәһәренең Генераль планын кабул итте. Зал бу вакыйганы аягүрә басып озак алкышлады. «Нәкъ менә 15 ел элек аны эшләү турында карар кабул ителгән иде. Генераль план башкала хуҗалыгын төрле яклап үстерү буенча төп документ, ул безнең киләчәгебезне билгели»,—диде шәһәр мэры Илсур Метшин.

Казан шәһәрен территориаль планлаштыру буенча мөһим документ проекты турында докладны башкарма комитет рәисе вазифаларын башкаручы (хәзер инде рәис итеп сайланды) Рафис Борһанов ясады.

Казан шәһәренең Генераль планы 2020 елга кадәрге үсешне үз эченә ала. Аның беренче чиратын гамәлгә ашыру 2010 елда тәмамланырга тиеш. 2010 елга Казанда яшәүчеләр саны 1,5 миллион булыр дип фаразлана.

Генераль планда шәһәрнең үзәк өлешен үзгәртеп кору күздә тотыла. Үзәк өлештәге кайбер оешмалар шәһәр читенә күчереләчәк. Докладта тимер-юл хуҗалыгының, аның склалларының, «Мэлита» берләшмәсенең, «Заря» фабрикасының, аяк киемнәре җитештерүче «Спартак» берләшмәсенең яңа урынга күчереләчәге әйтелде.

Шәһәрнең яңа торак төзелеше, нигездә, иске аэропорт территориясендә, Азино-1 һәм Азино-2, Идел буе районының 5а микрорайоннарында алып барылачак. Салмачы бистәсендә, Киров районының Күзәмәт авылы территориясендә, Урман арты бистәсендә кызу темплар белән яңа микрорайоннар төзү күздә тотыла. Генераль планда шәһәр транспортын үстерүгә зур игъ-

тибар бирелгән. Яңа магистральләр барлыкка киләчәк, метро төзелеше дәвам итәчәк. 2020 елга кадәр метро линияләренең озынлыгы 29 километрга җитәр дип фаразлана.

Сессиядә катнашкан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Генпланны тарихи һәм стратегик документ дип атады.

Генераль план кабул ителгәннән соң тагын бер мөһим документ эшләү кирәклеге зарур. Ул Генераль планны гамәлгә ашыру планы. Аны 3 ай эчендә эшләү бурычы куелды.

### ЯКЛАРСЫЗМЫ ИЛ ХАКЫН?

Президент Минтимер Шәймиев Россия Дәүләт Думасының бишенче чакырылыш Татарстан депутатлары белән очрашты.

«Бүгеннән сез зур федераль сәясәт кешеләре булып саналасыз. Дәүләт Думасының нинди карар, канун кабул итүе сездән дә торачак. Сезнең һәрберегез аерым һәм фракция составында мөһим вазифа башкарачак. Татарстан депутатлары башкалардан оештыру сәләте белән аерылып торырга, эшен сыйфатлы башкарырга һәм кирәк вакытта республика мәнфәгатьләрен дә якларга тиеш»,—дип ассызыклады Президент.

Очрашуда Премьер-министр Рөстәм Миннеханов, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Президент Аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов һәм башка рәсми вәкилләр, Татарстаннан Дәүләт Думасына сайланган 14 депутат: Олег Морозов, Ринат Гобәйдуллин, Айрат Хәйруллин, Илдар Гыйльметдинов, Алинә Кабаева, Фатыйх Сибагатуллин, Александр Козловский, Ирек Богуславский, Фоат Комаров, Марат Заһидуллов, Виктория Черкесова, Хафиз Салихов, Гөлнара Сергеева, Клавдия Новикова катнашты.

### ЖУРНАЛИСТЛАРНЫҢ ӨЛЕШЕ ЗУР

«Татмедиа» агентлыгында Россия матбугаты көненә багышланган тантана булып узды. ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова һәм башка рәсми кешеләр бәйрәм кунаклары булды.

«Татарстан җитәкчелеге исеменнән сезне Россия матбугаты көне белән котлыйм һәм зур эшләрегез өчен рәхмәт белдерәм,— диде Дәүләт Советы Рәисе гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләренә.—Узган ел социаль-икътисади яктан республикабызның үсеш чоры булды. Бу чорда Татарстан территориясендә бик күп җитди проектлар тормышка ашырылды. Әлеге юнәлешләрнең һәркайсында уңышларыбыз бар, һәм монда журналистларның да өлеше зур».

### ҖЫР ФЕСТИВАЛЕНЕҢ ЧИРАТТАГЫСЫ

Яңа ел алдыннан «Пирамида» күңел ачу үзәгендә VIII Халыкара татар җыры эстрада фестивале узды. Анда 70кә якын җырчы катнашып, шуларның 22сенә «Алтын барс» сыны тапшырылды һәм алар лауреат исеменә лаек булды.

Беренче көндәге концертта халык җырларын оста башкаручы күренекле артистларыбыз Венера Ганиева, Римма Ибраһимова, Зөһрә Шәрифуллина, Рәсим Низамов катнашты. Алардан соң «Йолдызлар фабрикасы-3» супер-проектының финалы үтте. Өч ел эчендә әлеге «фабрика»дан 34 җырчы зур сәхнәгә юл алган. Араларында быел «Алтын барс»ка ия булганнары да бар. Бу юлы Илдар Әхмәтов «Иң популяр ир-ат җырчы», Иркә «Иң популяр җыр» («Янадан тудым») һәм «Айфара» төркеме белән «Иң яхшы дуэт» төрләрендә бүләкләнде. Шулай ук Гөлназ Сираева башкарган «Кайтабыз да китәбез шул», Илдар Хәкимов җырлаган «Син бәхетле булсын өчен», Хания Фәрхи башкарган «Кунак егет» популяр җырлар буларак сайланган. «Иң яхшы музыкаль клип» булып Салават Миннехановның «Хыял кызы» табылды. «Иң яхшы театраль альбом»га Ландыш Нигъмәтҗанова лаек булды. «Иң популяр җырчы» булып Гүзәл Уразова танылды. Алинә Сафиуллина белән Эльвира Хамматова «Ел ачышы», Румия Фәтхетдинова «Ел ташкыны» төрләрендә бүләкләнде.

Илһам Шакиров яратып башкара торган «Бик еракта идек без» дигән җырына кушылып эшләнгән рэп өчен Шәкүр, «Иң яхшы рок проект» дип «Уйлану» җырын башкарган Илсөя Бәдретдинова табылды. «Иң яхшы музыкаль төркем» «Айфара» булды. Уфадан килгән Гүзәл Әхмәтова «Халык мәхәббәте» исемен яулады.

Фестивальнең йомгаклау концертын «Иң халыкчан» дип табылган җырчы Зәйнәп Фәрхетдинова ачып җибәрде. «Елның иң популяр җырчысы» булган Айдар Галимовка «Алтын барс» сынын Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тапшырды. «Иң популяр автор-башкаручы» булып Зөлфәт Хәким танылды. Салават Фәтхетдиновның «Яшисе килә» альбомы иң яхшы дип бәяләнде. «Татар җыры легендасы» төрендә бүләкне Илһам Шакировка Премьер-министр урынбасары, мәдәният министры Зилә Вәлиева тапшырды. Кинофильмдагы җырларны «Иң яхшы башкаручы» булып Асылъяр танылды. Әлеге җырчыларның һәркайсына «Алтын барс» сыны тапшырылды.

Йомгаклау концертын Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев һәм башка рәсми кешеләр карады.

### КЛАССИК ДРАМАТУРГ ЮБИЛЕЕ

Узган ел классик драматург Кәрим Тинчуринның тууына 120 ел тулды. Ул—Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Дәрдмәндләр замандашы. Үткән гасыр татар театрын аның исеменнән башка күз алдына китерү кыен.

Иң мөһиме—аның әсәрләре буенча куелган спектакльләр бүгенге тамашачылар өчен дә якын һәм кадерле.

27 декабрьдә драматургның юбилее уңаеннан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни-гамәли конференция узды. Анда Татарстаннан тыш, чит төбәкләрдән килгән галимнәр дә катнашты. Шул ук көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Тинчуринга багышланган тантаналы зур кичә булды.

Бу кичәдә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева Кәрим Тинчуринны «үткән гасыр әдәбиятының ташкыны» дип атады. Ул киләчәктә драматургның әсәрләрен башка телләргә тәрҗемә итеп киңрәк пропагандаларга киңәклеген искәртте. Шулай ук К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында аның музее булырга тиешлеген әйтте. Пенза өлкәсендә драматургның туган авылына Кәрим Тинчурин исеме бирү хакында сүз бара, дип белдерде.

Драматургның «Американ», «Зәңгәр шәл», «Хикмәтле доклад», «Сүнгән йолдызлар» спектакльләреннән өзекләрне Г. Камал, К. Тинчурин, Г. Кариев исемендәге театр артистлары башкарды. Режиссер Ренат Әюпов тарафыннан әзерләнгән әлеге кичәне (сценаристы—Рабит Батулла) Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакиров белән Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луара Шакирҗанова алып барды.

## ГАЛИМНӘРГӘ—ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕ

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә республиканың 2007 елда фән һәм техника өлкәсендәге казанышлары өчен Дәүләт премияләрен тапшырды.

Быел алар табигый, техник һәм гуманитар фәннәрне үстерүгә өлеш керткән, яңа технологияләргә, фән һәм техника казанышларына таянып, югары житештерү күрсәткечләренә ирешергә ярдәм иткән сигез фәнни эш өчен бирелде. Әлеге бүләкләргә нефть табу, фосфор-органик химия, нефть химиясе тармакларында, сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәләрендә көч куючы галимнәр лаек булды.

Мәгариф өлкәсен үстерүгә куйган хезмәтләре өчен Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты галимнәре эше бәяләп үтелде. Университет профессоры Гамирҗан Дәүләтшинга татар һәм рус телләрендә китап итеп бастырып чыгарган «Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы» монографиясе өчен Дәүләт премиясе тапшырылды.

## ФИЛАРМОНИЯ БИНАСЫ ЯҢАРДЫ

Ниһаять, шактый озакка сузылган капиталь ремонттан соң филармония ишекләре тамашачыларга яңадан ачылды. Сәнгатебез өчен горурланырлык бинага әверелгән ул.

Филармониянең 70 еллыгына багышланган тантананы Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев ачып җибәрде. Сәнгать дөньясында тирән эз калдырган һәм филармониядә эшләгән артистларга олуг рәхмәтен җиткерде. «Кармы, буранмы, яшенле яңгырмы—сез һәрвакыт юлда булдыгыз, халкыбызга хезмәт иттегез. Шуның өчен рәхмәт сезгә. Филармония сүзе миңа ошый. Ул ургылып чыккан мул сулы чишмәгә охшаш. Әгәр филармония булмаса, опера театры да булмас иде. Чит илләрдә үзебезнең булганлыкны күрсәтә әлеге коллектив»,—диде Президент. Аннан соң филармония коллективына Рәхмәт хаты, хореограф Халисә Шәрәповага Татарстанның халык артисты, концертны алып баручы Лилия Аппаковага һәм халык уен кораллары оркестрының бер төркем музыкантларына Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр язылган дипломнар тапшырды. Озак еллар филармониядә хезмәт куйган Татарстанның халык артисты Зөһрә Шәрифуллинаны туган көне белән тәбрикләп, аңа иҗади уңышлар теләде.

Күренекле музыка белгече Георгий Кантор күп кенә татар композиторларының әсәрләрен халыкка таныткан өчен Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестрына зур бәя бирде. Кичәдә Г. Тукай шигырьләре яңгыравы да очраклы түгел. 1946 елдан бирле филармония бөек шагыйребез исемен йөртә. Татарстанның халык артистлары Георгий Ибушев белән Рөстәм Маликов, Татарстанның атказанган артисты Резеда Галимова, Илшат Вәлиев һәм башка җырчыларның чыгышын тамашачы алкышларга күмде. Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге дәүләт фольклор ансамбле чыгышы кичәгә ямь өстәде. Ә инде Миләүшә Тәминдарова оештырган камера хоры тәүге тапкыр тәкъдим ителде.

Зал фоэсында элеккеге елларда филармониядә эшләгән күренекле иҗат кешеләренең портретлары урнаштырылган. Алар—филармония тарихының якты сәхифәләре.

Тантанада Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева һәм күп кенә сәнгать оешмаларының җитәкчеләре катнашты.

## КИНО СӘНГАТЕБЕЗНЕ ҮСТЕРҮ ӨЧЕН

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында кино сәнгате бүлеге ачылачак. Әлеге карар университетның гыйльми советы җыелышында кабул ителде. Яңа бүлекне Министрлар Кабинетының Татарстан халыкларының мәдәниятен һәм телләрен үстерү бүлеге җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Рамил Төхфәтуллин җитәкләячәк. Хәзер биредә укытучылар туплау һәм программа төзү эше бара. Курсларны алып бару

өчен Бөтенроссия дәүләт кино сәнгате институты белән сөйләшүләр дә алып барыла.

## МӨСЕЛМАННАРГА ТЕЛЕКАНАЛ КИРӘК

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин РФ Хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары, Хөкүмәт каршындагы Дини берләшмәләр мәсьәләләре комиссиясе рәисе Д. Медведевка федераль каналда Россия мөселманнар җәмгыятендәге процесслар турында сөйләүче махсус тапшыру булдыру мәсьәләсен унай хәл кылуга ярдәм итү үтенече белән хат җибәрде.

Исегезгә төшерәбез: Д. Медведевның узган елның 12 ноябрендә Казанга эшлекле сәфәре барышында бу хакта башлангыч килешүгә ирешелгән иде. Ул чагында Татарстан парламенты спикеры Ф. Мөхәммәтшин илнең барлык традицион дини конфессияләренә федераль телеканалларда эфир вакытын бирергә кирәклеге турындагы мәсьәләне күтәрде. РФ Хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары моның белән килешеп, дәүләт телерадиокомпанияләре җитәкчеләренә тиешле хатлар әзерләргә кушты.

«Дини үзаңның үсешенә гаммәви мәгълүмат чараларының мәгълүмати-мәгърифәт мәдәни ягы эшчәнлеге ярдәм итә,—диелә Татарстан парламенты җитәкчесе хатында. Бу җәһәттән Ф. Мөхәммәтшин федераль телевизион каналларның берсендә мөселман дине нигезләрен яктыртуга, Ислам диненең асылын (ул бары тик тынычлык-татулыкка өнди) пропагандалауга багышланган шуна охшаш программаның пәйда булу зарурлыгын ассызыклый. Татарстан парламенты хәзерге вакытта «Россия» телеканалында «Мөселманнар» тапшыруының әлеге бурычларны үтәп җиткермәвен искәртә, чөнки ул эшчәнлеген асылда этнографик юнәлештә генә алып бара.

## ЯҢА РЕКТОР

Филология фәннәре докторы, профессор, Россия табигый фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы Рәдиф Рифкать улы Жамалетдинов Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының 26 декабрендә үткәрелгән гыйльми совет утырышында шушы вузның ректоры итеп сайланды.

Рәдиф Жамалетдинов 1969 нчы елны Чүпрәле районының Кече Чынлы авылында колхозчы гаиләсендә туган. 1987-89 нчы елларда армия сафларында хезмәт итеп кайткач, ул Казан дәүләт педагогика университетының тарих-филология факультетында укый, татар теле, әдәбияты һәм тарих укытучысы белгечлеге ала. Соңгы курста укыганда ук (1994 нче елда) Рәдиф Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгында эшли башлый.

1995-98 нче елларда Рәдиф Жамалетдинов үзе тәмамлаган уку йорты каршындагы аспирантурада укый һәм татар филологиясе факультетының декан урынбасары, 1999—2002 нче елларда Татарстан хөкүмәтендә Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлегендә эшли. 2002-2004 нче елларда факультет деканы, 2004—2006 нчы елларда шушы ук уку йортының уку-укыту эшләре буенча проректоры, гомуми һәм чагыштырма тел белеме кафедрасы мөдире, 2006 нчы елның ноябреннән ТДГПУның беренче проректоры—уку-укыту эшләре буенча проректоры вазифаларын башкара.

## АҺ, ТУГАН КАУМЕМ ГАЗИЗ!

15 декабрьдә Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Уфа шәһәренең «Рамазан» төрки милли-агарту үзәге (җитәкчесе—Марат Шәрипов) татар шигъриятенең классигы, танылган меценат, җәмәгать эшлеклесе, нәшир, алтын приискасы хуҗасы Дәрдмәнд истәлегенә багышланган әдәбимузыкаль кичә уздырылды. Бәйрәмдә Татарстанның һәм Башкортстанның танылган әдәбият-сәнгать әһелләре катнашты. Алар арасында Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина, Рөстәм Маликов, Айдар Галимов, Айрат Арсланов, Әлфия Юлчурина, Айдар Габдинов һәм башкалар бар иде. Кичәдә Дәрдмәнд варислары һәм Башкортстанның Мәләвез, Баймак районнарыннан, шулай ук Оренбургтан килгән шагыйрьнең якташлары да катнашты.

Тамашачылар Зур концерт залының икенче катында «Дәрдмәнд мирасы» дип исемләнгән күргәзмә белән дә таныша алдылар.

## «РУХИЯТ» ЮБИЛЕЕ

«Казан» милли-мәдәни үзәгендә «Татнефть» акционерлар җәмгыятенең «Рухият» рухи яңарыш фондына 10 ел тулу унаеннан тантана үткәрелде, шунда ук әлеге фонд тарафыннан соңгы вакытта чыгарылган китапларны тәкъдим итү булды. Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов «Рухият»кә татар әдипләренең бай мирасын пропагандалаудагы зур хезмәтләре өчен Рәхмәт хаты тапшырды.

## ГЫЙБРӘТЛЕ САННАР

Тиражның зур, ягъни укучыларның ишле булуы һәр газет-журнал өчен абруй күрсәткече. Башкортстандагы газет-журналлар редакцияләре быелгы беренче яртыеллыкка матбугатка язылу нәтиҗәләрен игълан итте. Республикадагы байтак рәсми матбугат басмалары шактый югалту кичергән. Республикадагы татар газет-журналлары исә, башкалар белән чагыштырганда, яхшырак хәлдә икән.

Башкортстандагы иң популяр татар басмасы—«Өмет» татар яшьләре газеты узган яртыеллыктагы тиражын саклап калды. Аны алдагы ярты елда 37 меңнән артык әбунәче алдырачак. «Тулпар» татар яшьләре тиражы

кимемәгән. Аның әбүнәчеләре 12 меңнән артык. Балалар өчен нәшер ителүче «Әллүки» журналына 4 мең кеше язылган.

Татар телендә чыгучы «Атна» исемле атналык газетасы һаман да лидерлар рәтендә. Үзенең башкорт һәм рус телләрендәге «игезәкләрен» бер ярым тапкырга узып китеп, ул 35 мең укучысын булдырды. Әлеге язылу чорында «Кызыл таң» газетасы да 2007 елның икенче яртысындагы тиражын җыя алган. Аны быел 22500 кеше алдырачак.

## ӘДИПНЕҢ АБРУЙЛЫ ГОМЕРЕ

С. Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында күренекле әдип—Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әхсән Баянга 80 яшь тулу уңаеннан «Абруйлы гомер» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды. Анда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, филология фәннәре докторы, ТДГПУ профессоры Фоат Галимуллин, филология фәннәре кандидаты, КДУ доценты Әлфәт Закирҗанов әдипнең поэзия, проза, драматургия өлкәсендәге үзенчәлекле иҗаты турында сөйләде.

Юбилей кичәсендә Татарстан мәдәният министры урынбасары Айрат Җаббаров тәбрикләү сүзе белән чыкты һәм Әхсән Баянга Президент Минтимер Шәймиевнең Рәхмәт хатын укып ирештерде.

Юбилярны шулай ук Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры исеменнән Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Әзһәр Шакиров һәм Башкортстанның Илеш районыннан килгән якташлары котлады. Кичәдә Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Айрат Арслан, Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗан һәм Казан театр училищесы студентлары шагыйрьнең шигырьләрен укыды, Татарстанның халык артистлары Рөстәм Маликов, Лидия Әхмәтова һәм җырчылар Айгөл Бариева белән Ренат Хәбибуллин Ә. Баян шигырьләренә язылган җырларны, халык көйләрен башкарды.

Әдәби-музыкаль кичәне Айсылу Лерон алып барды.

## ТЕАТР ӘҺЕЛЛӘРЕН БҮЛӘКЛӘҮ

Үткән елның 22 декабрендә татар театрына 101 ел тулды. Шул көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында яшь драматург Илгиз Зәйниевнең «Мәхәббәт турында сөйләшик» спектакле алдыннан әлеге вакыйганы үзенчәлекле гамәл белән билгеләп уздылар: биредә сигезенче тапкыр күренекле режиссер Дамир Сираҗиев премияләрен тапшыру тантанасы үтте.

2007 ел нәтиҗәләре буенча Дамир Сираҗиев премияләренә Чаллы татар театры режиссеры Булат Бәдриев, Кырым татар дәүләт академия музыка театры сәнгать җитәкчесе Билал Билалов (Симферополь шәһәре), Уфа шәһәре «Нур» театры директоры Урал Ерфатуллин, театр белгече Нияз Игъламов, «Татарстан—Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе телевизион тапшырулар режиссеры Наилә Сабитова, Туймазы татар дәүләт театры артисты Рәсилә Сәлимгәрәева, театр белгече Анна Степанова (Мәскәү) ия булдылар.

Тантанада иң элек күренекле тарихчы галим, ТФ академиясе академигы, «Җыен» фонды җитәкчесе Миркасыйм Госманов чыгыш ясады. Ул премия исемен йөрткән режиссер һәм җәмәгать эшлеклесе Дамир Сираҗиевның шәхесе һәм иҗаты турында сүз әйтте.

## БЕР ДИСКТА—ЗУР ТАРИХ

Хәйрия елы кысаларында Казанның үзәкләштерелгән китапханә системасы хезмәткәрләре шәһәр мәктәпләренә үзләре махсус туплаган өйрәтүче дисклар бүләк итте. Җыентыкны караганда республиканың тарихи урыннары буенча виртуаль сәяхәт кылырга, XIX-XX гасырларда яшәүчеләр тормышының кызыклы мизгелләре, татар милли бәйрәмнәре һәм йолалары белән танышырга була. Тасмада Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Әхсән Баян, Ренат Харис һәм башка шагыйрьләрнең дә әдәби ядкәрләре урын алган.

## «ЙӨРТӘ БЕЗНЕ ЯЗМЫШЛАР»

III нче Бөтендөнья татар конгрессының рәсми ачылышы алдыннан Камал театрында әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Тәүфыйк Әйди истәлегенә багышланган кичә узды. Залда—чит илләрдән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән милләттәшләр күп иде.

Тәүфыйк Әйди, күренекле язучы һәм публицист булу белән бергә, безнең «Казан утлары» журналында ун елдан артык эшләгән бүлек мөхәррире дә әле. Аның төп әсәрләре безнең журналда дөнья күрде. Озак еллар «Татар халкы төрле илләрдә, төрле төбәкләрдә» дигән рубриканы алып барды.

Кичәдә әдип иҗаты һәм милләтпәрвәр эшчәнлеге турында М. Госманов, Т. Миңнуллин, Р. Вәлиев һ. б. чыгыш ясады. Кичәнең икенче өлешендә драматург Ю. Сафиуллинның Т. Әйди әсәрләре мотивы белән эшләнгән спектакле күрсәтелде.

## ГОМЕР ҺӘМ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Язучы Альберт Хәсәновка 70 яшь тулу уңаеннан Лениногорскида татар әдәбияте көннәре үткәрелде. Районның Зәй-Каратай, Шөгер мәктәпләрендә каләм әһелләре белән очрашулар оештырылды. Лениногорск мәдәният сараенда Альберт Хәсәнов юби-

лее унаеннан әдәби-музыкаль кичә булды. Бу чарада Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, язучылар Туфан Миннуллин, Гәрәй Рәхим, Зиннур Хөснияр, Данил Салихов, Рәшит Бәшәр, Нур Әхмәдиев, Әсгат Сәлах һ. б. катнашты.

Казан арты төбәгенең Дөбьяз егете—нефть якларының да атаклы шәхесе ул.

## ЛИТВА ТАТАРЛАРЫ ТУРЫНДА

Вильнюста Бөек Литва кнәзлегенә татарларның һәм караимнарның килеп урнашуларына 610 ел тулуга багышланган халыкара фәнни конференция булып узды. Аны Вильнюс университетының тарих факультетындагы Дәүләтчелеге булмаган халыклар мәдәниятен өйрәнү үзәге, Литва татарлары оешмалары берлеге һәм Литва караимнары оешмасы оештырды. Әлеге форумда Финляндия, Англия, Польша, Литва, Белоруссия, Украина, Төркия галимнәре белән беррәттән Россиядән дә ике галим катнашты. Литва татарлары секциясендә Яр Чаллы дәүләт педагогия институты профессоры Әнвәр Шәрипов «Узган гасырларда һәм тарихи яна шартларда Литва татарларының милли үзаңнарын саклауга омтылышы» дигән темага, ә Оренбург университеты фәнни хезмәткәре Динара Гыйльмуллина «Литва караимнары: тарихтан бүгенгә кадәр» дигән темага докладлар сөйләделәр.

## ШАГЫЙРЬЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Соңгы елларда Төркиянең Елазык (Әл-Ази) шәһәрендә «Хазар шагыйрьләре мәҗлесе» дигән халыкара шигырь бәйрәме оештырыла башлады. Бу бәйрәм шәһәр мэриясе инициативасы белән үткәрелә. Мәҗлескә төрки һәм башка мөселман илләреннән шагыйрьләр, әдипләр чакырыла. Үткән бәйрәмнәрнең берсендә Татарстаннан Ркаил Зәйдулла катнашкан иде, үткән ел ахырында үткән мәҗлестә бездән вәкил булып «Салават күпере» һәм «Сәхнә» журналларының баш мөхәррире Зиннур Хөснияр барды. Ул, шулай ук Төркиядә уздырылган «Чыңгыз Айтматов көннәр»ндә дә катнашты.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ

Бөгелмә районының Карабаш эшчеләр бистәсендә шунда туып үскән җәлилчеләр Гарәф Фәхретдинов, Гомәр Сәйфиев, Зәки Әһлиуллиннарга халык тарафыннан җыелган акчага һәйкәл ачылды. Анда районның, бистәнең муниципаль җитәкчелеге, татар җәмәгатьчелеге, Карабаш урта мәктәбе укучылары, каһарманнарның туганнары, чакырылган кунаклар катнашты. Чаллы җәмәгатьчелеге исеменнән истәлекле вакыйгада язучы Айдар Хәлим катнашты һәм чыгыш ясады.

Бу рәхмәтле эшнең башында Бөгелмә төбәгенең күренекле җәмәгать эшлеклесе, Карабаш татар иҗтимагый үзәге рәисе Фазыл Вәлиәхмәт торды.

***

Татарстан Республикасы халкына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар милли әдәбияты үсешенә лаеклы өлеш кертүе өчен язучы **Баянов Әхсән Фәтхелбаян улы** (Әхсән Баян) Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***

2007 елның 27 декабрендә шагыйрә, тәрҗемәче, «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Кожевникова (Бабекова) Роза Хәби кызы** каты авырудан соң 57 яшендә вафат булды.

***

2008 елның 5 гыйнварендә Чаллыда яшәп иҗат итүче язучы **Шәйдуллин Шамил Нәфыйкъ улы** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кол Шәриф мәчете.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* **Хәнисә Алишина**—филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан ФА шәрәфле академигы. Түмәндә яши.

# Яңа китаплар




**Разил Вәлиев.** Җанга уелган уйлар: күренекле шәхесләр белән әңгәмәләр.—Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2007.—720 б. Тиражы—2000 данә.

Китапка шагыйрь һәм прозаик, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиевнең күренекле дәүләт эшлеклеләре, сәясәтчеләр, татар галимнәре, язучылары, композиторлары, музыка белгечләре, рәссамнары, артистлары һәм дин әһелләре белән үткәрелгән әңгәмәләре тупланды. Әңгәмәдәшчеләрнең саны гына да житмештән артык. Исемнәрне аерымлап санау да кыен, чөнки аларның һәммәсе татар дөньясы өчен кадерле кешеләр.




**Фәнзаман Баттал.** Менә шулай яшә!: Сатирик һәм юмористик әсәрләр.—Казан: «Идел-Пресс» нәшрияты.—2008.—384 б. Тиражы—2000 данә.

Фәнзаман Баттал—бүгенге көндә юмор-сатира өлкәсендә эшләүче иң актив язучыларның берсе. Аның әсәрләре көндәлек матбугатта еш басыла, кайберләре безнең «Казан утлары»нда да дөнья күреп килә.

«Менә шулай яшә!»—авторның мона кадәр чыккан китапларының иң күләмлесе. Аннотациядә китапның төп исеме янәшәсендә өстәмә дә бар: гыйбрәтле дөнья хәлләре турында чын кыйссалар. Әче сарказмга ия язучының бу китабы өч бүлектән тора һәм ана нигездә, соңгы 5-6 ел эчендә язылган әсәрләр тупланган. Дөньяга үзгә һәм тәнкыйть карашы булган язучының уйландырырлык фикерләре күпсанлы укучыларга да гыйбрәтле булыр.



Хәнисә Алишина

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)